# Казан утлары

8

АВГУСТ • 1977

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

8
АВГУСТ
1977

## Бу санда

Г. РӘХИМ. Көннәр язга авышкач. Повесть . . . 3
Р. ЗАКИРОВ. Шахтер моңы. Шигырьләр . . . . 59
Г. ӘПСӘЛӘМОВ. Атакай, Анакай. Хикәя . . . . 61

ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

Ә. МӘХМҮДОВ. Халкыма. Шигырьләр . . . . 68
Н. ӘХМӘДИЕВ. Үзәктә. Шигырьләр . . . . . 70
Р. НИЗАМИЕВ. Ленин кулы. Шигырьләр . . . . 73
М. ГАЛИЕВ. Яңа көрәшләр өчен. Шигырьләр . . 76
Ф. ГЫЙЛЬМЕТДИНОВ. Урсай тау итәгендә. Повесть . . . . . . . . . . . . . . . . 80
Б. СӨЛӘЙМАНОВ. Себердән хатлар. Шигырьләр 103
Р. ХӘЙРИ. Юллар. Шигырьләр . . . . . . . 107

ОКТЯБРЬНЫҢ 60 ЕЛЛЫГЫНА

Җ. РӘХИМОВ. Тынгысыз як. . . . . . . . . 110
И. НИЗАМОВ. Кызыл укчылар . . . . . . . 118

ГАРИФ ГОБӘЙГӘ 70 ЯШЬ

Ф. ИБРАҺИМОВА. «Фикерләрем китапларымда...» 128

СӘНГАТЬ

Т. ӘЙДИ. Былбыллар сайратучы . . . . . . . 134

ИСТӘЛЕКЛӘР

Х. ЯКУПОВ. Үз шагыйребез . . . . . . . . . 142

ӘДӘБИЯТ ФӘНЕ

Т. ГАЛИУЛЛИН. Һәр шагыйрь — трибун . . . . 146
Г. ХАНТИМЕРОВА. Ф. Әмирхан иҗатында хатын-кызлар азатлыгы темасы . . . . . . . . . 155

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

**Р. ВӘЛИЕВ. Ни чәчсәң, шуны урырсың . . . . 159**

КИТАП КҮЗӘТҮ

**Ф. УРМАНЧЕЕВ. Җәлил белән яңадан очрашу . . 165**

ЯШЬ ТӘНКЫЙТЬЧЕНЕҢ БЕРЕНЧЕ РЕЦЕНЗИЯСЕ

**Г. САДӘ. Язгы урман яшеллеккә атлый . . . . 170**
**Г. МОРАТОВ. Һаман юлда . . . . . . . . . . 171**

**Безнең сафка . . . . . . . . . . . . . . . . 174**

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

**И. ФАТЫЙМА. Фәхрелислам Агиевка 90 яшь . . 179**
**З. МӘҖИТОВ. Яшь шытымнарга карап.** Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . **180**

ЕЛМАЕП ТА, КӨЛЕП ТӘ...

**Г. ШӘРӘФИ. Дәгъва.** Хикәя . . . . . . . . . **183**

МӘСӘЛЧЕЛӘР МӘҖЛЕСЕ

**Сүз әрмән фольклоры геройларына бирелә . . 186**

**Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189**

Редакциянең адресы. Казан, 420066, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: Баш редактор — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-69, поэзия бүлеге — 3-07-69, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Баш редактор: **Зәки Нури**
Редколлегия: **Әхсән Баянов, Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Аяз Гыйләҗев, Ләбибә Ихсанова** (җаваплы секретарь), **Шәйхи Маннур, Рафыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир**

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева*

Производствога бирелде 29/IV-1977 ел. Басарга кул куелды 15/VII-1977 ел. ПФ 09027. Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 84544 экз. Заказ Б-185. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1977 ел.

Гәрәй Рәхим

# КӨННӘР ЯЗГА АВЫШКАЧ

ПОВЕСТЬ

*Кадерле әтием белән әнием, Татарстанның элеккеге Шөгер районы, Федотовка авылының беренче комсомолы һәм ячейка секретаре, элеккеге «Икенче бишьеллык» исемендәге кустарь хуҗалык һәм Ленин исемендәге колхоз председателе, Бөек Ватан сугышы солдаты коммунист Родионов Василий Семенович һәм гап-гади колхозчы хатын Родионова Фекла Григорьевна каберләренә чәчәк урынына.*

## БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК

### Чирләү

1

Тимернең больницага керүенә бүген ике ай тулды. Үзенең соравы буенча аны бер кешелек палатага салдылар. Палатасы кайчакта аңа ошый иде. Дөрес, ул аны яратып ук бетерми, ләкин бер кешелек кечкенә палата аңа ошый иде. Чөнки бу палатада ул узган гомере турында уйлый ала. Кызык, монда ул бары тик узган гомере турында гына уйлый ала.

«Ә ни өчен мин монда киләчәк турында уйлый алмыйм икән? — дип куйды Тимер эченнән генә.— Югыйсә бит инде бу палата начар түгел, шулай да мин анда киләчәк турында уйлый алмыйм. Әгәр бу бүлмә больница палатасы булмаса, мин монда да киләчәк турында уйлый алыр идем».

Ләкин аңа үткәннәр турында уйлау да рәхәт иде. Дөрес, кайчакта үткәннәре турында уйлап аның елыйсы килә, шулай да үткәннәр турында уйлау аңа рәхәт.

«Бу минутта әни ни хәлдә икән?» — дип уйлады ул еракта, туган авылында үләргә ятучы әнкәсен хәтерләп. Аның әнкәсе рак белән

авырый иде. Ашказаны рагы белән. Моннан дүрт ай элек Тимер әнкәсен врачларга караттырга дип Казанга алып килде. Ул чакта әле әнисе дә, Тимер үзе дә, туганнары да рак турында уйлап та карамыйлар иде. Казан врачлары Фәкилә ападан ашказаны рагы таптылар. Ай буе больницадан-больницага чабып, Тимер әнкәсен онкология больницасына урнаштырды. Больницада рак буенча атаклы профессор эшли иде. Әнисен профессорга күрсәтте Тимер. Профессор Фәкилә апага операция ясап карарга вәгъдә итте.

— Ләкин рагы бөтен тәненә таралып өлгермәгәе,— диде профессор Тимернең үзенә генә.

— Таралып өлгергән булса нишләргә? — дип сорады Тимер.

— Таралып өлгерсә — хәлләр бөтенләй мөшкел була. Андый очракта профессорларга эш калмый. Шоферлар, төзүчеләр, игенчеләр, архитекторлар медицинада никадәр көчсез булсалар, рак бөтен тәнгә таралып өлгергән урында профессорлар да шулар кебек үк көчсез хәлдә кала.

— Шулай ук бер чара да күреп булмасмыни?

— Ул чагында бер чара да юк. Хәтта профессор үзе чирләсә дә. Хәтта профессорлар башлыгы үзе чирләсә дә.

Профессорның хәвефләнүе рас килде. Фәкилә апаның ашказанында башланган рак аның бөтен тәненә таралып өлгергән иде. Хәтта инде яман шешнең үсеше дәһшәтле ноктага — дүртенче стадиягә кадәр үк барып җиткән. Беренче дә, икенче дә, өченче дә түгел, ә дүртенче стадия.

Дүртенче... Дүртенче... Дүртенче...

Дүртенче стадия — үлем дигән сүз белән бер. Бернинди аерма юк. Алар арасында бары тик уртаклык кына бар. Дүртенче стадия белән үлем ике тамчы су кебек бер-берсенә охшашлар.

Профессор моны Фәкилә апаның күкрәген ачып карагач та күрде. Ул әле күкрәкне хирург пычагы белән ярып, анда күз салганга кадәр нидер өметләнгән: «Бәлки бөтенләй таралып өлгермәгәндер, бәлки шешне кисеп ташларга мөмкинлек бардыр»,— дип уйлаган иде.

Ләкин аның өмете акланмады. Фәкилә апаның күкрәгендә дүртенче стадияле рак ярылып ята иде. Моны күргәч профессор хәтле профессорның гәүдәсе буйлап салкын бер дерелдәү узды. Дерелдәү муен тирәсеннән башланды, аннары, үзенең салкынлыгы белән бөтен тәнне өшетеп, аска табан төшеп китте. Профессор бу дулкынның ничек итеп аяк бармакларыннан чыгып китүен тойды, салкын дерелдәү һәр вакыт аның тәненнән аяк бармаклары аша чыгып китә иде. Муен тирәсендә башлана да, бөтен тән аша үтеп, аяк бармакларыннан чыгып китә.

Башта профессор Фәкилә апаның күкрәген капыл гына ябып куярга уйлады. Дүртенче стадияле ракны күрәсе килми иде аның. Ул һәр вакыт аның башын әйләндерә, косасын китерә. Һәм ракка каршы нәфрәт уята. Нәфрәт һәм чарасызлыктан гасабилану. Бу юлы да нәкъ шундый хәл кичерде профессор. Чөнки дүртенче стадия ул — тере организм эченә кереп оялаган үлем.

Фәкилә апаның эчендә яткан рак профессорга карап мыскыллы елмайгандай булды. Һәрхәлдә, профессорга шулай тоелды. Дөрес, ул ракның елмая алмавын яхшы белә иде, ләкин бүген рак елмайган кебек тоелды. Профессор ракка озак карап торды. Янәшәдәге ассистентлар Фәкилә апа тирәсендә бөтерелеп йөрделәр, аның күкрәгендәге ракны төрле яклап фотога төшерделәр. Ләкин моннан Фәкилә апага бер җиңеллек тә юк иде. Һәм профессорга да. Һәм Тимергә дә. Һәм Фәкилә апаның туганнарына, авылдашларына, райондашларына, илдәшләренә, дөньядашларына да җиңеллек юк иде. Дүртенче стадия аларның һәрберсен һәлак итәргә мөмкин иде.

Профессор операция бүлмәсеннән чыгуга Тимерне чакыртты. Тимер коридорда көтә-көтә арып беткән иде. Хәвефтән ул ни үле, ни тере бер хәлгә килде. Чыннан да, энисе үлсә аңа дөньяда яшәүнең мәгънәсе калмас шикелле тоелды.

Хәбәрне ишеткәч кинәт аның тыелып торган күз яшьләре атылып чыкты. Ләкин ул кычкырып еламады. Чөнки аның елавын профессорга күрсәтәсе килми иде. Бу күз яшьләрен татлы дип әйтеп булмый иде. Моны Тимер ирен кырыенда туктап калган бер тамчыны ялап алгач тойды. Күз яше тозлы һәм ачы иде. Күз яше дә, әнкәсенең хәле дә һәм гомумән бөтен дөнья тозлы һәм ачы булып тоелды Тимергә. Профессорның гаепле кеше сыман үзенә карап торуы да, стенадагы ракның төрле стадияләрен чагылдырган фоторәсемнәр дә, менә бу ак халатлар һәм больницадагы үтә пөхтәлек тә ачы һәм тозлы булып тоелды Тимергә. Һәм бу чыннан да шулай иде. Ачы иде, тозлы иде дөнья Тимер өчен бу минутта.

Профессор Тимергә барысын да аңлатып бирде. Әнкәсенең әлегә хәле яхшырып китәчәген дә, операция ярасының төзәлеп бетәчәген дә һәм аның көннәр язга авышкач үләчәген дә...

— Тизрәк авылга, үз өенә алып кайтырга кирәк,— диде профессор,— ул барыбер үз өендә үләргә теләячәк. Аның үз өендә үләсе киләчәк. Аның өчен хәзер бердәнбер юаныч үз өендә үлү.



## 2

Тимер шулай итте дә. Әнисенең операция ярасы төзәлеп бетәр-бетмәстә үк ул аны авылга алып кайтып китте. Ә авылга кайткач үзе дә авырды. Әнисен карарга апасы Роза калды, ә Тимер көч-хәл белән Казанга кайтып егылды. Казанга кайтканның өченче көнендә ул инде больницада иде.

Беренче көннәрне ул югары температура һәм баш авырту белән азапланды. Ләкин врачлар көчле уколлар биреп аларын бетерделәр. Ә менә үпкәдән кан килү һаман туктамый. Больницада ятуына бүген ике ай тулды инде, ә кан килү һаман дәвам итә...

Палатага врач килеп керде.

— Я, кәефең ничек?

— Уртача. Зарланыр сәбәп юк кебек, ләкин кәефем уртача.

— Кан килү ничек?

— Бетеп җитми. Күп килми, ләкин мин аның бөтенләй бетүен телим.

— Аңа артык игътибар итмә һәм борчылма. Синең үпкәдәге процесс бик көчле иде. Шул туктап җитә алмый. Даруларның барысын да эчәсеңме?

— Биргәннең барысын да эчәм. Кайчакта кайсыбер дарулар булмый. Андый чакта барысын да эчә алмыйм.

— Эчәргә кирәк. Өзеклек ясарга ярамый. Югыйсә, процессны туктату читен булачак. Ә минем аны тизрәк туктатасым килә. Бу кыен һәм озак булачак, әлбәттә...

— Мин дә процесс тәмам беткәнче дәваланачакмын. Озакка сузылса сузылыр, ләкин мин түзәчәкмен. Үземне сагышка-моңга бирмәм. Бу бик кыен эш, ләкин мин бирешмәскә тырышам.

— Уңышлы дәвалану өчен бу бик әһәмиятле.

— Мин тырышам. Палатада ялгыз утыру бик күңелсез. Хәтта түзеп булмый башлый. Ләкин мин тырышам. Сагышка-моңга бирелмәс өчен үз-үзем белән сөйләшәм, үземне үзем тынычландырам.

— Ә син үз-үзең белән нәрсә турында сөйләшәсең?

— Әни турында. Аның үлем төшәгендә ятуы, аның үлеп баруы турында. Бу турыда уйлау бик авыр, ләкин мин көн саен шул турыда уйлыйм. Һәм үз-үзем белән дә шул турыда сөйләшәм.

— Әниең өчен елыйсың дамы?

— Әйе, елыйм да. Больницага килгәч инде ике мәртәбә еладым. Берсе узган айда, төнлә, ишегалдына һава суларга чыккач. Бер караңгы почмакка бардым да кешеләрдән качып кына еладым. Миңа еларга кирәк түгел иде, ләкин мин еладым. Икенче мәртәбә, әле күптән түгел генә, палатада караватка утырып еладым. Монысында миңа еларга кирәк иде, һәм мин еладым. Монысында миңа еламыйча мөмкин түгел иде. Күңелемә ниндидер каты нәрсә килеп бөялде һәм аны авырттырды. Миңа тизрәк аннан котылырга кирәк иде һәм мин еладым. Елагач ул бөялеп торган каты әйбер юкка чыкты. Ә бәлки ул әле юкка чыкмагандыр да, ә йомшаргандыр гына. Әни турында ныграк уйласам, ул бәлки тагын шунда килеп бөялер. Аннан котылу өчен миңа тагын еларга туры киләчәк. Елауның минем үпкә авыруына зыяны юкмы?

— Зыяны юк, ләкин еламау яхшырак. Күңеленә бөялгән каты нәрсәдән котылу өчен генә еларга ярый.

— Мин аннан һәр вакыт елап котылам.

— Аннан шунсыз котылып та булмый.

— Ә нәрсә бөялә икән ул күңелгә шундый каты булып?

— Ул турыда сорашмау яхшырак. Аны аңлатып биреп була, ләкин ул турыда сөйләшмәү яхшырак. Һәм ул турыда уйламау да яхшырак.

— Мин ул турыда уйламаска тырышам.

— Шулай әйбәтрәк.

— Хәтта рәхәтрәк тә. Тик менә әни генә истән чыкмый.

— Әниләр турында уйлауны без тыя алмыйбыз. Врачлар авыруларга беркайчан да, әниегез турында уйламагыз, дип әйтә алмый. Гомумән, уй дөньяда иң ирекле әйбер. Уйны беркем дә тыя алмый. Хәтта ул начар уй булса да.

— Уйны бары тик уйлаучы гына тыя ала. Һәм бер уйны икенче уй тыя ала.

— Монысы инде уйлар көрәше дип атала. Кеше күңелендә яхшы уй һәр вакыт начар уйны җиңәргә тиеш. Әкияттәге сыман. Анда да бит һәр вакыт яхшы күңелле егет җиңеп чыга.. Ә кешенең күңеле әкияткә тиң.

— Хәтта аннан матуррак та әле.

— Әйе, кайчакта хәтта матуррак та.

Врач чыгып киткәч Тимер бик озак уйланып ятты. Һәр вакыттагыча, бу юлы да киләчәк турында түгел, ә узганнар турында уйлады.

### 3

Аларның авылы бик матур җиргә урнашкан. Аның көнчыгыш ягында, Тимерләрнең бәрәңге бакчасы артыннан ук, текә тау күтәрелә. Тау шундый текә булып күтәрелә ки, аннан һәр вакыт вак ком агылып тора. Ком бик акрын һәм бик аз, бөртекләп-бөртекләп кенә ага, ләкин бер дә тукталып тормый. Тау битендәге ком һәр вакыт хәрәкәттә булу сәбәпле, анда үлән дә үсә алмый. Читтән караган кеше бу тау битендә берниндн тереклек иясе дә юктыр дип уйларга мөмкин. Ләкин Тимер беркайчан да болай уйламады. Ул бала чактан шушы тау битендә уйнап үскән кеше, һәм тау турында һич кенә дә узгынчылар кебек уйлый алмый иде. Чөнки тау битендә нәрсәләр барын бик яхшы белә ул.

Беренчедән, анда бик күп кызыл чикерткәләр яши. Июнь башларында алар шундый жуылдап очалар ки, вертолетлар диярсең. Кай-

чакта алар фырылдап оча-оча авыл өстенә үк килеп чыгалар. Андый чакларда Тимер бакчага чыга да зур чикерткәләрнең кызыл канатларына сокланып тора. Кызыл чикерткәләр авыр бомбардировщиклар сыман салмак кына очалар-очалар да, кире тау битенә кайтып китәләр. Тимер алар артыннан тау битенә йөгерә һәм анда бик күп итеп кызыл чикерткәләр тота. Кайчакта ул хәтта өчәр шырпы кабы чикерткә тутыра иде. Тик соңыннан ул аларны ни эшләтергә белми, аптырагач, шырпы кабын ачып, чикерткәләрне кире җибәрә. Ләкин кире җибәргәнче ул озак итеп чикерткәләрнең шырпы кабын кыштырдатуларын тыңлый. Ул шуны тыңлауны үлеп ярата. Ә бәлки ул чикерткәләрне нәкъ шуның өчен генә тоткандыр да әле...

Кыштырдауны ул шырпы кабын колагына якын ук китереп, кайчакта хәтта колагына куеп ук тыңлый. Андый чакта кыштырдау аның колагын кытыклаган кебек була һәм Тимер үзалдына шыркылдап көлеп җибәрә. Читтән карап торган кеше аны тиле дип уйларга мөмкин. Ләкин Тимер үзен һич кенә дә алай дип уйламый. Чыннан да, тиле кешеләр тиктомалга шыркылдап көлеп җибәрсәләр дә, чикерткәләрнең шырпы кабын ничек кыштырдатуына соклана белмиләр ич. Ә менә Тимер соклана белә. Шулай булгач ул ничек тиле булсын ди инде?!

«Бу очракта теләсәң дә тиле булып булмый,— дип уйлады Тимер,— гомумән, тилерү ул кешеләргә теләкләренә карап килми торгандыр. Ул нииндидер аңлашылмый торган серле халәт. Яшьли тиле булганнар ярар да инде, алар тумыштан тиле булсыннар ди, ә менә акыллы кешеләрнең тилерүен ничек аңларга? Әнә бервакыт безнең мәктәп директоры нишләде. Дөрес, ул котырынып, бәрелеп-сугылып йөрмәде, шулай да тилерде. Ул үз укучылары белән талаша-талаша «Кем сукты?» уйнады. Бүреген, пальтосын, киез итекләрен алдын-артка киеп урамда йөрде һәм бернинди сәбәпсез шырык-шырык көлде. Шуннан аны районнан килеп алып киттеләр. Ике айдан ул, яңадан җитдиләнеп, үз урынына кайтты».

Чикерткәләрдән башланган уй Тимерне әнә кайларга алып китте. Ә бит ул нибары авыл һәм чикерткәләр турында гына уйлый башлаган иде.

«Юк, тиләләр турында уйларга кирәкми,— диде Тимер үз-үзенә,— ул яхшы уй түгел. Алар турында гомумән бернәрсә уйламасаң да ярый. Миңа тиләләр турындагы уйны баштан куарга кирәк: көш-көш, китегез!..

Миңа хәзер бары тик авыл турында гына уйларга кирәк. Бүген төштән соң больницага мине күрергә дуслар килергә тиеш. Шуңа кадәр миңа авыл турындагы уйларны уйлап бетерергә кирәк. Һәрбер уй кешене рухи яктан баетырга тиеш. Ә тиләләр турындагы уй мине баетмый. Мине авыл турында уйлау гына баета. Һәрхәлдә, менә бу минутта шулай. Авыл турында уйлау мине дәртләндереп җибәрә, җаныма рухи көч бирә. Һәм миңа хәзер бары тик авыл турында гына уйларга кирәк. Тиләләр турындагы уй шайтаныма олаксын. Чәнчелеп китсен ул уй. Төкерәм мин аңа. Тьфү, әшәке уй!»

Әйе, авылның көнчыгышындагы текә, комлы тауда кызыл чикерткәләр яши иде. Һәм кечкенә ташлар астында — сөтле бакалар. Ул бакаларның тиресе яра өстендә катып калган кутыр шикелле кытыршы иде. Бакалар көндезләрен таш астындагы салкын чокырда, дөм-караңгыда яталар. Тимер ташны кубаргач, алар песи балалары сыман нәзек кенә итеп чинап куялар иде. Кояшны, яктылыкны, коры һаваны яратмыйлар ул бакалар. Шуңа күрә, ташны куптаруга, үз тәннәре юешләгән салкын комга ырграк елышалар. Тимернең кулы тию белән аларның кытыршы тәннәреннән сөт сыгылып чыга. Нәкъ сыер сөте төсле ап-ак сөт. Тимер бу сөтнең ник чыгуын һич кенә дә аңламый иде. Бер-

вакыт ул хәтта бармагына буялган сөтне теленә дә тидереп карады. Сөт ачы иде. Әрәм ачысыннан да ачырак. Гомумән, әле Тимернең бака сөтеннән дә ачы әйбер татып караганы юк.

Бакалар сөтләрен чыгарып бетергәч, Тимер алар өстендәге ташны яңадан ябып куя. Чөнки бакалар кояшны һәм яктылыкны яратмыйлар. Кешеләр төнне һәм караңгылыкны яратмаган кебек. Чөнки бу бакалар төнге җан ияләре иде. Кояш баюга алар таш асларыннан чыгалар һәм нәзек тавыш белән чыкыр-чыкыр чинап чебен-черки, күбәләк, төрле вак коңгызлар ауларга керешәләр. Ләкин инде Тимер боларын күрми иде. Чөнки ул караңгы төшкәч ялгызы гына тау битендә калырга курка һәм тизрәк өенә кайтып китә.

Ә көндезен ул бакалар сөтләрен чыгарып бетергәч тә ташны ябып куя. Тимер ни өчендер бу бакаларны кызгана иде. Ни өчен икәнен белми, әмма кызгана. Әллә ул аларны песи балалары кебек нәзек һәм мескен итеп чинаган өчен кызганды микән?! Бәлки, бәлки... Ләкин монысы инде Тимер өчен әһәмиятле түгел — кызгана һәм бетте-китте. Тимергә шушысы да җитеп ашкан. Ул кызгана белә, менә хикмәт кайда. Кызгана белүнең игелекле хис икәненә бала чактан ук төшенде Тимер.

Ләкин, Тимернең уенча, нәрсәнедер кызгана белгән кеше, кызганган әйберсен яклый да белергә тиеш иде. Югыйсә, коры кызгануның поты бер тиен. Коры кызгану ул мескеннәр өлеше. Менә ни өчен Тимер бакалар өстендәге ташны кире ябып куя торган иде.

«Мин бакалар турында күбрәк уйлап ташладым бугай,— диде Тимер үз-үзенә,— ә бит бу тау өстендә сары иген кыры җәйрәп ята иде. Нигә миңа шул кыр турында уйламаска? Яки шул кыр өстендәге тургай турында? Хәер, бер тургай гына да түгел иде ич безнең авылда. Әле бит мин авылның көнчыгышы, әлеге тау турында гына уйладым. Ә көнбатыш, көньяк һәм төньяк яклары турында уйлап та карамадым. Мәсәлән, көнбатыш ягындагы урманлы калкулык турында уйларга була ич».

Ләкин Тимернең инде авылы турында уйлыйсы килми башлаган иде. «Бүгенгә җитеп торыр,— диде ул,— болай озак уйларга ярамый. Миңа ял итәргә кирәк, башны арытмаска». Шулай диде дә Тимер, берни турында да уйлдмый башлады.

## 4

Бүген аның янына дуслары килде. Больница Казаннан читтә, урман эченә урнашкан. Шуңа күрә алар машина белән килделәр. Сөлек кебек ялтырап торган чем-кара «Волга» больницаның ишеге төбенә үк килеп туктады. Машинаның ике ягыннан да ишекләр ачылып китте һәм аннан Тимернең дуслары чыга башлады. Чибәр, хөр, матур егетләр Тимернең дуслары. Ул аларның ничек итеп машина эченнән чыгуларын больница коридорындагы тәрәзә аша карап торды.

Бүген алар өчәү килгәннәр. Нык бәдәнле, мәһабәт һәм сөйкемлеләр алар. Өчесе дә менә дигән итеп киенгәннәр, иң соңгы модалы галстуклар такканнар, кулларында күз явын алырдай күн портфельләр. Ә йөзләрендә — елмаю. «Антейлар, Геркулеслар, Алыплар! — дип уйлады Тимер дуслары өчен куанып.— Ә менә мин больницада ятам. Юк, мин аларның саулыгыннан аз гына да көнләшмим. Энә очы кадәр дә. Мин алар өчен горурланам гына. Ә көнләшү кирәкми. Ул миңа хас нәрсә түгел. Ул минем канымда юк. Һәм гомумән минем ул турыда уй озайтып торасым да килми. Кешенең саулыгыннан көнләшүдән дә яман эш юктыр дөньяда».

Ул арада егетләр гөлдер-гөлдер сөйләшеп больница коридорына килеп керделәр. Тимер дә аларны елмаеп каршылады. Егетләр Тимерне күргә бераз шымыеп, тынып калдылар. «Кызык гадәт,— дип уйлады Тимер,— больницага авыру янына килгән кешеләр һәр вакыт кинәт шымыеп калалар. Дуслар да, туганнар да, хәтта хатын да бер мәлгә шымыеп кала».

Ләкин бу ипсез тынлык озакка бармады. Палатага керү белән барысы да яңадан гөлдер-гөлдер килеп сөйләшә, хәтта көлешә башладылар.

Гадәттәгечә, беренче сүзне шалапут Миндуп башлады:

— Нәрсә син монда ояладың, сабака,— дип тезеп китте ул Тимергә,— урамда яз башланырга тора, ә син монда тынчып ятасың. Ниемә кирәк сиңа бу больница, әйдә киттек Казанга, төкер больницасына, төкер авыруына. Синнән башка анда Казанда да, Архитекторлар союзында да үлем тынлыгы. Кемнән көләргә белми аптырап йөри анда архитектор халкы.

— Төкерәм дә бит, Миндуп, төкерек белән кан килә,— диде Тимер шаяруны дәвам итәргә теләп.

Ләкин аның бу сүзе дусларына шаян сүз булып тәэсир итмәде. Киресенчә, алар бу сүздән дәррәү тынып калдылар. Җайсызрак чыкты шул Тимернең шаяруы.

— Шаярма әле, Миндуп,— диде Низам Миндупны шелтәләп,— авыру янына килдеңме син, әллә кәмитче янынамы. Больницада авыз ерып шаярып утыру бер дә килешми инде.

«Ә Низам һаман җитди, — дип уйлады Тимер, — Низам, Низам, җитди Низам. Архитекторлар союзында бүлек мөдире булып утыра-утыра тәмам сөрсеп бетәсең бит инде».

Чыннан да, Низам җитди кеше иде. Хәтта кирәгеннән артык җитди. Киенүен ул мода белән киенергә ярата, төшке ашны да гел ресторанда гына ашый. Хәтта аның Казан зыялылары арасыннан сөяркәсе дә бар дип сөйлиләр. Ләкин менә җитдилеккә җитди иде Низам. Шуның аркасында ул сирәк көлә иде. Дөресрәге, кешенең кызык сүзенә гомумән көлми, ә үзе шаярганда бик үк кызык сүз әйтмәсә дә көлә. Көлгәндә аның тавышы гөбердәп тамак төбеннән чыга һәм көлү аның гәүдәсенә ятышып тормый иде. «Көләргә өйрәнмәгән бугаз», — дип уйлый иде андый чакта Тимер, һәм ул дөрес уйлый иде. Низам кычкырып көләргә шул кадәр гадәтләнмәгән ки, очрак чыгып бик каты көлсә, соңыннан хәтта чирли торган иде.

«Бу Низам даһи заттыр, — дип уйлый иде Тимер аның турында, — чөнки дөньяда әле бер генә кешенең дә көлүдән чирләгәне юк иң. Көлүдән чирләгән кеше гади адәм булырга тиеш түгел, мөгаен, бу Низамда ниндидер илаһи көчләр яшеренеп ятадыр».

Низам Миндупның шаяруын тыйгач, палатада бер мәлгә тынлык урнашты. Ләкин бу тынлыкның Тимергә кирәге юк иде. Мондый тынлыкны ул ялгызы калгач та кичерә ала. Дуслары килгәч ул палатасының шау-гөр килеп торуын тели. Ләкин ул бу тынлыкка үзе сәбәпче булды шул. Кан төкерүе турында әйтмәгән булса, Миндуп әле һаман да шаярыр иде, Низам да аны болай капыл гына туктатмас иде.

— Я сөйләгез инде, эштә ниләр бар? — диде Тимер бөтен палатаны үзенә биләп алган тынлыкны бозарга теләп.

— Эш турында Низам сөйләсен әнә, — диде Миндуп этләшеп, — казна эшен ул барыбыздан да күп эшли. Үзе өчен генә түгел, безнең өчен дә эшли ул казна эшен. Кәгазь корты, кабинет күсесе.

Бу юлы барысы да дәррәү көлеп куйдылар. Больница палатасы дүрт егет көлүеннән киңәеп киткәндәй булды. «Менә бу миңа ошый,— дип уйлады Тимер, — менә монысы безнеңчә! Эх, шайтан алгырысы, шәп егетләр бит минем дуслар! Дуслар гына түгел, бүгенге яшәвемнең тот-

калары сез, шәп җаннар. Сездән башка яшәү миңа бик тә күңелсез булыр иде... Ә шулай да сез миңа әнине алмаштыра алмассыз шул... Юк, юк, хәзер миңа әни турында уйларга ярамый. Миңа дуслар килгән икән, мин бары тик алар турында гына уйларга тиеш. Ә әни турында соңыннан, ялгыз калгач».

— Эштә әллә ни яңалык юк, — диде Низам җитди генә, — менә син җитенкерәмисең. Дөрес, эш бара, барысын да план буенча үтибез, ләкин синең җитенкерәмәвең сизелә.

— Бигрәк тә Казанның тол хатыннарына җитенкерәмисең, — дип сүз арасына чөй кыстырып куйды Миндуп.

Ә Рөсти әле һаман дәшми утыра. «Ул һәр вакыт шулай аз сүзле, — дип уйлады Тимер Рөсти турында. — Шулай да аны сүзен үлчәп сөйләүчеләрдән дип булмый. Сөйләшүен аз сөйләшә Рөсти, ләкин аны үлчәп сөйләүчеләр рәтенә кертеп булмый. Дөрес, ул беркайчан да ахмак сүз әйтмәс. Һәм теләсә кайда теләсә нәрсә сөйләнеп йөрмәс. Шул ук вакытта аны сүзен үлчәп сөйләүчеләр белән дә янәшә куеп булмый. Ләкин аның бу үзенчәлеге минем белән дус булуга һич кенә дә комачауламый, — дип дәвам итте Тимер. — Киресенчә, һәр сүзен үлчәп сөйләшсә, бәлки мин аны өнәп тә бетәрмәс идем әле. Яки теләсә нәрсә сөйләнеп йөрсә. Юк, Рөсти дус буларак менә дигән кеше. Аеруча шәхси мәсьәләләрдә ул бер дигән дус. Аның белән хатын-кызлар компаниясендә булу үзе бер гомер».

— Я, Рөсти, син дә бер-ике сүз әйт инде, — диде Тимер олы пыялалы күзлеге артына кереп поскан Рөстигә.

— Әлегә бер яңалыгым да юк, егетем, — диде Рөсти. — Мин бит сезнең кебек сөйләшә белмим. Менә рәхәтләнеп тыңлап утырам сезне. Мин бит Миндуп кебек шарлатан да, Низам кебек җитди җитәкче дә түгел... Хатын-кыз ягыннан бернинди яңалыгым да юк.

Бусы Рөстинең шаяруы иде. Аның шаяруы һәр вакыт шулай хәзерлексез, юморсыз һәм дорфарак килеп чыга. Егетләр тагын дәррәү көлеп җибәрделәр. Ләкин алар Рөстинең кызык сүзеннән түгел, ә шаяруының килеп чыкмавыннан, Рөстинең шаяра белмәвеннән көлде. Рөсти моны үзе дә сизде һәм үзенең булдыксызлыгыннан үзе дә елмаеп куйды.

Ләкин ул көрсенмәде. Чөнки бу очрактагы булдыксызлыгының аның төп эшенә караганда бик вак нәрсә икәнен аңлый иде. Ә төп эшен шәп алып бара Рөсти. Үзенә тапшырылган архитектура проектын менә дигән итеп эшли. Аның өчен иң әһәмиятлесе дә шул — төп эш әйбәт барырга тиеш. Ә шаяруның килеп чыкмавы икенче нәрсә. Рөстинең дуслары да моны яхшы аңлыйлар иде һәм, шуңа күрә, көлсәләр дә, аңа хөрмәт белән һәм яратып карадылар.

«Әйе, иң әһәмиятлесе үзеңә тапшырылган төп эшнең уңышлы баруында, — дип уйлады Тимер. — Иң әһәмиятлесе кешеләр сиңа ышанып тапшырган эштә өзеклек булдырмауда. Өзеклек ясадыңмы — син егет түгел, ир түгел, хәтта кеше түгел. Төп эштә өзеклек ясау — хәрби операциядә өзеклек ясау белән бер. Яки иң якын кешеләреңнең ышанычын югалту белән тиң. Яки әти-әниеңнең ышанычын югалту белән. Төп эштә өзеклек булмасын өчен, байтак тир агызырга туры килә. Монысын мин бик яхшы беләм инде. Төп эштә өзеклек ясамас өчен, күп вакытта миңа үз-үземне да аямаска туры килә. Хәтта гаилә, хатын, сәламәтлек, вакыт һәм минем тормышымны тормыш итеп оештырган тагын бик күп, бик күп нәрсәләрнең байтагысы белән исәпләшмәскә туры килә. Бәлки әле минем больницага керүемә сәбәпче дә шул төп эшемә өзеклек китермәскә тырышуым булгандыр. Ә шунсыз мөмкин дә түгел. Чөнки мин җәмгыять, дуслар, туганнар һәм мине белгән яки белмәгән йөзләрчә, меңнәрчә, кайчакта хәтта аннан да күбрәк кешеләр алдында нindидер эш башкарырга алынганмын икән, аны үтәп чыгу өчен тәнне яки җанны кызганып тору ваклык яки мескенлек булыр

иде. Ә мин беркайчан да моңа бара алмыйм. Хәтта башымны киссәләр дә бара алмыйм. Һәм Рөсти дә бара алмый. Һәм Низам да. Һәм Миндуп та. Безнең дүртебездән беребез дә моңа бара алмый. Бәлки әле без нәкъ менә шуңа күрә дус булганбыз да. Ә бәлки әле без бөтенләй үк дуслар да түгелдер. Ләкин монысы инде бүтән мәсьәлә. Монысын инде киләчәк күрсәтер...»

Шуннан Тимер өч дустының өчесенә дә берәм-берәм карап сокланып торды. Тимер дусларын ярата һәм аларның шушындый шәп һәм сөйкемле булуларына куана иде.

Миндуп белән Низам күптән түгел генә булып узган бер җыелыш турында бәхәсләшә башладылар.

— Мәрдән абзыйның чыгышы бер тиенгә дә ярамый иде, — дип кызды Миндуп. — Пүчтәк чыгыш иде ул. Һәм зыянлы чыгыш иде.

— Ә син аңа каршы чыгып дөрес эшләмәдең, — диде Низам. — Дөресрәге, артыграк кызып киттең. Картларга алай ук каты бәрелергә ярамый.

— Ә нигә алар безгә каты әйтәләр? Каты гына түгел, бөтенләй юкка чыгарырга маташалар. Рөстинең проекты менә дигән хезмәт. Ә Мәрдән абзый берни аңламаган башы белән проектны сүгәргә алына. Надан, ликбез шәкерте.

— Ялгышасың, — диде житди Низам тагын да житдиләнеп. — Мәрдән абзый заманында ВУЗ бетергән белемле кеше. Ул безнең карт архитекторлар арасында иң белемлесе бугай әле. Әлбәттә, мондый кешенең талантлы проектка каршы чыгуы аяныч хәл. Ләкин мәсьәләнең икенче ягы да бар: пенсионер картлар безнең җыелыштан үзләрен бер нигә дә кирәкми торган кешеләр дип китмәскә тиеш. Такт дигән нәрсә бар бит әле дөньяда.

— Беренчедән, безнең эштә мәсьәләнең икенче ягы да, өченче, дүртенче, бишенче, алтынчы ягы да юк. Без иҗат кешеләре һәм бездә мәсьәлә бер генә яклы: талантлымы бу проект, әллә халтурамы? Икенчедән, минем өчен иҗат эшендә такт юк, ә факт кына бар. Син миңа факт бир, ягъни шәп проект бир. Ә бит уйлап карасаң, Мәрдән абзыйның бер генә сокланып карарлык проект та эшләгәне булмаган. Ул гомер буе трибунадан кеше өйрәтеп кенә яшәгән. Һәм син әйткән бөтен белемен шуңа гына сарыф иткән. Рөстинең бу яңа проекты Мәрдән абзыйның гомер буе эшләгән проектларын бәреп ега.

«Менә бу сөйләшү миңа ошый, — дип уйлады Тимер. — Аһ, мин никадәр сусаганмын икән иҗади бәхәсләргә! Кызык, мин Миндуп белән Низам бәхәсен моңлы бер җыр тыңлаган кебек тыңлыйм. Хәтта симфония кебек тә бугай әле. Ләкин бу симфониягә Рөсти авазы житеп бетми шикелле. Ә Рөсти әйтсә өздереп әйтә инде ул, сүзен үлчәп тормый» .

Һәм нәкъ шулай булды да.

— Ташлагыз әле өч тиенгә кирәкмәс бәхәсегезне. Минем өчен Мәрдән абзый сөйләде ни дә, сөйләмәде ни. Бар дип тә белмим мин андый критиканнарны. Миңа димәгәе ник унбиш Мәрдән абзый унбиш трибунага менеп унбиш тавыш белән әрләми. Шунысы кызганыч, минем проект андый чыгышлардан ни яхшырмый, ни начарланмый. Бик беләсегез килсә, минем проектка бер күз ташлау белән Мәрдән абзый кебекләрнең авызыннан теше коела башлый. Ни өчен дисәң, минем проекттагы яңалык андыйларның башына имән күсәк белән тондырган кебек тәэсир итә.

Менә монысы инде Рөсти шаяруы иде. Ачы, усал. «Тупас татар», — дип уйлады Тимер Рөсти турында. Ләкин ул моны яратып, үз итеп уйлады.

Рөстинең бу сүзләреннән соң инде Миндуп белән Низам бәхәсенең мәгънәсе калмады.

— Шәп егетләр сез, ләкин хатын-кыз мәсьәләсендә бер тиенгә дә ярамыйсыз, — диде Рөсти, Низамның йомшак ягына кагылып.

Әйе, хатын-кыз мәсьәләсе Низамның йомшак ягы иде. Чөнки ул никадәр генә җитди кеше булса да, һәм никадәр генә җаваплы постта утырса да, хатын-кыз мәсьәләсендә бөтенләй бала иде. Дөрес, Казан зыялылары арасында аның сөяркәсе бар дип сөйлиләр, ләкин ул хатын-кыз мәсьәләсендә бала иде. Ул хатын-кыз турында тотнаксызрак әйтелгән һәр сүзне, һәр анекдотны бөтен җаны-тәне белән, дерелдәп-калтырап тыңлый. Үзе ояла, үзенең һаман шул турыда сөйләшүне дәвам итәсе килә. Бу юлы да шулай булды. Ул үзенең:

— Қ чорту Мәрдән абзый, сөйлә, Рөсти, — дип әйтеп ташлаганын сизми дә калды. Дөрес, сүзен әйтеп бетергәч, ул бераз ашыкканын сизде, ләкин соң иде инде — сүз дигән чыпчык авыз дигән ботак тишегеннән чыгып очкан иде. Ләкин Миндуп, Тимер һәм Рөсти кычкырып көлмәделәр, ә Низам күрмәгәндә бер-берсенә күз кысышып кына алдылар. Бу аларның өчәүләшеп Низамны аздырырга, кыздырырга, чыгырыннан чыгарырга килешүләре иде. Бу аларның яраткан уеннары. Алар һәр вакыт өчәүләшеп Низамның шушы балалыгы белән уйныйлар. Бик җитди кыяфәттә хатын-кыз турында әллә ниткән уйдырмалар сөйлиләр, ә Низам чын күңелдән ышанып кыбырсый, кызара-бүртенә, елмайган-көлгәндәй итенә һәм маңгаена бәреп чыккан тирләрен сөртә.

— Миндуп, теге, пляждагы хатын турында сөйләгән идем бит мин сиңа, — диде Рөсти юри «пляж» һәм «хатын» дигән сүзләргә басым ясап. Әлбәттә, аның Миндупка бернинди пляж һәм бернинди хатын турында да сөйләнгәне юк иде, ләкин бүген аларның Низамны котыртасылары килә, шуңа күрә Миндуп:

— Ә-ә-ә, теге менә мо-о-о-ның киңлек хатын турындамы? — дип элеп алды. Ул хыялдагы хатынны ике кулын киң җәеп күрсәтте, янәсе таза хатын, нәкъ Низам ярата торган. — Әйе, әйе, сөйләгән идең, я, тагын бер кат сөйлә әле. Мең мәртәбә тыңласам да, туймыйм мин аңардан. Шәп ханым!

Низам инде урындыгын шыгыр-шыгыр иттереп кыбырсый башлады. Аны сиздермичә генә күзәтү шул кадәр рәхәт иде, мескен Низам үзе генә белми.

— Вә-ә-әт, — дип башлады Рөсти күзләрен тыйнаксыз хатын-кыз янында уйнаткандай хәйләкәр уйнатып. — Узган җәй бер көнне иртүк тордым да, су коенырга дип, Казанка пляжына төшеп киттем. Көн шундый матур, аяз, тыныч, җылы. Тирә-якта беркем дә юк. Кояш әле чыгып кына килә һәм бөтен нурын туп-туры пляж өстенә сибә. Бер ялгызым атлап килəм шулай сары комнан. Бер мәлне алга күтәрелеп карасам... Я, ходаl Миннән илле генә адым алда беләсеңме нәрсә?

— Шәрә хатын! — дип элеп алды Миндуп.

Низам төкереген йотып куйды, маңгаендагы борчак-борчак тирләрен сөртеп алды.

— Билләһи шулай! — диде Рөсти. — Анысы бер хәл, ә шәплеге! Бер-бер боты безнең Архитекторлар союзы председателенең секретаршасы кадәр бар. Ята, малай, минсиңайтим чалкан төшеп. Ул күкрәкләр! Һәрберсенә бер кагылып карау өчен генә дә берәр пот алтын бирерсең.

Низам тамак кыра, ләкин бу ниндидер гырылдау булып чыга. Үзенең чамадан чыгып кызыксынуын сиздермәскә тырышып утыра Низам. Ләкин егетләр аны сизеп, күреп, тоеп утыралар, эчтән генә көләләр һәм аның саен Низамны котыртасылары килә.

— Әй, егетләр, шул чакта ходай нинди түземнәр бирәдер ир-зат-

ка, — дип дәвам итә Рөсти әкиятен, — Низам булса һич түзмәс иде, юлбарыска, арысланга, барска әйләнер иде.

— Причем монда Низам? — дип көчкә аваз салды Низам тагын кып-кызыл булып.

— Низам азгын бит ул, — дип ут өстенә май сипте Миндуп. — Әйдә, әйдә сөйләп бетер инде.

— Ә мин һаман якынаям бит теге пәри янына, — дип дәвам итте Рөсти. — Ә ул селкенми дә ята бирә. Җитмәсә, кояш Казанканың каршы як ярыннан күтәрелеп, туп-туры минем биткә бәрә, тегенең бөтен җирен дә тәфсилләп карарга күз чагыла. Шуннан соң мин моны янъяктан күзләргә булдым. Хатынның уң ягына чыгып читкәрәк киттем дә, кояшка ян белән басып күзәтәм тегене. Минем инде аның бөтен җирен күрәсе килә. Карасам...

Рөсти шунда сөйләвеннән туктап озак кына тын алды. Палата кинәт тып-тын булып калды. Рөсти дә, Миндуп та, Тимер дә юри бер сүз дәшмичә Низамны күзәтәләр. Ә Низам... Низам егетләрнең берсенә дә күтәрелеп карамый, күзләрен идәнгә текәгән, чышт-чышт иттереп, кипкән иреннәрен ялый. «Низам, Низам, җитди Низам, — дип уйлады Тимер,— һәм бала, һәм җитди җитәкче, һәм талантлы архитектор... Ә бу минутта ташы кызган мескен бер егет».

— Карасам, — диде Рөсти сүзен очларга җыенган тон белән, — юан ханымның өстендә купальнигы бар икән. Шайтан алгыры, нәкъ үзенең кояшта янган тәне төсендәге купальник кигән дә рәхәтләнеп кызынып ята. Ерактан караганда купальник тән төсе белән бер булып күренә икән... Менә сезгә архитектураның тагын бер сере. Бер үк объектта әлле ничә төр детальне бер бөтен итеп күрсәтергә мөмкин икәнгә тагын бер мисал. Һәм мин сезгә ул хатын турында берниндн азгынлык белән дә сөйләмәдем, ә архитектор буларак профессиональ күзәтүләрем белән генә уртаклаштым. Шулаймы, Низам?

Ниһаять, Низам да җиңел сулап куйды. Миндуп, Тимер һәм Рөсти яшеренеп кенә көлештеләр, ләкин инде бер мизгел дигәндә Низам кинәт үзенең җитди һәм эшлекле хәленә кайтты.

Шуннан соң алар Казан яңалыклары, гаилә хәлләре, таныш-белешләр турында сөйләшеп утырдылар. Низам күптән түгел генә Мәскәүдә булган икән, башкала архитекторлары арасындагы яңалыкларны сөйләде.

Утыра-утыра шактый вакыт үтте һәм Тимернең дусларына китәргә кирәк иде. Ә аларның китүе инде Тимернең тагын бәләкәй палатада япа-ялгыз калуы дигән сүз. Дөньяда шушындый дусларың була торып та, бәләкәй палатада япа-ялгыз калу бик үк күңелле эш түгел. Моны Тимер дә, аның дуслары да яхшы беләләр. Шуңа күрә берсенең дә аерылышу турында тел ачып сүз әйтәсе килмәде. Һәрхәлдә, бу турыда беренче булып сүз кузгату һәрберсенә кыен иде.

«Бу сүзне башлау өчен иң кулай кеше мин бугай, — дип уйлады Тимер. — Чөнки моның белән мин беркемне дә җайсыз хәлдә калдырмаячакмын. Әгәр аларның берәрсе больницада ятып, аның янына барсам, мин, әлбәттә, китү турында беренче булып сүз кузгатмас идем. Чөнки ул, минем синең яныңнан тизрәк китәсем килә, дигән кебек килеп чыгачак. Яки, килдем-киттем, бурычымны үтәдем, дигән кебегрәк. Шуңа күрә авыру янына килгән кешеләргә кайтып китү турында беренче булып сүз башлау һәр вакыт кыен була. Бу кыенлыктан дусларны бары тик мин генә чыгара алам».

«Ләкин моны ничегрәк эшләргә соң әле? — дип уйлавын дәвам итте Тимер,— ярый, килдегез, хәзер сезгә китәргә вакыт, дип әйтеп булмый бит инде. Бу тупаслык булыр иде. Һәм тәрбиясезлек. Авыруы көчәйгән яки арыган кеше булып кылану да яхшы түгел. Һе, менә сиңа проблема».

Шунда кинәт Тимер бу мәсьәлә турында кирәгеннән артык тирән һәм нечкә итеп уйлавын тоеп алды. Тапкан проблема. Мондый чакларда бит ул һәр вакыт шаярып котыла торган иде. Һәм ул бүген дә шулай итте. Тегеләр сөйләшүдән туктап калган бер мизгелне эләктереп алды да:

— Әй, сез кунарга килмәгәнсездер бит монда. Бик оятсыз кунаклар булып чыктыгыз әле, китү турында уйлап та карамыйсыз, — дип әйтеп салды.

Һәм шаяру үз эшен эшләде дә. Инде баядан бирле китү турында уйлап та, кузгалырга кыймый утырган кунаклар көлешә-көлешә портфельләренә ябыштылар. Үзләре һаман шаяртканн булдылар.

— Ай, аллам, алай бик куасың икән, без вообще килмәскә можем, — дип кыланды Миндуп.

— Ярый, егетләр, кузгалырга вакыт, безне эш көтә, ә Тимергә ял итәргә кирәк — диде җитди Низам.

— Миңа киттем ни, кундым ни, Низам белән Миндупныкы шикелле, өемдә хатыным көтеп ятмый, — дип төрттерде тегеләргә Рөсти.

## 5

Киттеләр. Тимер аларны озатып керде дә, лып итеп караватына утырды. Әйе, киттеләр, һәм берни дә үзгәрмәде. Шул ук бер кешелек палата. Шул ук яшел буяулы стеналар. Шул ук иске тимер караватж, вак кына кызыл чәчәкле эскәтер җәелгән өстәл. Өстәл өстендә аркылы-торкылы сызгаланып беткән кәгазьләр — Тимернең сызымнары... Бары да үз урынында, бары да элеккечә. Тимернең дуслары килеп кичкенә палатада ни яңалык, ни искелек эзе калдыра алмадылар... Барысы да элеккечә... «Тик күңелдә генә менә...» — дип уйлады Тимер. Ләкин аңа болай уйларга ярамый иде. Чөнки ул үзен сагышка-моңга бирмәскә карар иткән кеше. Бәс шулай икән, «күңел-мүңел» дип утырасы түгел. Һәм палатада бернәрсә дә үзгәрмәве турында да уй озайтып торуның кирәге юк. Гомумән, аңа болай караватта боегып утырырга кирәкмәс иде. «Миңа хәзер хәрәкәт кирәк, хәрәкәт, хәрәкәт, хәрәкәт, — дип уйлады Тимер. — Болай утырсаң үзеңне сагышка-моңга бирү дә ерак йөрмәс. Хәзер миңа сикереп торырга да, үземчә ниндидер бер шөгыль уйлап табарга кирәк».

Һәм ул шулай итте дә. Яхшылабрак караса, дуслары аның палатасында әллә никадәр үзгәреш ясап киткәннәр икән ләбаса. Менә бу урындык һәр вакыт өстәлнең теге башында тора иде. Әнә ул Тимернең караваты янына килгән дә, Низам торып киткән көе калган. Өстәлнең сул як почмагында торырга тиешле өстәл лампасы ни өчендер тәрәзә төбенә менеп кунаклаган. Өчәүләшеп Тимернең яңа сызымнарын карағанда ул Рөстигә комачау итте бугай, һәм Рөсти аны тәрәзә төбенә алып куйды .Ә өстәлнең сул ягында, һәр вакыт Тимернең кул астында булырга тиешле башка бер папка карават буендагы тумбочка өстенә килгән. Аның эчендә нәрсә бар икәнен хәзергә Тимердән башка беркем дә белми. Монысын тумбочка өстенә Миндуп алып куйды. «Бөтен палатаның астын-өскә китереп бетергәннәр,» — дип зарланган булды Тимер юри генә. Югыйсә, бу тәртипсезлекләрне рәткә китерү аңа бик тә рәхәт иде. Үз урыныннан кузгалган һәр әйберде ул дусларының кул җылысын, якынлык һәм үзенә карата чиксез хөрмәт тойды. Һәм бу тойгылар Тимер күңеленә кереп кунаклый башлаган сагышны-моңны себереп түктеләр. Әшен бетергәч ул тукталып палатага тагын бер кат күз йөртеп чыкты. Урындыклар, лампа, өстәлдәге кәгазьләр, каләм, бетергеч, сызым кирәк-яраклары, көзге — бөтенесе дә ике ай буена гадәтләнгән үз урыннарына урнашып беткән иде.

«Менә шулай, — диде Тимер палатадагы әйберләргә, — дөньяда һәр нәрсәнең үз тәртибе булырга тиеш һәм һәр әйбер үз урынын белеп торганда гына әйбәт була... Шулай да кәгазьләр папкасына тумбочка өстенә барып яткан өчен ачуланмыйм мин. Адәм рәтле сызым ясалган кәгазьгә аңа больница тумбочкасы өстендә генә түгел, ә Архитекторлар союзы председателе өстәле өстендә ятарга да килешә. Һәм Министрлар Советы Председателе өстәле өстендә дә. Бик беләсең килсә, Мәскәүдәге вәкаләтле өстәлләргә дә барып ята ала ул. Шуңа күрә мин кәгазьләрнең өстәлдән тумбочкага күчүләренә ачуланмыйм да. Күчсен, хәрәкәттә булсын ул архитектор кәгазе. Хәрәкәттә булган архитектор кәгазендә өмет бар. Шәп әйбер ул хәрәкәттәге архитектор кәгазе. Молодец».

Палатадагы әйберләргә үзенең кәгазьләре турында тагын әллә нинди кызыклы нәрсәләр сөйли алган булыр иде әле Тимер. Ләкин, беренчедән, алар аны барыбер аңламаячак, икенчедән, ул бу палатада киләчәк турында уйлый алмый. Ә үзенең кәгазьләренең киләчәге, алай гына да түгел, матур киләчәге булуына нык ышана иде ул.

## 6

«Менә хәзер яңадан авыл турында уйларга да була, — диде Тимер караватына җайлап сузылып яткач. — Дөрес, мин авыл турындагы уйларны дуслар килгәнче уйлап бетерергә тиеш идем, ләкин өлгерә алмый калдым бит. Ә миңа һәрбер эшне үз вакытында эшләп бетерергә кирәк. Хәтта больницада да. Һәрхәлдә, үзеңне гомер буе шуңа күнектерергә кирәк. Шунсыз адәм рәтле архитектор булып булмый. Һәр вакыт, һәркайда, теләсә нинди ситуациядә һәм теләсә нинди халәттә дә эшне үз вакытында эшләп бетерергә өйрәнергә кирәк. Иҗат кешесе өчен бу закон булырга тиеш. Дөньядагы бернинди вакыйга да синең иҗат планнарыңны боза алмасын! Беренче чиратта иҗат! Калганнары — соңыннан. Гаилә, хатын, ашау-эчү, йокы, ял, хәтта котылгысыз үлем турында кайгырту да соңыннан. Иҗат кешесе хәтта иртәгә үләсен белсә дә, бүген иҗат итә торырга тиеш. Иртәгә күз күрер. Үлеп була ул, ә менә иҗат итүне чигерергә ярамый. Чөнки бары тик иҗат кына дөнья вакыйгаларына тәэсир итә ала. Чын иҗат, олы иҗат, кешелекле иҗат һәр вакыт дөнья вакыйгаларына тәэсир ясаган. Һәм киләчәктә дә ясар. Иҗат ул кешелек дөньясы ирешкән иң бөек казанышларның берсе».

«Юк белән баш ватма, — диде аннары Тимер үз-үзенә, — болар бит инде әллә кайчан билгеле хакыйкатьләр. Кемне шаккатырмакчы буласың син бу шомарып беткән хрестоматик фәлсәфәң белән?! Син бит авыл турында уйларга тиеш идең. Һәм шул турыда гына уйла да. Синең бу тапталып беткән фәлсәфәңә караганда авылның көнбатыш ягындагы урманлы калкулык мең мәртәбә кызыграк. Һәм матуррак, җанлырак, яңарак. Ул турыда уйлау хәзер синең иң акыллы эшең булачак. Чөнки дусларың килер алдыннан син нәкъ әнә шунда, авылның көнбатыш ягындагы урманлы калкулыкта тукталып калган идең».

Әйе, авылның көнбатыш ягында ямь-яшел урманлы калкулык сузылып киткән иде. Калкулыкның итәге авылга терәлеп үк тора һәм ул сөзәк кенә булып көнбатышка таба менеп китә. Ләкин урман авыл янының үк башланмый әле, авыл белән урман арасында ярты чакрым чамасы сөрү җире бар. Ә шуның теге ягы — урман, урман, урман. Ике, өч, дүрт чакрым урман. Тимерләр авылы яныннан башланган калкулык нәкъ урман уртасында үзенең иң биек ноктасына күтәрелеп җитә дә, кырт кына итеп Бигәдер авылына таба төшеп китә. Монысы инде урманның теге ягы. «Монысы инде миңа кагылмый, монысы турында Бигәдер авылы кешеләре уйласын», — диде Тимер үз-үзенә. Ләкин ул моны

күңелендә күтәрелеп килүче куе бер дулкын, бармак очларына кадәр көйдереп алучы бер хисне тыю өчен генә әйтте. Аһ, ул хисне шулай гына тыеп булса икән! Бу инде сиңа кызыл чикерткәләр һәм сөтле бакалар турындагы уй гына түгел. Чөнки моннан егерме ел элек шул Бигәдердә җидееллык мәктәпне тәмамлаган бер кыз урта мәктәптә укырга Тимерләр авылына килгән иде. Чөнки ул чакта унъеллык мәктәп күрше-тирә авылларда юк, бары тик Тимерләр авылында гына бар иде. Әйе, моннан егерме ел элек шулай иде шул. Хәзер ул кыз Тимерләр авылына килеп тә тормас иде, чөнки хәзер Бигәдернең үзендә дә унъеллык мәктәп бар. Хәзер ул кыз унъеллыкны үз авылларында гына тәмамлар иде һәм Тимер аның дөньяда бармы, юкмы икәнен белми дә калыр иде. Һәм шулай әйбәтрәк тә булыр иде. Бик шулай булган булыр иде дә соң, ул кызга да, Тимергә дә унъеллык мәктәптә моннан егерме ел элек укырга туры килде шул. Һәм аның шулай булуы Тимергә бик начар булды. Айкады, чайкады, талкыды, телем-телем телеп бетерде ул кыз Тимернең күңелен. Яралары хәзер дә төзәлеп бетми. Уйладың исә кан саркый башлый күңелдән. Һәртөрле больницаларыңны, таблеткаларыңны бар дип тә белми ул яра. Һәм Тимер бу больницага күңелдән саркыган канны туктатырга дип түгел, ә үпкәдән килгән канны туктатырга дип килде. Чөнки егерме ел буе төзәлә алмыйча азапланган ул яраның Тимер өчен гаять тә әһәмиятле тагын бер ягы бар иде. Күңелендәге шул яра, мәхәббәт ярасы, Тимерне кеше булырга, кешеләрне, урманкырларны, табигатьне, ниһаять, архитектураны яратырга өйрәтте. Һәм Тимер холкын, намусын, гадәтләрен шул яра белән тәрбияләде, чистартты, тазартты. Әгәр дә бүген ул нинди дә бандит бер малай, хулиган, эчкече яки тупас бер кеше түгел икән, үзендә булырга мөмкин булган бу әшәкелекләрдән аны әнә шул канлы яра, олы мәхәббәт ярасы саклап калды. Һәрхәлдә, ул кешеләргә карата кылган һәр яхшылыгын әнә шул яра хакына, мәхәббәте хакына эшләде. Мәхәббәт аның һәр игелегенең башлангычы һәм төп этәргеч көче иде.

Шуңа күрә Тимер өчен саф мәхәббәт кеше күңелендәге олы хис кенә түгел, ә гаять көчле тәрбия коралы да иде. Мәхәббәтне тәрбия коралы итеп каравын ул үзенең зур бер ачышы итеп саный. Аның хәтта җәмгыять тормышында бу көчле тәрбия коралының кайчакта тиешенчә файдаланылмый ятуына эче поша иде. Һәрхәлдә, мәхәббәтне тәрбия өчен файдалану, Тимер уенча, дәүләт күләмендә алып барылырга һәм иң вәкаләтле трибуналарда яклау табарга тиеш. Мәхәббәт белән тәрбияләү кирәклеге хәтта хөкүмәт карарлары белән ныгытылырга, киләчәк кешесенең гармоник үсешендә иң әһәмиятле бер күрсәткеч дәрәҗәсенә күтәрелергә тиеш. Һәм, Тимернең нык ышануы буенча, яшьләр күңелендә саф мәхәббәт никадәр күбрәк булса, илдә җинаять, тупаслык, хулиганлык кебек әшәке нәрсәләр шул кадәр азрак булыр иде. Чөнки мәхәббәт хисе үзенең табигате белән андый әшәкелекләргә капма-каршы күренеш. Бер үк кешенең күңелендә мәхәббәт белән әшәкелек беркайчан да янәшә яши алмыйлар. Яки тегесе, яки бусы гына. Адәм баласының күңелен табигать шундый итеп яраткан ки — яки гүзәллек, яки әшәкелек. Ә егерме ел буе күңелендә сакланып торган олы мәхәббәт хисен Тимер үз җанында булырга мөмкин булган иң гүзәл хис дип саный. Һәм ул, гомумән, мәхәббәт хисенең кешелек дөньясы ирешкән иң бөек казаныш икәнлегенә ышана иде.

Ләкин Тимернең әнә шул мәхәббәте бәхетле була алмады. «Ә монысы инде икенче мәсьәлә, — дип уйлады Тимер. — Һәр мәхәббәт өйләнешү белән тәмамлана торган булса, бәлки ул бу кадәр үк кадерле дә булмас иде. Һәм мәхәббәт хисе тәмле аш, яхшы кино яки рәхәт бер пикник кебек гап-гади күңелле бер нәрсә булып калыр иде. Юк, юк, һәр мәхәббәт һичшиксез өйләнешү белән тәмамланырга тиеш дигән карашны дөнья, яшәеш һәм тормыш турында берьяклы, җиңелчә һәм өстән-

естән генә фикер йөртүчеләр уйлап чыгарган. Саф мәхәббәт ул бәхетсез дә булырга мөмкин. Ләкин моңа карап аның гүзәллеге, күңелне сафландыру куәте кимеми. Ул һаман бөек, ул һаман матур, ул һаман игелекле».

Әйе, Тимернең мәхәббәте бәхет белән очланмады. Әлбәттә, моңа Тимер үзе гаепле түгел иде. Һәм алар авылындагы унъеллык мәктәпкә укырга дип килгән кыз да гаепле түгел. Юк, Тимер ул кызны гаепләми, аллам сакласын. Чөнки бит ул кыз да Тимерне ярата иде. Һәм ул үзенең тормышын Тимердән башка һич кенә дә күз алдына китерә алмый иде. Кыз моны Тимергә үзе әйтте. Сезнең авылга укырга килмәгән якшәмбе көннәрне үткәрә алмыйча интегәм, диде. Сезнең авыл миңа үзебезнең авылдан да якынрак, диде. Һәм һәр вакыт, Тимер, Тимер, без беркайчан да бергә була алмаячакбыз, дия иде. Чөнки, дия иде ул, бер-берсен артык нык яратышкан кешеләр беркайчан да бергә була алмыйлар, андый мәхәббәтләр бәхетсез була диләр безнең авылда, дия иде. Ә без артык нык яратышабыз. Син дә артык нык яратасың, мин дә. Безнең мәхәббәтебез бәхетсез булачак, ләкин мин синнән башка яши алмыйм.

Шулай диде дә ул шыпырт кына елап та алды. Ә Тимер еламады. Ул чакта әле ул алай тиз елый белми иде. Бернична елдан соң, мәхәббәтләре бәхетсез булачагына тәмам төшенгәч кенә елады Тимер. Һәм шундый тәмле, рәхәт, татлы итеп елады ки, ике көн буе күзеннән яшь кипмәде, йөрәге өздереп-өздереп унынчыда укып йөргән кызны сагынды. Һәм күңеленә ниндидер каты әйбер килеп бөялде. Тимер аптырап калды. Бу аның гомерендә беренче мәртәбә күңеленә каты нәрсә килеп бөялү иде. Ул чакта Тимер ул каты әйбернең нәрсә икәнен белми иде. Һәм хәзер дә белми. Ә менә соңгы айларда Тимернең күңеленә каты нәрсә килеп бөялү ешайды. Елаулар да ешайды. Һәм бу елаулар унынчыны тәмамларга килгән кыз өчен елаулар кебек татлы да түгел иде. Әнисенең үләргә ятуы менә өч ай инде Тимерне кыл өстендә тота. Кинәт кенә бер-бер хәл булыр да, дөньяның асты-өскә килер, күк йөзләре кара корымга әйләнер, аяк асты тотанаксыз көймә кебек чайкалыр һәм тирә-якта караңгы баз... баз булыр кебек иде Тимергә. Һәм ул хәл булачак та иде... Бу — котылгысыз.

Ә хәзергә әле Тимер үзен көчләп булса да бу турыда уйлаудан тыйды. Ул авылының көнбатышындагы урманлы калкулык һәм Бигәдер авылыннан унынчыны бетерергә дип килгән кыз турында уйларга тырышты.

Алар бер класста укыдылар. Яз һәм көз көннәрендә кыз авылыннан йөреп укый иде. Аңа көн саен ике мәртәбә әлеге урманлы калкулык аша үтәргә туры килә. Мәктәпкә килгәндә һәм мәктәптән кайтканда. Тимер аны көн саен иртән сәгать сигезенче яртыда теге як урман авызында каршы ала һәм дәресләр беткәч шунда озатып куя. Көн саен шулай. Алар бары тик якшәмбе көнне генә күрешмиләр һәм бу көн аларның иң яратмаган көне. Ләкин нишлисең, алар бер-берсен ярата дип беркем дә календарьны үзгәртергә ашыгып тормый иде.

«Анысы чорт с ним, — дип уйлады Тимер, — ләкин мин Аны беренче мәхәббәтем дип санамыйм. Чөнки «беренче» дигән сүз «икенче» дигән сүзне дә әйтергә урын калдыра. Ә мин мәхәббәтне беренче, икенче, өченче... бишенче... жиденче дип бүлә алмыйм. Минем өчен мәхәббәт я бар ул, я юк. Мәхәббәт — бердәнбер. Һәм бер кеше гомеренә бары тик бер генә мәхәббәт бирелә. Нәкъ гомернең үзе шикелле. Гомерне дә бит без «беренче гомер, икенче гомер...» дип әйтә алмыйбыз. Шулай булгач, мәхәббәт янына тагын «беренче» дигән сүзне дә китереп тагуның бер дә кирәге юк. «Мәхәббәт» дигән сүз «беренче» дигән сүздән башка да бик матур яңгырый...

Әйе, мин аны беренче мәхәббәтем дип саный алмыйм, «Мәхәббәтем» дип кенә әйтә алам. Һәм бетте-китте».

### 7

«Ә хатының?» — дип каршы төште шунда Тимергә бер яман уй.

«Провокатор! — дип атады Тимер ул уйны.— Шундый матур уй уйлаганда нигә мондый сорау бирәсең?»

Ләкин ул уй провокатор да, яман да түгел иде. Бик хаклы сорау бирде ул уй Тимергә. Һәм Тимер аңа туп-туры итеп җавап та бирергә тиеш иде. Чөнки хатынын ярата Тимер. Ул Тимернең дусты, иптәше, сердәше һәм рухы. Юк, Тимер инде аннан башка тора алмый иде. Һәм рухи яктан, һәм матди яктан. Ул пешергән аш Тимер өчен бөтен ашлардан да тәмле, ул юган кер хуш исле, ул бәйләгән оекбаш дөньядагы бөтен оекбашлардан да җылы, ул юган идәндә йөрү аяк табаннарына рәхәтлек бирә иде. Аның белән янәшә утырып караган юк кына фильм да шедевр булып тоела Тимергә, аның белән тыңлаган җыр — симфония булып. Командировка вакытларында ул аны сагына һәм аңа төрле бүләкләр алып кайта иде. Тимер аны җаны-тәне белән ярата. Ә тегене бит ул җаны белән генә яратты, моны — тәне белән дә.

Алар бер-берсен олылар кебек түгел, ә балаларча эчкерсез бер ярату белән яраталар. Җәйге айларда кызлары авылга әбисе янында торырга киткәч, алар бер-берсенә тагын да якынаялар. Кызларын сагыну хисен алар бер-берсенә бирәләр һәм алар арасындагы наз, игътибар, ир белән хатын арасында гына була торган сөйкемле итагатьлелек аеруча серле һәм нәфис төс ала иде. Йокларга ятар алдыннан кызлары өйдә чактагы оялу-яшеренүләр бетә, урын-җир җәюләр, чишенүләр һәрберсе наз белән тулы була. Тимер хатыны урын-җир җәеп йөргәндә аның йомшак, юка һәм нәфис эчке күлмәге чыгарган сизелер-сизелмәс кенә назлы җилне тоя һәм бу җил аның бөтен тәненә рәхәтлек бирә. Ул бу җилдә ерак бала чактагы апрель җилләренең монын, әле кичтән генә үзләре коенып менгән Идел дулкыннарының дәртләндергеч көчен тоя.

Кызлары авылда чакта алар йокларга ятканда өйдәге бөтен утларны сүндерәләр, бары тик Тимернең өстәл лампасын гына кабызып караватк кырыена идәнгә куялар иде.

Моны алар беренче мәртәбә моннан берничә ел элек эшләделәр.

— Бүген безгә яктылык гадәттәгечә өстән аска табан түгел, ә астан өскә табан төшсен, — диде Тимер, — миңа шулай ошый һәм бу кызыграк та. Табигать ни өчендер яктылыкны һәрвакыт өстән аска табан төшә торган итеп көйләгән. Кояш та шулай яктырта, ай да, урамнардагы утлар да. Һәм өйләрдәге лампалар да никтер түшәмгә эленгән. Ә мин бүген аның киресенчә булуын телим.

— Мин дә.

Алар икесе дә йомшак һәм киң юрган ябынып карават өстендә яталар, ә идәндәге өстәл лампасы өйне ничектер сәер һәм серле итеп яктырта. Бу яктылык өйдәге өстәл, урындык, китап шкафы һәм башка җиһазларның элек гел караңгыда булган өлешләренә төшә, һәм өйдәге җиһазлар да, тәрәзә пәрдәләре дә, түшәм дә, стеналардагы картиналар да бөтенләй бүтәнчә, үзгә булып күренәләр.

— Без бүген синең белән нинди дер сәер дөньяда яшибез. Миңа бу бик тә ошый, — диде Тимер.

— Минем бүген яшәрәсем килә,— диде хатыны, Тимернең кояшта янган тыгыз тәненә тагын да ныграк елышып.

— Ә безнең олыгайганыбыз да юк әле, — диде Тимер. — Безгә бүген икебезгә дә унсигезәр яшь...

— Һәм без әле өйләнешмәгәнбез дә...

— Һәм без мәңге өйләнешмичә шушы унсигез яшебездә калырбыз.

— Ләкин безгә өйләнешмәгән көе болай яту килешми, — диде Тимернең хатыны.— Һәм безнең инде ун яшьлек кызыбыз бар. Ул хәзер авылда.

— Без кызыбызга һәр вакыт ярдәм итеп торырбыз. Ул безнең белән бергә яшәр, унсигез, егерме яшькә җитәр һәм бердәнбер көнне без аны кияүгә бирербез. Ләкин без үзебез унсигез яшьтән китмәбез һәм беркайчан да өйләнешмәбез. Без мәңге бер-берсен өзелеп яраткан кыз белән егет булып калырбыз.

— Ләкин бит без инде күптән, моннан унбер ел элек загста булдык һәм безнең паспортларыбызда өйләнешү турында пичәт бар.

— Ул пичәт безгә унсигез яшьтә калырга һәм өйләнешмәскә комачауламый.

— Һәм безнең өйләнешмәвебездә беркемнең дә эше юк. Ләкин, минемчә, безгә өйләнешмәгән көенчә болай яту килешми. Бер юрган астында, эчке күлмәктән һәм идәндә өстәл лампасы яндырып.

— Килешә, бик тә килешә,— дип каршы төште Тимер,— без өйләнешмәгән булсак та, мин сине җаным-тәнем белән яратам.

— Безгә быел утызар яшь тулды, ләкин без синең белән унсигезәр яшьтә генә калырга сүз куештык.

— Әйе, без инде беркайчан да утыз яшькә җитмәячәкбез.

— Иллегә дә.

— Җитмешкә дә һәм туксанга да.

— Карале, — диде кинәт Тимернең хатыны нәрсәдәндер куркынып, — ә бит кайчандыр безнең икебезнең беребез үләргә тиеш булыр. Ягъни я син, я мин алданрак үләргә. Беренчедән, унсигез яшьтә үлеп китү бик кызганыч булачак, икенчедән, әгәр син алдан үлсәң, мин түзә алмаячакмын.

— Мин дә, — диде Тимер, — әгәр син алдан үлсәң, мин дә түзә алмаячакмын. Монда безгә нәрсәдер уйлап табарга кирәк. Безгә әлегә үләргә ярамый, кызны кеше итәсе бар.

— Юк, мин хәзер үлү турында әйтмим. Картайгач бит безнең кайсыбыз да булса беребез алдан үләргә тиеш булачак.

— Без картаймаячакбыз, — диде Тимер кырыс кына. — Без һәр вакыт унсигез яшьтә калачакбыз. Кызыбыз кырыкка җиткәндә дә.

— Анысы шулай. Ләкин үлем бер килер бит инде ул безгә. Дөньяда әле мәңгелек кешеләр юк. Хәтта мәңгелек агачлар да, ташлар да юк, сулар да мәңгелек түгел диләр бит әнә.

— Монысы икенче нәрсә, — диде Тимер уйланып, — әйе, кайчандыр безгә әҗәл киләчәк һәм ул баштан беребезгә генә килеп, исән калганыбызны бик зур хәсрәтләргә батырачак. Шуңа күрә безнең исән калуыбызга кыенрак булачак. Монда безгә ниндидер бер хәйлә уйлап табарга кирәк. Без бер-беребезне шундый нык итеп яратабыз ки, нужәли үлемгә каршы бер-бер хәйлә уйлап таба алмыйбыз? Минем синнән алдан үләсем килми, һәм син үлсәң, дөньяда яшисем дә килмәс.

— Беләсеңме, мин бер нәрсә уйлап таптым, — диде Тимернең хатыны ярым пышылдап һәм дәһшәтле итеп. — Әйдә бергә үләбез.

Тимер тетрәнеп китте.

— Хәзер үкме? — дип сорады ул куркынып.

— Юк, — диде хатыны көлеп, — хәзер әле безгә үләргә бер сәбәп тә юк. Киресенчә, безгә әле яшәргә дә яшәргә. Утыз, кырык, илле, алтмыш, җитмеш ел. Бәлки әле аннан да күбрәктер. Бәлки әле без йөзгә дә җитәрбез. Мин шул чакта үлү турында әйтәм.

— Нәрсә син, беребез үлгән көнне икенчебез үз-үзен үтерергә тиеш дип әйтәсеңме?

— Әйе,— диде Тимернең хатыны тагын дәһшәтле пышылдап,— лә-

кин бу эш кызыбызны тәмам кеше иткәч, үз оясын корып бетергәч, балалары булгач һәм алар бездән картлар дип туя башлагач кына эшләнергә тиеш.

— Үз-үзенне үтерү фәлсәфәсе әйбәт фәлсәфә түгел.

— Мин аптырагач кына әйткән идем инде, чын күңелдән ышанып һәм катгый карар кылып түгел.

— Ул турыда аптырагач та әйтергә ярамый. Үз-үзләрен үтерүчеләрнең күбесе шулай нәрсәгәдер аптырыйлар да, шул ситуациядән чыгарга юл таба алмыйча, үз-үзләрен үтерәләр. Ә чынлап карасаң, ситуациясе дә алай котылгысыз ук булмый. Кешеләр андыйны үзләренә үзләре уйлап чыгаралар. Ә без аны уйлап чыгарырга тиеш түгел.

— Һәм үлем турында уйламаска дамы?

— Әйе, уйламаска.

— Һәм сөйләмәскә дәме?

— Әйе, сөйләмәскә дә. Безгә үз-үзеңне үтерү фәлсәфәсен пропагандаларга һич тә ярамый. Чөнки ул гуманизмга каршы килә торган фәлсәфә. Ә без синең белән гуманистлар. Шуның өстенә без бер-беребезне яратабыз да.

— Һәм безгә әле нибары унсигезәр генә яшь!

— Һәм без бүгеннән соң үлем турында сөйләшмәскә тиешбез. Унсигез яшьлек кешеләр эше түгел ул.

Алар беразга тынып калдылар. Идәндәге өстәл лампасы ниндидер прожекторга охшап яна иде. Гадәти булмаган бу яктыртылышта Тимер бүлмәне ниндидер бер хыялый космик кораб салоны сыманрак итеп тойды. Ә үзе белән хатыны — шушы салондагы башка дөнья кешеләре. Алар бу кораб белән галәмдәге дөньяларга гомерлек сәяхәткә чыкканнар һәм менә Җир исемле гаҗәеп гүзәл бер бәләкәй планетачыкка кыска вакытлы ялга тукталганнар. Үзләре туып-үскән теге планетада аларга утызар яшь иде, ә менә Җиргә килеп җиткәч, аларга унсигезәр яшь тулды. Җир дигән планета аларга бик ошады һәм алар кыска вакытлы ялларын бераз гына озынайтырга булдылар. Бер җитмеш-сиксән елга гына. Һәм Тимер монда Җир кешеләре өчен әлегә беркемнең дә хыялында да булмаган матур-матур биналар төзергә дип архитектор булып китте.

— Бу Җир шары миңа шундый җайлы булып тоела, мин анда гомер буена калырга да риза, — диде Тимер. — Ләкин син дә минем белән калсаң гына. Син яңадан галәмгә очып китәргә теләсәң, мин дә монда калмаячакмын.

— Минем дә Җирдә генә яшисем килә, — диде Тимернең хатыны. — Минем сиңа җайлы җирдә яшисем килә. Җитмәсә, безнең кызыбыз да моннан ерак түгел, авылда гына. Аның да Фәкилә әбисен ташлап китәсе килмәс.

Аннары ул, бераз гына уйланып ятты да, Тимернең колагына гына:

— Ә син миңа ачуланмыйсыңмы, Тимер? — дип пышылдады.

— Бәй, мин сиңа ни өчен ачуланырга тиеш әле?

— Үз-үзеңне үтерү турында сүз кузгаткан өчен.

— Юк, ачуланмыйм, — диде Тимер, — син бит аны чын күңелдән ышанып һәм катгый карар кылып әйтмәдем диден.

— Әйе, мин аны ничектер уйлап бетермичә, сүз арасында гына ычкындырдым. Һәм бүтән чакта ул турыда беркайчан да сүз кузгатмам. Син мине гафу ит һәм ул турыда уйлама. Күңелеңне төшермә һәм һәр вакыттагыча шат бул. Синең шат күңелле булуың минем өчен иң зур бәхет. Хәтта мин шуның өчен генә яшим дә бугай әле. Һәм кызыбыз шат күңелле булсын өчен. Ләкин аны әллә никадәр сынаулар көтә, ана бит әле нибары ун яшь.

— Аның тормышы безнекеннән матуррак булачак.

— Ә ни өчен алай дип уйлыйсың?

— Чөнки ул Җир шарында яшәячәк.

— Әйе, ул да нәкъ безнең шикелле Җир шарында яшәячәк.

— Ярый ла, ул да безнең кебек матур гына парлаша алса.

— Һәм әйбәт кенә укып кеше булса. Хәер, анысы инде безнең үзебездән тора.

— Әйе, күпмедер дәрәҗәдә бездән дә тора.

— Ә ни өчен «күпмедер дәрәҗә» генә?

— Чөнки бездән башка әле мәктәп бар, дуслары, урам, радио, телевидение, китаплар.

— Һәм табигать.

— Әйе, табигать тә. Чөнки табигать тә кешене тәрбияли.

— Яхшы якка.

— Әйе, яхшы якка. Табигать кешене гел яхшы якка гына тәрбияли. Ә менә урам гел яхшы якка гына түгел. Кайчакта хәтта радио, телевидение, китаплар да яхшы якка гына тәрбияләмиләр.

— Ә архитектура?

— Архитектура кешене һәр вакыт яхшы якка гына тәрбияләргә тиеш.

— Ни өчен «тиеш» кенә?

— Чөнки архитектурада да ялгышлар булып тора. Тарихта эгоизмга, космополитизмга, милли гүзәллекне юк итүгә этәргән архитектура корылмалары да юк түгел, — диде Тимер. — Һәм аларның кайберләренең кайтавазлары белән бүген дә көрәшергә туры килә. Һәм без алар белән көрәшәбез. Ләкин безнең эштә иң әшәкесе — примитивизм. Примитивизмны кайбер эшем кешеләре җәмгыять тормышында, политикада һәм хәтта идеология көрәшендә гөнаһсыз бер күренеш дип саныйлар. Һәрхәлдә, талантлы уйланылган, ләкин әлеге эшем кешеләренең үз зәвыкларына туры килмәгән архитектура әсәрләреннән гөнаһсызрак дип саныйлар. Ләкин бу дөрес караш түгел. Примитивизм безнең җәмгыятьне надан, булдыксыз итеп күрсәтә. Миңа калса, примитивизм безнең бүгенге тормышта бик зур дошманыбыз ул. Ләкин әлеге эшем кешеләре моны аңламыйлар, алар әле һаман узган чорларда калган ниндидер букәйләр белән сугышалар һәм примитивизмны, талантсызлыкны, урта кул сәләтлелекне чын көрәш объекты итеп алмыйлар. Шуңа күрә безгә примитивизмга каршы көрәшү бик үк җиңел түгел.

— Сөйлә, сөйлә, — диде Тимернең хатыны йомшак кына, — ләкин миңа боларның барысын да аңлап бетерүе бик кыен. Дөрес, мин синең эшеңнең бик тә катлаулы икәнен тоям, әмма синең көрәшнең бөтен нечкәлекләренә төшенеп бетә алмыйм. Ләкин син моның өчен мине гафу итәсең, әйе бит? Чөнки мин хатын-кыз. Хатын-кыз ирләр уйлаган кебек үк уйлап бетерә алмый. Һәм алай ук көрәшә дә алмый. Без бит иң зур көрәшләрдә сезгә көч бирүчеләр генә. Ләкин бу да бик зур эш, чөнки ирләрнең бөтен уңышы хатын-кыздан тора.

— Хатын-кызның ярату дәрәҗәсеннән, — дип төзәтте Тимер. — Хатын-кыз ир-затны никадәр ныграк яратса, ирләр шул кадәр зуррак уңышларга ирешә алачаклар.

Алар икесе дә караватта чалкан яталар һәм идәндәге лампа яктысы ап-ак түшәмнән кайтарылып аларның битенә төшә иде. Түшәм аша төшкән яктылык аларның битен матур итеп яктырта һәм алар янәшә яткан сабый балаларга охшыйлар. Бер караганда алар әле хәтта игезәк балаларга да охшыйлар бугай. Ләкин монысы инде аларның берберсенә рухи якынлыкларыннан, бер-берсе турында уйлаган сөйкемле уйлардан гына иде.

Менә шулай чын дус һәм иптәш итеп ярата иде Тимер хатынын. Һәм мондый яратышуның бик күп гаиләләргә җитенкерәмәвен белә иде. Белә генә түгел, ә күрә дә иде. Хәтта ул архитекторлар арасында-

гы дусларының кайберләрендә дә мондый гаилә яратышуы булмавын күреп тора. Андый ир белән хатын бергәләшеп яшим өчен генә яшиләр. Ире дә яшим өчен генә яши, хатыны да яшим өчен генә. Ә минә Тимер алай түгел. Ул яратып яши. Яратып, ләкин... Ләкин бу аның өчен Мәхәббәт түгел иде. Мәхәббәт тегендә калды. Ә монда яратышу. Чын мәгънәсендәге, тирән һәм хөрмәт итеп, гомерлеккә яратышу. Ләкин Мәхәббәт түгел.

«Ә нигә соң син Аңа өйләнмәдең?» — дип сорау бирде тагын теге яман уй. Һәм бу юлы ул уй чыннан да яман иде.

«Нигә, нигә... — дип үчекләде аны Тимер, — моның хәзер минем өчен һич тә әһәмияте юк. Без Аның белән бергә була алмадык. Ләкин мин моны үкенеп әйтмим. Чөнки минем үз хатыным белән булган бүгенге тормышым беркемнекеннән дә ким түгел. Хәтта кайберәүләрнекеннән күркәмрәк тә әле. Ә Аның белән бергә була алмавыбызның сәбәбе пүчтәк кенә. Һәрбер аңлашылмаучылык пүчтәк булган шикелле, ул да пүчтәк. Минем ул турыда сөйләп торасым да килми, чөнки әһәмияте юк. Ләкин минем күңелемдә хәзер дә Мәхәббәт бар! Һәм ул — бөек. Безнең авылга укырга килгән ул кызны инде мин күптән оныттым. Ә Мәхәббәт калды. Ул миндә, минем эчемдә, йөрәгемдә, миемдә. Мин аның төнәтмәсе. Мәхәббәт төнәтмәсе. Минә миңа нәрсә әһәмиятле. Һәм мин шул Мәхәббәтне югалтмасам, дөньядагы бер генә кара көчкә дә бирешмәячәкмен. Ул минем җаным, тәнем, туган илем, Ватаным һәм гуманизмым. Ул минем туган илне сөюем, фидакарь хезмәтем, архитектурага биргән сәләтем, гражданлыгым, патриотизмым. Урынсыз сорау биргән өчен мин сине яман уй дип атыйм һәм дөрес атыйм. Чөнки миңа хәзер Аның турында уйлауның кирәге юк. Ул нибары күрше авыл кызы иде. Сипкелле, урта буйлы, куе чәчле чибәр кыз. Булмагае, миңа аның чибәрлеге дә, куе чәче дә, сипкеле дә кирәкми. Ул миндә Мәхәббәт кузгатып, соңыннан әнисе сүзенә каршы килә алмыйча, миннән йөз чөергән икән, моның өчен аны ачуланырга хакым юк. Һәм беркемнең дә хакы юк, чөнки яраткан анасының сүзен тыңлаган бала начар бала түгел инде ул. Менә бит мин үзем дә үлеп баручы әнием өчен әрнеп елыйм. Һәм берәр кеше мине шуның өчен гаепләсә, мин ул кешенең бугазын чәйнәп өзәр идем.

Ләкин бит ул кыз мине ташлаганнан дөньяда берни дә үзгәрмәгән. Кояш үз урынында, Ай үз урынында, йолдызлар да һәрберсе галәмдә үз юлларыннан белеп кенә йөриләр. Агачлар да нәкъ элеккечә язын яфрак яра, көзен яфрак коя. Ел саен шулай. Бер дә кышын яфрак ярырга тотынмыйлар. Дөньяда бары тик бер генә үзгәреш булды — ул да булса минем күңелемдә олы бер Мәхәббәт туды. Ә бу инде, әйтергә кирәк, минем күңел күгендә яңа бер йолдыз ачылу белән бер. Мәңге сүнми торган. Менә шул гына. Һәм мин моны бәләкәй нәрсә дип уйламыйм. Мин моны зур нәрсә дип әйтер идем. Һәрхәлдә, минем өчен бөек борылыш».

Тимер теге яман уйга шундый көчле отпор бирүенә куанып куйды. «Ләкин син бик кырлап-сырлап, китапча итеп уйлый башладың әле, — дип шелтәләп алды аннары Тимер үзен, — һәм уйлый башлаган уеңнан бик читкә киттең. Син бит нибары авылың турында гына уйлый башлаган идең!»

## 8

Тимерләрнең авылы керәшен авылы иде. Дөрес, хәзер инде аны башка татар авылларыннан аеруы кыен, шулай да әле анда борынгы болгарлардан һәм мәҗүси чорлардан калган байтак кына көнкүреш гореф-гадәтләре, төрле уеннар-бәйрәмнәр түкми-чәчми сакланып килә. Тимер керәшеннәрнең үзләренә генә хас үзгә бер моңы, үтә гади, ләкин гаять шигъри сүзләре булган җырларын аеруча ярата. Ул бәләкәйдән

үк өчәр көнгә сузыла торган, ниндидер бер тәртипле сценарийга буйсынган бик күп махсус җырлары, көйләре булган керәшен туйларын тыңлап үсте. Соңрак, Казанга килеп опера театрына йөри башлагач, ул бу туйларны экспромт белән куелган халык операларына охшата иде. Һәм ул моңа күпмедер хаклы да иде. Чөнки, беренчедән, керәшеннәр, башка татарлардан үзгә буларак, туйларда җырлаганда берничә тавыш кулланалар, икенчедән, кодалар, кодагыйлар, кияү егетләре һәм туйның бүтән башкаручылары бер-берсенә нәкъ операдагы кебек җыр әйтешәләр, җыр белән сөйләшәләр. Дөрес, беркайчан да радиодан да яңгырамаган, әллә нигә бер авылга килеп чыккан артистлар башкарында да ишетелмәгән бу җырлар бераз сәеррәк тә булып тоелалар иде Тимергә. Кызганычка каршы, керәшеннәрнең бу туйлар-җырлары, уен бәйрәмнәре, кызыклы гореф-гадәтләре берсе дә фәнни яктан тикшерелмәгән, Тимерләр авылына әле бер генә галим дә килеп карамаган иде шул. Ә менә соңгы елларда Тимер радиодан үзләренең авылларындагы җырларга охшаган җырларны ишеткәли башлады. Ләкин алар бик тә аз иде әле. Тимерләр авылындагы этнографик, музыкаль һәм фольклор әдәбият байлыклары белән чагыштырганда, бу дингездән бер тамчы гына.

Аннан соң Тимер туган авылындагы җор телле, шаян, мут керәшен картларын ярата иде. «Ычтуп дәдәй» дигәне аеруча якын иде аңа. Ике герман сугышында, гражданнар сугышы вакыйгаларында турыдан-туры катнашкан бу карт дөньяның ачысын-төчесен байтак татыган. Ул авылдашлары арасында яшь ягыннан да иң олысы иде. Ычтуп дәдәй керәшеннәр турында җыен тузга язмаган уйдырмалар, әкиятләр уйлап чыгарырга да бик оста иде. Шул ук вакытта ул җен карты шикелле үзсүзле һәм юк кына нәрсәдән дә үпкәләп, тузгып китә торган кеше иде.

Тимер инде институтны тәмамлаган елны ук нефть якларындагы бер яңа шәһәр өчен эшләгән кызыклы бина проекты белән исеме чыккан архитектор иде. Бу кыю уйланылган, төзү өчен бик үк кыйбатка төшмәгән бинаны бик тиз салып куйдылар. Аның турында республика газеталарында мактап яздылар, радиодан сөйләделәр. Ул чакта журналистлар Тимерне өметле, яшь татар архитекторы дип атады.

Бервакыт, авылга ялга кайткач, радиодан әлеге «татар архитекторы» дигән сүзне ишетеп калган Ычтуп дәдәй Тимергә бәйләнепмәбәйләнде. Бүген ул нишләптер Тимернең әдәби телдә сөйләшүенә кадәр гаепкә санады.

— Әй, син! Казанда җәшәп бөтеннәй бозылып беткәнсең, пычак малай. Үзебезчә сөйләшмисең, китапча сөйләшәсең, — дип тотынды ул.

— Нишләп китапча булсын, саф татарча сөйләшәм бит,— диде Тимер аптырап.

— Ә син керәшенчә сөйләш, атаң-анаң телендә,— дип кызды Ычтуп дәдәй. — Атаң-анаң сиңа керәшенчә итеп, Тимер дигән ат кушкан бит. Ә татарлар балага андый ат кушмыйлар. Алар балага җә «мулла», җә «дин», җә «җан» дигән сүзләрне кыстырып ат куялар. Муллаҗан, Бикмулла, Насертдин, Котбетдин дип. Тимер дигән исемне кушсалар да, барыбер артына җан дигәнен тагалар алар — Тимерҗан дип. Ә коры Тимер дигәнне генә кушмыйлар. Патамушты алар тимер дигәнне балта, чүкеч ише әйберләрдә генә була дип беләләр. Ә менә без, керәшеннәр, кешегә дә Тимер дип ат куябыз. Бала-чагаларыбыз тимердәй нык булсын өчен. Ә син Казанда җәшәп тимер түгел, ә камыр булып беткәнсең. Уңнан кыссаң сулга пылт итеп килеп чыгасың, җәнә килеп сулдан кыссаң — уңга.

— Ычтуп дәдәй, кызма әле, — диде Тимер картны тынычландырырга тырышып, — кайбер як татарлары балаларына, нәкъ безнең кебек итеп, Тимер дип тә исем кушалар...

— Мин кайбер җаклар турында сөйләмимен, — дип, Тимерне бүлеп алып китте Ычтуп дәдәй, — мин үзебезнең җаклар турында гына сөйлимен. Үз күзем белән күрмәгән, үз колагым белән ишетмәгән нәстәләр турында мин гүпче сөйләшмимен. Безнең җак татарлары балага андый ат кушмыйлар, бетте-китте. Җәп-җәш башың белән олы кеше сүзенә каршы килеп утырмасаң да җарый. Ычтуп дәдәң белмичә сөйләшмимен.

— Монысы ярар. Тик татар белән керәшеннең икесе бер бит инде хәзер, Ычтуп дәдәй, — дип аңлатырга тырышты Тимер. Һәм ник аңлатырга тотынганына үкенә язды, чөнки тегесе дәррәү кубып кызып китте:

— Ничек инде икесе дә бер, как так икесе дә бер?! Табак белән тагарак икесе дә бермени казер сезнеңчә? Элгәре, керәшен бабаңнарда ул алай төгел эйе.

— Ычтуп дәдәй, керәшен бабайлар турында сөйлә әле?

— Сөйләмимен. Син татарга сатылган, ата-бабаңны саткан кеше.

Тимергә бу сөйләшү хәтта кызык булып китте. Ычтуп дәдәйнең бердә юкка шушылай чын күңелдән кызып-үпкәләп утыруы кызык иде Тимергә. «Молодец карт, — дип уйлады ул. — Надан булса да, дөньяга үз карашы бар. Ә бит хәзерге кайбер бик укымышлы кешеләрне дә дөньяга үз карашлары булмау харап итә. Укымышлы булып дөньяга үз карашың булмауга караганда, надан булып дөньяга үз карашың булу яхшырак. Бәлки әле бу үзенә күрә бер бәхеттер дә».

— Юк, мин сатылган да, саткан да кеше түгел,— дип, бу кызыклы һәм эчкерсез әңгәмәне дәвам итте Тимер, — менә бит һәр вакыт сезнең янга, авылга кайтып торам.

— Авылга сатылган кеше дә кайта ала. Айрапылан теләсәң кая алып бара, акчаңны гына түлә. Җәле, әйт әле дөресен генә, сатылдыңмы?

Тимер аптырап китте. Ычтуп дәдәй бу сүзләрне шундый житди һәм катгый итеп күзгә туп-туры карап әйтте ки, Тимер чыннан да үзен ниндидер җинаятьче итеп тоя башлады.

— Нәрсә син, Ычтуп дәдәй, тыныч кына сөйләшик әле.

— Җук, баштан син татарга сатылмаган икәнеңә ышандыр мине. Җә? Җә?? Нәстә карап каттың, күрсәт, кистерденме?

Тимер берни дә аңламады. Туктале, нишли, ни таләп итә бу юләр карт.

— Нәрсә күрсәтим, нәрсә кистерим... — дип авызында ботка пешерде Тимер тәмам аптырап.

— Күрсәт! — дип кычкырды ачудан тәмам кызарынып-бүртенеп чыккан Ычтуп дәдәй, Тимернең чалбар каешына табан бармагы белән төртеп, — күрсәт, кистерденме?

Тимер шунда гына эшнең нәрсәдә икәнен аңлап алды һәм тыела алмыйча шаркылдап көлеп җибәрде. Кинәт бу кәмит аңа бик тә ошап китте. Гомумән, аңа һәртөрле гөнаһсыз юләрлек бик тә ошый иде һәм ул Ычтуп дәдәйне тынычландырырга булды.

— Монда, урам уртасында яхшы түгел бит, Ычтуп дәдәй, әйдә бүтән җиргә, — диде ул.

— Җарый, анда да җарый, — диде тәмам чыгырыннан чыккан Ычтуп дәдәй.

Бәдрәфтән чыкканда инде Ычтуп дәдәйнең авызы колагына житкән, йөзе ай-кояштай балкыган иде. Бу минутта ул Тимердән бик тәканәгать иде.

— Маладис, Тимер, ата-баба җоласына кер кундырмагансың, рәхмәт сиңа, — диде ул Тимернең җилкәсеннән сөеп.

Алар яңадан койма буендагы ташка килеп утырдылар.

— Җар-ра-ар,— дип сузды Ычтуп дәдәй бик тә кәефле итеп,— инде казер керәшен бабаңнар турында сөйләргә дә була. Керәшен бабаңнар алар бик затлы калык булган. Үзең дә беләсең инде, Тимер, адәм баласы бу дөнҗага маймылдан җаралган. Дөрес, элгәреге кенәгәләр кодай кешене тупрактан җараткан дип җазалар, тик казер инде без аңарга ышанмыйбыз. Элгәреге кенәгәләргә казер җәшләр түгел, безнең кеүек картлар да ышанмый инде. Тик шунысы бар, дөнҗада адәм балалары төрлечә бит — менәтерә кара тәнлесе бар, менәтерә сары тәнлесе ,ак тәнлесе. Үзбәге, урысы, нимесе, нигыры әм дә башка төрләләре. Тик кешеләр маймылдан үзгәргән чакта әммәсе дә бертөрле булганнар, аларның әммәсенең дә маймылы бер булган дей. Бөтен дөнҗа калкының маймылы бер нәселдән булган. Ә менә безнең керәшен бабайларның маймылы бүтән токымнан булган дей. Шуңарга күрә син татар да түгел, урыс та түгел, нигыр да түгел.

— Оhо! Син әйбәт кенә расист та икәнсең, Ычтуп дәдәй.

— Нәмәстәкәй дидең, улым? Ул расис дигәнең берәр пырафисырфәлән дигән сүздер инде.

— Юк, расизм ул, Ычтуп дәдәй... Ну, ничегрәк аңлатырга инде сиңа... Ни, расизм ул нацизм кебегрәк. Узган сугыштагы немец фашистларының нацизмы шикелле бер әйбер. Һәрхәлдә, расизм белән нацизм икесе бертуган.

Ул да булмады, Ычтуп дәдәй, урыныннан сикереп торды да, кипкән куллары белән Тимернең якасыннан эләктереп тә алды. Ачудан аның борын яфраклары агарып, иреннәре күгәреп киткән иде.

— Нәмәстә лыгырдап утырасың син, ысбулыч малай?!

Ычтуп дәдәйнең шыр сеңердән торган хәлсез куллары Тимернең якасын селки иде.

— Ычтуп дәдәң булып Ычтуп дәдәңне фашис белән чагыштырырга ничек ауызың чалышаймый?! Чалышаймаса чалышайтам бит, колак төбеңне чиләк төбе җасыйым, пычак малай. Мин германга каршы ике мәртәбә барган Ычтуп солдат булам, беләсең килсә. Ике герман сугышында да нимескә каршы сугыштым. Шулай булгач, мин нимескә ошый аламмы? Әйт, маңка, ошый аламмы мин нимескә?

Ычтуп дәдәй кызганнан-кызды, аның кулындагы, чигәләрендәге һәм муенындагы кабарып торган зәп-зәңгәр кан тамырлары сулык-сулык килеп сулкылдадылар.

— Туктале, Ычтуп дәдәй, мин бит сине немецка тиңләмәдем — диде Тимер картны тизрәк тынычландырырга тырышып. Ул инде үзе дә берничә сугышта катнашкан ветеран алдында чамасызрак сөйләп ташлавын сизде, һәм аңа хәзер һич кичекмәстән эшне төзәтергә кирәк иде.

Ләкин Тимер аны тиз генә төзәтә алмаячагын белми иде. Тәҗрибәсез иде шул әле Тимер ул чакта, ике герман сугышында катнашкан карт ветераннарны алай тиз генә ышандырып булмый икәнен белми иде.

Һәм ышандыра алмады да. Ул Ычтуп дәдәйне тынычландырырга дип ничә мәртәбә ымсынып карады, ләкин тегесе Тимергә авыз ачарга да ирек бирмәде, һаман сүкте дә сүкте. Ул Тимерне укый-укый надан-лана баручы дип атады. Тимерне укыткан Казан профессорларын, галимнәрен, укытучыларын эттән алып эткә салды. Ничәмә ел укытып Тимергә Ычтуп солдатның нимес белән әпсәлүтне уртаклыгы юклыгын да аңлатмаганнар бит дип зарланды. Әлбәттә, таякның юан башы Тимергә төште. Бик әшәке итеп сүкте Ычтуп дәдәй Тимерне. Аның анасын, атасын, әбисен, бабасын, энеләре-сеңелләрен, туган-тумачаларын, хәтта домовой кенәгәсенә кадәр туздырып ташлады. Ниһаять, Тимердән бер генә сүз дә әйттермичә, тузанлы юлга лач итеп бер төкерде дә, авыз эченнән сүгенә-сүгенә өенә кайтып китте.

Картның бу кыланышыннан Тимер кинәт югалып калды һәм үзен дивана сыман бер хәлдә сизде. «Картны бик нык үпкәләттем, — дип уйлады ул әрнеп, — хәтта мин аны чыгырыннан ук чыгардым бугай. Һәм аны да, үземне дә ахмак бер хәлдә калдырдым».

«Ул бит үзен фашистлар белән чагыштырдым дип аңлады, — диде аннары Тимер. — Мин алай теләмәдем, ләкин Ычтуп дәдәй шулай аңлады. Аның керәшеннәр чыгышы турындагы тузга язмаган фәлсәфәсе чыннан да расистлар фәлсәфәсенә тәңгәл килә. Расистлар да бит шулай фәнгә бер катнашы да булмаган уйдырмалар белән үзләрен өстен раса, өстен милләт итеп танытмакчылар. Ләкин надан Ычтуп карт боларны аңлыймыни?! Ә менә мин, каты баш, аны фашистлар белән чагыштырдым. Ычтуп дәдәйне, фашизмга каршы сугышкан ветеранны! Бөтен ил белән бер тән, бер җан булып, фашизмны җиңү өчен күпме кан кой, газап чик, аңа каршы сугыш-сугыш та, берничә елдан сине шул ук фашист белән тиңләсеннәр. Һәм кемнәр диген?! Синең балаларыңның балалары, тамагы туйган, өсте бөтенләнгән, иң алдынгы белемнәргә тиенгән маңка малайлар! Әйе, монда ачулану гына түгел, хан заманыннан бирле чөйдә эленеп торган ау мылтыгыңны алып чыгарга да күп сорамассың», — дип уйлады Тимер.

Икенче көнне иртән иртүк Ычтуп дәдәй Тимерләргә үзе килеп житте. Аның кыяфәтендә сабырлык һәм хәтта бераз гына оялчанлык та бар иде бугай.

— Йокы капчыгыңны тутырдыңмы, мать җакаңнан, — диде ул Тимергә үзенчә булдыра алган итәгать белән. — Кенәгенге өчен ачуланма, казер мин сиңа бер әйбер сөйләп җиппәрәм. Кая, утырырга урындык бир әле, агач матрус.

Тимер аңа урындык китереп куйды.

— Әй, син, кенәгенге өчен ачуланма, мин әз генә кызып киткәнмен, — диде Ычтуп дәдәй, — тик аңарга мин гаепле түгел, наданлык гаепле. Синнән суң өйгә кайткач бәләкәй оныктан расисның нәстә икәнен аңнаттырттырдым. Ул аны үзе дә белеп бетермәгән, библиатикадан инсыклапиде дигән әдәм шонныгы калын кенәгә алып кайтты. Анда дөнҗадагы бөтен нәмәстә жазылган икән. Җакшысы да, страмы да. Менә шуннан укып белдек без ул расислар турында. Әдәм түгелләр икән. Сбулычлар, аналарын шулай-болай итеп бетерим. Син дөрес әйткәнсең, алар без сугышкан нимесләр белән бер икән. Инде бит без кырык бишенче җылда ук аларның дөнҗада эзләрен калдырмадык дип уйлаганыек, мона казер бу расис дигәннәре килеп чыккан икән. Этне аны үлде дигәч тә жарты көн кыйнарга кушадырые безнең әтей. Кырык бишенче җылда кыйнап бетерә алмаганбыз микәнней суң, ә? Әттәгенәсе, кыйнап бетерәсе калган аларны шунда, расис дигән кечеөнчекләре тыумаслык итеп.

— Ансы инде аның икенче мәсьәлә, — диде Тимер, Ычтуп дәдәйнең үзенә карата яңадан яхшы мөгамәләгә кайтуына шатланып. — Кичә мин дә ялгышып күбрәк сөйләп ташладым бугай, гафу ит инде, Ычтуп дәдәй. Рәнҗеттем бугай.

— Нинди рәнҗү дей ул тагын, — дип ачулана төште Ычтуп дәдәй, — сез дә кайтып сөйләмәгәч, кем сөйләр безгә дөнҗа җаңалыкларын. Тик аңнатыбрак сөйләгез, ату сез үзегезчә итеп, укымышлылар телендә генә сөйлейсез дә, без пырастуй калык күп сүзләрне аңнамый да калабыз. Казанга кайткач әйт, тилибизыр да, ырадиу да без аңнамаган сүзләрне кушмыйча гына сөйләсеннәр. Гәҗитләргә дә әйт, алар да әрбер сүзне аңнатып җазсыннар. Колакларына киртләп әйт ыштубы. Ничу дәүләт акчасын җукка туздырырга. Тилибизырына да, ырадиусына да, гәҗитенә дә акчаны кызганмыйча бирәбез, рас шулай булгач, үзебез рәхәтләнеп тыңларлык та булсын пиридачлары. Шуларны

колагыңа киртлә. Ике герман сугышында катнашкан Ычтуп дәдәгез әйтте диең. Андый кешене белмейбез дисәләр, әнә маршал Чуйковтан сорагыз диең. Ул сезгә әйтеп бирер, диең, граждан сугышында Минзәлә өязенең Чүти тавы итәгендә батырлык күрсәткән красныәрмис Җәрмиев Ычтапан Җәгурович булыр ул дибәйтеп әйтер, диең. И вчу!

## 9

Дуслары килеп киткәнгә әле ике-өч сәгать тә үтмәде, ә Тимер инде әнә никадәр уй уйлап өлгерде. Моны инде, кем әйтмешли, бер олау уй уйладым дип кенә дә әйтеп бетереп булмый. Төяп карасаң бер олауга гына сыеп та бетмәс иде бу кадәресе. Хәер, бик нык бастырыклап төясәң, бәлки сыяр да иде. Ләкин Тимернең уйны бастырыклыйсы килми. Уйны бастырыклау ул, Тимер өчен, кешенең уйлау сәләтен кысрыклау, аны ничек тә булса тарайтырга, бәләкәйләтергә, ниндидер кысаларга кертергә тырышу белән бер иде. Хәлбуки, шунсы да бар, кешене уйлау ирегеннән тыю үзе үк шактый кыен нәрсә. Кешене теләсә нинди эш эшләүдән, теләсә нинди теләген тормышка ашырудан тыеп була, ә менә нәрсә турындадыр уйлаудан тыеп булмый.

«Кешене уйлаудан тыярга тырышу кирәкле һәм мактаулы эш түгел,— дип уйлады Тимер.— Ләкин мин үз мәнфәгатьләре күзлегеннән, яки бер төркем кешеләр мәнфәгате күзлегеннән генә чыгып уйланган эгоистик уйларны тыяр идем. Кызганычка каршы, мондый уйларны да тыеп булмый. Мондый уйлар да тулып ята әле әдәм затларының башларында. Хәтта үзебезнең арада да бар андый уйлы кешеләр. Менә боларын мин бик рәхәтләнеп тыяр идем. Көчемнән килсә, мин андый уйларга мәңгелек вето куяр идем. Һәм музейга да кертмичә, турыдан-туры тарих чүплегенә озатыр идем. Һәрбер чүп-чар әнәсеннән җебенә кадәр яндырылып барыла торган һәм бу эш шундый шәп итеп оештырылган чүплеккә! Мин әле хәтта шул чүплектә директор булып эшкә дә урнашыр идем. Һәм ул уйлар янганнан соң калган көлне әйбәт пакетларга төрер идем дә җиде кат җир астына күмдертер идем. Чөнки ул көлне ашлама итеп сөрү җиренә сипсәң, эгоизмның көлдә калган микроблары сап-сары икмәк рәвешенә кереп янадан тишелеп чыгуы мөмкин».

«Менә бит син нинди каршылыклы кеше, — диде аннары Тимер үзен шелтәләп. — Үзең әле генә кешене уйлаудан тыюны начар эш диден, хәзер инде уйга вето куярга маташасың. Һәм уйларны чүплеккә озатырга телисең. Һәм шул чүплекнең директоры булырга. Һай, этәч! Синең кадәр генә уйламаганнар ди анда дөньяның акыл ияләре. Әдәм уен тыеп була торган берәр чара булса, аны инде урта гасыр инквизиторлары уйлап тапкан булыр иде. Яки алардан алдагы инквизиторлар. Яки алардан соңгы инквизиторлар. Һәм бүгенге инквизиторлар. Акыллы баш. Үз акылың җитмәгән җиргә үрелгәнче әнә өстәлдә яткан мунча проектыңны сызып бетерсәң әйбәтрәк булыр иде. Рөсти әнә моның ише пүчтәк уйларны башына да кертеп карамый һәм менә дигән проект эшләгән. Ә син шул мунчаң белән инде ярты ел азапланасың. Хәсрәт мунчасы. Мунча проекты сызучы архитектор булып түгел, ә шул мунчада арка ышкучы булып эшләргә иде сиңа».

Шунда Тимернең хәтеренә, кылт итеп, Тукайның «Тәнгә мунча, җанга юк» дигән сүзләре килеп төште. Әйе, Тимер бу проектны шундый итеп эшләргә тиеш, ул тәнгә генә түгел, җанга да мунча булсын.

Монысы инде Тимернең күктән җиргә, хыялдан чынбарлыкка кайтуы иде. Һәм шулай итеп дөрес тә эшләде. Уй — уй белән, ә эш — эш белән. Һәм Тимер бары тик эш белән генә үз-үзенә тынгылык табачагын яхшы аңлый иде. Тынгылык табачагын һәм җыен юк-бар уйлардан котылачагын. Аңа хәзер бик күп уйлардан арынып торырга кирәк иде. Хәтта әнисе турындагы елата торган уйлардан да. Боларның ба-

рысыннан да эш, бары тик эш белән котылып була иде. Тимер моны бөтен барлыгы белән тойды һәм ниндидер бер күтәренке рух белән өстәлдәге сызымнарына чумды.

Булачак мунчасы турындагы татлы хисләрен тыеп, акрынлап, тәфсилләп, җентекләп эшләде Тимер. Аңа хәзер бу сызымнарны хыялый мунча итеп күз алдына китерергә ярамый иде. Аңа хәзер бу объектны тормышка ашыру өчен бөтен мөмкинлекләрдән дөрес файдалану кыйммәт иде. Ә объектны төзүнең мөмкинлекләре Тимернең хыялында булган мөмкинлекләрдән бик күпкә ким. Мәсәлән, әгәр Тимергә мунчаны ялан кыр уртасында төзеп куярга кушсалар, ул менә дигән хан сарае эшләр иде. Ләкин мунчаның ялан кыр уртасында төзелүе дә, хан сарае булуы да чуртыма да кирәк түгел. Мунча шәһәр уртасындагы дүрт яктан биналар, урамнар, трамвай юллары белән кысылган уч төбе кадәр буш урында төзелергә тиеш. Чөнки кешеләргә мунчага монда йөрү җайлырак булачак. Һәм ул хан сарае да булмаска тиеш. Чөнки кешеләргә нәкъ менә мунча — юына, парлана, коена торган гап-гади һәм бик тә җайлы мунча кирәк. «Мунча... мунча... мунча», — диде Тимер сызымнары өстеннән күз йөгертеп. Аннары: «Һәм тагын бер кат мунча!» — дип, ниндидер фикерләренә йомгак ясап куйды.

Эшен тәмләп эшләде Тимер. Хыялланмый дисәң дә хыялланды. Хан сарае ук булмаса да, шәһәрне ямьсезләп торырга тиеш түгелдер бит инде ул мунча дигәнең. Кем мунчасы дигәндә безнең мунча диярлек булсын. Һәм анда берьюлы бик күп кеше юынырга тиеш. «Халык үрчи, — диде Тимер, — һәм үрчегән берсенең адәм рәтле мунча керәсе килә. Шайтан алгырысы, миллион кешелек шәһәр мунчасы өчен урынны тар-рак бирә бит бу горисполком миңа. «Түшәгеңә карап аягыңны суз» дигән мәкаль дә бик үк ошап бетми миңа. Чөнки хәзерге адәм баласының инде түшәкне аякка карап тегәсе килә. Ләкин минем түшәк горисполком биргән караватка сыймаска маташа бит әле. Әһә, менә бу бассейн бүлмәсен менә болайрак итеп куйсаң, оригинально гына килеп чыга түгелме соң? Һәм юыну бүлмәләрен менә болай төзәрбез. Әлбәттә, Мәрдән абзый моңа каршы киләчәк. Дөньяның бер генә мунчасында да юыну бүлмәләре болай төзелгәне юк әле, диячәк. Һәм борынгы болгар мунчасында да, һәм хәзерге фин мунчасында да, диячәк. Ләкин ул нәкъ менә шуның белән ялгышачак та. Чөнки Низам аңа әйтәчәк: ни болгар мунчасына, ни фин мунчасына хилафлык юк монда, диячәк. Рөсти аңа: шул ук вакытта ни болгар мунчасында, ни фин мунчасында хәл итеп булмый торган проблема Тимер проектында гаҗәеп оста хәл ителгән, дип өстәячәк. Ә Миндуп, Мәрдән абзыйга карамыйча гына, бары тик миңа таба гына карап: надан киңәшне тыңлама, Тимер, үз акылың үзеңдә, үзеңчә эшлә, диячәк. Һәм алар дөрес әйтәчәкләр. Чөнки алар, беренчедән, болгар һәм фин мунчалары тарихын Мәрдән абзыйга караганда биш мәртәбә артык беләләр, икенчедән, архитектура фәненә иҗади якын киләләр»...

Әнә шулай дип уйлады Тимер проектын эшли-эшли. Аннары сызымнарын өстәлдә калдырып, тәрәзә янына килде. Урамга карады. Тәрәзә каршында зур-зур чыршылар, нарат-лар һәм каеннар үсеп утыра иде. Һәм тәрәзә өстендәге түбәдән быелгы беренче тамчылар тама. Ишегалдында авырулардан калган бик күп азык-төлекне ашап көн күрүче бер өер эт йөри.

«Юк, беркайчан да үзеңнән акыллы булырга тырышырга ярамый, — дип уйлады Тимер. Акыл мәсьәләсе ул гомумән кызык нәрсә. — Мәсәлән, шартлы рәвештә, нормаль кешедә уртача 65 микъдар акыл бар дип алыйк. Дөрес, ул кайберәүләрдә 70—80 гә, хәтта 90 га җитәргә мөмкин, ә кайберәүләрдә 50 дән дә артмавы бар. Ләкин эш анда түгел, сүз бит үзеңнән дә акыллы булу-булмау турында бара. Әйе, мәсәлән, миндә 65 микъдар акыл бар, ди. Табигать акыл өләшкәндә миңа шулай

эләккән. Бәлки бераз күбрәк тәдер. Хәер, кайчакта бераз азрак та була бугай әле ул миндә. Ләкин мин монда уртача 65 дип алам. Көннәрдән бер көнне мин үземне 80 микъдар акылга ия булган кеше дип саный башладым, ди. Икенче төрле әйткәндә, үземне үземнән дә акыллы дип хис итәм, һәм шуңа башка кешеләрне дә ышандырырга тырышам, ди. Ләкин бит минем хезмәттәшләрем, танышларым, дусларым, күршеләрем, хатыным миндә тулар-тулмас 65 микъдар акыл бар икәнен күптән беләләр. Һәм минем үземнән дә акыллы булырга тырышып йөрүем шул кадәр кызганыч, мескен тәс ала ки, кешеләр минем алдымда да, артымда да, уңымда да, сулымда да, миңа бармак белән төртеп тә, төртмичә дә көләчәкләр. Минем әле бу кадәр кеше көлкесе булудан да хәтәррәк нәрсәне күргәнем юк. Ә бит байтак кешеләр нәкъ менә шушының белән, ягъни үзләрен үзләреннән дә акыллырак дип уйлап ялгышалар. Мәрдән абзый да шулай ялгыша. Һәм әнә җыелышта да адәм мәсхәрәсенә калган.

Димәк, нәтиҗә шул — беркайчан да үзеңнән акыллы булып булмый икән. Хәтта теләсәң дә. Шулай булгач, дөньяда яхшы кеше булып яшим дисең икән, үз акылың җиткән эшне генә башкар. Һәм шәп итеп, җиренә җиткереп башкар, кешеләр сокланырлык булсын. Ә үз акылың җитмәгән эшкә тотыну бер яктан тыйнаксызлык булса, икенче яктан син эшкә бер тиенлек тә файда китермәячәксең, киресенчә, эшне бозып ташлавың бар. Ә бу инде зыян дигән сүз. Үзеңә дә, хатыныңа да, дусларыңа да, җәмгыятькә дә. Ә җәмгыятькә зыянга эшләгән эшнең кирәге юк. Үзеңнән дә акыллы булырга тырышмаска! Менә иң шәп лозунг! Һәм мин гомер буе шул лозунгка турылыклы булачакмын».

«Ләкин мәсьәләнең икенче ягы да бар,— дип дәвам итте Тимер,— бик тырышканда акылны микъдари яктан арттыра барырга да була бит. Акыл ул шәкерт кебек — аңа даими рәвештә яңа белемнәр өстәп торырга кирәк. Һәм ул спортсмен кебек тә — һәр вакыт акыл күнегүләре ясап тормасаң — зәгыйфьләнә башлый»...

Һәм Тимер сүзне озайтмый гына яңадан сызымнарына тотынды.

## 10

Әйе, уй — уй белән, ә эш — эш белән. Бу сүзне кешеләр юк-бар уйның файдалы эш эшләргә комачауламаска тиешлеген аңлату өчен уйлап чыгарганнар. Ләкин адәм баласы гел эш белән генә дә яшәми шул. Әлегә фәнгә билгеле булган бөтен җан ияләреннән үзгә буларак, адәм баласы уй уйлый. Эш — эш белән, ә уй — уй белән!

«Һе, сүзләрне алмаштырып кына куйдым, ә бөтенләй яңа мәгънә килеп чыкты», — дип уйлады Тимер. Ул инде бүгенге эшен тәмамлаган, сызымнарын өстәлнең уң почмагына пөхтәләп җыеп куйган, больница ашханәсенә барып кичке ашны ашап килгән, эчәсе даруларын эчкән, радиодан Казанның кичке концертын тыңлаган һәм йокларга ятарга тиеш иде. Димәк, эш эшләнеп беткән, ә уй калган. «Менә сиңа әкәмәт, — диде ул үз-үзенә,— торам-торам да, уй белән икәүдән-икәү генә калам. Ичмасам, бу үпкә дигәне бераз авыртып җәфаласын иде. Юк, аз гына да авыртып карамый. Ни тын бетми, ни авыртмый. Ә үзеннән һаман кан килә. Ккым дип бер ютәлләдең исә, төкерек белән кан килә. Ләкин минем аның турында уйлыйсым килми. Врач әйтте, туктатабыз, диде. Миңа шул җиткән. Ә мин врачларга ышанам. Чөнки ышанмасам да, берни дә эшли алмыйм. Үзем туктата алмыйм ич инде мин ул канны. Ләкин минем ул турыда уйлыйсым килми. Беренчедән, ул мәгънәсез уй, икенчедән, авыртмаган көенчә нигә уйлап торыйм әле мин ул үпкә турында?! Һәм гомумән үз әгъзаларың турында гына уйлап тору яхшы эш түгел. Андый кешеләр күбесенчә эгоист булалар. Ә минем һич кенә дә эгоист буласым килми. Җенем сөйми шул сүзне.

Әйе, минем үпкә авыртмый, ә менә әнинең ашказаны авырта. Бик нык авырта аның ашказаны. Профессор әйтте, үләр алдыннан түзеп булмаслык авыртачак, диде. Үләр алдыннан... Ә бәлки инде болай дию хәзер соң дадыр. Бәлки инде бу минутта ул... Юк, юк, бу мөмкин түгел. Мин бит туганнарга язган хатта, ул-бу булу белән телеграмма сугыгыз, дип аерып әйттем. Дөрес, инде профессор әйткән срок үтеп бара. Һәм озак та үтмәс, миңа ул телеграмма килеп җитәр. Ә мин кумәргә дә кайта алмам. Врач әйтте, бөтен дәвалаганны юкка чыгарачаксың, диде. Һәм юлда кан төкерек белән генә түгел, ә авыздан-борыннан гөрләп китәргә мөмкин, диде. Андый чакта оешкан кан тын юлларын каплый һәм кеше кинәт томаланып үләргә мөмкин икән. Бөтен туганнар да, больницадан чыга күрмә, кайтма, инде эшлисен эшләдең, дәвалан, синең кайтуың безгә кайгы өстенә кайгы гына булырга мөмкин дип язалар. Һәм әни дә, бәхиллим, ерактан гына бәхиллим, больницадан чыга күрмәсен, киресенчә, кайтырга уйласа бәхиллегем юк, ди икән. Болай бер җирем дә авыртмый да бит. Бәлки кайтып килсәм дә берни дә булмас иде. Дөрес, мин аннан бик нык ябыгып киләчәкмен. Ә кинәт ябыгу — үпкә авыруның иң якын дусты. Сөяркәсе. Кинәт ябыгып киткән кешеләргә чат ябышып ята да инде ул. Анысы ябыгуына гына түзәр дә идем. Ә менә авыз-борыннан гөрләп кан китсә? Үләсе килми бит. Юк, бер дә үләсе килми.

Ә әни? Аның үләсе киләмени?

Ләкин бу дөрес үк сорау түгел бугай. Әни чарасыз. Әнине алып кала торган бер генә әмәл дә юк. Ә минем бер мөмкинлегем бар. Ул да булса — алты ай буена больницадан чыкмыйча дәвалану. Мин шушы бердәнбер мөмкинлекне файдаланам инде, әни, бәхиллегеңне бир. Мин кайта алмыйм инде, әни, калам. Еракта, хәтта Казаннан да читтә, урман эчендәге бер больницада дөм ятим калам. Син миннән башка гына китәрсең инде, кадерле әнкәем. Дөрес, әле син үлмәгән көе бу турыда авыз ачып әйтү килешми, шуңа күрә мин бу турыда кычкырып әйтмим, ә урман эчендәге больницаның бер кешелек аулак палатасында ялгызым уйланам гына. Минем бу уйларымны беркем дә ишетми, беркем дә белми. Ә син ишет, әнием, ишет һәм бәхиллегеңне бир. Мин бит сине өзелеп яраттым, яратам һәм яратачакмын. Син дә мине һәм башка балаларыңны шулай яраттың. Ә безнең бу аерылышуыбыз табигатьнең бер ялгышы гынадыр. Мин синең рухыңнан мәңге аерылмам, әни. Синең игелекле, түзем, сабыр һәм кешелекле рухыңны гомер буена саклармын. Үзем үлгәндә аны кызым алып калыр. Кызым үлгәндә аның баласы. Һәм шулай итеп, синең рухың мәңгелеккә барыр, әни. Син больницадан чыккач, без синең Казанга алып килгән алмаш күлмәгеңне төсең итеп үзебезгә алып калдык. Сине сагынган саен мин ул күлмәкне алып карармын. Һәм һәр вакыт ул күлмәк эчендә сине күрермен. Ул күлмәктән безнең авыл тирәсендәге кыр-болыннар, урман-таулар исе киләр. Яз көннәрендә ул күлмәкне җилләтергә ишегалдына чыгарып элгәч, безнең болын исләре бөтен Казанга таралыр. Мин ул күлмәк белән нәкъ синең белән сөйләшкән кебек сөйләшермен, итәгенә күз яшьләремне сөртермен. Ул күлмәк беркайчан да картаймас һәм искермәс, әнкәй. Кан төкермәс һәм рактан үлмәс. Ул һәр вакыт моңлы һәм киң күңелле булыр. Нәкъ синең шикелле.

## ИКЕНЧЕ БҮЛЕК

## Үлем

### 11

Фәкилә апа әле операциядән соң өч ай яшәде. Февраль башлары җиткәндә инде ул тамагына ярма бөртеге кадәр дә азык каба алмый иде. Баштагы мәлләрдә ул соң чиккә җитеп ябыкты, аннан бөтен тәненә

сары иңә башлады. Берникадәр вакыттан соң аның тәне карасу-сары төскә керде. Бусы инде үлек төсе иде. Мәетләр һәр вакыт шулай карасу-сары төстә булалар. Яки саргылт-кара. Кеше тәнендәге кара һәм сары төсләр беркайчан да яхшыга алып бармый.

Ләкин Фәкилә апа әле мәет түгел иде. Ул әле яши. Чөнки аның кан тамырына глюкоза биреп торалар, ә авыртуларны басар өчен уколлар кадыйлар.

Ул үлгәнче телдән язмады. Шулай да аз сөйләште. Чөнки сөйләшәсе сүз инде сөйләшенеп беткән иде. Ләкин, аның уенча, яшисе гомер әле яшәлеп бетмәгән иде. Фәкилә апа яшисе гомере яшәлеп бетмәгән көенчә үләчәген аңлый иде. Тагын бер ун ел гомер яшисе бар иде әле аның бу җирдә. Менә бу көтелмәгән рак кына харап итте. Ә Фәкилә апаның эчендәге рак ул көннәрдә котырынып тантана итте. Ул үзеннән көчсез һәм ярдәмчесез бер корбан тапкан ниндидер ерткыч җанвар кебек комсызланып Фәкилә апаның бөтен әгъзаларына ташланды. Ашказаныннан үңәчкә, бавырга, эчәкләргә, бөерләргә, ниһаять, йөрәккә үрмәләде. Юлында нинди тере күзәнәк булса — барысын да үзенә йотты һәм һаман зурая, көчәя, ныгый барды. Фәкилә апаның үлеме белән үзе дә үләчәген белә иде микән ул рак? Ләкин рак киләчәк белән яши торган нәрсә түгел шул. Ул бүгенге көн белән генә яши торган җисем иде. Шуна күрә ул, юлында бер генә каршылык та очратмыйча, Фәкилә апаның бөтен тәне буйлап һөҗүмгә күчте. Чөнки Фәкилә апаның тәмам ябыгып, кибеп беткән организмы инде аңа каршы көрәшә алмый, ә дөнья галимнәре әле дүртенче стадия ракка каршы куярлык бер генә чара да уйлап таба алмаганнар иде. Рак тантана итте, рак Фәкилә апаны бернинди тукталышсыз үлемгә табан сөйрәде. Фәкилә апа үлемнең килгәнен көн саен, сәгать саен көтә иде. Ләкин ул нигәдер бик акрын килә. Фәкилә апа еш кына аңын югалтты, уйлау сәләтенең югалып-югалып китүен тойды. Кайчакта аның билгеле бер тәртип белән генә барган уйлары, кырын юлда салулап киткән чана кебек, әле бер, әле икенче якка бәргәләнделәр. Ә кайчакта уйлар бөтенләй чуаланып, чәбәләнеп каядыр еракка-еракка китеп югалалар, күз кабаклары үзеннән-үзе авыраеп йомылалар һәм каяндыр күңел төбеннән, күкрәк авызыннан Фәкилә апаның баш миенә ниндидер томанлы бер рәхәтлек күтәрелә башлый. Бу рәхәтлек баш миен миңгерәтә, бөтен тәнне изрәтә, һушсыз итә... һуш китә... һәм дөнья ничектер ерагая... ерагая... ерагая бара. Фәкилә апа баш миенең кайсыдыр бер иң ерак почмагында гына калган зәгыйфь уйлау сәләте белән моны үлемдер дип уйлый. Озакламый бу зәгыйфь уйлау сәләте дә бетә һәм Фәкилә апа бөтенләй юкка чыга...

Ләкин бу үлем түгел иде әле. Бераздан Фәкилә апа тагын күз кабакларын күтәрә, телен селкетә, сизелер-сизелмәс кенә итеп мышнап куя һәм аңа тагын үз аңы кайта. Мондый чакларда Фәкилә апаның кәефе төшә. Тәмам килеп җиткән үлемнең кире китүенә үпкәли ул. Озакламый аның уйлары яңадан тәртипкә килә һәм алар билгеле бер эз буйлап ага башлыйлар...

Әйе, чама белән бер ун ел яшәлеп бетмәгән гомере кала аның җирдә. Ул аны, әлбәттә, дүрт баласына бүлеп калдырыр. Һәрберсе үз гомерләренә тагын икешәр ел ярым өстәсеннәр.

Тагын нәрсә калдырам соң әле мин аларга? Менә бу өй кала. Туыпүскән, тәүге канат каккан һәм киң дөньяга чыгып очкан өйләре. Ләкин бу өй бит аларның берсенә дә кирәкми. Дүртесе дә читкә чыгып киттеләр дә, дүртесе дүрт төштә — шәһәр җирләрендә оя кордылар. Һәм дүртесенең дә бу өйгә караганда әллә никадәр әйбәт өйләре бар. Газы, суы, пары, бәдрәфе, мунчасы-ние белән бергә. Ишегаллары, урамнары асфальтлы, язын-көзен бот тиңентен пычрак ерып йөрисе түгел.

Дүртесе дә адәм рәтле булды балаларым. Барысы да казна эшендә намус белән эшлиләр, берсе дә ике мәртәбә кияүгә чыкмады, ике мәртә-

бә өйләнмәде. Әлегә кадәр азып-тузып йөрмәделәр, урлашмадылар, төрмәгә кермәделәр. Инде бу яшькә җиткәч, үзләре бала-чагалы булгач бозылмаслар. Балаларым рәтле кеше булып җитеште, ул яктан үлемемнең бер үкенече дә юк. Тик өй генә менә... Нигез бетә. Һәм моңа бер чара да юк. Шәһәрдәге өйләрегезне, казна эшегезне ташлап монда кайтыгыз, дип әйтү минем тарафтан дөрес булмас иде. Аларга анда ошый икән, шундагы эшләрен яраталар икән, шунда эшләсеннәр дә. Ә бу нигезнең безнең нәсел нигезе булуы минем белән бергә үләчәк. Миндә генә тотылып тора иде бит бу нигезнең безнең нәселнеке булуы. Мин үлгәннән соң бер атна да үтмәс, монда бүтән кешеләр яши башлар. Өй акчасын балалар дүртесенә бүләрләр дә, бетте-китте. Әй, гомерләр, гомерләр!

Ничәмә йөз еллар буе үрчеп килгән нәселнең нигезе бер атна дигәндә җимерелеп төшсен, имеш! Нәсел нигезен корытуның соңгы кешесе булу минем өлешкә язган икән. Монысы минем үлемемнең беренче үкенече.

Икенче үкенечем — әлегә яшәлеп бетмәгән ун ел гомер. Ун ел ук та түгел, хәтта ике-өч елы да җитәр иде. Һәрбер баламда яртышар ел гына яшәп, аларның матур тормышына куанасым килгән иде. Булмады. Юк, моңарчы чакырмадылар түгел алар үзләрендә яшәргә, чакырдылар, бик чакырдылар. Үзем ашыкмадым. Һаман соңрак, соңрак, картайгач барыгызда да яшәргә өлгерермен әле, дидем. Ә менә үлем картайганны көтеп тә тормады. Туп итеп килде дә җитте. Көтмәгәндә, уйламаганда. Әле бит моннан җиде ай элек кенә, узган сентябрьдә бакчада бәрәңге алып йөрдем. Үзем казыдым, үзем күтәреп ташыдым. Балаларның тыюына да карамадым, ашкынып эшләдем. Картаерга бер дә исәп юк иде әле ул чакта. Үлү турында искә-оска да кереп чыкмады. Ә менә җиде ай дигәндә көне-сәгате белән үлем көтеп ятучы хастага әйләндем.

Тагын нинди үкенечләрем кала соң әле бу дөньяда? Башкача юк та бугай инде. Нибары ике үкенеч. Узган гомеремдә булган авырлыклар, сугыш елларындагы газаплар, ил белән күргән кайгы-хәсрәтләр берсе дә үкенечле түгел. Ач та булдым, ялангач та булдым, эчем төшкәнче колхоз эшендә дә эшләдем, аталарының балаларга, өйгә игътибар бирергә вакыты булмавын да кичердем. Ләкин боларның берсен дә үкенечкә санамыйм. Күп авырлыкларны ил белән уртак күтәрдем, үз башыма гына төшкәннәренә тешне кысып түздем. Инде балаларыма мондый ук авырлыклар төшмәячәген белеп үләм. Сугыш-фәлән кебек афәт килеп чыкмаса, шушы урта тормышлары белән гомер кичерерләр балаларым. Бик үк бай да булмасыннар, безнең кебек үк кысрыкланып та яшәмәсеннәр. Ике кулларына бер эш булса, тамаклары тук, өсләре бөтен булса — шул җиткән.

## 12

Аталары белән без үзебез кешедән кимрәк, ярлырак яшәдек шул. Безгә шулай кирәк булгандыр инде. Яшьрәк чагыбызда аталары авылда беренче комсомол, актив булып, дөнья малына теше-тырнагы белән каршы булды. Күмәк тормыш, колхоз, совет өчен дип тырышты. Ә өйдә мал булдыруны җене сөймәде, үзем байларга каршы көрәшеп, үз өемдә байлык җыймам бит инде, дип кенә җибәрә иде.

Коммуна төзегәч әйбәт яшәрбез, диде. Бу эш белән артыграк мавыгып ташлады шул. Яшь иде, дәртле иде, тормышны яңача төзергә дип ашкынды, тик бу эштә белеме бөтенләй юк иде. Надан иде шул, хәрефне дә көчкә генә таный иде, көтүче малае иде.

Соңрак, сугыш алдыннан укытырга да тырышып карадылар, тик көчкә-көчкә хәреф таныган кешене ничек курсларга җибәрмәк кирәк?! Булмады. Аннары сугыш чыкты. Биш ел сугышта йөреп, коммунист булып

булып кайтты. Инде нимесне җиндек, тормышны корабыз, дип дәртләнеп эшкә тотынды. Ирләрнең күбесе сугыштан кайтмады, колхозны үз кулында тотарлык гайяр кеше юк иде, ни чарадан бичара дип, колхозга председатель итеп аны куйдылар. Әй гайрәтләнеп эшкә тотынды, тик тагын әлеге дә баягы надanлык юлга аркылы төште. Ул чакта инде ул дүрт бала атасы иде, уку турында уйларга да калмады. Председательлегә дә шул элеккедән килгән активлыгы, кешеләр белән әзме-күпме эшли белүендә генә эленеп тора иде. Берничә ел да үтмәде, укыган яшьләр үсеп житте һәм аның колхоз җитәкчелегенә керәге калмады.

Тик моны анларга теләмәде этиләре. Ул әле таза иде. Көче ташып тора иде, дәртле иде. Шулай да бөтен авылдашлар колхозның алга бармавын күреп тордылар. Күпме генә коммун дәртле булса да, эшне уптым-илаһи алга җибәрергә тырышып, зурдан кубып йөрсә дә, колхозны тернәкләндерә алмады этиләре... Юк, өй өчен дә тырышмады. Без кешедән әйбәт яшәргә тиеш түгел, хәтта алардан бераз ярлырак та яшәргә тиеш, диде ул. Беркемгә дә, председатель үзенә байлык җыя, дип авыз чайкарга ирек бирмәм, диде. Һәм көнен-төнен белмичә чапты да чапты. Ләкин инде безнең колхоз тормышы районлагыларның да эчен пошыра башлады һәм бер җыелышта аны председательлектән азат иттеләр.

Шул көннән башлап ул бәләкәй генә җитәкчелекне дә өстенә алмады. Ләкин колхозга эшкә йөрде, урман кисте, салам эскертләде, печән чапты. Унбиш ел буена шулай дәвам итте.

Ә көннәрдән бер көнне колхоз чөгендерен алып ятканда кырга хәбәр салдылар: «Фәкиләнең ире салам эскертләгәндә эче төшеп үлгән». Җирдән сөйрәп чыгарырга дип ике кулым белән кысып тоткан чөгендер яфракларыннан ике учыма кайнар кан бәргәндәй булды. Чирканып учларымны итәгемә сөрттем һәм басуга күтәрелеп карадым. Кинәт чөгендер басуы асты-өскә килеп чайкалып китте. Моны күреп мин кычкырып җибәрдем:

— Җирнең асты-өскә килде, чөгендер өемнәре ишелә-түгелә бит!

Шуннан соң өйдә генә аңыма килдем. Юк, мин тилермәгән идем, чөнки өйгә үз аягым белән кайтканмын. Өй тулы кеше, ишегалды тулы кеше, урам тулы кеше... Шулай итеп, суга төшкән балта кебек кырт кына юк булды авылның беренче комсомолы, ветеран. Бу яңа тормышта, аны башлаган давыллы, дәртле, ялгышлы, ләкин җиңүле елларда ул булмаган да кебек булды.

Ярар инде, нишлисең бит, хәзер алар барысы да артта калды. Менә озакламый мин үзем аның янына барам. Үзе белән янәшә куярга куштым. Бер чардуган эченә. Мин шунда аңа барысын да сөйләрмен. Һәм без мәңге бергә, мәңге янәшә булырбыз. Шулай итеп, безнең бу дөнья белән булган алыш-бирешебез тәмам булыр. Әнә миңа тагын укол ясыйлар. Бераздан мин исәнгерәрмен һәм тәмам изрәрмен... Ә бәлки әле шул изрәүдән уяна да алмам, бөтенләйгә үк китеп тә барырмын. Әгәр шулай булса, бәхил булыгыз, балалар, бәхил бул, өем, бәхил бул, тәрәзәдән төшкән яктылык, бәхил бул, борынымнан кергән татлы һава, бәхил бул, кан тамырымны ертып кергән укол энәсе — мин сезнең барыгызны да ярата идем. Һәм исәнме, ирем, исәнме, татлы туфрак, исәнме, мәңгелек онытылу.

## 13

Уколдан соң Фәкилә апа гадәттәгечә изрәп йоклап китте. Ләкин ул уянды әле. Чөнки аның йөрәге таза иде. Менә дигән йөрәк. Больницада яткан чакта да врачлар аның йөрәгенең тазалыгына шаккаталар иде. «Гринвич сәгатьләреннән дә төгәлрәк эшли синең йөрәгең», — дия торган иде врач аңа. «Әй, шушы йөрәгемне берәр балама биреп калдырыр-

га, — дип уйлады Фәкилә апа. — Нигә кирәк миңа анда бу кадәр таза йөрәк?!»

Ләкин Фәкилә апа ялгыша иде. Ул инде балаларына үзенең йөрәген биргән иде. Ничәмә-ничә еллар буена, авыр һәм җиңел, тырыш һәм сынаулы еллар буе телгәләп бирде ул йөрәген балаларына.

«Чыннан да, — дип уйлады аннары Фәкилә апа. — Мин бит бу дөньяда аларның үзләрен калдырам. Берсен дә корсак төшереп тончыктырмадым, күкрәк сөтемне кызганмадым, үз тамакларын үзләре туйдыра башлаганчы үстердем. Балаларым — минем бу дөньялыкта калдырган иң зур байлыгым».

Фәкилә апа сиртмәле караватындагы иске түшәге өстендә чалкан ята. Ул хәзер бары тик шулай гына ята ала. Ул хәзер яңа туган бала кебек: утырып тора алмый, мендәргә терәп утыртып куйсаң да, башын тота алмый. Шуңа кызы Роза аны стенага сөялгән мендәргә терәп, башы бер якка да авып төшмәслек итеп утыртып куя. Ләкин болай да озак утыра алмый Фәкилә апа, кайнарланып эче авырта башлый.

— Рак уйный башлады, — ди андый чакта Фәкилә апа, — аз гына кузгаттың исә елан кебек уйный башлый. Тамак төпләренә кадәр яндырып менә. Кире чалкан яткырмасагыз тынычланмый инде ул хәзер. Үземнең бер дә ятасым килми дә шул.

Бераздан ул яңадан утыртып куюларын сорый. Чөнки өенә шушылай гына булса да карап утырасы килә аның. «Чалкан яткач, күзгә бары тик түшәм генә күренә, — дип уйлый ул, — туйдым инде түшәмне күрә-күрә. Ике ай карап яттым бит. Ә менә утыргач, өй бөтенләй күренә. Ишек тә, ишек катындагы кием элгече дә, аның өстендәге такта шүрлек тә, алгы өйгә керә торган урта ишек тә, өстәл дә, аның янындагы диван да, мич почмагы да. Ә менә мичнең авызы күренми, аны күрер өчен башны аз гына сулга табан борасы бар. Тик көч җитми шул башны борырга».

— Роза, кызым, башны аз гына сулга таба борып куй әле, мич авызын, казан асларын күрәсем килә.

Кызы Роза килеп әнисенең мендәр чокырында яткан башын бераз гына сулга борып куя.

— Күбрәк бордың ла, кызым, мич авызы белән казан асты бөтенләй уңда калды, ә күзгә караңгы мич арты гына күренеп тора. Минем әле хәзер аңа карыйсым килми, башны бик әз генә уңга бора төш.

Роза аның башын бик аз гына уңга бора.

— Менә булды, яхшы булды, — ди Фәкилә апа һәм мич авызына текәлә.

Асты тип-тигез, өсте ярым түгәрәк сымаграк итеп эшләнгән мич авызы. Мичнең эче дә шундый. Фәкилә апа көн дә, таң белән ишегалдындагы лапас эченнән җәен үк кисеп-өеп куйган коры утын алып кереп, шушы мич эчендә ут дөрләтеп җибәрә торган иде. Әнә мич авызының өстендә генә урнашкан кучкарда аның үзе бәйләгән йон бияләйләре. Утын алып кергәндә ул гел шул ак бияләйләрне кия иде. Суга баргандада, мал асларын карарга чыкканда да. Менә инде өч ай була, шул бияләйләрне алып кигән кеше юк. Кучкарга җылынырга менгән игезәк песи балалары кебек йомарланып ятканнар да өч ай буена кузгалмыйча йоклыйлар шунда.

Кинәт Фәкилә апа мич эчендә үзе урләткән утны күргәндәй булды. Саргылт-кызыл ялкын телләре усак каерылары арасыннан килеп чыгалар да мич эченнән һаман түргә таба, төтен юлына үрмәлиләр. Ә Фәкилә апаның битенә шундый ягымлы, йомшак, нәфис җылы килеп бәрелә.

«Ялкын җылысы һәр вакыт шулай каз мамыгыдай йомшак була, — дип уйлады Фәкилә апа, — ә менә электр җылысы алай түгел. Электр җылысында озаграк торсаң баш авырта башлый, күңел болгана. Ялкын җылысына җитәме соң инде?! Һәм күмер җылысына».

Мич эчендәге хыялый ялкын янды да янды. Менә озакламый мич эченә шаулап күмер төште. «Мичнең коймак пешерү өчен иң өлгергән чагы, — дип уйлады Фәкилә апа, — яңа төшкән күмер өстендә пешерергә яратам мин коймакны. Мондый коймак аерата тәмле булып пешә. Бу күмерне мич артындагы зур чуенга тутырып өстен иске таба белән каплап куйсаң да ярый. Менә шушы вакытында алып сүндерелгән күмер самавар кайнатырга әйбәт була. Биш-алты кисәк күмере бер чиләк сыешлы самаварыңны «эһ» дигәнче кайнатып чыгара инде. Исе дә чыкмый, чөнки хәзер күмернең иң гөжләп торган чагы. Күмерен алмыйм дисең икән инде, мичне тартырга кирәк хәзер. Күмере көлгә әйләнеп беткән мичнең ни ипи пешерергә, ни чуен белән аш куярга рәте калмый. Күмере шаулап торган чакта тартсаң, мич эчендәге кирпечләр кызарып, янып калалар. Хет ипиеңне сал, хет бәрәңге тәгәрәт, хет чуен белән ашыңны куй».

Шуннан Фәкилә апа мич артыннан агач саплы кисәү агачын алды да шыңгыр-шыңгыр китереп мичен тартты.

«Менә шулай әйбәтрәк булыр, — дип уйлады ул, — казан астына шыңгырдап торган утлы күмер тулгач, казандагы малларга дигән су да бик тиз генә җылынып чыгар. Каяле, казанга бераз су да өстәп җибәрим.»

Фәкилә апа, су чүмечен алыйм дип, стенадагы савыт-саба шүрлегенә үрелгән генә иде, кинәт эчендә нидер өзелеп киткәндәй булды һәм ул авыртуга түзә алмыйча бөгелеп төште.

Әйе, бу хыялдан чынбарлыкка кайту иде. Аркасы белән мендәргә сөяп куелган Фәкилә апаның эчендәге авыруы кузгалды. Һәм ул ыңгырашып куйды. Кызы аны тизрәк чалкан яткырды.

«Я хода, — дип уйлады түшәгенә җайлап яткан Фәкилә апа, эч авыртуы басылгач,— бүтән беркайчан да мич ягарга насыйп булмас микәнни?! Әй, дөнья, рәхәтлекләреңнең исәбе-хисабы юк икән. Чүтлап чүтына, санап санына чыгарлык кына түгел икән рәхәтлекләреңнең. Моңа чаклы әле беркайчан да мич ягуларның, күмер төшерүләрнең, мич тартуларның бу кадәр рәхәт эш икәнен уйлап та караганым юк иде. Менә кайчан килеп төшенергә язган икән миңа дөньядагы һәр кылган эшнең рәхәт икәнлегенә. Ник алай? Ник боларны бугазга үлем ябышкач кына тойдырасың, дөнья? Мин бит инде гомеремдә ничәмәничә мең мәртәбә шушы мичкә ут элдердем, күмер тарттым. Ник ул чакларда бу эшләрнең шушы кадәр дә рәхәт икәнен тоймадым?»

«Вакытым юк иде, — дип уйлады ул аннары җитди итеп. — Ул турыда уйлап торырга да, рәхәтләнергә дә вакытым булмады. Бер эш бетүгә икенчесе көтеп торды. Иртән — иртәнге эшләр, көндез — көндезге эшләр, кич — кичке эшләр. Муеннарга таккан муенсалар кебек тезелеп кенә тордылар. Тазалыгым бар иде, көчем ташып торды һәм көн дә нәрсәнедер эшләргә аз гына вакыт җитми кала иде.

Ә менә хәзер киресенчә. Тазалыгым юк, көчем юк, ә буш вакытым муеннан. Инде анысы да бетеп бара. Вакытым да санаулы гына калып бара шул инде. Бер көн, ике көн, бер атна, яки аннан күбрәк, ләкин санап бетермәслек түгел».

## 14

Әйе, Фәкилә апа соңгы атналарда күбесенчә уйланып кына ятты. Узган айларда ул байтак сөйләште һәм инде сөйләшәсе сүз сөйләшенеп беткән дип уйлый иде. Тимерне исәпләмәгәндә, балаларының барысын да кулларыннан тотып бәхилләп чыкты. Ә Тимерне ерактан гына бәхилләде. Кайтмасын дисә дә, күрәсе килә иде аның Тимерне. Шул ук вакытта аны больницадан да чыгарасы килми иде.

«Әй, көчләрем булса, үзем генә барып кайтыр идем шул бала янына», — дип уйлады Фәкилә апа. Аннары ул, бу уенның никадәр мескен, көчсез һәм чарасыз икәнлегенә төшенеп, көрсенеп куйды.

Фәкилә апа белән Тимер арасы, аның башка балалары белән булган мөнәсәбәтенә караганда, үзгәрәк иде. Дөрес, ул барлык балаларын да бердәй ярата, күзен бәрәңге, каз мамыгы, сугым сарык өләшкәндә һәрберсенә тип-тигез итеп бүлә торган иде. Һәрберсе белән ачыклап сөйләшә, киңәшләшә, шаяра. Ләкин Тимер белән мөнәсәбәт бөтенләй икенче төрле. Ул аны яшерен рәвештә генә, башка балаларына күрсәтмичә генә, хәтта Тимернең үзенә дә сиздермәскә тырышып кына, калган өч баласына караганда энә очы кадәр генә артыграк ярата. Һәм ул аннан никтер ояла. Һәр вакыт ояла ул үзенең баласы Тимердән. Тимер белән сөйләшкәндә үзен ниндидер бер тәҗрибәле, күпне күргән, күпне белгән ил карты белән сөйләшкәндәй тоя. Ләкин ул бу тойгының ярату галәмәте икәнен белә.

Әллә ниндирәк, сәеррәк һәм моңлырак бала булды шул аның Тимере. Һәм бераз серлерәк тә. Укытучылары аны унынчыны укып бетергәнче аңламадылар. Шуңа күрә күбесе яратмый да иде. Ләкин бик сирәк һәм зирәк укытучылар гына: «Фәкилә апа, бу балаңнан бер-бер кеше чыга. Ул безнең бөтенебездән дә акыллы», — ди торганнар иде. Әйтүләре рас килде. Бик зур кеше булып күтәрелде Тимер. Яңа өйләр уйлап табучы. Фәкилә апа, чи надан буларак, бу эшне ничек кенә дә аңламый иде. Ләкин ул аның бик тә катлаулы, четерекле эш икәнен төшенә. Һәм аңа шунысы җиткән дә. Тагын ул шунысын да белә: Тимернең эше язучылар, шагыйрьләр, көй чыгаручылар, рәсем, сын ясаучылар эше белән бер. Менә монысы инде Фәкилә апага горурлык өсти иде. Ләкин ул моны беркайчан да, беркемгә дә, хәтта Тимернең үзенә дә сиздермәде. Чөнки мактануны җене сөйми иде Фәкилә апаның.

Газеталарда һәм радиода Тимерне язучылар, шагыйрьләр белән тиңли башлагач, кинәт Фәкилә апаның күңелендә сүзләр ниндидер сәер бер тәртип белән тезелә башлады. Һәм, Фәкилә апаны гаҗәпкә калдырып, күңелдә ниндидер тезмәләр туа башлады. Аның хәтере гаҗәеп яхшы иде һәм ул һәр тезмәне күңеленә бикли барды. Бик күп туды ул тезмәләр. Шунысы кызык, бер мәлне ул тезмәләрнең Фәкилә апа күңелендә генә бикләнеп ятасылары килмәде, ә каядыр иркенгә чыгасылары, башка кешеләргә дә ишетеләселәре килә башлады. Ләкин Фәкилә апа хәреф танымый иде, шушы гап-гади сәбәп аркасында әлеге гаҗәеп тезмәләр кәгазьгә төшә алмый интектеләр. Ә бу турыда кешеләргә сөйләп карарга ояла иде Фәкилә апа. Ояла һәм курка. Аллам сакласын, бу хатын тилергән икән, диярләр. Дөрес, Фәкилә апа улы Тимернең шигырь китапларын бик яратуын белә. Ул авылга кайткан саен Фәкилә апага күп итеп шигырьләр укый. Араларында Фәкилә апага бик ошаганнары да була торган иде. Һәм Фәкилә апаның күңелендә яшерен бер теләк яши — Тимер тыңлап караса ни әйтер иде икән аның тезмәләре турында? Юк, Фәкилә апаның үзенә берни дә кирәкми, аңа бары тик үзенең тезмәләренең Тимергә ошавы гына кирәк. Үзенең тезмәләре белән Тимернең күңелен бер мәртәбә кузгатып куя ала икән, шул бик җиткән Фәкилә апага. Аннан соң ул тезмәләрен хәтер сандыгыннан чыгарып ыргытачак. Чөнки аларның башкача кирәкләре калмаячак. Тимер тыңлады — җитте. Бер үк нәрсә турында ике мәртәбә тыңлыйсы килмәячәк ич инде аның. Әкиятне дә, биләмнәрдә сөйләнә торган авыл хәлләрен дә, хәтта кызык-кызык мәзәкләрне дә бер мәртәбә тыңлаганда гына күңелле.

Сәер тезмәләрнең Фәкилә апа күңеленә килүенә тагын бер сәбәп бар иде әле. Ул — этиләренең үлеме. Этиләренең үлеменнән соң китереп суккан кара кайгы Фәкилә апаның күңеленә әнә шул тезмәләр булып тезелә башлады. Алар янына яңалары өстәлә барды. Яңалары ин-

де балаларны, авылны, авыл тирәсендә үзе күреп белгән урман-кырларны, тауларны, чишмәләрне ярату турында иде. «Кызык икән бу, — дип уйлый иде Фәкилә апа. — Бу тезмәләрне ике әйбер тездертә икән күңелгә — кайгы һәм ярату».

Тезмәләр күбәйгән саен аларны Тимергә сөйләп карыйсы килү теләге дә арта иде. Ләкин Фәкилә апа аларны Тимергә сөйләү турында уйлап та карый алмый. Кит аннан, надан башың белән, оялмыйча ничек инде үз балаңа көйсез җырга охшаш ниндидер тезмәләр әйтеп утырмак кирәк? Җитмәсә, иң укымышлы балаңа. Көләр дә оятка калдырыр үзеңне. Юк, ана кешегә һич тә килешә торган эш түгел бу. Ә менә олы кызы Розага сөйләп караганда ярый. Беренчедән, анысы сигез класстан артык укый алмады, алай көләрлек үк белеме юк, икенчедән, хатын-кыз хатын-кыз күңелен аңламый калмас. «Бәлки әле Тимергә дә Роза аркылы ирештерергә ярыйдыр бу тезмәләрне? — дип уйлады Фәкилә апа. — Ләкин Роза аларны Тимергә минем алда укытырга тиеш түгел. Чөнки мин бик нык оялачакмын. Икесе генә очрашканда укырлар шунда үзләре. Соңыннан Роза тезмәләрнең Тимергә ничек тәэсир итүе турында миңа әйтер.»

Бу уе Фәкилә апага бик ошады һәм ул көннәрдән бер көнне тезмәләрен кызына сөйләп бирде.

Роза бик ошатты бу тезмәләрне, әтисе турындагыларын тыңлаганда хәтта елап та алды. Аннары ул аларны, әнисеннән яңадан әйттереп, бер дәфтәргә күчереп алды һәм тезмәләрне Тимергә дә, энесе Ривалга да һәм сеңелесе Верага да укыячагын әйтте. Фәкилә апа каршы килмәде. Киресенчә, куанды әле ул. Бигрәк тә кызының Тимергә укыячагы өчен куанды ул: «Менә бит ничек әйбәт килеп чыкты, үзем этеп-төртеп әйтеп торасы да калмады», — дип уйлады.

Тимергә ошамады бу тезмәләр. Әлбәттә, дөнья поэзиясеннән шактый авыз иткән, ул гына да түгел, шигъриятне бик яратуы, күп укуы аркасында шигырь китапларын бик талымлап кына кабул иткән Тимернең надан авыл хатыны язган бу зәгыйфь һәм примитив тезмәләрне поэзия итеп кабул итүе ким дигәндә көлке тоелыр иде. Әйе, ул надан авыл хатыны Тимернең сөекле әнисе булуга да карамастан, бу чыннан да шулай иде. Ләкин ул бу турыда апасына әйтүне кирәк тапмады. Ни ошады, ни ошамады дип әйтмәде Тимер. Укып бетергәч, дәфтәрне читкәрәк этеп куйды да, аларны укымаган да кеше шикелле, сүзне икенчегә борып алып китте. Ләкин Розага тезмәләрнең Тимергә ошамавын аңлау өчен шунысы да бик җиткән иде.

Роза бу турыда әнисенә әйтмәскә булды. Ниемә дип күңелен төшерсен әле ул аның? Шуңа күрә ул беркайчан да әнисенә бу турыда авыз ачып сүз әйтмәде. Фәкилә апа үзе дә сүз башлап сорашырга базмады. Шулай итеп, ул тезмәләрнең Тимергә ошаганмы, юкмы икәнен тәки белми калды. Һәм хәзер дә белми. Ләкин хәзер инде моның әһәмияте юк иде. Тезмәләрдә түгел иде шул инде хәзер Фәкилә апаның кайгысы. Үлем түшәгендә яткан ана инде ул тезмәләр турында җитди уйлый алмый иде. Ләкин ире турындагы тезмәләре аның әлегә кадәр онытып торган бер әйтәсе сүзен искә төшерделәр, һәм ул ым белән генә үз янына кызы Розаны чакырып китерде.

## 15

— Өч ай урын өстендә ятып, әйтеләсе сүзем әйтелеп бетте дип уйлаган идем, бер сүзем калган икән әле, — дип башлады Фәкилә апа сүзен.

— Әйт, әни, әйт, бөтен үтенечләреңне әйтеп бетер, барысын да эшләрбез, — диде Роза, гадәттәгечә хәсрәтле һәм тәмле итеп.

— Поминкаларымның берсен дә аракы белән үткәрмәгез, күмгәндә дә, өчемне, тугызымны, кырыгымны, елымны үткәргәндә дә[1]. Атагыз аракы эчү гадәтен сөйми иде, шул эчүчеләрдән бик зарлана иде. Күмү атагызча булсын, поминкаларымда аракы заты булмасын. Туганнарга да, балаларга да әйт, әнинең васыяте, диген.

— Ярар, әни, әйтермен, — диде Роза, — тик менә кабер казучыларга, күмеп кайтучыларга гына күңелсезрәк булыр инде.

— Булсын,— диде Фәкилә апа кырыс итеп.— Мәет күмүнең кайчан күңелле булганы бар?! Күңелсез булсын, мине күмү генә түгел, дөньядагы иң сантый кешене күмү дә күңелсез булсын. Иң адәм актыгын да. Адәм актыгы бит әле ул хайван актыгы түгел. Шуның өчен генә булса да һәр кешене күмү күңелсез булырга тиеш.

Роза соңгы сүзен ник әйткәнгә үкенеп куйды. Әлбәттә, ул дөресен әйтте, ләкин бу сүзне нәкъ менә үлем түшәгендә ятучы әнисенә әйтү ничектер җайсызрак килеп чыкты шул.

— Күмеп кайтучыларга аракы кую гадәткә кереп китте бит инде хәзер, дип кенә әйтүем инде, — диде Роза. — Бөтен кеше шулай итә бит.

— Гадәтләнмәсеннәр, — диде Фәкилә апа һаман шул хәлсез һәм кырыс тавышы белән. — Бер дә ата-баба йоласына сыя торган гадәт түгел. — Аннары ул, күзләрен түшәмнән алмыйча бераз гына уйланып ятты да, бөтенләй күңелсезләнеп: — Минем бер генә поминкама да аракы кертмәгез. Сезгә үпкәләмәсеннәр, миңа үпкәләсеннәр. Күмеп кайткач аракы өметләнүчеләргә әнинең васыятен боза алмыйбыз дип әйтегез. Ашатуын әйбәт ашатыгыз, сыйны кызганмагыз. Чәйне мәтрүшкәләп, баллап эчертегез, суык зираттан кайтып салкын тидерә күрмәсеннәр. Бал чоланда, мәтрүшкә чолан ишеге өстенә элеп куйган.

Шуннан Фәкилә апа сүзе беткәнлеген белдереп тынып калды. Өй эче тагын өч ай дәвам иткән тынлыкка талды. Роза бик шыпыртлап кына, тавыш чыгармаска тырышып кына өй эшләре белән булаша башлады.

Ләкин Фәкилә апаның сүзе бетмәгән иде. Аракы турында сүз чыккач, бик күпне сөйлисе сүзләре бар иде әле аның. Тик менә арып кына китте. Арыта шул хәзер, сөйләшергә дә арыта. Балаларны харап итмәгәе аракы, дип курка иде Фәкилә апа. Дөрес, аның бер баласына да әлегә андый куркыныч янамый янавын. Кызлары турында әйткән дә юк инде, малайлары да алай аракы дип атлыгып тормыйлар. Шулай да дөньясы шул аракыга көйләнеп бара. Өстәлгә аракы куеп сөйләшмәсәң, кеше белән юньле эш башлап булмый. Такта ярдырыйм дисәң — аракы куй, утын китертсәң — аракы куй, ишегалдына бер машина ком китереп аударсалар — тагын шуны... Кешеләргә хәзер акча да кирәкми, эшләгән өчен бирсәң алмыйлар, бер шешә аракы куйсаң — күңелләре була. Акча чыгарсаң көләләр генә: «Шту син, Фәкилә апа, — диләр, — егерме сум колхоз пенсиясенә яшәгән карчыктан бер машина ком китергән өчен акча алып тораммы соң, булмаганны. Җитмәсә, машинасы колхозныкы, комы әнә бакча артыгыздагы тауныкы. Акчаны аны без колхозда эшләп тә көрәп алабыз. Аллага шөкер, хәзер җиде кат тир агызып аласы түгел аны, машина келтерәп эшләп

[1] Христианнардан кергән гадәт буенча, керәшеннәр кеше үлгәннән соң өч, тугыз, кырык көн һәм бер ел тулган көннәрдә мәрхүмне искә алып үткәрелгән мәҗлесләрне поминка дип йөртәләр.

торса, колхоз кассасы зарплатаны күп итеп чутлый тора. Акча малмыны хәзер безнең кебек өрлектәй ирләргә. Менә инде әз генә күгәрчен сөтеннән авыз итеп карау мишәйт итмәс иде эштән соң». Шофер үзенчә җайлаша, тракторчы үзенчә, такта яручысы үзенчә. Игенче үзенчә, терлекче үзенчә дигәндәй. Еегерме сум пенсия дип әйтүләре дә мине кызганудан түгел, тәрбияле кеше булып кылануда гына. Алар бит миңа атна саен ук булмаса да, ай саен диярлек балалардан акча килгәнне белеп торалар. Аллага шөкер, авылның колагы сизгер, теле чос. Почта хатын үзе генә дә ни тора. Юкка гына почтага куймаганнар үзен, кемгә каян, ни калынлыкта хат килгән, кемгә кемнән күпме акча килгән — сәгате-минуты белән бөтен авылга таратып кына тора. Һәм рәхмәт ул почта хатынга. Балалардан хат килү, акча килү барыбыз өчен дә күңелле хәбәр, сугыш елларындагы хәтәр хәбәрләр түгел. Тик менә ирләр генә ул еллардагыча түгел хәзер. Ул чакта аракы эчүче ир авылына бер була, аның да илгә-көнгә начар даны тарала иде. Хәзер алай түгел. Хәзергеләр — киресенчә. Эчмәгән ирдән көләләр, катынша диләр. Эш ягыннан аларны булдыксыз дип әйтеп булмый. Эшне җир җимертеп эшлиләр, малын да табалар. Безнең ирләргә караганда укыганраклар да, эш рәтен дә әйбәтрәк беләләр. Әнә колхоз елның-елында байый бара хәзер. Бөтен фермалары, амбарлары, колхозчы хуҗалыклары-ние белән байый. Бу байлыкларның барысын да хатыннар гына булдырмаган бит. Киресенчә, һәммәсенә ирләр көче, ирләр гайрәте, ирләр кулы күбрәк керә. Булдыклылар, бик булдыклылар хәзерге ирләр. Ләкин... эчәләр.

Эшли-эшли дисәң дә, араларында эшләмичә эчеп йөрүчесе дә күренгәли башлады. Шул аракы аркасында чир-чорга тарып китүчеләре дә юк түгел».

«Җитәкчеләрендә дә гаеп бар,— дип уйлады аннары Фәкилә апа, — шушы аракы эчү гадәтен белә торып, каты чара күрмиләр. Председателебез тырыша тырышуын колхозчыларны эчертмәскә. Ичмасам, машинада эшләүчеләрегез бераз тыелыгыз, машина булып машина тик тора бит дип инәлә. Тиргәп тә карый. Тик эшеннән куып чыгара алмый. Чөнки тегеләре тырт итеп борылалар да, шәһәргә китеп, шундый ук тракторга утыралар.

Аракы — хәсрәт, — дип уйлады Фәкилә апа. — Ирләрне вата, эчтән җимерә аракы. Ирләрнең үзләрен генә түгел, гаиләне... Мин китәм дә котылам, балаларыма гына афәт булып төшә күрмәсен... Әй, дөнья, саклый күр балаларымны бу афәттән. Сакла... сакла...»

## 16

— Әни, әни, саташасың бугай, — диде Роза, әнисенең колагына иелеп.

Фәкилә апаның тамагындагы тонык гырылдау туктап калды һәм ул көч-хәл белән генә күз кабакларын күтәрде. Көн саен Фәкилә апаны саклап кунучы карчык-корчык, туган-тумачалар барысы да куркынып аның өстенә иелгәннәр, ә Роза кулына бер кашык су тотып тора иде. Фәкилә апа керфекләрен тәмам күтәрде, күз алмаларын селкетеп алды, хәлсез теле белән кипкән иреннәрен ялады.

— Һаман үлә алмадым бит әле, кызым, — дип пышылдады ул, Роза кулындагы бер кашык суны күреп. Өйдәгеләрнең куркынган йөзләре тынычланып киткәндәй булды һәм аларның һәрберсе дәшми-тынмый гына үз урыннарына барып утырыштылар.

— Юк, әни, мин моны үлгәч авызыңа салырга дип алып килмәдем, иреннәрең кипшенгән бит, менә су кабып җибәр, — диде Роза тәмам гасабиланып.

— Тагын үлеп булмады шул, — диде Фәкилә апа ишетелер-ишетелмәс кенә. — Инде тәмам киттем бугай дигән идем, менә син пышылдап туктаттың. Бөтенләй килеп җиткән иде бугай инде. Туктатмасаң да ярый иде дә бит. Китәргә кирәк иде инде миңа, бик кирәк иде. Күпме кешене интектереп, ишек төбенә килеп җиткән үлемне айлар буена көтеп яту килешми. Бер дә килешми.

— Юкны сөйләмә, әни, — диде Роза. — Сине шушы хәлеңдә булса да яшәтәсебез килә безнең. Сине караудан беребез дә туймады һәм беркайчан да туймабыз. Без бит синең балаларың, якыннарың, җиде ят түгел.

— Балаларым шул менә. Шуңа интектерәсем килми дә. Шәһәрдәге эшеңне ташлап өч ай буена бәйләп куйган кебек минем янда утырасың. Оялам, балам, бик оялам. Нишлим соң, килми бит үлем, килми.

— Андый сүзләр сөйләмә, әни. Менә Тимердән дә хат килгән.

Фәкилә апаның карасу-сары йөзендә нindidер җанлану галәмәтләре кузгалгандай булды. Ләкин бу шулай тоелды гына. Нинди җанлану булырга мөмкин иде инде бу тәндә?! Бу тәнгә инде җансызлану гына иңә бара иде.

Ә күңелдә җанлану булып алды. Әнә шул күңелдәге җанлану гына мираж төсле күренеп китте Фәкилә апаның йөзендә.

— Ниләр яза соң? — дип сорады Фәкилә апа ашыгуын тыя алмыйча.

— Кайта алмасам, мәңгелек үкенеч булачак, — дигән.

— Кайтмасын, кузгалмасын, чыкмасын больницасыннан, — дип тезде Фәкилә апа, һәр сүзенә басым ясарга тырышып. — Инде ул турыда сөйләштек бит. Үлгән артыннан үлеп булмый дигәнне аңлыймы ул бала?! Аның кайтуы үлгән артыннан үлү булып чыга бит. Хат барып җитмәс, телеграмм сугыгыз. Кайтма, әни кушмый, диегез. Нишләп ана сүзен тыңламаска әйләнде әле ул. Телеграмм артыннан ачуланып хат салыгыз. Әй, сөйләшергә хәлем булса, үзем генә әйтеп яздырыр идем дә шул.

— Борчылма, әни, телеграмманы хәзер үк сугарбыз,— диде Роза. — Язган хатында, врачлар больницадан чыгарга ризалык бирми, дип язган иде бит. Хатына да кайтам ук димәгән ул. Үкенеч булачак кына дигән. Ул бит әле кайтам дигән сүз түгел. Аннары синең хәлне сораган. Әни турында күп итеп язгыз дигән. Теге тезмәләрен югалтмагыз дигән, алар шундый әйбәтләр иде дигән.

Әйе, Тимер хатка чынлап та шулай дип язган иде. Әйбәт дип алдады Тимер. Ләкин моның изге алдау икәнен белеп алдады һәм әнисенә нindidер җылы сүз әйтәсе килеп.

Фәкилә апа чыннан да чиксез шатланды. Дөрес, ул бу турыда бер сүз дә әйтмәде. Тезмәләрнең инде аның өчен күптән бер әһәмияте дә юк иде. Алар инде Фәкилә апа өчен вак нәрсәләр иде. Әллә кайчан онытып бетерде инде ул аларны һәм кирәкләре дә юк. Ә менә Тимернең әйбәт дип әйтүе куандырды Фәкилә апаны. Димәк, Тимер тезмәләрне укыган һәм аларны укып аның кәефе яхшырган. Кәефе начарланса, әйбәт дип әйтми бит инде кеше. Ә инде баласының кәефен әйбәтләндерү ана өчен иң зур бәхет.

Гаҗәп, үзе үләргә ята, үзе бәхет кичерә Фәкилә апа. Ләкин бу бәхетнең гомере бик кыска иде шул. Чөнки Фәкилә апаның бөтен тәне карасу-сары төстә... Ул моны үзе дә белә һәм яңадан заркып-зарыгып шул үлемне көтә башлады.

Бу чакны Тимер больницаның өченче катындагы кечкенә генә караңгы бүлмәдә операция өстәленә охшаш биек һәм каты ятакта наркоз иснәтеп йоклатылган хәлдә ята иде. Ул һушсыз һәм бер нәрсәне дә тоймас хәлдә.

Кичә больницаның медколлегиясе Тимернең авыруы турында махсус җыелышка җыелды. Җыелышта профессор да бар иде. Тимерне дәвалаучы врач авыру турында кыскача белешмә бирде.

— Дәвалау әйбәт нәтиҗәләр бирә, — диде ул. — Үпкәсе ай саен арулана бара. Авыру физик яктан тазарды, әйбәт ашый, әйбәт йоклый, ютәл юк, бөтен дарулары файдага. Ләкин кан килүе тукталмый. Терелүнең алга бару дәрәҗәсе буенча кан килергә бер сәбәп тә юк. Авыруның бу стадиясендә теоретик яктан инде кан килергә тиеш түгел. Мин бик күп авыру тарихларын актарып чыктым. Берничә елныкын. Ләкин дәвалануның бу стадиясенә җиткән бер генә авыру да кан төкермәгән. Ә бу төкерә. Мин кан килүнең сәбәбен таба алмадым. Шуна күрә бүгенге коллегияне җыюны үтендем.

Җыелыш залының каршы як стенасында эчтән яктыртыла торган кабарынкы ак пыяла экран. Аңа Тимернең үпкәсе төшерелгән рентген рәсемнәре эленгән. Тимернең врачы, озын күрсәткеч таяк белән төрле рәсемнәргә күрсәтә-күрсәтә, дәвалану процессының ничек баруы турында сөйли.

— Кан каян килә? Үпкәдәнме? Үпкәдән булса аның кайсы урыныннан? Күмәк көч белән минем менә шушы сорауларга җавап табасым килә, — дип тәгәлләде врач.

— Кан борыннан, авыз куышлыгыннан яки тамак төбеннән килмиме? — дип сорады берәү.

— Кан тын юлларының югары өлешләреннән килми,— диде больницаның колак-тамак-борын врачы.— Дөрес, кайчандыр авыруның борын эчендәге кимерчәкләре җимерелгән булган. Ләкин бу бик күптән булган хәл һәм кимерчәкләр шулай җимерелгән килеш төзәлгәннәр. Төзәлү күптән булган һәм аннан кан килми. Тамак төбендәге кан тамырлары ялкынсынган, ләкин алардан да кан килә алмый.

— Бугаз һәм үпкә тирәсендәге тын юллары ничек? — дип сорады профессор.

— Без әлегә бронхларны тикшермәдек. Дөресрәге, тикшерүне кирәк тапмадык, — диде Тимернең врачы.

— Тикшерергә, һич кичекмәстән бронхоскопия ясарга,— диде профессор.

Аннары профессор Тимернең авыру тарихы һәм ак экрандагы рәсемнәр буенча үзенең нәрсәләр уйлавын сөйләде. Аның уенча, үпкәдән кан килергә мөмкин иде әле. Фән мондый очракларны кире какмый һәм дәвалау элеккегечә дәвам ителергә тиеш.

— Дәвалау озакка сузылачак, — диде профессор. — Әле эшнең беренче яртысы да эшләнеп бетмәгән. Авыруга вакыт һәм дәвалану кирәк. Иң көчле даруларны соңгырак чорга тотып торыгыз. Авыру психологик яктан сәламәтме?

— Авыру профессиясе буенча архитектор һәм палатада үз эше белән шөгыльләнә. Эш аңа психологик яктан яхшы тәэсир итә. Тик авылда аның әнисе рактан үлеп ята.

— Озак ятамы? — дип сорады профессор.

— Менә өченче ай китте инде.

— Авыру бу фактны ничек кичерә?

— Авыр, бик авыр. Елаган чаклары да бар.

— Елаудан тыймагыз, ләкин авыруны үз эченә бикләнүдән саклагыз. Күңелендә булган авыр уйлары белән уртаклашып торыгыз.

Югыйсә, ул озакламый үз эченә бикләнәчәк. Монысы аңа бик начар булыр. Эш белән юанудан тыймагыз. Эш белән мавыгып, режимны бозган очракларда да тыймагыз. Һәм иртәгә үк аңа бронхоскопия ясагыз, нәтиҗәсен миңа әйтерсез.

Җыелып сөйләшү шуның белән бетте. Чөнки инде барысы да аңлашылган иде. Аңлашылмаганын бронхоскопия күрсәтәчәк...

Тимерне бронхоскопиягә кичтән үк әзерләргә керештеләр. Аның тирәсендә шәфкать туташлары тыз-быз килеп йөри башлады. Әйтерсең нииндидер зур бер операциягә әзерләнәләр.

Бронхоскопия дигәннәре чыннан да кечкенә генә бер операциягә охшый икән охшавын. Кешене махсус бүлмәдәге махсус ятакка салалар, наркоз белән йоклаталар да очына кечкенә лампочка куелган тимер торбаны бугаз аша тын юлларына кертеп җибәрәләр. Тын юлларына кергән шул лампочка кабынгач, торба эчендәге нәни көзгеләр һәм төрле линзалар ярдәмендә бугазның һәм тын юлларының эчке стеналарын карыйлар. Моны наркозсыз да эшләргә була, ләкин алай иткәндә бугазны һәм тын юлларын озаклап, иркенләп тикшереп булмый икән.

Ләкин бу эш әле иртәгә иртән генә булачак иде. Шуңа күрә Тимер бүген кичтән бераз эшләп алырга булды.

Кичке сәгать уннарда палатага шәфкать туташы керде. Ул Тимергә иртәгә иртәнге ашны ашамаска кушты һәм ике төймә йокы даруы бирде. Тимер хәзер үк шуларны эчәргә һәм йокыга ятарга тиеш. Ләкин бу вакытта Тимернең эше бик шәп бара иде. Ул, шушы яраткан эшеннән аерылырга теләмичә, даруларны бирәр сәгать соңрак эчеп ятарга булды. Утыра-утыра ул проекты белән мавыгып китте һәм сәгатенә күз төшерсә, инде уникe тулып килүен күрде. Ул сызымнарын пөхтәләп җыеп куйды. Тиз-тиз генә даруларны кабып йотты да йокларга ятты.

Икенче көнне иртәнге сәгать тугызда аны кереп уяттылар һәм ун минуттан процедура кабинетына укол кадатырга барырга куштылар. Тимер тиз-тиз генә урын-җирен җыйды, аннары өс-башын киенде һәм укол кадатып килде. Бу укол да йоклата торган иде булса кирәк, палатасына кайту белән изри дә башлады Тимер. Ун минут та үтмәгәндер, шәфкать туташы килеп аны больницаның өченче катына, әлеге караңгы бүлмәгә алып менде. Бүлмә тулы ак халатлы врачлар иде, Тимергә билгә кадәр чишенергә һәм бүлмә уртасындагы биек һәм каты ятакка ятарга куштылар. Тимер инде укол тәэсиреннән исерек кеше кебек иләс-миләс бер хәлгә килгән иде, бүлмәдә хатын-кызлар күплеге турында нәрсәдер шаяртып алган булды, ләкин аның шаяртуыннан беркем дә көлмәде дә, елмаймады да, барысы да, таш гасырлардан калган уникаль экспонатка караган кебек, җитди һәм уйчан кыяфәт белән Тимерне күзәттеләр. Тимер шаяртуның урынсыз һәм вакытсыз икәнен үзе дә сизде. Чөнки аның тәне исерек хәлдә булса да, зиһене ап-аек, чиста һәм сизгер иде. Әлеге каты ятакка чалкан сузылып яткач, Тимернең уң кулындагы кан тамырына укол энәсе кертеп җибәрделәр, һәм ятак буендагы озын тимер аякка беркетелгән пыяла шешәдән кызгылт резин көпшә аша Тимернең тәненә ниндидер сыекча ага башлады. Тимер тәненең һаман саен йомшара, сыегая баруын тойды. Аннары аңа телен күрсәтергә куштылар һәм борынына наркоз маскасы киертеп куйдылар. Салкынча кислород агымы белән кудырылган наркоз башта Тимернең аңын әле томалый алмады. Аннары масканы алып яңадан телен күрсәтергә куштылар. Тимер телен чыгарып күрсәткәч, кемдер: «Җиткән», — дип куйды һәм борынга яңадан наркоз маскасы киерттеләр. Ләкин монысын инде Тимер бик аз хәтерли. Инде ул тәмам оеды, врачларның пышын-пышын сөйләшүләрен ишетми башлады. Әмма бөтенләй йоклап китәм генә дигәндә, башына кинәт бер уй килеп,

аңын сафландырып җибәрде. «Кам тамырына наркотик укол кадаганнан соң әни дә шушындый хәлдә була микән?» — дигән уй иде ул.

Шунда кинәт Тимергә әнисе дә шушы бүлмәдә, шушындый ук тар һәм биек ятакта аның белән янәшә ятадыр, аның шикелле үк наркоз исеннән исерә барадыр шикелле тоелды. Менә алар икесе дә тәмам исереп беттеләр һәм Тимер акрын гына әнисенә дәште:

— Әни, син дә монда, минем больницада ятасыңмыни?

— Юк, улым, — диде әнисе, — мин бит инде үлдем. Син аны ишетмәдеңмени әле? Мин бит инде моннан өч көн элек үлдем һәм хәзер җир астында, әтиең белән янәшә ятам. Әтиең белән мине нибары бер адым киңлектәге туфрак аерып тора. Тик без аның белән көн саен сөйләшеп торабыз.

— Шулаймыни-и-и, — дип сузды Тимер, гап-гади бер нәрсә турында сөйләшкән кебек итеп.— Нишләп соң мин синең үлгәнеңне белми калдым икән? Син үлгәч, миңа телеграмма суктылармы соң алар?

— Белмим шул, улым. Мин бит инде хәзер мәрхүммен, андый нәрсәләрне белмим.

— Алайса, телеграмма килеп җитмәгәндер әле, — диде Тимер тыныч кына. — Сезнең каберегезгә хәзер бер һәйкәл дә кирәк булыр бит инде, әни. Ничегрәк итәрбез икән соң, әтигә дә, сиңа да аерым-аерым куйыйкмы һәйкәлне, әллә икегезгә берне ме?

— Икебезгә берне куегыз, улым. Без инде әтиең белән бу турыда сөйләштек, ул да икебезгә берне куйсыннар ди. Безгә шулай яхшырак булачак.

— Ярар, әнкәй, икегезгә берне куярбыз. Менә больницадан терелеп чыгыйм да, шундый итеп һәйкәл куярбыз без сезгә! Мин бит архитектор...

Шунда Тимер кинәт үзенең эчендә ниндидер ят бер җисем йөргәнне тоеп алды. «Торба! — дип уйлады Тимер. — Кай арада кертеп өлгерделәр соң әле бу торбаны, авыздан кергәнен сизми дә калдым бит».

Әйе, Тимернең эчендә йөрүче бу ят җисем чыннан да бронхоскопия торбасы иде. Торба үзенең салкынча тәне белән Тимернең тын юлларын капшады. Эчендәге бу ят әйберне косып чыгарасы килде Тимернең. Чөнки, аның уенча, кешенең эчендә, үз әгъзаларыннан тыш, ят әйбер булмаска тиеш иде. Тик косып булмый икән шул. Хәер, нигә косып торырга, кул белән генә алып ыргытырга кирәк ул ят әйберне. Ләкин уң кулны кузгатырга ярамый, чөнки анда укол энәсе аша тәнгә ниндидер сыекча агып тора. Ә менә сул кул буш һәм тын юлында капшанып йөрүче теге әшәке торбаны сул кул белән алып ыргытырга кирәк тә.

Тимер сул кулын күтәрим дип кенә омтылган иде — бу ни бу?! Кул тыңламый һәм урыныннан кузгалырга кымшанып та карамый. Нәрсә булды бу кулга, ник ул Тимерне тыңламый?! Ничек булып чыга инде бу? Үз кулыңа үзең хуҗа була алма, имеш? Кая монда дөреслек? Кеше хет үз әгъзаларына гына булса да үзе хуҗа булырга тиештер бит инде?! Үз әгъзаларына да хуҗа була алмаган кешенең җәмгыять өчен нычагыма кирәге бармы? «Алайса, әнә роботлар уйлап табыгыз да эшләгез шулар белән», — дип ачуланды Тимер врачларны.

Ләкин инде бу минутта каяндыр еракта н, болытлар артыннан килгән бер пышылдау: «Уяна, уяна, венасына кадагыз, венасына», — диде һәм Тимер сул кулындагы бер кан тамырының черт итеп тишелеп киткән һәм кан тамыры эченә салкынча укол энәсе килеп кергән тойды. Шуннан соң ул бер мәлгә онытылып торды һәм яңадан әнисенә дәште.

— Әни, монда минем эчкә ниндидер торба керттеләр, мин азрак шул эш белән мәшгуль булдым, — диде.

— Тикшерсеннәр, улым, — диде әнисе, — врачларның вакытында тикшереп торулары яхшы. Менә мин генә, ашказанын вакытында тикшертмичә, авыруны ауздырып харап булдым.

— Хәзер ул турыда сөйләшергә соң инде, әни, — диде Тимер, һаман гап-гади нәрсәләр турында сөйләшкәндәй тыныч кына. — Син бит инде үлдең һәм ул турыда сөйләшүнең мәгънәсе калмады. Без лутчы бая өзелеп калган сөйләшүне дәвам итик. Нәрсә турында сөйләшә идек әле?

— Әтиең белән минем кабергә һәйкәл кую турында.

— Ә, әйе, — диде Тимер, исенә төшереп. — Мин бит инде хәзер зур архитектор, әни. Мин сезнең каберегезгә шундый итеп һәйкәл куярмын! Юк, ул күкләргә ашып торган һәйкәл булмас. Кабер өстенә андый һәйкәлләрне гомумән куймыйлар бугай. Күңелгә шом салып торган кара мәрмәр дә булмас ул. Һәм ак мәрмәр дә булмас. Гомумән мәрмәр булмас ул һәйкәл. Әнә безнең бакча артындагы комлы тау башында, каен кәүсәсендә бүлтәеп-бүлтәеп торган шешләр кебек, зур-зур кара ташлар чыгып тора бит? Әнә шул ташларның берсеннән һәйкәл уярмын мин сезгә, әни. Мин бәләкәй чакта ул ташларның берсен пычкы белән кисеп караган идем, эчләре ап-ак икән ул ташларның. Тышларын җил белән яңгыр гына каралтып бетергән. Үзләре йомшак ул ташлар, гап-гади кул пычкысы белән дә кисеп була. Шул ташларның берсен җирдән казып чыгарырмын да, бакча турына гына тәгәрәтеп төшерермен. Киртәне җимерүен җимерер инде ул, ярар, соңыннан төзәтербез әле. Һәм шунда, үзебезнең бакча артында мин сезгә һәйкәл уярмын. Уеп бетергәч, колхоз тракторы белән зиратка, сезнең каберләрегез өстенә китереп куярбыз.

— Ләкин һәйкәлне бик зур таштан ясама, улым.

— Ник алай дисең, әни?

— Үзегезгә күтәреп йөртергә авыр булыр дим. Уртача гына таш булсын.

— И әнкәй, үлгәч тә безгә авыр булмасын дип борчылып ятма инде. Ә син уртача зурлыктагы таш булсын дип дөрес әйтәсең. Мин үзем дә кабер ташларының артык зур булуын яратмыйм. Минемчә, кабер ташы чамалы һәм тыйнак булырга тиеш. Мин барыгыздан да бай, дип кычкырып торган иләмсез зур да булмасын. Һәм артык мескен кыяфәттәге кечкенә дә булмасын. Кабер ташының иң әйбәтләре — уртача зурлыктагылары.

— Ә нәрсә уярсың соң син ул ташка?

— Һәйкәлегез дүрт почмаклы булыр, әнкәй. Чөнки ул бу дөньяның дүрт ягына да йөз белән карап торырга тиеш. Язуларга килсәк, бик күп язу язарга исәпләмим. Бер ягына әтинең фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм туган, үлгән еллары. Аның капма-каршы ягына — синекеләр. Ә ташның кояш чыгышы ягына ике юлга аерып дүрт кенә сүз язарга исәп:

**«Сезнең гомер —**
**аккан су,» —**

дип. Нибары дүрт сүз. Һәр балагыздан берәр сүз. Бу сүзләрне мин ташка чокып язармын һәм көн саен кояш чыкканда аларга кызыл нурлар төшәр. Кызыл нурлар ак ташны яктыртып сезнең гомернең никадәр саф булуы турында сөйләсәләр, чокып язылган хәрефләр эчендәге кара күләгәләр гомерегезнең аккан су кебек бик тиз үтеп китүе турында искәртерләр. Ә ташның кояш баешы ягына мин дулкыннарын кабартып-кабартып кечкенә генә бер чишмә рәсеме ясап куярмын. Ул чишмәнең таш дулкыннары челтер-челтер килеп гомер буе сезнең турыда сөйләп торырлар. Баеп баручы кояшның кабарынкы дулкыннарга төшкән сүрән нурлары тиздән көннең бетәчәген, җир өстенә караңгы төн киләчәген хәбәр итәрләр. Һәм көн дә шулай булыр, ап-ак кабер ташы дөньяның дүрт ягына да йөз белән карап торыр, таш дулкыннарын челтерәтеп чишмә агар... чишмә агар...

...Тукта, уң кулдагы укол энәсе аша тәнгә ага торган сыекча тукталды түгелме соң? Тукталды шул. Энә инде энәсен дә суырып алдылар. Эчтәге теге ят торбаны да тартып алганнар. Тимер күзен ачып караса, бүлмәдән ак халат кигән бер төркем врач чыгып бара. Ул да булмады, носилка тотып, ишектән таза-таза ике авыру егет килеп керде. Тимерне күтәреп носилкага салырга тотынганнар иде, ул: «Үзем, үзем»,— дип исерекләргә генә хас сәер хәрәкәтләр белән носилкага менеп ятты, һәм аны беренче катка, үз палатасына төшереп куйдылар. Ул караватына сузылып яткач, шәфкать туташы килеп, аңа юрган япты һәм ярты сәгать дәвамында йокларга ярамаганын әйтте. Ләкин Тимернең үтереп йокысы килә, күз кабаклары ихтыярсыздан бер-берсенә ябышалар иде. Шуңа күрә шәфкать туташы аны ярты сәгать буена үзе сөйләндереп торды. Бу сөйләшүнең рәте-башы юк иде. Һәрхәлдә, соңыннан Тимер ул сөйләшүләрдән бер генә нәрсә дә исенә төшерә алмады. Ярты сәгатьтән соң шәфкать туташы палатадан чыгып китте. Ул китүгә Тимер күзләрен йомды һәм шул мизгелдә үк тирән йокыга талды.

## 18

Шул йокысыннан Тимер кичке сәгать җидегә кадәр уянмады. Аны беркем дә килеп борчымады. Бронхоскопия алдыннан иртәнге ашны ашамаган, төшке аш вакытын йоклап үткәргән Тимер карыны ачканлыгын тойды. Тагын ул уйлау сәләтенең ниндидер томанлы һәм эзлексез булуын, тәнендәге бөтен мускулларының җиңелчә сызлануын сизде. Ашыйсы килүгә карамастан, бераз гына косасы да килә иде. Шулай ук күз кабаклары авырайган һәм күз алмасын як-якка йөртү дә кыенлашкан икән. Һәм үтереп су эчәсе килә — тел тәмам кипкән, әйтерсең авыз эченә тел урынына киң бил каешының очын кисеп тыкканнар. Тимер үрелеп кенә тумбочка өстендәге стаканны алды һәм, комсызлыгын басарга тырышып, уртлап-уртлап кына ачкылт-татлы мүк җиләге суын суырды. Сусавы басылгач, ике кулын баш астына куеп ятты да нигәдер йөртергә авырлашкан күз алмаларын көч белән әле бер, әле икенче якка авыштырды. Күз мускулларының авыртуына да карамастан, ул моны берничә мәртәбә кабатлады һәм озакламый аның күз алмалары хуҗаның иркенә буйсына башлады. «Менә шулай, — дип куйды Тимер үз-үзенә, — югыйсә, берегез дә тыңламый башладыгыз әле. Наркоз белән исереп ятканда сул кул буйсынмады, ә хәзер инде күз алмалары санламаска маташа. Кул үзенчә, күз алмасы үзенчә, йөрәк үзенчә, аяк үзенчә, колак үзенчә генә яши башласа, ни була инде ул аннары? Сез мине адәм көлкесенә калдырып бетерерсез. Ю-у-у-к, миңа сезне тизрәк кулга алырга кирәк. Кулга алырга һәм йөгәнләргә! Минем һәр әгъзам, һәр теләгем бары тик миңа гына хезмәт итәргә тиеш! Коллар шикелле! Менә монда инде колбиләүчелекне кире кагып булмый! Ә мин үземнең кемгә хезмәт итәргә тиешлегемне яхшы беләм! Минем яраткан эшем, яраткан җәмгыятем һәм гаиләм бар. Һәм мин шуларга хезмәт итәргә тиеш. Ләкин бу очракта инде колбиләүчелек не причем!»

Шул вакытта палатага аны дәвалый торган врач килеп керде.

— Я, ничек, тәнең сызламыймы? — дип сорады ул кергә-керешкә.

— Бик аз гына. Ләкин түзәрлек.

— Иртәгә тәнең бик каты сызлар. Бөтен мускулларың авыртыр. Бәлки әле төнлә үк авырта башлар. Иртәгә иртән урыныңнан тора алмавың да ихтимал. Ике көн буе шулай авыртыр әле ул. Бронхоскопиядән соң һәр вакыт шулай була.

— Мин бүген ашамаган.

— Беләм. Озакламый китерерләр. Ашханәгә үзең барып йөрмә, ашарыңа палатаңа гына китерерләр. Һәм иртәгә дә барып йөрмә. Берсекөнгә дә. Палатаңда гына аша һәм ят. Мускулларыңның авыртуы беткәнче ят.

— Бронхлардан нәрсә таптылар? — диде Тимер, төп мәсьәләгә күчеп.

— Бронхоскопия нәтиҗәләре әлегә бөтенләй үк эшкәртелеп бетмәде. Ләкин куркыныч нәрсә юклыгы билгеле. Иртәгә бу мәсьәләдә биш кенә минутлык медколлегия утырышы була. Шунда барысы да ачыкланачак. Минем уйлау буенча, кан бары тик үпкәдән генә килергә мөмкин. Бронхоскопиядән соң мин шундый нәтиҗәгә килдем. Ләкин бу гайре табигый хәл түгел. Профессор шулай диде. Сирәк очрый торган хәл, ләкин гайре табигый түгел.

— Сирәк очрый торган хәл гадәти хәлгә караганда куркынычракмы?

— Һәр очракта да шулай була дип әйтүе кыен. Кайчакта шулай, кайчакта киресенчә. Минем уемча, синең очрак куркынычлылардан саналмый. Гадәти авыруларга караганда сине дәвалау озаграк кына булачак. Аерма шунда гына. Синең организмың даруларны озаграк үзләштерә. Шуңа күрә кан килү дә озаккарак сузыла.

— Бу сезнең катгый карашыгызмы?

— Катгый дип әйтерлек. Иртәгәге медколлегия бу карашка күп үзгәреш кертмәс дип уйлыйм.

— Нигә сез минем белән болай ачыктан-ачык сөйләшәсез? — диде Тимер. — Әлегә бөтенләй үк хәл ителеп бетмәгән мәсьәләләр турында да әйтәсез. Медицина этикасы буенча, авыруга тәмам хәл ителгән мәсьәләләр генә әйтелә. Һәрхәлдә, гадәттә врачның икеләнүен авыру сизмәскә тиеш. Ә сез медколлегия утырышы булганчы ук үз уйларыгызны ачып саласыз.

— Мин бары тик синең белән генә шулай сөйләшәм.

— Ни өчен?

— Син — архитектор.

— Архитектураның монда ни катнашы бар?

— Архитектураның бер катнашы да юк. Ләкин син, архитектор буларак, иҗат кешесе. Шуңа күрә әгәр мин нәрсәне дә булса әйтеп бетермәсәм яки ялганласам, син моны шунда ук сизәр идең. Дөрес, син минем, конкрет алганда, нәрсәне әйтмәвемне һәм нәрсәне ялганлаганымны белмәс идең, ләкин нәрсәнедер әйтмәвемне яки ялганлавымны сизәр идең. Ә бу инде синә авыруың һәм минем турыда төрлечә уйларга урын калдырыр иде. Шуңа мин синең белән һәр вакыт ачыктан-ачык сөйләшергә булдым.

— Сез дөрес эшлисез. Һәм бу нәкъ шулай булыр иде дә.

Тимер бу тәҗрибәле һәм олы яшьтәге абзый белән үзе дә ачыктан-ачык сөйләшергә ярата иде.

— Ә нигә сез минем белән «син» дип сөйләшәсез? — диде Тимер, эчкерсез кызыксыну белән. — Мин сезнең белән һәр вакыт «сез» дип сөйләшәм, ә менә сез «син» дисез.

— Миңа шулай җайлырак, — диде врач. — Һәм врачларга гомумән шулай җайлырак. «Син»нең «сез»гә караганда ышандыру көче зуррак. «Сез» арада ниндидер киртә, җайсызлык, барьер калдыра. Ә «син» дип сөйләшкәндә һәр сүз нәкъ үз ноктасына барып төртелә. Авыруны үзенә ышандыруда моның әһәмияте бик зур. Авыру үзенең врачына тәмам ышанганда гына дәвалану уңышлы була ала. Ләкин авырулар врач белән «сез» дип сөйләшергә тиеш. Монысын инде элементар этика таләп итә. Хәтта авыру үзенең эше, яше, җәмгыятьтә тоткан урыны белән врачтан өстенрәк булса да.

— Сез дөрес эшлисез, — диде Тимер, тагын врач белән килешеп.

Врач чыгып киткәч, Тимергә кичке аш китерделәр. Ул караватыннан тормыйча, яткан килеш кенә ашады. Аңа шулай җайлы һәм рәхәт иде. Ашагач кинәт аның аңында булган баягы томаннар таралып китте, тәне җиңеләйде һәм ул урыныннан торып бераз сызымнарын эшләргә булды. Өстәл янына ул аерата күтәренке бер дәрт һәм җиңеллек белән утырды һәм шул утыруыннан төнге сәгать бергә кадәр тормады. Күп эшләде, әйбәт эшләде ул бүген. Төнге сәгать бердә арыганлыгын сизде һәм, тиз-тиз чишенеп, йокларга ятты.

## 19

Төннеңме, таңныңмы бер мәлендә ул бөтен тәне сызлауга чыдый алмыйча уянып китте. Аның бөтен мускуллары үтереп сызлый иде. Шунысы кызык, бу сызлау Тимерне кәефсезләндермәде дә, куркытмады да. Киресенчә, мондый халәт ничектер кызык булып тоелды Тимергә. Чөнки бит врач мускулларның авыртачагын алдан ук әйтеп куйган иде. Тимер борылып ятыйм дип кузгалган гына иде, чак кычкырып җибәрмәде. Аз гына кузгалдың исә, мускуллар түзеп булмаслык авырта башлый икән. «Монысы инде бик үк шәп түгел, — дип уйлады Тимер.— Ком тутырган капчык кебек, кымшанмыйча да ят, имеш». Дөрес, соңыннан ул кузгалды, икенче ягына әйләнеп ятты. Ләкин бик авырлык белән. Кул, аяк, корсак, җилкә мускулларын кузгату шундый кыен иде, әйтерсең лә Тимернең бөтен тәнен бәләк белән тапалаганнар.

Озакламый мондый халәт Тимергә бер дә кызык булып тоелмый башлады. Авырту үзенекен итте, төннең калган өлешен Тимер бик авырлык белән үткәрде. Иртән инде ул урыныннан тора алмаслык хәлгә килгән иде. Торба тыккан тамак төкерек йотып булмаслык дәрәҗәдә авырта, тәндәге һәр мускул: «Мин монда, мин монда, мин монда», — дип кычкырган шикелле, үз-үзләрен сиздереп тора. Тимер шәфкать туташы кергәнгә кадәр хәрәкәтсез ятарга мәҗбүр булды.

Ниһаять, палатага шәфкать туташы килеп керде. Ул бүген нигәдер аеруча ягымлы һәм хәвефлерәк иде бугай. Тимер моны шунда ук сизде һәм шәфкать туташының мондый халәтен үзенең гаҗиз булып урында ятуын кызгануга юрады. Шәфкать туташы караватк кырыена килеп утырды да Тимернең кулын алып, пульсын тикшерә башлады. Ул ягымлы һәм хәвефле күзләре белән Тимергә карап:

— Бүген төнлә берәр төш күрмәдегезме? — дип сорады.

Тимернең тәне буйлап кайнар бер дулкын сызылып узды.

— Әниме? — диде ул калтыравык тавыш белән.

— Әйе, — диде шәфкать туташы. Ягымлы күзләрен идәнгә төбәде, ак халатының кесәсеннән телеграмма кәгазен алып, Тимергә сузды.

Тимер күзе белән генә тумбочкага күрсәтте. Аның телеграмманы укыйсы да, күрәсе дә килми иде. Шәфкать туташы үрелеп кенә кәгазьне тумбочкага куйды, ләкин Тимернең пульсын тоткан кулын җибәрмәде.

Күз кабаклары тагын авырая башлады. Нәкъ кичә наркоз биргәндәге шикелле. Тимер хәлсезләнеп күзләрен йомды һәм аның күз кабаклары арасында ике бөртек күз яше кысылып калды. Шәфкать туташы пульсның үзгәрешен тойды, ләкин кан тибеше нормадан читкә китмәгән иде.

Тимер артыгын елый алмады. Күз кабаклары арасына кысылып калган ике күз яше һаман шул көенчә тора бирде. Тимер бер нәрсә дә уйламады да, еламады да, йокламады да. Шул көенчә ятты да ятты. Шәфкать туташы да Тимернең пульсын тоеп утырган хәлдә кузгалмады да, дәшмәде дә.

Инде байтак вакыт үтте. Шәфкать туташы Тимернең пульсы акрын-акрын яңадан элекке хәленә кайтуын тойды. Димәк, Тимер нәрсәдер уйлый башлаган иде. Менә ул күзен ачты. Кысылып торган әлеге ике бөртек күз яше битләрен тәгәрәп төшеп киттеләр. Алар инде суынырга өлгергән, сап-салкыннар иде.

— Моннан Казанга шалтырату кыенмы? — дип сорады Тимер.

— Туры телефон элемтәсе юк, ләкин заказ белән биш-алты минуттан бирәләр,— диде шәфкать туташы.

— Казанга, өйдәгеләргә шалтыратасы иде, — диде Тимер, — хәзер үк минем янга килсеннәр. Әнә, өстәлнең теге башындагы урындык аркасында минем пиджак эленеп тора. Шуның сул якгагы түш кесәсендә телефон номерлары язылган блокнот булыр. Шуны гына алып бирегезче?

Шәфкать туташы блокнотны алып килде. Тимер аны уң кулы белән үрелеп алды. Кулны кузгатканда тәндәге бөтен мускуллар тагын сызланып куйды. «Бүген минем мускулларның болай авыртуы ярый әле, — дип уйлап алды Тимер. — Алар миңа өерелеп килгән уйларны куачаклар һәм мине кайбер нәрсәләрдән коткарып калачаклар».

Шәфкать туташы кирәкле исем-фамилияне һәм телефон номерын язып алгач, чыгып китте.

Тәндәге авыртулар гына Тимергә өерелеп килгән уйларын һәм ул кичерәсе кичерешләрне куып бетерә алмады, әлбәттә. Ләкин бер уйның да рәте-чираты юк иде. Әллә кайчан булып үткән вакыйгалар бернинди тәртипкә салынмаган рәвештә күз алдыннан узып китәләр. Бала чактагы хәлләр өйләнгән чорга кушылып китә, әнисе белән кызы бер кеше булып күз алдына баса. Әйтерсең лә төрле фильмнардан теләсә нинди кадрларны кисеп-кисеп алып бергә ябыштырганнар да шуны Тимергә бер кинофильм итеп күрсәтәләр. Ләкин бу корама фильм Тимерне куркыта иде. Һәм күңелдә нәрсәгәдер бик нык үпкәләү хисе уята. Елыйсы килми, ә ачу килә. Нәрсәгәдер бик нык ачуы килә һәм Тимер бөтен ачуын үз тәненнән ала башлады. Ул, аз гына кузгалса да тәнендәге бөтен мускулларының авыртасын белгән көе, куллары, аяклары белән селтәнде, авыртудан күз аллары караңгыланганчы башын артка таба каерды. Ләкин күңелгә кереп оялаган, нииндидер аңлашылмый торган ачу һаман басылмады.

Телефоннан Казанга шалтыратып, яңадан палатага кергән шәфкать туташы, Тимернең бу кыланышын күргәч, аны әрләп алды:

— Ә монысы бөтенләй кирәкми инде. Мондый гимнастика әлегә сезнең мускулларыгыз өчен зарарлы. Бу бөтенләй килешә торган эш түгел.

Шунда гына Тимер үз-үзен кулга алырга кирәклеген аңлады. Чөнки ул, әлеге адрессыз ачуыннан буылып, шәфкать туташына чак кына: «Ә сезнең анда ни эшегез бар? Чыгып китегез палатадан! Шайтаныма олагыгыз барыгыз да!» — дип кычкырмыйча калды. Ул күңелендәге билгесез ачуның нәфрәткә әверелә баруын сизде. Әгәр бу нәфрәткә ирек бирсәң, ул ерткычлыкка ук барып җитәргә дә мөмкин иде. Ә ерткычлыктан инде ниндидер акылсызлык эшләп ташлауга да ерак калмый. Әнисенең үлеменә, чарасызлыкка, үзенең хәзер авылда түгел, ә менә бу больницада ятарга мәҗбүрлеккә карата булган ачу әнә шундый шәфкатьсезлеккә, кыргый теләккә әверелә башлады. Менә ни өчен үз-үзен кулга алырга кирәк иде Тимергә.

«Нигә елатмый соң, ичмасам, — дип уйлады ул аннары аптырап. — Елаганда күңел тәмам йомшара бит. Ә болай һаман катылана гына бара. Әни үлгәнче күпме елап-елап та, хәзер елый алмыйча интегәм һәм күңелгә изгелек түгел, ә әшәкелек тула бара.. Әнисез кешеләрнең күңеле шулай әшәке була микәнни соң?»

Тимер, үз-үзен тыярга тырышып, аскы иренен тешләре белән кысты һәм һаман да әле нишләргә белмичә гасабиланып караваты янында басып торган шәфкать туташына карады. Ләкин Тимернең күзләрендә әле һаман ачулы очкыннар бетеп җитмәгән иде. Дөресен генә әйткәндә, аның бу күз карашы ямьсез иде, врачлар һәм шәфкать туташлары гадәтләнгәнчә түгел иде. Бу караштан шәфкать туташы үзен ниндидер бер гаепле кеше сыман итеп тоя башлады һәм:

— Әллә сезнең ялгыз каласыгыз киләме? — дип сорады.

— Әйе, — диде Тимер алдап. Чөнки ул үзенең ялгыз каласы килүкилмәвен анык кына белми иде. Шулай да аңа ялгызы гына калу әйбәтрәк булачак бугай.

Шәфкать туташы, һаман үзен гаепле кеше сыман тойган хәлдә, палатадан чыгып китте. Ул китүгә Тимернең күз алдыннан баягы төрле кадрлардан кискәләп оештырылган корама фильм тагын үтә башлады. Бу фильм бик озак дәвам итте һәм һаман аның «Фильм тәмам» дигән соңгы титры күренмәде.

Күпмедер вакыт шулай яткач, кинәт кадрга Ычтуп дәдәй килеп керде.

— Нихәл, бала? — диде ул. Картая-картая бәләкәй генә булып калган күзләреннән сытылып чыккан күз яшьләрен тыярга тырышты. — Айкаламы, чайкаламы җаның, телем-телем теленәме? Теленсен, тыйма. Баланың җаны ана өчен телем-телем теленергә тиеш. Тик усалланма. Зур кайгы кешене усаллата, төкселәндерә, кырысландыра. Кайгы әйбәт кенә кешене дә эчтән кимереп акрын-акрын әшәкеләндерә бара. Ә син бирешмә. Һәм иртәгә үк шәфкать туташыннан гафу үтен. Син аңа бүген начар итеп карадың. Тиз бирешә башладың, бала. Әниең алай түгел иде. Чиксез-чамасыз кайгылар төште аның башына, ә күңеле саф килеш калды. Асыл кеше иде Фәкилә. Күрше-күлән бөтенебез дә иң авыр чакларыбызда киңәшкә аңа килдек. Һәрбер кайгының дәвасын белә иде. Чөнки ул кичереп карамаган кайгы юк иде. Тик түзде Фәкилә, начараймады.

Аннары Ычтуп дәдәй экраннан Тимергә таба иелә төште һәм шыпырт кына:

— Миңа Фәкилә алдында оят, балам, — диде.

— Ни өчен? — диде Тимер аптырап.

— Фәкилә алтмышын да тутыра алмыйча китеп барды, ә менә мин туксаннан аштым, һаман яшим. Оялам, Фәкилә гомерен яшимдер кебек тоела. Әгәр шулай булса, бу коточкыч нәрсә.

Ычтуп дәдәй картларча йомшак итеп елап җибәрде. Ләкин Тимер аны юатмады. Дөресрәге, юата алмады. Чөнки бу вакытта аның үз хәле бик мөшкел иде. Бүген әле аңа үзенә юатучы кирәк.

— Мин сезнең нәсел кешесе түгел, — дип дәвам итте бераздан Ычтуп агай. — Безнең арада чыбык очы кадәр дә туганлык юк. Шулай да мин бүген синең катыңа килдем, Тимер. Әй, бала, бала, никтер бик яраттым шул мин сине. Мин бит хәзер инде авылда иң карт кеше, шулай булгач, бөтен авылдашлар да минем балаларым, һәрберегез кадерле миңа. Фәкилә аеруча асыл балам иде. Инде менә син калдың. Мин бүген сине юатырга дип килдем. Теге вакытта керәшеннәрнең килеп чыгышы турында тузга язмаган сүзләр сөйләвем өчен, сиңа ачуланган булып тузгып йөрүләрем өчен ачуланма. Ул чакта күңелләр көр иде. Синеке дә, минеке дә. Күңеле көр булган кешегә тузга язмаган сүз сөйләсә дә килешә.

— Рәхмәт, Ычтуп дәдәй, синең килүең миңа әйбәт булды әле. Дөм ятим калган көнне янымда синең булуың азмы-күпме юаныч бит.

— Рәхмәт, бала. Яшь булсаң да, акылың бар синең. Гомерле була күр. Фәкилә үләр алдыннан әйтте, яшәлеп бетмәгән гомерем кала,

балаларыма булсын диде. Кара аны, юк-барга түгеп-чәчеп бетермә әниең гомерен. Әйбәт эшләргә генә сарыф ит.

Шулай диде дә Ычтуп дәдәй экраннан китеп югалды.

Ычтуп дәдәй Тимернең күңеленә кереп оялый башлаган ямьсез хисләрне дә үзе белән алып китте кебек. Бу — туган як тамырының шифалы дәвасы иде. Һәрхәлдә, Тимер туксан яшәр авылдашы Ычтуп дәдәй турында уйлаган уен шуңа юрады. Һәм бу чыннан да шулай иде.

## ӨЧЕНЧЕ БҮЛЕК

# Яшәү

### 20

Озакламый больницага Тимернең хатыны килеп җитте. Ул юлда ук елаган булса кирәк, күз төпләре җилсенеп, борын яфраклары кызарып тора иде. Тимер хатынының хәсрәтле күзләренә күтәрелеп карады да кинәт үзенең аңа карата булган мөнәсәбәтендә нинди дер үзгәреш булганлыгын сизеп алды. Нинди икәнен төгәл генә әйтеп булмый, ләкин үзгәреш бар яки булырга тора иде. Чөнки кинәт хатыны аңа тормыш иптәше, сөйгәне кебек кенә түгел, ә әнисе кебек тә булып китте. Бу хисне инде Тимер элегрәк тә сизенеп йөри иде бугай. Чыннан да, аның хатыны белән өйләнешкәннән соңгы тормышы кайчандыр авылда, әнисе янында яшәгән тормышына бик охшаш иде. Мәсәлән, авылда китапханәдә эшләгән чагында ул өйгә аракы эчеп яки кичен артык соңгарып кайтырга курка һәм ояла, чөнки әнисе ачулана иде. Нәкъ шуның шикелле Тимер хәзер дә өйгә аракы эчеп яки соңга калып кайтырга курка һәм ояла, чөнки хатыны ачулана. Бу яктан караганда хатыны белән әнисе бер-берсенә бик охшаганнар. Аннары килеп, авылда чакта аны әнисе аш пешереп ашата, керен юа,урын-җирен, кием-салымын карап тота, элгече өзелсә элгечен, төймәсе төшсә төймәсен тага иде. Ә хәзер бу эшләрне хатыны эшли. Бу яктан да алар бер-берсенә нык охшаганнар. Менә ни өчен Тимер хатынын әнисе сымаграк тоеп йөргән икән. Ләкин әле бүгенге көнгә кадәр Тимернең тагын бер гаять тә рәхәт, гаять тә татлы, гаять тә назлы бер хисе бар иде. Ул — кайдадыр еракта, бер ягы комлы тау, бер ягы урманлы калкулык белән уратып алынган кечкенә генә керәшен авылында күңелгә бик тә якын булган бер кешең — әниең бар икәнен тою хисе һәм һәр вакыт шуның янына кайтасы, аны күрәсе, аның белән сөйләшеп, киңәшләшеп утырасы килү хисе. Менә инде бүгеннән соң бу хискә... юк, нокта куелмады, бүгеннән соң инде бу хис тә менә хәзер аның янәшәсендә басып торучы, аның хәсрәте белән хәсрәткә баткан шушы хатынга күчәчәк. Дөрес, Тимердә әнисенең кабере янына, авылга кайтасы килү хисе беркайчан да сүрелмәячәк. Ләкин, ни әйтсәң дә, кабер кабер инде ул, әнинең үзе түгел. Кызганычка каршы, каберләр беркайчан да әниләрне алыштыра алмый шул.

Шунда Тимер теге чакта, больницага кергәч, саф мәхәббәт, авылларына унынчыны тәмамларга дип килгән кыз һәм хатыны турында уйлаган уйларыннан кинәт кенә оялып куйды. Юк, ул чактагы уйларны бетереп ташламады Тимер — чөнки алар дөрес уйлар иде. Ләкин хәзер, яраткан хатының белән бер түбә астында унбиш ел яшәгәч, аларны уйламасаң да ярый икән. Хәтта алар чишмә суы төсле саф, дөрес уйлар булсалар да.

Тимер хатыны килгәч бер мизгел эчендә генә әнә шундый уйлар уйлап куйды һәм хәтта хатынының йөзендә әнисенең йөз чалымнарын да күргәндәй булды. Ләкин монысы инде аның өзелеп-өзелеп әнисен күрәсе килгәннән генә иде. Монысы аның бары тик хыял җимеше генә. Чөнки инде Тимер бүтән беркайчан да, беркайда да әнисе йөзенең чалымнарын күрә алмаячак иде.

Тимер хатынына, ым белән генә, тумбочка өстендәге телеграмма кәгазен күрсәтте. Тегесе телеграмманы ачып укыганда Тимер ап-ак кәгазьгә басылган кап-кара хәрефләрне күреп алды. Ак кабер ташына чокып язылган караңгы ,җан өшеткеч караңгы хәрефләргә охшый иде алар. Тимер карават башында эленеп торган ап-ак сөлгене алып битенә каплады да үксеп-үксеп елап җибәрде. Монысы инде аңсыз, томанлы, исәнгерәүле елау түгел, ә аек, саф, бүгенге хәбәрнең бөтен нечкәлекләренә төшенгән ачы елау иде.

Икенче көнне Тимер янына дуслары килде. Алар бу юлы палатага теге чактагы кебек шаулап-гөрләп, гөлдер-гөлдер көлешә-көлешә килеп кермәделәр. Өчесе дә шып-шыпырт һәм сабыр-салмак иделәр. Алар урамда ук Тимер янында аның әнисе турында күп сөйләшмәскә, аның болай да әрнеп торган ярасына тоз салмаска килештеләр. Һәм дөрес тә эшләделәр. Керү белән тәртипле генә исәнләштеләр, артык нечкәрмичә генә Тимернең кайгысын уртаклаштылар. Низам бүгенге газетаны алып килгән иде, портфеленнән алып шуны Тимергә бирде. Газетаның соңгы битендә, астагы сул як почмакта Архитекторлар союзының Тимер кайгысын уртаклашкан кечкенә генә белдерүе басылган. Тимер аның басылачагын белә иде, шуңа күрә кара кайма белән әйләндереп алынган бу кечкенә белдерү аңа артык авыр тәэсир итмәде. «Әнинең исеме беренче һәм соңгы мәртәбә типография хәрефләре белән басылды», — дип уйлады Тимер.

Дуслары Тимернең ниндидер уйларга бирелә башлавын шунда ук тоеп алдылар һәм аны ул уйларыннан аралап алу өчен төрле сораулар бирә башладылар.

— Я, исәнлегең ничек? — диде Низам. — Кан килү турында врачлар бер-бер нәтиҗәгә килә алдылармы әле?

— Әйе, — диде Тимер. — Ниһаять, бер нәтиҗәгә килделәр.

— Я, я? — диделәр Миндуп белән Рөсти түземсезләнеп.

— Канның үпкәдән килүе тулысынча ачыкланды. Күптән түгел генә тын юлларын торба белән карадылар. Авыру анда да бераз бар. Ләкин анысы куркыныч түгел. Хәзер җиң сызганып үпкәне, бары тик үпкәне генә дәвалаячакбыз, диделәр.

— Анысы әйбәт булган, — диде Миндуп. — Чирне тәмам ачыклап бетерү үзе ярты дәва ул.

— Үзегездә ниләр бар? — дип сорады Тимер. — Архитекторлар союзында нинди яңалыклар? Күптән белешкән юк.

Тегеләр өчесе дә бер-берсенә караштырып алдылар. Аларның ниндидер әһәмиятле хәбәр әйтәчәкләре көн кебек ачык иде. Шуңа Тимер түземсезләнеп Низамга карады.

— Алай шаккатырлык нәрсә юк, — диде Низам, хәбәргә юри бик зур игътибар бирмәскә тырышып. — Мәрдән абзый югары оешмаларга жалоба язган.

— Кем өстеннән? — диде Тимер, тагын да кызыксына төшеп. — Мин Мәрдән абзыйның жалоба язуына бер дә шаккатмыйм, моны аннан көтеп була. Тик менә ул кем өстеннән язган, шунысы кызык.

— Талант өстеннән, — диде Рөсти, мәсьәләне гадәтенчә дорфа һәм уптым илаһи гына йотарга тырышып.

— Һәм Архитекторлар союзы соңгы елларда ирешкән уңышлар өстеннән, — дип өстәде аңа Миндуп.

— Ашыкмагыз әле. Кешегә аңлатыбрак сөйләргә кирәк, — диде Низам, Рөсти белән Миндупны шелтәләбрәк.

Низам дөрес әйтә иде. Миндуп белән Рөсти яшь әтәчләр кебек Мәрдән абзыйны чукый башладылар, ә Тимер әле ни өчен икәнен тәгаен генә белми.

— Мәрдән абзый кайбер архитекторларның проектларын тормышка ашыру зыянлы булачак дип расларга маташа, — дип дәвам итте Низам. — Аеруча безгә ташлана. Мәсәлән, Миндуп проекты белән төзелә башларга тиешле кафены, Рөстинең Мәскәүгә расларга җибәрергә әзерләнгән курчак театры проектын, минем былтыр төзелгән читек тегү фабрикасы бинасын кире кага.

— Ничек инде кире кага? — дип гаҗәпләнде Тимер. — Ә дәлилләр?

— Җалобада ул конкрет дәлилләр китерми. Проектларны гомуми методологик яктан зыянлы дип исәпли. Яшьләр дөрес методология белән бармыйлар, ди. Хәтта зыянлы юлдан баралар, ди. Үзенең фикерләрен ныклы, тирән эчтәлекле цитаталар белән ныгытырга маташа. Цитаталарда әйтелгән фикерләрнең берсенә дә каршы килеп булмый.

— Димәк, сезнеңчә дә Мәрдән абзый хаклы булып чыгамыни инде? — диде Тимер кызыбрак.

— Һич юк, — диде җитди Низам сабыр гына. — Шунысы кызык, безнең проектлар Мәрдән абзый китергән цитаталарда әйтелгән бер генә фикергә дә каршы килмиләр.

— Шулай булгач, нигә тел озайтып торырга? — диде Тимер.

— Тел озайтмыйча мөмкин түгел,— диде Низам.— Мәрдән абзый җалобаны шундый итеп язган ки, мәсьәләне үзебездә, махсус белгечләр арасында гына хәл итеп була. Шуңа күрә дә югары оешмалар җалобаны хәл итү өчен Архитекторлар союзына җибәрделәр. Ләкин бит әле безнең проектларның Мәрдән абзый китергән цитаталарга каршы килмәвен тәфсилләп ачып саласы ,дәлиллисе бар. Моңа шактый вакыт кирәк булачак. Җалоба буенча чыгыш ясарга билгеләнгән махсус белгеч, мәсьәләне дәлилләп доклад әзерләү өчен, ай ярым вакыт сорый. Һәм ул дөрес эшли, ай ярымсыз мәсьәләнең очына чыгып булмаячак. Югары оешмалар, мәсьәлә хәл ителгәнче дип, җалобада телгә алынган проектларның хәрәкәтен туктатып торырга куштылар. Шуның аркасында Миндупның проекты буенча башланган коммуникация эшләре туктатылды. Ярый, күчмә техниканы башка объектка алдылар, ди, ләкин бит кафе төзеләчәк урынга китереп көйләнгән башка техника җиһазлары һәм корылмалар ай ярым тик торачак.

— Ай ярым гына булса ни әйтер идең әле, — диде ачуы чыккан Миндуп. — Җалоба бездә тикшерелү белән төзелештә эш башланмаячак бит, чөнки җалобаны тикшерү нәтиҗәләре югары оешмаларда яңадан каралачак. Кайчан каралыр ул, ярый ла, көне-сәгате белән каралса. Ә бер ай, ике ай, өч ай ятса. Төзелешнең яңадан башлануы ярты елга кичектерелергә мөмкин.

— Да-а-а! — диде Тимер уйланып. — Ә Рөсти проектын нишләтәсез?

— Ул да ай ярым буена Мәскәүгә китмичә ятачак.

— Ай ярымнан соң югары оешмада каралачак диген, — дип төзәтте Низамны Рөсти.— Курчак театры белән курчак уены ясады бу Мәрдән абзый.

— Олы кеше турында ямьсез сөйләшмә, — дип тыйды аны җитди Низам. — Тимер, Мәрдән абзый сиңа да бер җөмлә кызганмаган.

— Миңа? Минем мунча проекты бит әле больница өстәле өстендә ята.

— Анысы шулай, — диде Низам. — Мәрдән абзый, мунча кебек катлаулы һәм четерекле проектны сиңа тапшырып Архитектерлар союзы ялгышты, дип исәпли. Булдыра алмаячак, башы яшь, ди.

— Һм-м-м,— дип мыңгырдады Тимер аптырап. Аның үзен яклап чәпчисе килми иде.

— Низам,— дип дәште кинәт Рөсти. Аның мут күзләренә карағанда, ул тагын ниндидер дорфа шаяру уйлап тапкан иде булса кирәк.— Ә нигә син Тимергә Мәрдән абзыйның синең мораль тотнаксызлыгың турында да язганны әйтмисең?

— Ә-ә-ә,— дип елмайды Низам.— Аның нәрсәсен әйтеп торасың инде.

— Әйт, әйт,— диде Тимер кызыксынып.

— Пүчтәк. Мәрдән абзый мине мораль яктан чиста булмаган житәкче, аның Казан зыялылары арасында сөяркәсе бар дип сөйлиләр, дип язган. Ләкин анысы инде төп эшкә кагылмый.

Барысы да тынып калды. Бу сүздән көләргә дә, көлмәскә дә белмәделәр алар. Бераздан Тимер, нәрсәнедер искә төшереп, Низамга карады.

— Синең фабрикаң премиягә куелды бит. Газетада игълан ителгән исемлектә бар иде. Премиягә тәкъдим ителгән әйбер өстеннән жалоба... Монысын ничек аңларга?

— Премия комитеты утырышына кадәр нибары бер ай вакыт калды,— диде Низам.— Жалобаны тикшерү жыелышы премияләр бирелгәннән соң булачак. Димәк, Архитекторлар союзы утырышка кадәр мәсьәләне хәл итеп өлгермәячәк. Ләкин миңа әйттеләр, фабриканың премиягә тәкъдим ителүе үз көчендә кала, халыктан нинди отзывлар килер, карарбыз, диделәр.

— Анысы инде комитет эше,— диде Миндуп.

— Комитет Мәрдән абзыйның жалобасын да халыктан килгән бер отзыв итеп теркәп куймаса ярый инде,— диде Рөсти, шаярырга маташкан булып. Ләкин аның бу сүзе шаяру түгел, ә шом иде.

— Әй, премиясе өчен алай бик шаккатмыйм да әле,— диде Низам.

Ләкин ул моны тыйнаклык өчен генә әйтте. Ул, әлбәттә, әйбәт чыккан фабрикасы өчен эчтән горурлана һәм аның премиягә тәкъдим ителүенә шатлана иде. Хәтта бу премиягә өметләнә әле ул. Хәер, халык ни әйтер бит.

— Болары барысы да бик үк гажәп тә түгел әле,— диде Низам, бераз тын гына торгач.— Әлбәттә, Миндупның һәм Рөстинең эшләре ничәдер айга тукталып тору бик кызганыч, ләкин аннан да кызганычрагы бар.

— Анысы нәрсә тагын?— дип сорады Тимер шомланып.

— Жалобага Имаметдинов та кул куйган.

— Теге бездән ике курс түбән укыган, беркайчан да тормышка ашмаячак әллә ниткән проектлар сызучы Имаметдиновмы?

— Әйе.

— Минә монысы аңлашылмый,— диде Тимер.— Аның бит Мәрдән абзыйны жене сөйми иде.

— Һәм безне дә,— дип өстәде Миндуп.

— Монысы катлаулы мәсьәлә,— диде Низам.— Бу турыда нығытып уйламыйча булмый һәм ул турыда монда сүз озайтып торуның кирәге юк.

— Мәсьәләнең бернинди катлаулыгы да юк,— диде Рөсти кызып.— Мәсьәлә ап-ачык. Ике кәжә бер кәбестә тапканнар да, икесе ике яктан килеп кимерә башлаганнар. Кәжәләр арасында бер генә аерма да юк. Тик аларның берсе ак кәжә, икенчесе кара кәжә һәм берсе яшь кәжә, икенчесе карт кәжә. Минә шул гына.

— Кешеләр турында алай дорфа сөйләшмә,— диде Низам, Рөстине тыеп.— Мәсьәлә алай ансат кына хәл ителми.

Һәм Низам хаклы иде.

Тимер әле дуслары киткәч тә күңеле беләң алардан һәм палатада булып алган сөйләшүләрдән аерыла алмады. «Әйе-е-е, — дип сузды ул эчтән генә. — Бүген алар шундый сабыр-салмаклар. Башка вакыттагыча шаярмадылар да, көлмәделәр дә. Аның каравы, алар гомеребезне багышлаячак эшне яраталар һәм беләләр. Бу яктан аларга бер сүз дә әйтеп булмый. Шулай ук алар көнкүрештә дә чисталар, сафлар. Низамның Казан зыялылары арасында сөяркәсе бар икән дигән сүзне дә Низамны шаяртыр өчен генә үзебез уйлап чыгардык ич без. Низамның хатын-кызга карата булган балалыгыннан көләр өчен генә. Ә менә шул җор сүзне Мәрдән абзый чынга алып (ә бәлки чынга әйләндерергә тырышыптыр?) югары оешмаларга җибәргән жалобасына язган. Югарыдагылар бит безнең арадагы шаяруны белмиләр, димәк, алар да бу сүзгә чынлап игътибар итәргә мөмкиннәр. Әлбәттә, дөреслек ачылыр, ләкин бит юк сүзгә нигезләнеп дөреслек ачып утыру үзе үк бик күңелле эш түгел. Низамның сөяркәсе бармы, юкмы дип җыелышта тикшерү алып бару ким дигәндә намуслы кешегә пычрак ату дигән сүз. Шайтан алгырысы, юк кына шаяру сүзе шушындый җитди төс алыр дип кем уйлаган? Шаярганда бераз чаманы арттырып җибәрәбез бугай шул үзебез дә. Моннан соң алны-артны карабрак шаярырга кирәк».

«Аһ, аллам, — дип уйлады аннары Тимер. — Инде шушындый гөнаһсыз шаярулардан да тыела башласаң, дөньяда яшәүнең ни кызыгы кала? Киресенчә, шаярырга кирәк һәм күбрәк шаярырга! Күңелле булсын тормыш, гөрләп торсын.»

«Ә Имаметдиновның танавын җимерергә кирәк, — дип этәчләнде аннары Тимер. — Физик яктан түгел, ә рухи яктан. Без аны, беркайчан да түзеп булмаслык проектларына карап, бу малай эзләнә, тора-бара эзгә төшәр әле дип, Архитекторлар союзына алырга үзебез тәкъдим иттек. Ә ул әнә ни кылана башлаган.

Ләкин Тимер бу этәчләнүенең шактый көчсез бер ыргылу гына икәнен тоеп торды. Чөнки Имаметдиновның жалобага куелган имзасы артында шомлы, Тимергә һәм аның дусларына бөтенләй ят булган бер күренеш бар икәнен искәрмичә мөмкин түгел иде. Әйе, тора-бара Имаметдиновның матур гына иҗат итеп килгән коллектив өчен куркыныч бер көчкә әйләнүе бар. Ул әле яшь, көче ташып тора. Шуның өстенә бөтенләй үк талантсыз да дип булмый. Әгәр дә ул шушы талантны һәм ташып торган көчне иҗатка түгел, ә чын иҗатчылар белән көрәшүгә сарыф итә башласа, югары оешмалардагы җитәкчеләрнең дә, Архитекторлар союзының да башын байтак әйләндерәчәк әле. Бу инде сиңа элеккеге запаслары белән генә трибунага чыгып акыл өйрәтергә тырышучы, төп көчләрен инде күптән сарыф итеп бетергән карт Мәрдән абзый гына түгел. Юк, Имаметдинов Тимер һәм аның дуслары башлаган төп эшне ил һәм заман өчен кирәкмәс якка борып җибәрә алмас. Моның өчен инде алар теш-тырнаклары белән көрәшәчәкләр. Шулай да бу көчле, белемле һәм шактый талантлы тәти егет, бик күп кешеләрнең тәгәрмәченә таяк тыгып, аларны вакытлыча гына булса да төп эштән аерып торырга, бөтенләй кирәкмәс мәшәкатьләр белән мәшгуль булырга мәҗбүр итәчәк әле. Имаметдиновның Тимер күңелендә кузгаткан шомы менә каян килеп чыга. Чөнки Тимернең дә, аның дусларының да һич кенә дә юк-бар эш белән шөгыльләнәселәре килми. Һай, бер дә килми. Алар алдында шундый зур иҗат эшләре торганда ничек инде әллә кайчан билгеле булган хакыйкатьне раслау өчен вакытны әрәм итмәк кирәк?!

«Монда әле эшне алай тиз генә җайлап бетереп булмый икән, — дип уйлады Тимер. — Монда, теләсәң-теләмәсәң дә, юк-бар эш белән

шегыльләнергә туры киләчәк икән әле безгә. Чөнки мин әтәчләнгән бе-
ләп генә Имаметдиновның танавы җимерелеп төшмәячәк. Шактый ка-
ты материалдан ясалган танау булып чыга әле бу безнең өчен. Әйе,
Низам дөрес әйтә, мәсьәләне Рөсти әйткәнчә уптым илаһи гына хәл
итеп булмый икән әле монда».

«Ләкин без барыбер төп юлдан тайпылмабыз, — диде аннары Тимер
үҗәтләнеп. — Без беркайчан да архитектураны кимсеттермәбез. Юк,
без инде Имаметдиновка беркайчан да архитектурадан уенчык ясарга
ирек бирмәбез. Архитектурага карата булган катгый өч таләбебездән
бер генә адым да артка чигенмәбез без. Нык эшләргә, матур эшләргә,
арзан эшләргә! Менә безнең иманыбыз. Шушы өч таләпне үзләштермәгән
бер генә кеше дә бүгенге көндә юньле архитектор була алмый. Хәтта
ул талантлы кеше булса да! Шушы өч таләпнең берсен генә өнәп бетер-
мәсәң дә, юньле архитектор булып булмый хәзерге көндә. Бигрәк тә бе-
ренче икесен. Ә өченчесе — бүгенге көн таләбе. Һәм безгә монысы бе-
лән дә килешмичә ярамый. Бүген производство бездән матур һәм нык
биналарны тизрәк төзүне сорый. Һәрхәлдә, төзелешкә үз вакытында
нокта куя белүне. Еллар буена сузыла торган эленке-салынкы төзелеш
безгә кирәкми. Дөрес, монда бер архитектор гына берни дә эшли ал-
мый, әлбәттә. Төзүчеләрнең роле зуррак монда. Шулай да, бүгенге ар-
хитектор төзүче кулына чагыштырмача тиз генә төзеп була торган про-
ект эшләп бирергә тиеш. Ә Имаметдиновның бөтен архитекторлыгы кә-
газьдә генә. Ул синең производство мөмкинлекләрең белән дә, вакыт
таләбе белән дә исәпләшмәскә чамалый. Ләкин безнең өчен ватман кә-
газеннән төзелеш объектына күчә алмаган архитектура әсәренең бәя-
се бер тиен. Без мондый әсәрне яклаучыларга ким дигәндә ялган сән-
гатькяр дип кенә әйтәбез.

Менә ни өчен мин мунчамны кәгазьгә төшерер алдыннан ук аның
төзеләчәк урыны, кешеләргә җайлылыгы, төзү мөмкинлекләре һәм, әл-
бәттә, шәһәр ансамблендә ничегрәк булып күренәчәге турында уйла-
дым. Ләкин әле аның эше күп шул, бик күп. Шулай да эшләрмен мин
аны, Имаметдиновка, Мәрдән абзыйга үч итеп, менә дигән мунча про-
екты ясармын. Һәм, мунча төзелеп беткәч, авылдан Ычтуп дәдәйне алып
килермен дә, без икәүләп мунча керербез... Аннан соң минем ул мунча-
ны әнигә дә күрсәтәсем киләчәк. Ләкин инде монысын эшләп булмая-
чак. Беркайчан да... беркайчан да...»

## 22

Ниһаять, көннәр бер эзгә төшеп тыныч кына ага башлады. Март үт-
те, апрель, май үтте, инде менә июнь дә үтеп бара. Тимер ята торган
больница тирәсендәге урманда әле кайчан гына бил тиңентен кар иде.
Кар япмасы акрын-акрын басыла барып, ниһаять, былтыргы яфраклар
астына ук кереп югалды. Ул да булмады, җирдәге каралып, калҗаеп,
куырылып беткән былтыргы яфракларны сыек яшел төстәге очлы үлән
кыяклары тишеп чыкты. Озак та үтмәде, әлеге очлы үлән кыяклары
шундый күбәйделәр һәм биегәйделәр, теге кипкән яфраклар тәмам кү-
ренмәс булды. «Безнең көндәлек мәшәкатьләр дә шушы очлы үлән кы-
яклары кебек узган сагышларны, кайгы-хәсрәтләрне тишеп чыгалар һәм
аларны тәмам каплап китәләр, — дип уйлады Тимер. — Ләкин мин әни-
гә карата булган хисләремне һич кенә дә моның белән чагыштырмас
идем. Һәм әнине калҗаеп, каралып беткән былтыргы яфраклар белән
дә чагыштырасым килми».

Тимер карт бер нарат төбендә тукталып калды. «Ә нәрсә белән ча-
гыштырырга мөмкин соң әле әнине бу урманда? Әһә, менә бу нарат
белән чагыштыру әйбәт була бугай. Әйе, әнкәй минем күңелдә шушы

карт нарат кебек җәен дә, кышын да мәңге яшел килеш сакланыр. Дөрес, нарат та үз ылысларын коймый түгел, коя. Ләкин ул аны яфраклы агачлар кебек берьюлы коеп ташламый. Иске ылыс коела бара, яңасы үсә тора. Шуңа күрә дә нарат агачы безгә беркайчан да ямь-яшел ылысларын җуймаган кебек булып тоела. Минем әниемә карата булган хисләрем дә шулай булырлар. Бер төрләләре искереп хәтер сандыгыннан җуела барсалар, алар урынына икенче төрле өр-яңа хисләр өстәлер».

Кинәт Тимер үзенең бу больницада киләчәк турында уйлый алмаячагы хакындагы фикерләрен исенә төшерде.

Ул чакта ялгышкан икән Тимер. Чөнки аннан соң инде ничәмә-ничә мәртәбә киләчәк турында уйлады ул. Һәм начар итеп түгел. Гел яхшы, матур һәм перспективалы итеп уйлады ул киләчәк турында, Һәм дөрес тә эшләде. Мондый кәеф аның авыруын уңышлы дәвалауга бик нык ярдәм итте. Теге чакта бронхоскопиядән соң бер ай эчендә үпкәдән кан килүне туктаттылар. Ә аннан соң дәвалану шундый әйбәт китте ки, врачлар үзләре дә шаккаттылар. Хәзер инде Тимер тәмам тазарып килә һәм үзен менә дигән итеп хис итә. Ә соңгы айлардагы эшләве! Җир җимертеп эшләде Тимер. Сызымнар үзләреннән-үзләре агылып торды. Илһам килсә дә килә икән кешегә! Башка вакытта бу кадәр сызымны еллар буена да эшләп бетереп булмас иде. Мондый көчне аңа әнисе үлгәннән соң үзен олыгайтып җибәргән нindидер изге хисләр, Мәрдән абзыйга һәм Имаметдиновка үз көчен күрсәтәсе килү һәм җаны-тәне белән савыгасы, тереләсе килү теләге бирде. Моның нәкъ шулай икәнен Тимер тоеп тора һәм шуны тою аңа яңадан-яңа көч өсти.

Дусларының уңышлары да байтак көч бирде бугай Тимергә. Теге чакта Мәрдән абзыйның жалобасын тикшергән җыелыш тулысынча алар файдасына булды. Ул гына да түгел, Мәрдән абзый белән Имаметдиновка бик нык эләккән дә әле. Трибунадан торып бөтен Архитекторлар союзыннан гафу үтенергә мәҗбүр булган тегеләр. Дөрес, бу гафу үтенү генә Тимерне дә, аның дусларын да тынычландырмады. Чөнки трибуна Мәрдән абзый белән Имаметдинов киләчәктә тагын нинди дә булса этлек эшләмәсләр дигән гарантия бирә алмый иң. Тимерне һәм аның дусларын башка нәрсәләр шатландырды. Әнә бу көннәрдә Миндупның менә дигән кафесы шау-гөр килеп төзелеп ята; Рөстәмнең проекты Мәскәүдән зур бәя алып кайтты; Низам читек фабрикасы проекты өчен премия лауреаты булды.

Шәхсән Тимернең үзенә килгәндә, мунча проекты төзү эше анда калдырылды. Болармы Тимергә көч бирмәде?! Бирде, бик бирде һәм тәмам савыгырга ярдәм итте. Хәер, әле тәмам савыгу дип әйтү бераз иртәрәк бугай. Чөнки Тимер әлегә больницадан чыкмаган иң.

Тимер сәгатенә карап алды да, кире борылып, ашыга-ашыга больницага таба китте. Аңа бер кешелек палатасына кайтырга вакыт иде, чөнки озакламый аның янына дуслары киләчәк. Һәм... Тимер аларга бер сюрприз күрсәтәчәк.

## 23

Дуслары әйткән сәгатькә килеп җиттеләр. Сөлек кебек ялтырап торган чем-кара «Волга» больница ишеге төбенә үк килеп туктады. Тимер дусларын каршыларга больница ишегалдына йөгереп чыкты. Аннары алар бөтенесе бергә гөлдер-гөлдер көлешә-көлешә бер кешелек палатага килеп керделәр.

— Нәрсә син һаман шушы аю өнендә ятасың, сабака малай, — дип тезеп китте Миндуп гадәттәгечә.

— Әйдә, әйдә, ныграк чыбыркыла, Миндуп, — дип кыздырды аны житди Низам, житдилеген онытып.
— Хатын-кыз мәсьәләсендә бер яңалыгым да юк, — диде Рөсти ни он суы, ни тоз суы тәме килмәгән шаяруы белән.
Ләкин бу сүздән Низам никтер кызарып куйды. «Хатын-кыз дигән сүзне гомумән тыныч кына тыңлый алмый башлаган бу, тәненә кан йөгерде», — дип уйлап алды аның турында Тимер.
— Төкер әле, Рөсти, шул бетмәс-төкәнмәс хатын-кызларыңа, — диде Тимер, Низамны тагын бер мәртәбә кызартып. — Менә хәзер мин сезгә бер әйбер күрсәтәм. Ләкин барыгыз да утырышып бетегез, югыйсә, күрү белән һушыгыз китеп аяктан егылуыгыз бар.
Бәләкәй генә интрига барысына да тәэсир итте һәм өчесе дә: «Я, я», — диешеп, Тимергә текәлделәр. Тимер өстәлдән бер төргәк кәгазь алды да, аларны һәркайсы күренеп торырлык итеп, караватына тезеп салды.
Егетләр бик җентекләп бөтен сызымнарны да карап чыктылар.
— Вәт мунча-а-а! — дип суызды Миндуп,— сызымнарын карау белән үк җилкә чокырлары кычыта башлады, тизрәк кереп чабынасы килә бу мунчада.
— Идеально! — диде житди Низам,— без синнән нәкъ шундый мунча көтә идек тә.
Рөсти, әлбәттә, башта бик җайсыз итеп шаяртып алды:
— Сөяркә белән керә торган кабинет ясамагансың икән Низамга.
Низам моңа чын-чынлап үпкәләде. Ләкин ул шул кадәр оялды һәм:
— Причем монда Низам?! — дип кенә әйтә алды.
— Борынгы болгарлар да, хәзерге финнәр дә рәхәтләнеп чабынырлык мунча ясагансың, Тимер, маладис, — дип сүзен очлады Рөсти.
Караваттагы кәгазьләрне Тимер ипләп кенә җыеп алды һәм астыртын елмаеп әйтеп куйды:
— Монысы әле баласы, алда булыр анасы.
Егетләр дәррәү колакларын шымыйттылар. Тимер, дулкынланмаска һәм ашыкмаска тырышып, өстәл астыннан тагын бер төргәк кәгазь чыгарып караватка тезде. Егетләр тагын кәгазьләр өстенә иелеп, тынып калдылар. Ике-өч минут шундый озакка сузылды ки, Низам, Миндуп һәм Рөсти караватөстенә иелгән килеш катып калган таш сыннар булып тоела башлады.
Караваттан беренче булып Низам баш күтәрде. Аның йөзе уйчан һәм шатлыклы иде. Житди Низам, гомердә кыланмаганны эшләп, Тимерне кысып кочаклап алды.
— Ике кулымны кисәргә бирәм, киләчәк премияләрнең берсе шушы проектка булачак,— диде ул.
Аннары Миндуп күтәрелде.
— Ах, сабака малай, бездән яшереп нәрсә эшләп яткан. Мә бишне!
Ниһаять, Рөсти дә зур күзлеген сала-сала башын күтәрде.
— Бетердең! — диде ул, күзлек пыялаларын сөртә-сөртә.— Мәрдән абзый белән Имаметдиновның теш казналарын тәмам җимердең.
Бәй, бу ни бу?! Кинәт Тимернең күңеле тулып китте һәм тамак төбенә теге чактагы кебек каты әйбер килеп бөялде. Менә сиңа әкәмәт! Ничек котылырга инде бу каты әйбердән. Теге чакта врач әйткән иде, тамак төбенә килеп бөялгән каты әйбердән бары тик елап кына котылып була, дигән иде. Ә монда, берни булмаган көе, дусларың алдында ничек елап тормак кирәк? Ниһаять, ул төкергән йотты һәм шул чакта теге каты әйбер дә эчкә, ашказанына төшеп китте. «Синең юлың әнә шунда»,— дип уйлап куйды Тимер.
Озакламый Тимернең дуслары китеп барды. Тимер аларны озатып кергәч тә әле һаман караватөстеннән җыеп алынмаган сызымнарына карады.

## 24

Аның бу сызымнарында хыялый бер агрошәһәрчек сурәтләнгән ид Артык зур булмаган агрошәһәрчек. Күп дигәндә, хәзерге уртача бе колхоз авылы кадәр генә. Чөнки бу шәһәрчектә чыннан да авыл х җалыгы белән шөгыльләнүче кешеләр яшәргә тиеш. Андагы йортла биналар, юллар, бакчалар, нәни буалар һәм фонтаннар шул кадә гүзәл ки, монда килеп кергән кеше үзен әкият дөньясында итеп тоя иде. Һәм һәрбер кешегә яшәү өчен җайлы иде ул. Картларга да, урт яшьтәгеләргә дә, яшьләргә дә, балаларга да. Хатын-кызларга да жай лы иде ул, ир-атларга да. Гаиләләргә дә һәм буйдакларга да. Тирә як мөхиткә шул кадәр җайлы кереп урнашкан иде бу агрошәһәрче янына ук килеп җитмичә аның торак пунктмы, әллә табигатьнең гүзә бер почмагымы икәнлеген аерып та булмый иде. Чөнки көнчыгы яктан текә генә күтәрелеп киткән комлы тау, ә көнбатыш яктан сөзә кенә урманлы калкулык белән уратып алынган иде ул.

Шәһәрчек уртасында зур культура сарае. Дөрес, аның тамаша зал чиксез зур түгел, шушы шәһәрчектәге кешеләр санына карап таманч гына итеп төзелгән. Ләкин, тамаша залыннан тыш, анда бик күп бүл мәләр бар иде: тыныч уеннар бүлмәсе, үзешчән сәнгать өчен төрл бүлмәләр, китапханә бүлмәләре, бинаның көньякка караган ягынд гөлләр бүлмәсе, колхоз үстерә торган игеннәр бүлмәсе, терлекчеле бүлмәсе, умартачылык бүлмәсе. Бинаның байтак кына өлешенә музе бүлмәләре урнашкан. Алар элек шушы агрошәһәрчек урынында яшә килгән авыл, колхоз тарихы, аның хезмәт һәм сугыш ветераннары та рихын сөйли... Аерым бүлмәләрдә элеккеге керәшеннәрнең үзенчәлекл кием-салымнары, эш һәм көнкүреш кораллары, гореф-гадәтләре, үзе бәйрәмнәре турында бай материал тупланган. Мондагы бик күп магни тофон тасмаларына әллә никадәр җырлар, әкиятләр, мәзәкләр, сөй ләкләр язып алынган.

Культура сараеның көнчыгыш якка караган тәрәзәсез зур стенасы шәһәрчек тирәсендәге инеш ярларыннан җыеп алынган төрле төстәге чуерташлардан ясалган мозаика бизи. Ул «Ана» дигән җыелма образ ны чагылдырырга тиеш. Мозаикада гаҗәеп сабыр һәм мөлаем йөзле күзләреннән бераз гына моңсулык та сирпеп торган алтмыш яшьлә рендәге хатын сурәтләнгән. Сурәткә игътибар белән карасаң, анда Фәкилә апаның йөз чалымнары да бар икәнен күрү кыен түгел иде

## 25

Икенче көнне больницада үткәрелгән биш кенә минутлык медкол легия утырышында Тимернең тәмам терелүе һәм иртәгесе көнне боль ницадан чыгарылачагы турында сүз булды.

Биектау Каменка
1976.

------------

## Рифгать Закиров

### Шахтер моңы

Үз моңыңны табу җиңел түгел,
Тамырлары аның тирәндә;
Тамырлары аның, һай, тирәндә —
Үлчәп булмый нәрсә белән дә!..

Хыялымда үткәннәргә кайтып,
Узып борма, урау юлларны,
Әбкәм эчкән сагышларны татып,
Чиртеп бабам чирткән кылларны,

Халкым кичкән гарасатны кичеп,
Заман йөген төяп иңнәргә,
Кат-кат утка кереп, суга төшеп
Киләм кабат якты көннәргә.

Һәр сәгате җырда җырланырдай
Шушы чорга килеп юлык та,
Ут уйнатма, имеш, кулларыңда,
Ярма, имеш, кылны кырыкка!

Аңлап шуны, эшнең иң авырын
Сайлап алдым йөзне чөерми. —
Шахтада мин. Монда үзгә урын:
Җилләр исми, чәчәк сибелми.

Күк гөмбәзе монда — каты токым,
Ә офыклар... — тоташ таш күмер.
Тоеп шунда яшәү матурлыгын,
Гөрләп чәчәк ата яшь гомер!

Кыю җырлап, үз моңымны эзләп,
Күмер чабам, — төшәм тирәнгә.
Тамырлары моңның, һай, тирәндә —
Үлчәп булмый нәрсә белән дә!..

Хезмәт — бәхет. Шуннан зурракны мин
Эзләмим дә бүтән, тапмам да.
Катлам ача барып бер-бер артлы
Якынаям яңа катламга!

## Алыш - биреш

Син аңларга мине тырыш,
Күп сорамыйм, тормыш, синнән.
Ләкин сиңа күпме тиеш, —
Шуның барсын ал син миннән!

Ал син миннән яшьлегемне,
Алган сыман бала чакны.
Вакыты җиткәч — сорап торма,
Каерып ал алачакны.

Хакыйкатькә син тугры бул,
Ялган белән иркәләмә.
Кайгым булса — бүген үк бир,
Калдырмыйча иртәгәгә...

Алда күпме алыш-биреш,
Вакыт көтми, вакыт кырыс.
Һәр таң саен көтә безне
Яңа тормыш, яңа бурыч!..

## Идел кызына

Күңел күзең шунда тарткан сыман
Киләсең син Идел ярына:
Чәчләреңнән сыйпый җиңел томан,
Тезләреңә дулкын сарыла.

Серле пышылдыйсың: китәм! диеп,
Зәңгәр офыклардан күз алмый.
Өнем микән, төшем микән диеп,
Оеп тора Идел кузгалмый.

Шул Иделне ташлап китсәң әгәр,
Бу якларда нинди ямь калыр?
Ярда биер шомлы күләгәләр,
Айкалыр да дулкын чайкалыр.

Читтән син эзләгән алтын балык
Нәкъ шушында, Идел суында.
Китсәң — бәхетеңнән коры калып,
Үкенерсең гомер буена.

## Урманчы үе

Йокың ачып, җанны сискәндерә
Таң җиленең кинәт исүе.
Агач очларыннан әйтерсең лә
Йөгереп уза тиен көтүе.

Җилфер-җилфер җилкәй өлгермидер
Урман куенына сыенып,
Аннан бары берәм-сәрәм сары
Яфрак кына кала коелып.

Гомер җилдәй шаулап узган чакта
Агач түгел, еллар башыннан,
Узган юлларымда һәр адымда
Яфрак ярыр күкрәп яшь имән!..

Габдрахман Әпсәләмов

# АТАКАЙ, АНАКАЙ

хикәя

Ахрысы, чынлап торып картаела. Уйларым, бабайларныкы кебек, һаман-һаман яшьлегемә кайта. Еллар сиздермичә генә үткән дә киткән, үрләр тауларга әверелгән. Хәзер бертуктаусыз шул гомерем тауларын актарам. Нәрсә эзлим, нинди серләр бар ул гомер таулары астында? Минем гомерем — гап-гади бер гомер, никадәр эзләсәм дә, кыйммәтле мәгъдәннәр таба алмам анда. Шулай да бертуктаусыз актарам гомерем тауларын. Һай, күп нәрсә өелгән дә соң!

Сәламәт, эшчән кеше үткәннәр белән артык яшәми, ул киләчәккә карый, аның иң татлы, иң кыю хыяллары иртәгәге көнгә төбәлгән. Тик чынлап торып картая башлагач кына, җитмәсә, сәламәтлек тә какшагач, ниндидер юаныч эзләгән сыман, гомерең тауларын актарырга керешәсең икән. Шулай үзенә күрә бер йомгак ясыйммы әллә? Булмас! Болай, уйланып утыру гынадыр.

Хәтер чоңгылыннан Атакай, Анакайларның кадерле сурәтләре калка. Мин аларга, сихерле көзгегә караган шикелле, әсәрләнеп карап торам. Бәлки кайберәүләр көлеп тә куяр: «Эзләгәнен тапкан икән!» — диярләр. Раушан йолдыз кебек «әткәй-әнкәебез» бар чакта, нигә ул әллә кайчангы сүзләрне казып чыгарырга? Кемгә кирәк алар?

Бәхәсләшмим, дөресрәге, табигатем шундый, бәхәсләшә белмим. Әмма ул сүзләр минем өчен тарихчыларга гына кулланырга ярый торган архаик сүзләр түгел, яшьлегем кебек кадерле, мәгънәләре гаҗәеп тирән, хәтта үзенә күрә тылсымлы... Аларда халыкның күп гасырлык хикмәте, акыл энҗе-җәүһәрләре бар кебек. Аннары шунысы да бар бит: кеше үзе теләгән җирдә тумый, бала чагында — ягъни дөньяны таный башлаганда — торыр урынын да үзе сайламый. Ул барына да канәгать. Аңа үз авылыннан да матур, аннан да ямьле җир беркайда да юктыр кебек тоела, ә үз авылының сөйләше — гәрчә ул бер шивә теле генә булса да — сандугачлар сайравы кебек иң гүзәл тел булып яңгырый. Ахыр килеп, Туган ил төшенчәсе дә шул үз авылының басу капкасыннан башлана бит. Соңыннан язмыш сине кайларга гына ташламасын, син нинди генә данлыклы, гүзәл җирләрдә яшәмә, күңелеңдә шул туган авылның кура белән генә тоткан басу капкасы була — синең юл башың шунда. Тарихларга һәйкәл

булып калган капкалар да синең күзеңнән яшь сыгып чыгармый, ә менә туган авылыңның гади генә басу капкасы каршында, дөнья гизеп кайтсаң, тезләнеп елыйсы килә!

Кайдандыр, Идел киңлегеннән моңлы җыр ишетелә:

Кайтам, кайтам туган якларыма,
Талларына хәтле сагынган...

Без авыл очында тора идек. Авылны чыккач та киң кыр башлана. Анда, күңелне әллә нишләтеп, арышлар куян куа. Шул чаларган арышлар арасыннан тар гына юл сузыла. Еракта арышлар бергә кушылгандай була, юл югала кебек. Сул якта куе яшел үзәнлек, үзәнлектә тын гына инеш ага. Ярлары текә. Кайчандыр, урман бар чагында, инеш мул сулы булган дип сөйлиләр, хәзер безнең авыл агайлары аны көлеп кенә дәрья диләр, югыйсә, ул чыпчыкка — муеннан, каргага — тездән. Уң якта, кыр түрендәрәк, ялгыз имән тармакланып үсә. Аңа әлмисак бардыр диләр бабайлар. Монысы мине гаҗәпләндерми, мин әле еллар санын күз алдыма китермим. Ә менә шул имән яныннан үткәндә өлкәннәр, ничектер, юашланып, кече күңелле булып китәләр, әллә моңаеп җырлыйлар, әллә колху алла укыйлар шунда. Монысы малай-шалайны ярыйсы гаҗәпләндерә. Сораштыра башласаң, үскәч белерсең әле, дип кенә җибәрәләр. Хәер, безгә, малай-шалайга, имән чикләвекләре, безнең авылдагыча әйтсәк, имән шәрәләре кыйммәтрәк, без алар белән төрле уеннар уйныйбыз, ә өлкәннәре башларын салындыралар икән, әйдә салындырсыннар, анда безнең ни эш.

Ялгыз имәннән ерак түгел бер урынны авыл халкы «Урман авызы» дип йөртә. Ә урманы кайда? Аны күптән кисеп, төпләп бетергәннәр. Кызык, урман хәтле урман беткән, ә исеме халык телендә калган. Димәк, сүз урманнан да озаграк яши!

Кулымны каш өстенә куям. Әлеге арышлар арасыннан сузылган юлдан карт белән карчык килә. Җентекләбрәк карасам, таныйм да: бу Атакай белән Анакай ич! Кулларында тырыслары белән таяклары да бар. Каршы очрап сәлам бирсәң, кем баласы буласың, улым? дип, бер уч тәмле җир җиләге белән дә сыйлыйлар. Безнең түбәбез күккә тия. Ни өчендер аларның җиләге иллә тәмле була торган иде.

Безнең авылда күбрәк әткәй-әнкәй дип сөйлиләр, тик кайбер гаиләләрдә генә атакай-анакай кулланыла. Аннары тагын бөтен авыл халкы — яше-карты, баласы-чагасы — Атакай-Анакай дип йөри торган хөрмәтле кешеләр дә бар. Гадәттә, алар күп булмый. Кайчак аларны Ил атасы, Ил анасы дип тә атыйлар. Билгеле, мондый олы исем тикмәгә генә бирелмәгәндер. Тик сабый чакта кем моны төпченеп тора, башкалар Атакай-Анакай дигәнгә, мин дә шулай дәшә биргәнмен. Алар үзләре моңа бик тә куаналар иде шикелле, еш кына башыбыздан да сыйпыйлар, атаң яхшы, анаң яхшы, син дә тәүфыйклы бул, балам, дип аркабыздан да сөяләр иде.

Ул хөрмәтле карт белән карчыкның, билгеле, үз исемнәре дә булган, тик, без алардан шактый ерак торганга, мин генә белмәгәнмен. Кайбер чордашлары Анакайга Аппак диюләрен генә хәтерлим. Тик бу исем түгел, кушамат та түгел, бу сердәшем, ахирәтем дигән кебек иркәләп әйтү генә. Безнең якта кызлар арасында бу шактый таралган күренеш.

Ул вакыттан бирле бик күп еллар үткән, бик күп сулар аккан, туган авылымнан да бик ерак киткәнмен, ә Атакай белән Анакайның йөзләрендәге тирән җыерчыкларын, кыяфәт-торышларын, хәтта гәлдери төшеп сөйләшүләрен бүгенгедәй исемдә тотам. Күзләремне йомсам, хәзер күз алдыма тере килеш килеп басалар. Кайчандыр аларның да йөзләре ап-ак булгандыр, ә мин белгәндә инде алар кызыл-көрән иде. Хәзерге заман булса, болар әле яңарак кына курорттан

кайтканнар икән, дип әйтерләр иде. Ул чакта исә моның нәрсә икәнен дә белмәгәннәр бит.

Яшь чагында Атакай, мөгаен, бик килбәтле ир-егет булгандыр. Хәзер дә аркасы бөкрәймәгән, сынын туры тотып йөри, җилкәләре киң, тик сакалы белән кашлары гына агарган, әмма күзләре һаман әле тере, кара. Әллә кашлары агарганга шулай кара булып күренәләрме икән?

Атакайның өстендә озын ак киндер күлмәк, күлмәк өстеннән җиңсез «җан җылыткыч» кигән. Башында җәлпәеп беткән кәпәч, ыштаны алача, кулында каезланган артыш таягы. Ул аңа бик озак еллар хезмәт иткән булса кирәк, тәмам шомарып беткән. Шул таягы белән Атакай бер кыш көне бүре сугып үтергән, дип сөйлиләр иде безнең авылда. Шуңа күрә без, малай-шалай, бу таякка сихерләнеп карый торган идек.

Анакай гәүдәгә Атакайдан кечерәгрәк, бераз бөкрәя дә төшкән. Өстендә аяк тубыкларына җиткән бизәкле күлмәк, башына чәчкап киеп, тастар сарган. Шунлыктан башы, чәүкәнеке кебек, гәүдәсенә караганда бераз зуррак булып күренә. Анары бик эссе көннәрдә дә күлмәк өстеннән хәтфә камзул кия торган иде. Тик камзулының төсе нинди булгандыр — белмим, хәтфәсе күптән кыршылып беткән, ямау өстенә ямау салынган иде. Анакайның да, Атакайның да аякларында, ишегалдында йөргәндә, чыбык башмак булыр иде. Безнең авыл тирәсендә, инде әйтелгәнчә, урманны күптән кисеп бетергәннәр, юкәләр дә калмаган. Базарда чабатаны урыс-мукшы сата, чөнки акча кирәк. Шуңа күрә чабата да кадерле, аны күбрәк кыр эшләренә генә тоталар, ә чыбык башмак тиз тетелә, ул бары ишегалды тирәсендә генә кияргә ярый.

Атакай белән Анакайның кызлары гына булган, малайлары булмаган. Кызлары күптән кияүгә чыкканга, карт белән карчык эчтәнтыштан кызыл балчык белән сыланган бәләкәй өйләрендә икәү генә торалар. Өйләре мәчеттән ерак түгел, текә яр башында. Читән тоткан бакчаларында кып-кызыл тәлгәшле пизел агачы үсә. Пизел дигәне — миләш ул. Аны безнең авылда ни өчендер «саваплы» агач, «изге» агач диләр. Тәлгәшләрен кар төшмичә өзмиләр. Шунда аларга пизел чыпчыклары ябырыла. Атакай белән Анакай аларны кумыйлар, бер сыйлангач, алар үзләре китә диләр.

Бервакыт кыр юлында җайдакчы күренүгә, без, шаян малай халкы, карчыгадан качкан чебиләр шикелле, төрлебез-төрле якка шылабыз. Бу җайдакчы безнең авылның кыр сакчысы — Чапыр Али. Ул ат өстендә як-ягына каранып килә, күзләренең усал ялтыравы ерактан ук котны ала, мыек чылгыйлары үрә басканда — ул гел безне генә сагалый кебек. Кулында әллә сигездән, әллә уникедән үргән зәһәр камчы. Искәртмәстән килеп, сырт буеңа берне сызса, шунда ук җиргә чүгәләп, күз яше белән акырып җибәрәсең: «Али абзый маем, чәчәбичәгә бүтән бер дә кагылмам!» — дип ант итәсең. Ләкин бу тукран тәүбәсе генә. Чапыр моны бик яхшы белә, шуңа күрә тагын берне сызып ала. Ул яшел борчак һәм чәчәбичә (ясмык) өчен малайларны гына түгел, яшьрәк хатын-кызны да җәлләп тормый. Ә ирләр аңа сүз әйтми, мыек астыннан елмаялар гына — Чапыр кыр сакчысы, ул җәмәгать милкен каравыллый. Бер елны авыл халкы ни өчендер Чапырны — бу аның кушаматы иде — кыр сакчысы итеп сайламыйлар, малай халкы ул елны шундый азынды, картлар Чапырның каршына барып: «Алла хакы өчен, Али, кыр сакчысы була күр. Ялан аяк шайтан чагалары кырыбызны таптап бетерде», дип гозерләп үтенгәннәр. Без, малай-шалай, тагын Чапыр кулына калдык, рәхәт көннәребез бетте...

Гомер дигәнең агымдай ага. Хәзер үзем дә җитмешкә якынлашам,

җитмәсә, сәламәтлек тә чамалы. Шунлыктан күбрәк тәрәзәдән генә карап утырырга мәҗбүрмен. Әлбәттә, манзара матур — илле-алтмыш адымда Идел җәелеп ята. Быел су аеруча күп — Идел нәкъ диңгез кебек, һич күзеңне ала алмыйсың. Без Иделнең сөзәк ярында. Су буенда гына батып барган кояшның кызгылт нурлары белән яктыртылган мәһабәт кәүсәле төз наратлар. Алар арасыннан яшел һәм текә аргы як яр күренә. Урман һәм бакчалар өстенә кичке кызыл шәфәкъ җәелгән. Кояш шары гаҗәеп зур, кып-кызыл, үзе агач башларына тияр-тимәс кенә тора. Мин шул кызыл шәфәкъка карап уйланып утырам. Ә хыял картаюны да, авыруны да, аруны да белми ул, һаман яшь, һаман җитез, ничек кенә уйнамый да, ничек кенә дуламый. Бер секунд эчендә әллә нәрсәләр искә төшеп китә, кызыл нурга манчылган тау-тау ак болытлар арасында кайчандыр, кайдадыр күреп үткән юллар шәйләнә кебек: әле Ерак Төньяк, әле Заполярьеның аппак яки соргылт таулары, әле Төньяк балкышы уйнап ала сыман. Ул да булмый, күзләр Ерак Көнчыгышка хас манзарага туктала. Монда да бихисап таулар, үрләр, тик төсләре генә башка — ямь-яшел. Шунда ук гаҗәеп зәңгәр күлләр, болыннар җәелә. Шундый болыннарның берсендә, кыр уртасында, җирдән фонтан булып аткан чишмәдән солдат котелогы белән нарзан эчкәнемне хәтерлим. Чишмәнең тирә-ягы билдән яшел үлән иде.

Шулай хыял дөньясында байтак вакыт тын калып утырам һәм әле генә нәрсәләр турында сүз алып барганымны да онытам кебек. Хәлбуки, бернәрсә дә онытылмаган, бераз артка гына чиккән икән. Күзләремне йомуым була, хәзер күз алдымда туган авылым калка. Ул моннан бик-бик еракта, анда гүзәл Идел дә, төз наратлар да юк. Кырлардан килеп,ындыр артларыннан бәләкәй генә инеш ага, таллар үсә, алар шундый матур — нәкъ яшьлегем кебек.

Һәр кеше үз яшьлеген үзенчә күрә, үзенчә генә сагына. Шуның өстенә һәр кеше күңеле белән гаҗәеп рәссам да бит. Кулы белән бер сурәт сыза алмаса да, күңеле белән искиткеч картиналар тудыра һәм шул нәрсә аңа матурлыкны аңларга, тоярга ярдәм итә. Ул инде көндәлек нәрсәләрдә дә чын матурлыкны таный, тик моны үзенчә аңлата: «И яшьлекнең алтын чагы!» ди. Ул берни дәгъва итми, бернидән зарланмый.

Уйларымны яңадан Атакай белән Анакай били. Балалыгым белән төшенмәгәнмен, яхшылап сораштырырга кирәген белмәгәнмен, тик хәзер генә: аларга ни өчен бөтен авыл иң бөек исем белән дәшә торган булган? дип, табылмас өерне табарга тырышкан булам. Халык бит беркайчан да сүз белән уйнамаган, сүз җилгә чәчелми, кеше аның кадерен бик яхшы белә. Халык сүзе алтыннардан кыйммәт ул.

Миңа ул чакта алты-җиде яшь булгандыр. Дөнья миңа ашык-кузна уены кебек гади, рәхәт тә тоелган, бөтен барлыгымны шул биләгән. Ләкин адәм баласы бер уен белән генә яшьтән үк гомер сөрә алмый, ул дөньяны танып белә башларга тиеш. Таный аламы — анысы башка эш.

Һәр кешенең күңел дәфтәре дигән кадерле һәм серле китабы бар. Шунда барысы языла бара. Тик аны, чын китапны ачып укыган шикелле, утырдың да укыдың түгел. Хәтердә аның әле бер бите, әле икенчесе ачыла. Битләр тоташтан булмый, аралары буш, бер-берсенә бәйләнмәгән — нindидер бик әһәмиятлесе югалганмы, онытылганмы. Шулай да, күпмедер тырышкач, хыял томанында нәрсәләрдер бераз ачыклана башлый шикелле, гомер дәрьясы чоңгылыннан тоныклanып беткән, ләм белән капланган нindидер табылдыклар калкып куя. Калганын инде иҗат фантазиясе төгәлләргә булыша.

Мин менә көн саен шундый мәшәкатьләр белән шөгыльләнәм. Кешегә берни сөйләмим, аннары сорашучы да юк.

Хәтер югалту дигән бер бик әшәке авыру бар. Билгеле инде бер сырхау да яхшы түгел. Аннары син шул чиргә ризамы дип тә сорамыйлар. Тик күңелдән генә уйлап куясың: мин иң каты сызлауларга да түзәргә ризамын, тик хәтер генә югалмасын иде. Хәтер югалган көн — кешенең үлгән көне...

Ярый, бераз лирик чигенү дә ясап алдык ди.

Безнең авыл тирә-ягында урман булмаса да, кыр уртасындагы бер урынга «Урман авызы» дип әйтүләрен бер язган идем. Җәй уртасында бер дә бер көнне шул үрдән — Урман авызыннан ут күтәрелә. Ниндидер бер ачык авызы учагын сүндерми киткән булгандырмы, узып баручы берәр юньсез тәмәке төпчеге ташлагандырмы, коры үлән бик тиз яна башлый. Ул елны җәй буена бер тамчы яңгыр яумады. Күкрәп үскән игеннәр — бездә җир кара туфраклы, корыга артык бирешми — шул күкрәп үскән игеннәр дә бик иртә шиңделәр. Халык, уткүз була күрмәгәе дип, күптән инде пошынып йөри иде. Ахрысы, күңеле сизгәндер, аяз көндә яшен яшьнәгән кебек, кыр яна башлады.

Ул көнне халыкның күбесе авылда була. «Пожар, пожар!» дигән куркыныч тавышларны ишетүгә, кешеләр, кулына нәрсә эләксә шуны алып, кырга таба йөгерә башлый, янгынчылар атлары белән җилеп үтәләр. Тагын атлылар күренә... Шау-шу куба.

Халык Урман авызы турысына барып җиткәндә ут инде шактый зур мәйданны ялмап алган була. Кешеләр ажгырып килгән афәт утны күреп бер мәл аптырап калалар, нәрсә эшләргә, нидән тотынырга белмиләр, һәркем үз иманасына ташлана. Якын-тирәдә су-фәлән юк, янгынчылар китереп җиткергән ике-өч кисмәк су белән кыр янгынын сүндереп буламы соң? Аны да һәркем үз иманасына тартырга тырыша. Талаш, кычкырыш китә. Ул арада, үч иткән кебек, җил куба. Нинди зур өметләр белән үстерелгән игеннәр күз алдында бер минут эчендә көл була да бетә.

Ут инде аның иманасына сикергән киң күкрәкле, күлмәге кендегенә хәтле ертылган, ялан башлы Айзүк агай, гаҗизлектән, җиргә ятып, үкереп елап җибәрде. Зур гына бер төркем, күбрәге картлар:

— Җәмәять, тәкбир әйтергә кирәк, ходай тәгалә безнең тавышны ишетсен! — дип шаулашалар һәм кемнәрдер тәкбир дә әйтә башлый. Ул арада җирдә аунаган Айзүк агай сикереп тора да, инде янып бетә язган иманасына шашкан күзләре белән бераз карап торгач, ялт итеп артына борыла:

— Чапыр! Кая Чапыр, эт орган нәрсә! Шулай саклыйсыңмы син кырны! Ләгънәт — дип кычкырып җибәрә ул һәм, халык арасында басып торган кыр сакчысының күкрәгенә ябышып, җан ачуы белән селки башлый, сугып та җибәрә.— Син, кара шайтан, малайлар белән хатын-кызлар алдында гына батыр икән. Ах, башың беткере!

Кемнәрдер, гаепле кеше табылганга шатлангандай, кыр сакчысын канга батырып кыйный да башладылар. Һәр вакыт җәнҗал кубарырга яраткан, кулыннан бер нәрсә килмәсә дә, башкаларны котыртырга бик һәвәс кәҗә сакаллы Пәрәү карт, башкаларга куәт биргәндәй, нечкә тавыш белән чәрелдәргә тотынды:

— Кул-аягын бәйләп утка ташлагыз шул кяферне! Аның шомлыгы бу афәт: изге китапларда әйтелмеш... Бер вакытта да намазга йөрмәс, кыр саклыйм дип, җомгага да бармас, һы. Изге рамазан аенда көпә-көндез чәй эчеп утырганын хатыннар күргән! Хәзер аның бәласе бөтен авылга... О, мәләвен!

Үз-үзләрен белештермәгән кешеләргә шул җитә калды. Берничә агай шунда ук Чапыр Алиның кул-аягын бәйләргә керешә. Башка бер вакыт булса, без, малайлар,кан дошманыбыз Чапырга эләккән

өчен авыз гына ерыр идек. Әмма кешене терелəй утка ташлауны күрү — котны ала. Кыз балалар илереп еларга ук тотынды.

Менə шул аерата хəтəр чакта чалгысын күтəргəн Атакай килеп чыкты. Бите-башыннан кара тир ага. Ул əле самосуд ясарга җыенучы кешелəргə, əле кычкырып тəкбир əйтүче карт-корыга бер карап алды да:

— Халаяк, котырдыкмы əллə? — дип кычкырды. — Нишлəвегез бу?! Кеше яндырып, тəктибар əйтеп янгын сүндереп буламыни. Утның юлын тиз генə кисəргə кирəк! Пəрəү кебек авыз чайкап тормагыз. Менə болай таба бер-ике полоса чабып китик. Вəт минем имана. Шуннан башлыйк. Бисмилла иррахман иррахим...— Атакай бөтен колачына селтəнə дə башлады. Аңа берничə өлгер егет иярде.

— Əй, əй, күзең чыкканмы əллə! — дип кинəт кычкырды Пəрəү,— кая кеше иманасына керəсең. Башыңны сугып ватканны...

Мондый мəхшəрдə Пəрəүнең җəнҗалына берəү дə карамады. Ут бик якын килгəн иде.

— Җəмəгать, нəрсə шаккатып торасыз. Ут кøтми бит. Алгарак йөгереп чаба башлагыз. Тырмалылар покосларны арырак алсын. Көрəклелəр камылларны казысын — ут камыллардан күчмəсен. Əнə, карагыз хатыннарга — ничек дөбердəтеп эшлəп килəлəр.— Үр ягыннан бер-бер артлы тезелгəн хатын-кыз чалгычылар килə иде. Иң алда Анакай. Селтəнгəн уңайга чəчкабы гына чайкала, тастары артка шуган.— Пəрəү иманасын хатыннардан сакласын, ə сез, Абидүк, Хөсəй, Шəйдүк...— алга, утка таба элдереп китегез. Тиз булыгыз!

Шунда аптырап калган халык гүя аңга килде. Берьюлы берничə кеше Атакай күрсəткəн якка йөгерде. Алар артыннан башка чалгычылар кузгалды. Безгə, балаларга да, эш табылды: утны күзəтергə, камылларга ут капса, кулыбыздагы таяклар белəн шунда ук аны сүндерергə тиешбез. Ул арада авылдан сукалар җигеп килгəн кешелəр күренде. Алар, килүлəре белəн, чабылган җирне сөрə башладылар.

Хəзер инде һəркем нишлəргə кирəген белə. Төтен эчендə йөзлəрчə кешелəрнең ут белəн аяусыз көрəшүлəре күренеп-күренеп кала. Янгынчылар кабат су алып килде. Лəкин бу су утны сүндерергə түгел, бəлки утка якын торып эшлəгəн кешелəрнең битлəрен-башларын чылатырга кирəк иде.

Байтак вакыт үтте, көн кичкə авыша башлады. Берəү дə кайтып китү турында уйламый, ару-талу сизелми. Көннең кинəт караңгыланып китүен дə абайламадылар. Без, малайлар да, тик тормадык. Əгəр ут берəр җирдə полосаны сикереп чыга башласа, без төркемебез белəн шунда йөгерəбез. Билгеле, безгə, ялан аяклы «армега», камылдан йөгерү кыен, ə сукаланган җирдəн элдертəбез генə. Шаугөр килеп, кулларыбыздагы таяклар белəн утны сүндерəбез, я учларыбыз белəн аңа туфрак сибəбез.

Бер вакытны яңгыр сибəли башлады. Əй шатландык та инде. Бездəн дə бигрəк картлар сөенде.

— Вəт, ходайның хикмəте, ишетте бит ялваруыбызны, — диде сүзгə барысыннан да өлгер Пəрəү карт. Без, малайлар, Пəрəү сүзенə əллə ни игътибар итмəдек. Ходайның хикмəте булса, нигə ул башта ук яңгыр койдырмады, нигə ул ут сүнə язгач кына сибəли. Хəлəй кебек мактаныр өчен генəме?

Кайберəүлəр инде кайтсак та ярар дип сөйлəнə башлады.

— Юк, халаяк, яңгыр сибəли дип таралмагыз, — диде Атакай җиң очы белəн маңгай тирен сөртеп. — Пəрəүгə генə кайтырга ярый, ул изгелəргə якын кеше. Əнə иманасын фəрештəлəр саклап калды ич! — дип ачы көлемсерəде. — Ут ул хəйлəкəр, Пəрəүнең киткəнен генə көтə. Китсə, хəзер, каплан кебек, полоса аша сикерə. Ə балалар-

га кайтырга ярый, алар күп тырмашты. Рәхмәт, оланшак, яхшы эшегез өчен!

Була да соң шундый киң күңелле кешеләр. Пәрәүне халык алдында хур итте, ә безне, малайларны, ил алдында мактады. Без Атакайга чиксез рәхмәт белән карадык.

Бераздан без, малайлар, авылга кайтып киттек. Күлмәкләребез көйгән, ертkаланган, чыланган, буялган. Ләкин без әниләрдән шүрләмибез, күрсеннәр: янгын сүндереп кайтабыз бит, безне авылның иң олы кешесе — Атакай үзе халык алдында мактады!

Шулай да малайлар — малайлар инде. Җитди нәрсәләр турында күп уйлау безне ялыктыра. Шуңа күрә без күбрәк көлке якларны эзлибез: бабайларның тәкбир әйтеп янгын сүндерергә чакырулары, Пәрәү бабайның чәрелдәүләре һәм без кайтып киткәндә дә имана межасы янында утырып калуы, Айзүк агайның җиргә ятып тәгәрәп-тәгәрәп елаулары, кемнеңдер тырма белән арыш чаба башлавы, тагын әллә нәрсәләр — азмыни мондый мәхшәрдә андый хәлләр. Ләкин барыннан да бигрәк безгә Чапыр Али вакыйгасы кызык. Без инде коточкыч фаҗига була язуын оныткканбыз. Борчак, чәчәбичә урлаган өчен Чапыр Алиның әллә ничәдән үргән камчысын күбрәк татыган бер малай — аның кушаматы Кыкы чыбыр иде, чөнки йөзе гаҗәеп сипкелле, — ант итеп сөйли:

— Валлаһи, таллаһи, малайлар, Чапыр күз яше белән акырды. Мыек очлары аска салынып төшкән, алардан яшь тама... Моннан соң борчак урлаган бер генә малайга да тимәм ди...

— Ялганлама, Кыкы, анысын әйтмәде.

— Җир упсын менә, әйтте.

Шулай бәхәсләшә-бәхәсләшә басу капкасына ук килеп җиткәнбез.

Авыл очында карт-карчыклар һәм балалаы хатыннар җыелган. Йөзләре аптыраулы, хәсрәтле.

— Я, оланшак, утны сүндердегезме? — дип сорый таякка таянган бер карт калтыранган тавыш белән.

— Сүндердек, сүндердек! — дибез бер тавыштан. Тавышыбыз шундый көр яңгырый, әйтерсең без чын батырлар, барысын үзебез генә эшләгәнбез!

Шунда арба шыгырдаган тавышка артыбызга борылдык. Бер авыл агае арба яныннан килә. Арбасында нидер бар тагы. Бер минутта халык арбаны урап алды: анда яңа чабылган арыш өстендә канга баткан Чапыр Али сузылып ята, күзләре йомык. Битен-башын бәйләгән чүпрәкләреннән кан типкән.

— Атакай белән Анакайга рәхмәт, алар булмаса... — диде агай халыкның соравына каршы. — Пәрәү сүзенә карап, бер гаепсез кешене утка ташламакчылар иде.

— И-и, тагын шул юньсез Пәрәү! — диде бала күтәргән бер хатын. — Ирләр булып шуның сүзен тыңлыйлар.

— И, килен, аптыраган үрдәк күлгә арты белән чума ди бит. Ни эшлисең, аптыраш, — диде ак сакаллы бер бабай.

...Мин тагын уйга батып утырам. Мөгаен, барысын да тәртибе белән хәтерли алмаганмындыр. Нәрсәләрдер онытылган, буталган булуы бар. Атакай белән Анакайга шул вакыйгадан соңмы бөтен авыл әлеге хөрмәтле исем белән дәшә башлаган, әллә аңарчы да бер-бер җитди эш булганмы? Мин тагын һәм тагын хәтерләргә тырышам — әмма... еллар бик күпне күмеп киткән, таулар өелгән дә өелгән. Ә таулар тиз генә эндәшми. Алар сер саклый.

## Әмир Мәхмүдов



*Уралда, Уфадан туксан чакрым ераклыкта биек таулар, хәтфә болыннар, алтын күлләр белән уратып алынган татар авылы Габдрәшиттә 1947 елда дөньяга килгәнмен...*

*Әдәбиятка булган мәхәббәт мине Бөре дәүләт педагогия институтының филология факультетына алып килде. Дөнья халыкларының, шул җөмләдән үз халкымның бай эстетик мәдәниятен өйрәнү теләге Н. К. Крупская исемендәге Мәскәү педагогия институтының эстетика кафедрасы каршындагы аспирантурага укырга керергә, бөек шагыйрь Муса Җәлилнең эстетик карашларына багышланган фәнни хезмәт язарга этәрде.*

*Хәзер СССР Фәннәр академиясенең Казандагы Галимҗан Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтында фәнни хезмәткәр вазифасын башкарам.*

*Фән өлкәсендә эшләү миңа үз иҗатыма да тәнкыйть күзлегеннән карарга ярдәм итә. Кайнар, давыллы океанга тиң татар әдәбиятының үсешенә үз өлешемне кертәсе, шул колач җитмәслек дәрьяга бер тамчы булып кушыласым килә.*

### Халкыма

Гомер буе халкым моңлы булган,
Кубызларын уйнап туймаган.
Күңеле аның һәрчак нурлы булган,
Күзләрендә утлар уйнаган.
«Карурман»ны сузып җырлаган ул...
Ә уйлары кара булмаган.
Биеклекне максат итеп куйган,
Якты уйлар гына уйлаган.
Якты уйлар гына уйлаган ул...
Тормышы гел якты булмаган.
  Әйтерсең лә тарих, карак булып,
Ак айгырын аның урлаган...
... Ак айгырны инде күптән таптык:
Халкым йөзе бүген нур гына!
Озак яшәр минем моңлы халкым,
Охшап моңлы, озын җырына.

## Дулый кырык чаптарым

Ашкынып мин юлга чыктым,
Җигеп кырык чаптарым,
Дулый-дулый җилгән җирдән
Егып качты атларым.

«Дилбегәне ычкындырдың!» —
Диде заман картлары...
Үземнән дә алда йөри
Хәзер яманатларым.

Җир тетрәтеп, тып-тып басып,
Чайкап яшел ялларын,
Урап килеп, кулбашыма
Сыендылар атларым.

Бәреләм-сугылам заманга...
Дулый кырык чаптарым...
Заманның таләпчән чагы...
Минем яшьнәр чакларым!

## Торналар

*Мостай Кәримгә*

Үз түмгәген эзләп кайта торналар,
Үз көенә кыллар тарта торбалар.
— Тор-рыйк, тор-рыйк — әнә безнең күлебез,
— Тор-рыйк, тор-рыйк — күлебездә күңелебез.
— Тор-рыйк, тор-рыйк...— туганнар, сез күрегез,
Суы кипкән, корыган бит күлебез!
«Тор-рыйк, тор-рыйк» торналарда сагыш бар.
Ишетелә зәңгәр күктән тавышлар.
Ник чыгармый көйне хәзер торбалар?
Ник боз чатнаганда күлдә — яралар?
Ник берәүләр шулай дорфа кыланып
Йөрәкләрне нигә шулай яралар?
... Үз түмгәген эзләп кайта торналар,
Үз көенә кыллар тарта торбалар.

Җиз торбалар, һич тынмагыз, тынмагыз, тынмагыз!
Тормыш сагышларын җиңеп, уйнагыз сез, уйнагыз!

## Тормыш

Кечкенәдән йөгәнләдем
Мин сине, кырыс тормыш!
Сизмәстән егылып төштем.
Теләгем — тормыш кормыш.

Түбәннән биеккә очам,
Мин, тормыш, горур balaң.
Сине үзгәртеп корам, дип,
Үземчә көям, янам.

Кызык дөнья: үлем, тумыш.
Мин ашкынам, мин тырыш.
Җитез чорны юлдаш иттем —
Теләгем — тормыш кормыш!

# Нур Әхмәдиев



*Туган елым — 1946.*

*Туган җирем — Азнакай районының Әсәй авылы. Урта мәктәпне Азнакайда тәмамладым.*

*Әдәбиятка хәреф таный башлаган көннән алып гашыйкмын. Моңа бәлки сабый вакытта ишеткән җырлар, әкият һәм табышмаклар сәбәпче булгандыр. Мәктәптә, аннары университетның татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укыганда үзем дә каләм тибрәткәли башладым.*

*1970 елда университетны тәмамлагач, үзебезнең районның Сарлы авылында балалар укыттым. Өч ел чамасы ВЛКСМ райкомында эшләдем. 1974 елдан башлап район радиотапшыруларын алып барам.*

*Әдәбиятта вак нәрсәләр юк, шагыйрь бөтен темаларга язарга да хаклы, ләкин иҗат үзәгендә табигатьнең иң бөек казанышы — Кеше торырга тиеш дип исәплим.*

*1975 елда нәшриятка «Аһәң» исемле беренче шигырьләр җыентыгымны тапшырдым. Ниятләр һәм өметләр әздән түгел болай...*

## Үзәктә

Таләпләрне һаман арттырам да
Канәгатьлек тапмыйм нилектән? —
Ил каршында нинди хезмәтем бар? —
Җавап бирә торган яшь җиткән:

Вак җанлылык күрсәтмәдем микән,
Куркып калмадыммы авырдан?
Шул сораулар, ычкындырмас өчен,
Эләктергән йөрәк, бавырдан.

Ирексездән һаман күз салырга
Туры килә кылган эшемә.
Дөнья — чиксез!.. тик үзәге аның
Мин яшәгән шушы төшендә.

## Бу заманда

Арысаң да, тирләсәң дә
Туры килә таманга.
Йөкнең җиңеле бармыни
Бу тынгысыз заманда?
Тартылып куйган нервлар
Җәя кереше төсле.
Кагыл ялгыш: ракетадай
Атылып китәр кеше.

Кулга эш тә калмады күк,
Прогресс бит, машина...
Машиналарны да узып,
Кеше кая ашыга?

Туктамый ул ашыгудан,
Юлларын хет киртәлә.
Үзе белә: бүгенгедән
Җиңел булмас иртәгә...

## Нефтькә ода

Без дә бит нефть иленнән,
Азнакай — безнең яклар.
Бәреп чыгар кебек фонтан,
Хет таяк белән актар.

Я, шаярма, җир маен син
Табарсың җиңел генә!
Аның өчен нефтьчеләр
Төшә җир кендегенә.

Потлап-потлап «тоз ашала»,
Җиде кат тирең чыга.
Бу безнең намус вахтасы,
Почетлы вахта, чыда.

Бу безнең дуслык вахтасы,
Нефть ул — политика.
Көнбатышка кара алтын
Дипломат булып китә.

Без тумыштан Азнакайдан,
Нефть диңгезе бу як.
«Кара алтын», дуслык булып,
Тарала дөнья буйлап.

## Рәссам мастерскоенда

Пумалада — буяу!
Тын кал, дөнья,
Могҗизага үзең шаһит бул:
Сурәтләргә хәзер җан иңдерә,
Яшәү бүләк итә гади кул.

Төннәрен дә монда кояш чыга,
Шау чәчәктә кышын болыннар.
Бу дөньяда Киек каз юлларын
Көпә-көндез күрер урын бар.

Идиллия... Тагын шул ук бүлмә:
Сугыш гарасаты, яу кыры.
Авызыннан дзот ут төкерә,
Корбан эзли пуля яңгыры.

Илһам көче, илаһи бер сулыш:
Газинурлар кабат терелә.
Оста кулындагы җиде төстән
Үлемсезлек туа бирелә.

## Ничек әйтим?..

Без даланы буйсындырган чакта,
Сулыш җиткерәлми тузанда,
Бер кешене бишкә бүләр көндә
Күләгәдә яттың урманда.

Атылганда давыл уртасына,
Өлгерик дип тизрәк ничек тә,
Тамашачы кебек карап йөрдең,
Гамьсез карап йөрдең бер читтә.

Һичнәрсәгә каршы төшмәсәң дә,
Төзүдән — син читтә Яңаны.
Бер аяктан атлап бармагачтын,
Замандашым дия аламмы?

Замандашым минем — җиң сызганган,
Иҗатчысы чорның, заманның.
Безнең сулышыбыз кайтавазы —
Гудоклары яңа «КамАЗ»ның.

Сулышыбыз әнә БАМнар аша
Кояш илтә тайга эченә.
Шпал өсләренә рельс ята,
Ядкарь булып яшьлек көченә.

Башкалар күк яши белмәгәчтен,
Яшәсәк тә бер җир өстендә,
Ничек сине лаек диеп әйтим
Замандашым дигән исемгә?

## Рашат Низамиев

### Ленин кулы

Давыллы чор чатларында
Ильичның зур, гигант кулы —
Кешеләргә бәхеткә юл
Күрсәтүче компас угы!

Илләр карый шушы кулга
Сайлар өчен язмышларын.
Һәм Ленинча төзәтәләр
Яраларын, ялгышларын.

Яшь дәүләтләр рапорт бирә
Шушы тугры кулга карап.
Ильич әйткән васыятьләргә
Йөзен бора һәрбер тараф.

●

Күзләрем аера төсләрне:
Каеннар тарата яктылык.
Тын гына ял итә кара җир,
Талпына биектә ак болыт.

Колагым ишетә һәммәсен:
Челтери саф чишмә сулары.
Үләннәр сөйләшкән авазны
Тургайлар күтәрә югары.

Кулларым иркәли гөлләрне,
Кирәксә тау-ташлар җимерә.
Аяклар саныйлар чакрымны —
Беркайчан кайту юк кирегә.

Кычкырып тормасын — сөюне
Йөрәкнең түренә яшердем.
Күзләрем дөньяны күргәндә,
Иренем һәр вакыт: «Яшим...» ди.

## Утлар йөртәм күкрәгемдә

Тышка түксәм йөрәгемнең ялкыннарын —
Дөньясына көчле утлар кабар төсле!
Карурманнар, ут-давылга чорналыр да,
Дәрьяларның кочагына авар төсле.

Әнә шундый утлар йөртәм күкрәгемдә,
Сөю йөртәм — күккә, җиргә, кешеләргә!
Күпләр шушы халәтемне аңламыйча,
Гаҗәпләнеп карап кала мин юләргә.

Урман-кырлар — гүя минем патшалыгым,
Яратамын хәтта җирнең бөҗәкләрен.
Битарафлар мыштым гына уза алмас,
Матурлыкны исбатлармын үҗәтләнеп.

Тынгы белмәс, туктый белмәс бер җан булып
Кушылам мин тормышның һәр мизгеленә.
Шатлыклардан көнгә мең кат тетри күңел,
Кайгылардан көнгә мең кат өзгәләнә.

Гамьнәремнең олысы да, кечесе дә —
Бар да уза шушы нәни йөрәк аша.
Дәрманыма мәйдан сорап, киңлек сорап,
Анда уйлар һәм давыллар тарткалаша.

Дөньясына көчле утлар кабар иде!
Ярый, димен, бу табигать җаен белгән:
Утлы йөрәк кенә биреп калмаган ул,
Сөйләр өчен, җырлар өчен тел дә биргән.

## Диңгездә

Инештәге бозлар
Агып китте ерак —
Диңгездә йөр менә
Адашып һәм елап!..

«Монда дәрья, дәрья,
Юктыр иге-чиге,
Инешемнең яры
Иркенрәк иде.

Монда дөнья кысан,
Бозлар олы, эре:
Этә-төртә мине —
Йөзеп килгән бере...»

## Хыялга мең рәхмәт!

Мин сине иң элек
Хыялда тудырдым.
... Бер башым бикләнеп,
Моңланып утырдым.

Һәм килде каршыма
Ап-ак сын-сурәтең, —
Тәңредә бер тылсым
Бардыр ул, күрәсең.

Чорналды җаныма
Пакь сөю пәрдәсе.
Борчулар, кайгылар —
Онытылды һәммәсе.

Тыялмыйм гыйшкымны,
Гүяки мин — Таһир.
Ямьлерәк күренә
Монда күк, монда җир.

Каршымнан ничәмә
Чибәрләр узмады,
Ә минем күңелдә —
Хыялый кыз бары.

... Хыялый кыздан син
Күп тапкыр көчлерәк.
Ярата белүдә
Зөһрә кыз төслерәк.

Ярый, дим, сурәтең
Җаныма сыялган...
Мең рәхмәт — сөюне
Эзләшкән хыялга!

## Марсель Галиев

# ЯҢА КӨРӘШЛӘР ӨЧЕН

●

Сабан туйда көрәш барган мәйданнардан
Сугыш җиле әтиләрне тартып алган.
Сөлгеләре — яшел чирәм өсләрендә
Яраланган аккош кебек ятып калган.

Европада илләр янган учаклардан
Әнкәйләрнең чәчләренә көлләр кунган.
Сыеныр җир эзләп, көнбатыштан килеп,
Илгә якты өмет вәгъдә иткән кебек,
Ак ләкләкләр таллыкларга оя корган.

Яраланган илләр байрак үпкән чакта,
Фанфаралар кояшкача сузылганда,
Уйнаганда җиңү гимнын бер сулыштан —
Без туганбыз! Сугыш тынган. Без туганбыз.

Әтиләрнең сафларына соңгарганбыз.
Яңа көрәшләр өчен вакытында туганбыз!

●

Туй күлмәген салгач,
алмагач
оялып куйды кояштан.

Күбәләкләр бии,
яз авазы булып күбәләкләр оча...

Сарысымы сиңа?
Яшелеме?
Кызылымы?..

Сөенче алып яздан
йөгерәсең, йөгерәсең...
Пар күбәләк булып күңелемә куна
күзләреңнең зәңгәр шәүләсе.

# Кышкы төн

Фонарьларның салкын уты
Эретеп яна төнне.
Сары сыкы булып карга
Коела төннең көле.

Урамнар тын, кешеләр тын...
Салкыннан тавыш сына.
Каенда йөрәккә охшаш
Ялгыз яфрак атына...

Шәһәр читендә ай йөзә,
Болытлар — кара күбек...
Ай — корабыннан йолкынып
Атылган җилкән кебек.

●

Күбәләк килеп кунгач,
чәчәк ачылып көлде.
... Кеше искәрмәде.

Пәрәвезгә көз хәбәре булып
яфрак кунды.
... Кеше искәрмәде.

Күләгәсен җиргә кысып
елан узды.
... Кеше искәрмәде.
Тыңлый иде:
күке — урман чегәне аңа
гомер юрый иде.

●

Ак чалмалы горур таулар!
Сискәнмәс тә бер кычкырсаң,
Кайтавазың гына сулкылдар.
Таулар шаркылдап көләр дә
Күкрәп шарлавыклар туар,
Ычкынырга торган ташлар
Түземлеген җуяр.

Ак чалмалы сабыр таулар...
Синең аваз — бер тамчыдай
Шарлавыктан чәчрәр дә
Тын упкынга тамар.
— Ай!..

## Кая соң?..

Кая соң шаулы елганың
Ашкынып аккан чагы.
Юлын бүлгән буаларны
Бөтереп аткан чагы.
Кая соң?..

Яралы ярлар читендә
Күз яше — чуерташлар.
Посып ага сулган инеш,
Төшендә — шашкан чаклар.

Дулкыннар шавын пышылдый
Хәтер күк кабырчыклар.
... Хәрабә — шәүләләр ярда.
...Биектә — ак болытлар.

●

Соңгы сүзең әле сүрелмәгән:
— Диңгез тели, — диден, — күңелем.
Сүзе бардай үрелеп ярыннан
Ымсынып калган иде Иделем.

Хәтеремдә калсаң горур килеш
Сагыныр да идем еш кына,
Ә син кайттың, адашып кайттың син,
Мин төн булып чыгам каршыңа.

Сүзсез сүзләр. Очынулар кая.
Төнге күлдәй күзләр тын... боек...
Таҗларына йомып ак кояшны
Күл төбенә чумган төнбоек...

●

Киләчәге — васыятендә калыр,
Яшәлгәне инде яшәлгән,
Картлар бит ул — серле дөнья кебек,
Акыл ташын тирән яшергән.

Дөньялыктан күңеленә китеп
Еллар санын алар чигерә.
... Ә тәрәздә пәрәвезләр яна,
Җәй, хушлашып, артка чигенә.

Безне, имеш, язлар гына котә,
Мәңгегә дип җиргә килгәнбез!
Китә барган саен аксакаллар,
Урыны буш кала — күрәбез.
Әйтелмичә калган васыятьләрен
Музейларга килеп эзләрбез.

Сызланмасмы күңел шундый чакта
(Вакытында белеп кал икән!):
Соңгы яфрак кебек өзелгәндә
Тукайларга чордаш могикан.

●

Күңелемдә адашырга яратам мин,
Андый чакта син чакырма мине.
Кемнәр белән, кайсы чакта хушлашылган,
Мин шуларны сагынып кайтам кире.

Дөньялыкта бүтән, ә күңелдә һаман
Туктап калган Вакыт бер ноктада.
Иделемнең ачык көндәлеге сыман
Акчарлаклар күктә — укып кара...

Барлыйм-саныйм. Асылын-чынын белгән
Күпме кеше күңел галәмендә?
Сокланырга кабат яңа өмет туа
Якынлашкан саен үткән көнгә.

Бар да исән монда, чиста карашларда
Чагылмый да ниләр күрәчәгең.
Ә тормышта шулай: кайсы түләп,
Кайсы яулап алган киләчәген.

Бар да шул ук монда. Бар да якын итә,
Күрешергә әзер сузган куллар.
Исемен җуеп олы сулар кочагында
Күмелмәгән әле инеш-сулар...

... Күңелемдә онытылырга яратам мин,
Сәҗдә кылам кайтып узган чакка.
Ә син дәшмә андый чакта, чакырма син:
Бер чистарып кайтыйм дөньялыкка.

## Тополь

Очарга дип талпынамы —
Җирне күтәреп карый кебек.
Давыл тынгач, кешегә ул
Мөлдерәп карый сабый кебек.

# Фәрит Гыйльметдинов

# УРСАЙ ТАУ ИТӘГЕНДӘ

ПОВЕСТЬ

## «Штрафной батальон»



Шәһәр чите. Тагы да кырыйдарак ике катлы бина. Анын түбәсендә «Автовокзал» дигән сүз ясаучы берәр метрлы эре хәрефләр көндез дә, төнлә дә янып тора. Каршыда эреле-ваклы, төрле төстәге, төрле формадагы автобуслар. Алар тигез булып, бер рәткә тезелгән. Асфальт мәйданчык та, бина эче дә халык белән тулы. Утырганнар нәни шахмат такталарына текәлгән, бер ишләре шау-гөр килеп домино суга. Урамдагылар төркем-төркем булып гәп кора, иртәнге сәгать булуга кармастан, бәхәс ачып җибәрүчеләр бар, тәмәке тарталар. Эче-тышы гөрләп, мыжгып торган шул бинага һаман төрле яктан халык агыла. Килүчеләр арасында уртача гәүдәле, йөзе ак булса да, кара-күгелҗем чәчле бер яшь егет тә бар. Бик әкрен атлый. Туктап-туктап тирә-ягына карана. Аннары, октябрь ае булуга карамастан, җиңелчәрәк киенгән: өстендә свитер гына. Башкалардан ул шунын белән аерыла. Сәгатенә карады: алты туларга унбиш минут, вокзал эченә кергәч, әрле-бирле сугылды да үзе кебек яшь бер егет каршысына туктады.

— Якташ, вышка монтажлаучылар кайда җыела?

Тегесе кулы белән урам якка ишарәләде.

Сораша торгач, үзенә кирәк кешене тапты. Анысы, кулларын сабыр гына артка куеп, кызып-кызып сөйләүче, яшел куртка кигән бер кешене тыңлый иде.

— Даут Сөнгатович сез буласызмы?

— Тыңлыйм.

— Мине сезнең бригадага җибәрделәр.

— Кем итеп?

— Хәзергә гади эшче итеп.

Бригадирның йөзе тартылып куюын Әндәм күз очы белән генә күреп калды.

— Кайдан, ГПТУданмы?

— Юк, урта мәктәп бетердем.

Бер мизгелгә тынып калган «яшел куртка», кулларын бутый-бутый, яңадан башлады. Бригадир аның ягына борылды. Аптыраудан гаҗиз булган Әндәм бригадир каршысына күчеп басты. Әмма аңа барыбер игътибар юк. Автобусларга утырыша башладылар. «Бездә эгоизм, кешеләргә игътибарсызлык түбәннән, үз арабыздан башлана,— дип уйлап алды Әндәм.— Начальство гади халыктан, һич бәхәссез, бер баш югары тора». Башта идарәдә, аннан соң кадрлар бүлеге начальнигы аны бөтенләй башкача каршы алганнар иде. Укыган халык — укыган халык! Монда? Кара, гап-гади бригадир гына бит ул, ә кыяфәте — король!

«Яшел куртка» аны уйларыннан айнытып җибәрде.

— Энекәем, болай эшлә: кайт өенә, йокыңны туйдыр, аннары кадрлар бүлеге начальнигы янына тагын бар. Хәмитов бригадасына мин кирәк түгел, диген. Икенче эш сора. Аңладыңмы?

— Минем кәгазем бар. Менә. Шушында дигән...

— Энекәш, без әйткәнчә эшлә. Сау бул!

Әндәм тагын нидер әйтмәкче иде, кул һавада асылынып калды.

— Даут Сөнгатович, кышка каршы балалар бакчасы ачмагыз. Әле болай да... Кадровик янына үзем керәм бүген. Пока!

Ул йөгерә-йөгерә вокзал эченә кереп китте. Бригадир, йөткерә-йөткерә килеп, каршысына ук туктаган автобусның ачык ишегенә сикерде. Машина пошкыру катыш үкереп торды да, дулап, кузгалып та китте, егермеләп метр үтүгә, һавасы белән тузаннарын туздырып туктап калды. Тәрәзә ачылып, бригадир башы күренде.

— Малай, йөгер әле монда. Ишектән кер!

Кузгалдылар. Урыннар җитмәгәнлектән, хәтсез кеше басып бара икән.

— Исемең ничек?

— Әндәм. Әндәм Галиев. Уникенче мәктәпне быел бетереп... — аның күзеннән утлар күренде. Авыртудан йөзе чытылды, гәүдәсе җыерылып, тагы да кечерәеп калды.

— Үзең гаепле. Башыңны бәрмә, дип кенә әйтмәкче идем, күп сөйләп ирек бирмәдең...

Зәй күперен чыккач, юл үргә таба менә башлады. Салонда эсселәтеп җибәрде, берничә тәрәзәне ачып ташладылар. Кемдер шофер янәшәсендәге чиләкне әйләндереп, Әндәмгә шунда утырырга ишарәләде. Автобус, йөк машиналарын уза-уза, үрнең түбәсенә үк менеп җитте. Табигатькә көзге алсу нурлар сибелде. Юлның күз күреме иңләгән ары очыннан, тау, елга, кырларны гына түгел, күңелләрне дә иркәләп, яктыртып, октябрьнең алтынсу кояшы чыгып килә иде. Егеткә җиңел булып калды: әйтерсең шул нурлар аның баш авыртуын да сыпырып алдылар. Утыз чакрымнар тирәсе юл үткәч, бер авылның итәгеннән күтәрелеп, башкорт җирләренә таба сузылган тау сыртына менә башладылар. Машина менә сүнәм дип буыла, яңадан сулышы ачыла, үкерә башлый. Шофер ишекләрне ачып ташлады. Таратып ташланган тимер-томыр, торба, агач ящиклар өеме каршысында туктадылар. Арткы рәттән кемдер русчалап: «Штрафной батальон, на выход!» — дип кычкырды. Ирләр дәррәү җанланды. «Нинди батальон, отделение дә юк монда! Оо-о, үзләренә яңа будка куйганнар. Даут агай малайларны тәрбияли!»

Төшүчеләр дәшмәде. Автобус ары китте. Тау өстендә бөтен дөнья уч төбендәгедәй ялтырап ята. Ары-бире каранырга вакыт юк, егет агайларга иярде. Будка чыннан да менә диган. Эскәмия буяулары ялтырап тора, ике озын өстәл, почмакта тимер шкаф. Утырыштылар. Барысы алтау.

— Бригадасына карап, эше, иптәшләр. Бүгеннән менә шушы вышканы кора башлыйбыз. Берничә электр моторы кайтып җитмәгән, без казына торган арада өлгерерләр. Сораулар юкмы? Тәк, тәк... Кичә башлаган вышкага икенче бригада күчте. Начальствога план кирәк, план. Ә без аны бирә алмыйбыз. Сораулар? Алайса, стоп! Тагын бер минут. Менә бу тәти егет безнең белән эшлим, ди. Киемең кая?

— Өстемдә. Күренмимени? — Әндәм үзенчә елмаеп җавап бирергә тырышты.

— Спецовкагыз дим! — бригадирның кашлары җыерылган иде.

— Мин...

— Каскаң? Аңлашыла. Рәис, Рәис дим! Нәрсә? Чалбар? Кичә салган идеңме соң аны? Әзлә! Иске будкада сынган калак та калдырмадык. Барысы монда. Риман, чибәр егетне таныштыр булмаса вышка белән. Ярты сәгать вакыт сезгә.

Бригадир ящиклар өеме янына китте. Риман — Әндәм кебек үк яшь егет, чандыр, озынча, чәчләре сары каскасыннан көлтә булып чыгып тора — ашыкмыйча гына өстәл түренә утырды. Башындагы каскасын салды.

— Исем, фамилиягез?

Әндәмнең йөзе чытылды, әмма җавап бирергә кирәк тапты.

— Әтиегезнең исеме? Ну-ну, мимика, иптәш Галиев! Шулай, безнең эштә барыннан да әһәмиятлесе — мимика, Әндәм Камилович. Мимика, ассызыклап әйтәм, яшь эшченең күңел көзгесе ул. Хәзер төп мәсьәләгә күчәбез. Урамга чыгыйк. — Ул брезент куртка белән каскасын Әндәмгә сузды. — Югалтмагыз. Менә шушы мәйданчыкта эшләячәксез. Безгә ияреп. Ашыгу, кабалану кирәк түгел, әмма йөрәк җылыгыз мул булсын. Монтажникларга кирәк ул. Көз, кыш көннәрендә аерата... Алга таба атлыйбыз.

Каршыда ябык кабыргалар белән кояшта ялтырап, буынлы-буынлы зур зәңгәр кәлтә еланы кыяфәтендә вышка ята. Сәер, Әлемдә җылы иде, әллә тау өсте булгангамы, монда суык. Әндәм калтырый ук башлады, бөрешеп төште.

— Маркасы кирәкме? Маркасы, маркасы төрле вышканың төрлечә. Ә моның — уртача. Уртача зурлыкта дигән сүз. Чамалый белергә кирәк. Син курыкма, сораш, сораш, эшләргә җиңелрәк булыр. Яшермим, мин дә шулай башладым. Хәзер, әнә үзең күрдең, бригадир күп вакыт миннән ярдәм сорый. — Риман, читен теманы аңлатучы өлкәннәр кыяфәте алып, әрле-бирле йөренә башлады.

Ул арада икесен дә чакырып кул изәделәр. Бардылар. Тегеләр дүртәүләп өем астыннан озынча бер ящик суырып чыгармакчылар. Бригадир, төркеменнән аерылып, ашыкмыйча гына сигарет кабызды. (Шунысы үзенчәлекле, аның һәр хәрәкәтеннән салмаклык сизелеп тора.) Озын итеп, тирән итеп суырды да Риманга дәште: «Вагон астында ломнар булырга тиеш, икесен дә апкил». Риман Әндәмнең иңсәсеннән этәрде: «Һаман аңышмыйсың, тиз, тиз бул, көттермә мине!» Әндәм килеп җиткәч, ломнарны, аның кулларыннан алып, бригадирга сузды: «Шеф, рәхим итегез!» Ярты сәгатьтән өем таралып, чәчелеп калды. Ул арада күрше буровой ягыннан, борынын югары чөйгән күтәргеч кранын сөйрәп, трактор да килеп җитте. Тимер-томыр, баскыч, төрле зурлыктагы блокларны вышканың кирәк турларына күчерә башладылар. Әндәм гаҗәпләнә калды: эш барышында, Риманнан кала, беркем сөйләшми. Ниндидер уртача бер темп алганнар да селкенә бирәләр. Ашыгучы да юк, туктап та тормыйлар! Рәис дигән юан малайдан рәт юклыгын сукыр да күрер. Хәрәкәтләре акрын, иренеп кенә атлый. Ата ялкау! Тартма белән аны да сөйрәргә кирәк. Риманның файдасы шул: кеше күтәргәндә кычкырып, көч биреп тора белә. Ә үзе тимерне энә тоткан кебек баш һәм имән бармаклары белән генә чеметеп күтәрер. Да, бригадир-

ның шәп ярдәмчесе икән бу! Даут Сөнгатович юка китабын ачып куйган да сызымнар өйрәнә. Ә калган ике агай кранның элмәген эләктереп, ычкындырып йөриләр, трактор борылып, чигеп, төрле маневрлар ясап алган арада, кирәк ящикларны шатыр-дөбер сүтеп ташлыйлар. Мондый минутларда Риман кайнар темпераментлы тамашачыга әверелде. Бугазы җиздән ясалган дип уйларсың, тавыш ифрат көр чыга.

— Кизәнеп бәр! Во! Лом белән, лом белән тарт! Отлично! Почмагына ман, почмагына дим, чүкеч белән! Шәп!..

Төш вакыты җитәрәк, ялга туктадылар. Риман да тәмәке тартучылардан түгел икән, укытучылык эшенә кереште. Куртка белән каскасын Әндәмгә янә сузды:

— Югалтма!

— Ну, агай-эне, ничек?

— Нәрсә ничек?

Риман тагын йөзен чытты.

— Беренче тәэсирләр?

— Әле эшләп карамадым ич.

— Аның өчен үзең эшләү шарт түгел. Күзәтеп тору да җитә. Борчылма, кардәш, әкренләп күнегәсең аны. Беренче сәгатьләрдә миңа да авыр булды. Ничу халыктан яшерергә.

— Күптән эшлисезме соң монда?

— Кәнишне, күптән. Өч көн булды инде, бүген дүртенчегә китте.

— Һмм... Аңа хәтле?

— Аңа хәтле төзелеш техникумы шәкерте идек, ачуланмасагыз. Сөрделәр. Тәртибең начар, диделәр. Хәзергесе көндә үз-үземне хезмәт белән тәрбиялим.

Баш очында аксыл күк, анда октябрьның тонык кояшы; аста, тау итәгендә — татар авылы, боргаланып агучы елга. Барысы да, өсләреннән сыек томан пәрдәсе белән тартылгандай, хәрәкәтсез, катып калган, коңгырт күренәләр. Әндәм белән Риман шулар уртасында. Тау кырында йөзтүбән ятканнар.

— Шулай, туган, үткән көннәр искә төшсә, күңел нечкәреп китә. — Риман изүен ачып җибәрде. — Шауламый тын гына ят. Ни сәбәптер, лирик чигенеш үзенә тарта әле мине.

Ул, кулларын алга җәеп, күзләрен йомды. Борынына фуражкасыннан тир исе, җир, кипкән эрем исе бәрелде...

*

* *

Билгеле, барысына да мин үзем гаепле. Акылны югалттым. Ул көннәрдә дөньяда мин генә кебек иде шул. Калганнар — тамашачы, зам, ярдәмчеләр. Бар да миңа ялагайлана. Кыскасы, икенче, өченче сорт. Ә мин — төрек солтаны! Кесә тулы акча, уңга-сулга сибәм! Позировать итәм. Чама дәрәҗәсе турында, кая ул, уйлау да юк. Булсын ие шул чакта бүгенге акыл! Әмма пожардан соң су сипмиләр. Әрмәннәр белән генә бәйләнмәскә иде дә бит миңа. Кая ул, эти дә тырышты инде. Югыйсә, сопроматтан экзаменны бер атнага алдан тапшырдым. Курсовойдан кара, бар да отлично! Каникулга иптәшләрдән ун көнгә элек киттем. Авылга кайтасы түгел, төзелеш отряды белән Төмәнгә китәсе калган миңа. Ак сакаллы акыл иясе була идем. Кая ул, эти чарасын куймады бит. Нинди җилләр китергәндер, унлап әрмән колхозга сыер торагы төзеп маташалар. Эшләрнең кызып бара торган чагы гына. Фундаментларны өеп бетереп килиләр. Эти завхоз кеше, тегеләргә азык-төлек җибәрә, бер пот бал, ике сарык тондырган. Әрмәннәрдә — акча, этидә — нигъмәт: дуслашмас җиреңнән дуслашырсың. Шул, боларның шайкасына, бәяләребез бер чама булгандыр, күрәсең, сарыкка өстәп,

мине дә төртте эти. Шабашник булып киттем! Ә эш дигәннән әрмәннәр булдыра икән. Класс! Иртәнге дүрттән кичке тугызга тиклем сөрәбез! Эш беткәч, юынып торырга ирендерә: хәл беткән. Аннан-моннан ашап аласың да ферма йортының киң сәкесенә авасың. Иртән күзне тырмап ачам, бәбәкләргә шырпы кыстырып дәрәҗәгә житешәсең: йомылалар! Бармакларны җылы суда җебетмәсәң, язылмыйлар. Менә шулай ике ай ярым эшләдек! Иңбаш, бил сызлый. Кыскасы, медаль алырлык. Безгә аны бирмәделәр, акча бирделәр. Район үзәгендәге банктан шайка бригадирының «Жигули»е белән бер капчык акча алып кайттык, банкет оештырдык. Колхоз председателе белән баш бухгалтер түрдә (дус булып йөрсә дә, эти эләкмәгән: ранг түбән), мин ишек катында, уртада әрмәннәр — типтерәбез. Хәмер — марочный, елга булып ага, ит — тау. Аксак бухгалтердан кала барыбыз да бии. Инде агач аягы белән хисапчы да сикерә башлагач, өй түзмәде, морҗаның алгы өлеше ишелеп төште... Көтү куар вакытлар житкән булгандыр, әтәч кычкырды, миңа хезмәт хакы бирделәр. Тау булып өелеп торган акчаны күргәч, күзләр колхоз пичәте хәтле булды. Айнып киттем. Байлыкны цемент капчыгына тутырдым да, иңгә салып, урам буенча өйгә кайттым. Бригадир миңа, өч мең ярым тия, дигән иде, акчаны эти, ак ыштаннан гына торып санагач, ике ярым диде. Кабалана-кабалана киенә башлады. Кая ул, әрмәннәр тайган, председатель белән хисапчы сугышып беткәннәр. Эш арасында гына елгага аркылы басма ясаган идек, бухгалтер ярдәме белән, шул күпер дип оформить ителгән икән... Авыл халкы арасында сүз китте. Әни кырын карый. Эти генә шат. Мал таба белә, үзем кебек үткен булыр, дип, иртә-кич мине мактый. Мин шәбәргән тавык кебек: кәеф юк, арылган, бөтен тән сызлый. Йоклыйм да йоклыйм. Ярый әле, техникум, лекция, дуслар бар. Уку елы башлануга сөенеп туя алмыйм. Үземчә, план төзеп куйган булдым. Семестр дәвамында бер сәгатьне дә бушка уздырмаска, картежникларны чакрымнан әйләнеп узарга, кызлар дип вакыт үткәрмәскә, эш дип янарга — программа минимум. Ленин стипендиаты булу — программа максимум. Өченче курста уку — шалкан ашау түгел. Завуч әйтмешли, йөз процент отдачи! Болар минем хыялым иде. Ә чынлыкта... Шәһәргә китәргә җыенып бетеп, иртәнге чәйне эчәргә утыргач, эти кулъяулыкка уралган төргәк сузды: «Кием-салым ал, авыл йолкышы кебек йөрмә, башың бар, шәһәрчә киен, кыяфәтең Гыйлемхан нәселеннән бу дип кычкырып торсын, кызганып тотма!» Актарам, башланмаган пачка: димәк, йөз бишлек. Кире этәрәм, акча болай да житәрлек иде. Әни дә минем яклы. Җебегән мин: соңгы минутта алдым. Ә алмаган булсам соң!

Минем хыяллар, сабын куыклары кебек, берничә көн эчендә шартлап беттеләр.

Лекциядән тулай торакка кайткан берничә малай, очрашу хөрмәтенә дигән хәйлә белән, бүлмәгә бикләнеп, хәмер белән кәефләнеп утыралар икән. Бусагадан кире борылу — дусларны якын итмәү дигән сүз. Тегеләр бик инәлеп ялынгач, мин дә чак кына йотып куйдым. Аз тоелды. Тагын бирделәр... Ике-өч айда сөйләр сүз хәтәр җыелган, берберебезне туктата алмый интегәбез. Шуннан китте! Нык китте. Кирәкмәгән якка юләрлек көчле бит безнең. Тора-бара дөнья күргән өлкән агайларга әйләндек:

— Я, Исламгали кордаш, хатын-кыз булма, төбенә хәтле тот!

— Мелла Касыйм, мин сиңа мәңге бәхил түгел!

— Бәлешен, бәлешен кап, ак май белән кап!

— Сарык итеннән дә авыз итегез инде, рәнҗетмәгез нәфис күнелемне!

— Эчәм, күкрәк киереп эчәм, келәт тулы икмәк, ике сыер, бер бурам бар, миңа тагын бу дөньяда ни кирәк?!

— Бәлешен, бәлешен кабыгыз инде, ак май белән!

Да, кая инде өстәлдә бәлешләр булу! Ашханәдән ялынып-ялварып алган винегретлар да (савыт-сабаны бүлмәләргә бирмиләр) чи йомырка. Ирәюнең чиге юк: шулай үсә-үсә, төрек солтанына әверелгәнмен. Кем вәзир, кем киңәшче булып киткән. Ханнар, гаскәр башлыклары — барчабыз бергә ашханәгә төшеп киттек. Ачык хәтерлим: чиратта торган курсташларга күрсәтеп, баш вәзирләрдән, болар кемнәр, нишлиләр, ник мине бил бөгеп сәламлиләр, дип сорадым. Ул, падишаһым, алар безнең халык, гөнаһ-бурычлары булса, зинһар ярлыка, мәрхәмәт күрсәт, диде. Мин ни, солтан кеше бит, «мәрхәмәт күрсәтергә» тиеш таптым. Кассир ягына юнәлдем.

— Апа, әллә мине танымыйсыз инде?

— Таныйм, балам, таныйм.

— Юк шул, таныганга охшамый. Бүген кәефле көнем, апа. Рәхим итеп, мондагы халыкларга бушлай ашасыннар!

Кассирга карап та тормыйча, инсә аша гына, аның алдына бер кесә бишлек ыргыттым. Аннары витринадан сыр алдым да, учта әвәләп, өскә чөйдем, һавада килеш аны авыз белән эләктереп, йотып җибәрдем...

Уф, чигәләрем кыса! Тән кыза. Өстәге брезент капчыкны болгап атып бәрдем. Рәис төркемнән аерылган да утырган килеш йоклый. ГПТУ тюлене! Ничек бетерде икән ул аны? Ә монда тагын берсе. Бикәч бозау кебек миңа карап ята. Әндәм. Тапканнар исем. Әндәм-Агдам! Агдам дигән вино эчкәннәр иде шул теге вакытта.

...Ашханәдән чыккач, караңгы төшкәнче футбол уйнадылар. Капкачы падишаһ ярлы-ябагайдан ике гол керттерде. Аннары тагын — Риманның кәефле көне бит — ресторан. Шул дәрәҗәгә барып җитәргә кирәк бит әле: ничек кайтканыңны хәтерләмә! Дуңгыз дуңгызович! Кирәк вакытта милиция кайда йөри, ник эләктермәгән ул мине? Мондый мәсхәрәгә юлыкмас идем. Вахтерша төн уртасында кайттыгыз ди. Аңа тиклем кая йөрелгән?

Иртәгесен яртылаш уянып киттем. Үтереп су эчәсе килә. Хәл юк. Бик зур авырлык белән, көчәнеп уң күзне ачтым. Ап-ак стена, нииндидер балерина фотолары. Безнең бүлмәдә мондый сурәтләр юк иде ич. Йөз процентка уяндым. Көч кереп китте. Сул күз дә ачылды. Чәчләр, коңгырт кара чәчләр! Менә спектакль! Кызлар бүлмәсе ич бу! Икенче курстагы чуваш кызы Эльвира койкасы. Хуҗасы һаман йоклый. Чәчләре белән бөтен кровать тулган. Бәхет, чишенелмәгән. Галстукны рәтләдем дә торып бастым. Чынлап, бергә йокланылган ич! Аяк тавышына-дыр, ишек төбендәге кроватьта йоклаучы Света башын күтәрде, кычкырып җибәрде...

Директор бүлмәсендә аңыштым. Чама дигән әйбер югалган булган, күрәсең. Баскычтан күтәрелүгә нәкъ каршы бүлмә, стена түреннән сул кровать — болары дөрес. Туры килә. Ә этаж? Этажы шул... дүрткә күтәреләсе урында, өчтә тукталынган. Ә анда кызлар бүлмәсе. Эльвира Чувашстаннан төнге унберләрдә килеп төшкән. Юл мәшәкате, фәләнтөгән, кыскасы, капитально йоклаган кызый. Кызык, уянгач, берәр нәрсә сизенде микән? Аңлатмага «Вакыт белешергә кердем» дип яздым. Бер гөнаһсыз кызлар исемен кәгазьгә төшерү егетлек булмас иде. Директор да молодец. Уратып-нитеп тормады, үгетләмәде, бүлмәсенә керү белән турысын ярды: куабыз! Фикерләр туры килә, ризалык белдереп, баш селкедем.

Да, ат белән егет башы ниләр генә күрми бу дөньяда! Әмма тиз генә бирешмик әле! Елама, оркестр! Әз булса да биография баер, тормыш күрермен. Бригадир болай ярыйсы күренә. Килешергә мөмкин булыр кебек. Прораблыктан куылган булуы гына кызганыч. Шуларны уйлап, характер күрсәтүе мөмкин. Әсхәт тә фигура. Плюс куябыз. Калганнар — бәрәңге. Белеп әйтәләр: штрафной батальон. Җыен чуп-чар, гөнаһ ияләре җыелган. Кешеләр арасында читен булачак. Гел-гел койрыкта,

юньлерәк бригадаларның калдыгын җыйдырта башласалар, оят, көн челек уянып, башка бригадага качарга туры килмәгәе. Алсалар. Әкрен Ашыкмыйча уйлаганда болай: язга барыбер армиягә китәм, түзәргә д мөмкин. Бер кичкә — кер мичкә... Җылымса, рәхәт җил исә. Йокларга иде рәхәтләнеп! Әллә кичкә Эльвира янына барып кайтырга микән Гафу үтенергә кирәк аннан. Мине яклап та сөйләгән бугай. Эх, көз Моңсу сагыш баса. Сары үлән, сары яфраклар. Күчәләр бу дөньядан Җир, туфрак ясыйлар. Ә шулай да чуваш кызының гәүдәсе кечкенә булса да, кыяфәте йогышлы, ягымлы да...

*
* *

— Риман, Риман дим. Әллә йоклап киткән тагы.
— Ну?
— Безгә дәшәләр бугай. Спецовкаңмы? Хәзер табам.
Әндәм анысын да алып килде. Бригадир чакырткан икән. Тартмаларга ышыкланып, ярым түгәрәк ясап утырдылар. Барысы алтау.
— Төштән соң, егетләр, әнә теге күрше будкага, трансформаторны рәткә кертергә дип, электриклар килә. Инструментларны җыеп тотыгыз. Ачкычлар наборына миннән рөхсәтсез тотынмыйсыз. Бусы — бер. Икенчесе: Әсхәт, сваркага тотынырга кирәк. Ярдәмчегә кемне? Риман. Яхшы. Галәү ага, бисмилла әйтеп, көч блогына тотынабыз. Рәис синең белән булыр. Тәти егет, обед заказать иттеңме?
— Кайчан?
— Мәсьәлә ачык. Аш-су китергән машина белән кайтып китәрсең. Спецовка ал. Җылы киемнәр юнәт. Риман, Рәис, монда, якынрак. Чит кешеләр алдында кичәге кебек безнең йөзне кызартмыйсыз. Бик теләгегез булса, әнә тау астына төшеп әрепләшегез. Аңлашылдымы?
— Мин беркемгә дә кысылмыйм. Риман башлый. Тел чарлап азаплана. — Рәис русча сөйли. Юан гәүдәсе белән торып ук басты.
— Татар теле аның өчен подпольный тел. Подумаешь, мистер!
— Соңгы тапкыр сорыйм: аңлашылдымы?!
Малайлар башларын иде.
— Аңлашылды.
— Эшкә!

## Дөнья мәңгелекме?

Гаҗәп дәрәҗәдә коры һәм җылы килгән көз ноябрь урталарында биреште: кышка тарта башлады. Бөтен дөньяны тутырып, ишеп яуган күбәләк карны төштән соң вак яңгыр алыштыра. Тау түбәсенә автобус белән менеп-төшеп йөрүләр бетте. Караңгылы-яктылыда таякка таянып күтәреләләр, эңгер-меңгер җиткәч, кайсы шуып, кайсы тәгәрәп төшә. Кара балчык лае цемент измәсе кебек: бер аягыңны күтәреп күчерә алсаң, икенче итегең, әлбәттә, җирдә кала. Вышканың бер очыннан икенчесенә бару өчен, берничә җирдә туктап ял итәргә кирәк. Элек өйрәнелгән гадәт буенча, бригадирның вышканы алданрак, бәйрәм хөрмәтенә, алтынчы ноябрьга тапшырырга дип уйлаган ышерен өмете бар иде. Ун көнгә якын штурмлап та карадылар. Тик... Шул, электр. моторларын беркетеп бетерүдән ары уза алмадылар. Атналык эше калды. Көннәр буенча бер минут ял белмәгән Әсхәт кул селтәде. Премия алырга гадәтләнгән Галәү, чит терминнарны кертеп, озак итеп сүгенде. Бу хакта өлкәннәр тарафыннан кычкырып сөйләнелмәгән иде. Һәркайсы үз тәҗрибәсе, тоемлавы буенча эшләгән, тырышкан иде, яшьләр бу

«челлә»нең хикмәтен идарәдә тантаналы кичәнең төп докладыннан гына шәйләделәр шикелле. Партоешма секретаре, барлык бригадалар хакында да кабат-кабат тукталып сөйләсә дә, Хәмитов бригадасын телгә дә алмады. Тынгы белмичә көн-төн чабып йөреп, гади эшче кебек үзе эшләп йөргән Даут Сөнгатовичның шушындый изге көндә фамилиясе яңгырамавы Әндәм өчен зур гаделсезлек булып тоелды. Дулкынлануыннан бит очлары кызышты, уч төпләре тирләп чыкты. Күршесе Рәис йокымсырап утыра икән, ачудан тегенең кабыргасына төртеп алды. Риман башын аска игән, үзе тирән уйда. Картларның карашы салкын, докладчыга текәлгәннәр, кыяфәтләреннән аны-моны чамаларлык түгел. Башкалар шат, елмаялар, кирәк булмаган урында да шаугәр китереп кул чабалар. Әндәмгә залны күзәтү туйдыра башлады. Җыелган ачуын прорабка юнәлтте. Тегесе яшел курткасын яшел костюмга алыштырган да президиумның беренче рәтендә җәелеп утыра. Губернатормыни? Җитмәсә тагы, бүләк итеп, аңа да кул сәгате бирделәр.

Өч көн ял итеп, эшкә чыкканның беренче көнендә бөтенләй сөйләшмәделәр. Ике этәч — Риман белән Рәис — ләм-мим әйтешмичә, баскычларны беркетеп бетерә яздылар. Кичке якта һава күзгә күренеп бозылган иде. Вак кына сибәләп, салкын яңгыр ява башлады. Күк йөзен солдат шинеледәй соры болытлар каплаган; куна килә яңгыр, моны һәркем чамалый, әлбәттә, тик барыбер — аңа да игътибар итүче юк. Көч блогындагы гидравлик тормозны көне буе диярлек оясына төгәл утырта алмыйча азапланучы Галәү агай белән Әндәмнең йөзләренә яңгыр туры төшә, майлы бияләй белән җиң арасыннан кергән дымлы суык җил, эчкә үтеп беләкләрне өшетә — игътибар итмиләр. Кечкенә кара тәрәзәле битлеген киеп алган ябыштыручы Әсхәт робот-машинага охшап калган. Торна борынылай озын электроды белән тимергә кагылып ала да тирә-якка ап-ак очкыннар чәчә: «Чтр-р-р-р!..»

Вахта йөртүче автобусның тау астында озын-озын итеп кычкыртуын ишеткәч тә туктарга ашыкмадылар. Бары тик тау түбәсенә күтәрелеп килүче, мышнап беткән шофер күренгәч кенә бригадир, бияләйләрен салып, кулын югары күтәрде: «Моторларны сүндерергә!»

Карлы яңгырлар көчәйгәннән-көчәйсә, егетләр арасындагы салкынлык кимегәннән-кими: вышканы күтәртер сәгать җитте. Билгеләнгән вакытка, ни сәбәптер, тракторлар килеп җитмәгән иде, яшел курткасы өстеннән брезент плащ бөркәнгән прораб белән бригадир, саз ярып, күрше буровойга киттеләр. Дизельләргә тагар өчен, иллешәр метрлы тросларны вышканың төрле урыннарына бәйләп йөреп, хәлдән тайган егетләр солидол баганаларына әйләнгәннәр, киемнәре суга тәмам туенган: яңгыр, калай өстенә тамган кебек, шыбырдап төшә дә җиргә ага. Бөтен кирәк-яракны хәзерләп бетергәч, бата-чума будкага тулдылар. Әсхәт ясап куйган электр «кәҗәсе» бөтен көченә кыздыра. Аның «мөгезенә», «койрыгына» күлмәк-чалбар элделәр. Тирә-ягына каешланып каткан тышкы киемнәрне тезеп утыртып куйдылар.

Рәис буш калган эскәмияләрнең берсенә сузылып ятты. Калганнар сумка, портфельләрендәге азык-төлек запасларын өстәлгә бушата башладылар.

— Корректно коя яңгыр, почти ферзевый гамбит! — Галәү агай ишек төбендәге чиләктә кулын юа башлады.

— Риман, минем портфельдә чиста сөлге булырга тиеш,— диде Әндәм, күлмәген салып азапланган җиреннән.

— Өлкәннәргә хөрмәтне үзем күрсәтәм.

— О-о, монда күпме китап! Библиотека ачарлык! Платон. Гегель. Диамат! Юкка интеккәнсең, дус кеше, рәсемнәре юк ич боларның, кеше күргәнче кире илт. Ә бусы? Но-о! — Риман торып басты. — Галәү ага, ферзевый гамбит! Кулларыгызны майкагызга сөртегез.

Интонациянең шулай кырт үзгәрүеннән, өстәл янына барырга дип кузгалган Рәис тә туктап калды.

— Шулай, аягүрә басып тыңлагыз. Галиев Әндәм Камилович академик Губкин исемендәге нефть институтының кичке факультеты студенты. Беренче курста укый. Сабыр итегез, иптәш Галиев, бу очракта тыйнаклык сезне бизәми. Дәлилләр кирәкме, Галәү ага, рәхим итегез студент кенәгәсен. Корректно гына карагыз!

Китапларын кочаклаган Әндәм гаепле кыяфәт белән читтә басып калды, тегеләр Риманны сырып алдылар.

— Рәис, иснәп карама, фальшивый түгел.

— Пошел ты!

— Яле, яле, акыллым, әйтеп бетер.

Бригадир югалып торганда, житәкчелек автомат рәвештә Әсхәткә күчә.

— Малайлар!! — Шау-шу басылгач, тавышын үзгәртте.— Барыгыз да өстәл янына. Ә син, студент, түргәрәк уз. Шулай кирәк, молодец!

Төш вакытында үзәнлеккә төшеп йөрүгә бик күп вакыт һәм көч сарыф ителгәнгә күрә, һавалар яхшырганчы кайнар аштан вакытлыча баш тартканнар иде, термослардагы жылымса чәй белән канәгатьләнделәр. Үткән көндә башланып калган Чистай побының финанс кереме мәсьәләсе ачыкланып бетмәсә дә, бүген яңа, «фәнни»рәк әңгәмә башладылар.

Галәү аганың укыган кешеләрне ярата, алар тирәсендәрәк буталырга тырыша торган гадәте бар. Үзенең биш кенә класс бетерүеннән ояла, кул астына нинди журнал эләксә, шуны укып, сөйләшкәндә чит термин, сүзләр кыстырып, шушы кимчелеген капларга тырыша иде. Әндәм аның каршысында бер башка үсеп китте. Соңгы вакытларда күптән борчып, бигрәк тә тынгысызлап йөдәткән мәсьәләсен кузгатты.

— Син инде арада корректныйрак кеше, Әндәм, әйт әле, синеңчә дөнья бетәме? Бетсә, әйтик, кайчанрак?

Жавапны беренче булып, әлбәттә, Риман бирде.

— Бетәр. Әмма якын арада түгел әле. Башка кайгыларың булмаса, тынычлап эшлә, Галәү ага.

— Юк, юк, син кысылмый тор. Мин Әндәмнән сорыйм.

Тегесе көлеп куйды.

— Бетми, Галәү ага, курыкмагыз, Риман шаярта. Каян башыгызга килде әле бу?

— Килде дип, китап шулай яза бит. Ахырзаман алдыннан жирнең маен суырырлар, һавада тимер кошлар очып йөрер, дигән. Корректно бит, туры килә.

— Уйдырма болар Галәү ага, ялган. Минем әби дә гел шуны сөйли, димәк, шәһәрдә кемдер коткы таратып ята.

— Коткы дип, күршедә бер пенсионер карчык тора. Реально. Хатын шуның яныннан чыкмый да хәзер. Дөнья бетә икән, ди.

— Минем дә әни сөйләнде бит бу хакта,— ни аз сүзле Әсхәт тә кушылды.

— Шул, хатын әйтә, күрше карчык ишеткәнен реально әйтә, Мөхәммәт пәйгамбәр үлгәндә ике бармагын югары күтәргән дә көнчыгышка күрсәткән ди. Значытсы бу, ике меңенче еллар ягына чыккач, жир өстенә афәт кояш чыгышы ягыннан киләчәген аңлата икән. Чын булырлык булса, бик корректлы булачак бу.

— Олы башыгыз белән шуңа ышандыгызмы?

— Ышанмый ни, Кытай ягы хәзер дә шаулый. Япун да кушылып, зуррак бомба жибәреп куйсалар, илең түгел, дөньяң шартлар. Корректномы?

— Дөрес, атай, корректно!

Риман илһамланган кыяфәт белән сикереп торды. Кулларын артка куеп, ишекле-түрле йөреп алганнан соң, Әндәмнең портфеленә тыгылды. Аның бу кыланышын охшатып бетермичә, сәерсенеп күзәттеләр.

— Студент, кәгазь алырга рөхсәт итегез?

— Алдың ич инде!

— Пардон! Башта тыңлагыз. Һәрбер предмет, материя, җисем, тереклек иясе һәм башка шундый иярләр молекулалардан тора. Ә аның төзелеше болай. Ясап күрсәтәм: үзәктәге нокта — төш. Аның тирәсендә электроннар әйләнә. Икенче рәсем: үзәктә кояш, тирәсендә планеталар әйләнеп йөри. Төзелешләре охшаш бит.

Дәфтәр бите кулдан кулга китте.

Шул чак каерылып ишек ачылды. Шыбыр суга батып бригадир килеп керде. Нәрсәдер әйтергә теләп, ачулы кыяфәт белән, кулын күтәргән иде, Әсхәт торып басты, тавышланмаска ишарәләп, башы белән эскәмиягә таба ымлады.

Хәмитов аптырап калгандай тоелды, хәтта кызарып куйды, әмма утырды.

Риман Хәмитовка да игътибар итмичә сүзен дәвам иттерде.

— Бәлки бу планеталар, шул исәптән җир дә, чынлыкта электроннардыр? Мөмкинме? Кояш — төш, планеталар — аның тирәсендә әйләнүче электроннар?!

— Ха-ха-ха! Уф! Җир — электрон! Нидер җитми сиңа, чын күңелдән әйтәм, кичтән балык мае эчкәләп кара! Ха-ха-хи! — Рәис, эчен тотып, почмакка өелгән газета өемнәре өстенә ауды.

Дөнья чынлап беткәндә дә ваемсыз гына йокымсырап утырыр кебек тоелган Рәиснең шулай кинәт кабынып китүеннән сәерсенеп калдылар.

Бәхәснең сүнеп калу мөмкинлеге Галәү ага өчен олы бәхетсезлеккә тиң булыр иде. Өстәлдәге кәгазь битен ике куллап, кадерләп тотып, Риманга сузды.

— Ферзевый гамбит! Риман, зинһар өчен, әтиең кебек агаң сорый. Сөйләп бетер.

— Шулай, дөнья чиксез. Галәмнең очы-кырыена чыгу мөмкин түгел. Әмма ул кечерәю ягына да шулай ич! Бүгенге көн өчен кечкенә кисәкчә — электрон. Бәлки аның эчендә тагын бер төш, аның тирәсендә әйләнеп йөрүче электроннар бардыр. Димәк, «төш-электроннар» системасынарак охшаган чылбыр хасил була. Бер очы чиксез кечерәюгә китсә, икенчесе — чиксез зураюга юнәлгән. Без шул чылбырның бер бөҗрасында яшибез. Башка звеноларда тормыш юк дип кем инкарь итә ала? Ул — тормыш гигант зур масштаблы яки гаҗәп кечкенә формалы тереклек иярләре арасында да булырга мөмкин.

— Отлично, ферзевый гамбит!

— Стоп! Синеңчә, без ниндидер гигант хайванның атомы, юк, электроны эчендә яшәп ятабыз.

— Башта урамга чыгып, уянып кер. Югыйсә, сиңа нәреп иснисе килә.

— Рәис, кысылма. Сүз бирербез — сөйләрсең. Риман, атаң кебек кеше мин...

— Юк, Риман башта җавап бирсен. Мин әйткән фикер мөмкинме?

— Мөмкин.

— Ха-ха-ха!! Кичен балык мае эчкәлә. Хи-ий!

— Галәү ага, әгәр мена бу тюлень урамга чыгып китмәсә, сөйләмим.

Галәү ага бала-чага кебек сикереп торгач, Әндәм кушылды.

— Риман, син инде бәхәсне егетләрчә алып бар. Сорыйлар икән — исбат ит.

— Итәм! Әгәр дә ниндидер көч тәэсир итеп, электрон үз орбитасыннан читкә ычкына икән, материя халәтен үзгәртә, башка төрле формага күчәргә мөмкин. Җир үз орбитасыннан ычкынса, Кояш системасы үзе-

нең шушы торышын югалтачак. Җирдә тормыш бетәргә мөмкин, ә дөнья кала, чөнки ул чиксез, мәңгелек.

— Алайса, җирдә тормыш дигәнең кай тирәдәрәк бетәргә мөмкин соң, реально гына?

— Курыкма инде, атай, шул хәтле. Әйттем ич, бүген-иртәгә генә бетми әле.

— Галәү ага, ник шул хәтле кызыксындыра соң әле сине дөнья бетүе?

— Кызыксындыра дип, шул хатын инде һаман. Кассада бераз акча бар иде. Әрәм булып калыр, машина алып, ичмасам, бераз йөреп калырбыз дип, үтерә инде. Аптырагач, шоферлыкка укырмынмы әллә дип, ДОСААФка да барып караган идем. Күзләр хөртирәк бит минем, комиссиясен узып булмады.

Ул арада тышта моторлар гөрелтесе ишетелде. Ашыгып киенә башладылар. «Гыйльми» бәхәстән иң канәгать калган кеше Галәү ага иде. Ихтирам йөзеннән, Әндәмгә каска сузды. Идәнгә утырган Риман янына чүгәләп, аякка чолгауларны ничек урарга икәнлеген күрсәтә башлады. Бәхетләренә каршы, яңгыр туктап калган иде. Җылытып та җибәргән кебек тоелды. Тросларны алты тракторга тактылар. Даут Сөнгатович машиналар каршысына чыгып басты. Бу — аның иң яраткан урыны, иң дулкынландырган минутлары. Мондый мизгелләрдә аның күз алдына һәр вакыт оркестр каршысына чыгып баскан дирижер килә. Ул кулын югары күтәрде: «Игътибар! Барыгыз да әзерме?» Әкрен генә эшләп утырган моторлар дәррәү гөрелдәп куйдылар: «Әзер!» Бөтенесенең дә карашы бригадирга юнәлгән. Менә ул алга сузылган кулларын салмак кына үзенә таба җыя башлады: «Башладык!» Дизельләр шушы хәрәкәткә иярде. Йөрергә яңа өйрәнгән балалар кебек, кыюсыз гына алга үрмәләделәр. Беренче тракторның канаты тартылып бетте. Башкаларныкы әле буш. «Беренче стоп!», «Дүртенче, бишенче, тукта! Икенче, алгарак!» «Кереш музыка тәмам, төп әсәргә күчәбез! Игътибар! Алга!» Тыныч кына яткан вышка, башта ризасызлык белдереп, калтыранып куйды, башын калкытты, аннары бөтен гәүдәсе белән җирдән аерылды. Оркестр бар көченә уйный: тракторлар, күзләрен бригадирга текәп, тамак төпләре белән сузып җырлыйлар, аларга скрипка кылыдай нечкә тавышы белән вышканың тимер кабыргалары арасында яңа уен тапкан ноябрь җиле кушыла. Куллары югары күтәрелүгә җитмеш тонналы әзмәвер, тураеп баскан килеш, бер каршылыксыз туктап калды. «Дирижерның» яңа ишарәсе — һәм егетләр корыч арканнарны җиргә кагылган якорьларга беркетә башладылар.

Асфальт юл буйлап, фараларын кабызган «ЛАЗ» автобусы чаба. Кузов зур, иркен, буш урыннар да күп, әмма хәмитовлылар бер тирәгәрәк утырган, элеккеге кебек, башка бригадалар арасында буталып бетмәгәннәр. Беренче утыргычта бригадир белән Рәис, аннары Әсхәт, Әндәм, Галәү белән Риман. Җылы. Суыкта тартылып калган тәннәр язылып киткән. Адәми зат карангыда артык җәелеп сөйләшүне хуп күрми. Һәркем үз уена чумган. Кайтыр юл шактый озын, борчучы юк, рәхәтләнеп хыяллан, уйла! Каршыга килүче машиналарның уты яктысында сваркачы Әсхәтнең кырыс йөзе чагылып китә. «Заманалар тиз үзгәрә башлады. Күз иярми. Яшьләрне генә кара хәзер. Гәүдәләре күсәк кебек, фикерләре — бала-чаганыкы. Төпле акыл утырмаган. Уйлап чыгаралар бит әле: җир шары бетәргә мөмкин, ә дөнья — юк. Җир ярылып-нитә калса, дөнья бетә дигән сүз ич инде. Юләр дә моны гына чамалар. Ә хәзерге яшьләр — юк, ди, бетми, ди. Яшәү, тереклек итү җиңел бирелә аларга. Бары да житеш, төзисе, җитештерәсе, юнәтәсе юк. Һоп, тегеләр әзер өстенә! Шуңа күрә кадере дә юк. Әйтәм ич, хәзерге тормыш уен гына. Һәр эштән кәмит табарга гына торалар. Яшьләр анда уйнап кына йөриләр. Без үсkәндә булсын иде ул шушындый шартлар. Кая

ул?! Унсигез яшемдә мин Кенигсберг янында, автомат тотып, беренче тапкыр атакага бардым. Атакага! Әйтергә генә җиңел. Окоп төбендәге кызыл балчыкка сыенып, өстеннән үз иле танкасын үткәрмәгән, кабалanудан бруствер балчыгын ишә-ишә, броняга ышыкланып, бөтен гәүдәсе белән дошман каршысына калкып карамаган кеше, мөгаен, бу сүзне әйтергә дә лаек түгелдер. Чөнки ул барыбер аның мәгънәсен, эчтәлеген аңламаячак, авырлыгын тоймаячак. Менә бу шантрапаларга шуны сөйләсәң, мәзәккә әверелдереп, хәзер көлә башлаячаклар. Заманалар! Кайсы якка — юньлегәме, әллә кирегәме үзгәрә алар? Әгәр менә бу тәти егетләргә корал тоттырып, дошман өстенә җибәрсәң, ни белән бетәр иде икән? Уен тиз онытылыр иде, бусы — бәхәссез. Иң мөһиме: күпмегә түзәрләр иде икән? Атна яки айгамы? Ә бит безнең буын түзде. Ничек кенә түзде әле! Җиңү яуланып, сугышны бетергәч тә әле адәм рәтле йокы күрмәдем. Башны мендәргә генә терим, каршыма шул ут, шул танк баса. Кыш чыккан салам чүмәләсе эченә танк яшерергә кайсы фриценең башына килгәндер, ничек абайламаганбыз, язмыш шулай язгандыр бәлки, без — иң сул канаттагы отделение — каршыдагы шул салам өеменә томырылдык. Алдан кинәт тубал хәтле ут бөркелде дә, яңакларны көйдереп, тылга сызылды. Шартлау дулкыны мине әйләндереп җиргә салды. Шулай да гранатаны томырырга өлгереп калдым... Колактан аккан канны госпитальдә туктаттылар, ә ялкын шәүләсе, ерактагы аҗаган кебек, күңел түрендә озак еллар уйнады. Инде ул онытылып та беткән иде. Сваркага күчкәч, шул галәмәт кабат калкып чыкты. Йончылып, янган тимер исеннән исереп, катып авасың, күз алдына сварка утына кушылып, дөрләп янучы танк килеп баса. Менә шулай, безнең яшьлек башка төрле үтте. Хәзерге кебек дөнья мәңгелекме дип, әкият сатарга, паркларда кичләрен маймыл кебек кыланып биеп йөрергә вакыт булмады. Тиздән ел ахыры, суыклар башлана. План дип кыса башлаячаклар. Хәзергә бик көр утырасыз, дөнья дисез. Хәмитов биетәчәк әле сезне, ученыйлар. Бу эштә ул бүре ашаган албасты, кайсы кнопкаларыгызга ничегрәк басу җаен тиз табар. Кемнең кем икәне ачыла инде анда. Бәйрәмне премиясез үткәрттегез, шаулаучы булмады. Хәмитов вакланмады. Монысы алай шома үтмәс. Сәгатьләр буе будкада кызыну төш булып кына калыр. Ни дөнья күргән безне дә маемлата ул план куулар. Күп йөрдек без яшьләр белән, беләбез. Барысы да кулларыннан килгәнчә тырышты, тир түгеп эшләделәр. Өлкәннәрнең авызларына гына карап торалар иде. Ә болар? Тфү! Бар да ученый, белдекле, ә син ак чәчле башың белән шуларның әкиятен тыңлап тор. Әле ничек, вакыты белән онытылып китеп, үзең дә сизми утырасың бит. Сүзләренә кушылып китәсең! Менә кая тарта заманалар! Бала атадан узып сүз ката, эшләгән эшеңне мәзәккә чыгара, әкият итә, син шуңа сөенеп, кул чабып тор. Шулай килеп чыга да. Әнә бит Галәү, карт юләр, бер шалапутының күзенә карап, авызын ерган. Бәхет кошы тотканмыни. Хәзергә шатланып кал, картлач, шулай ирәйтсәк, тоттырырлар әле алар, күрсәтерләр безгә бәхет кошын!»

Әсхәтнең күршесе Әндәм, кулларын чалыштырып күкрәгенә куйган, башын әз генә артка ташлаган, күзләре йомык. Ул уйланып кайта: «Хәзер биш тулып килә. Кайтып җитеп, ашап киенгәнче җиденче ярты җитә. Ә җидедә дәресләр башлана. Философиядән семинар. Уңайлы вакыт йолкып, караштырып булмасмы дип, дәресләкләрне дә кыстырган идем, кая ул, бар, укырсың янәшәңдә Риман булганда. Өченче сәгать — математика. Әзер түгел. Кара исәп белән генә дә, минем килеп җитүне көтеп, ике-өч икеле елый. Болай дәвам итүе мөмкин түгел. Икенче вариант эзләргә кирәк. Бәлки бер-ике сәгатькә йокыны кыскартыргадыр. Алай итсәң, әбигә читен булачак. Нәрсә эшләтәсең, гадәтенә кергән бит: мин йокыга китмичә, караватына ятмый. Аннары биштән торып, иртәнге аш хәзерли. Ял кирәк аңа хәзер. Кешеләргә свитер, оекбаш

бәйләвен дә туктатырга кирәк. Мәктәп баласы түгел мин, эшлим, акча җитәрлек. Һәрбер көн әбигә бәйрәм булырга тиеш. Уйларга, оештырырга гына кирәк. Әллә берәр йөз сумга әҗәткә кереп, телевизор алып кайтыргамы? Юк, чынлап, ни тора ул, эшлим ич мин! Рәхәтләнеп татарча концертлар карар иде. Ял көнне берәр театрга алып барырга кирәк. Стоп, каршыда Зирекле борылышымы? Әйе. Вакыт? Алтынчы ярты. Кичәгедән унбиш минутка иртәрәк кайтабыз. Яхшы. Димәк, дәресләр башланганчы бер мәсьәлә булса да чишеп куям. Алга, шофер. Кызганма, ку «Чайка»ны!»

Галәү ага аш-су, чиста эчке кием-салым йөртә торган хуҗалык сумкасын кочаклаган. Аның да үз уе: «Эш дип, бу егетләр белән полный эшләргә була. Итәгатьлеләр. Арурак участоклар бирсәләр, бер дигән бригада булачак. Даутны селкеткәләргә кирәк, соңгы арада йоклап йөри. Я ут бетә, я тракторлар килми... Малайларның рухын төшермәскә кирәк. Ничек башласалар, гомер буе шулай дәвам итәргә мөмкин. Рәис дигәне болай да үшәнләнеп беткән. Я чирле ул бала, я бер-бер хәл булган. Сәламәт, бер кайгысыз кеше шулай йомык булырга мөмкин түгел, Риман белән Әндәм алтын егетләр. Алар белән эшләгәндә күңел ял итә. Беренче чиратта кеше шат булырга тиеш. Шулай булса, эш тә барачак, көннең үткәне дә сизелми кала. Разе бу начар? Риман белән Рәис обед алып килсәләр киләләр, килмәсәләр юк. Общежитие галәмәте инде бу. Хатынга әйтергә кирәк, аларга да суган белән колбаса булса да төрсен. Машина, комбинация ди-ди, балаларны ачлы-туклы йөртер хәл юк. И аңлатырга кирәк булыр, дөнья бүген-иртәгә генә бетми әле, бездән соң да бетүе шикле, ничу куркып яшәргә!.. Бу арада көнтөн гарәпләрне сөйлиләр. Әйтергә кирәк, мөселманнар бит алар, ник шулай үзара сугышып яталар, бер-берсен хәлсезләндереп кенә бетерәләр бит, шуны да аңламыйлар микәнни? Җай чыкса, иртәгә шушыннан башларга кирәк. Егетләр грамотный, ул яктан рәхәт. Укыган кеше белән эшләве үзе бер гомер. Ферзевый гамбит булса булыр, иртәгә гарәпләрдән башлыйбыз».

Рәис сул яңагын тәрәзәнең салкын пыяласына терәгән, калын гәүдәсе кузов стенасына сыланып диярлек беткән. Аның белән утырган бригадир арасында өченче кеше сыярлык буш ара калган. Суыктан ярылган куллары маңгаен, йөзен каплый: «Булды. Хәл кылынды. Кылынды гына түгел, ант итәм. Әгәр суд шул маймылны якласа, мин аңа темный ясыйм. Көч җитмәсә, бер-ике малайны яллыйм. Ярты куям, акча бирәм, әмма үземнекен эшлим. Гомерлек төрмәгә керәм, әмма ул маймылны дөньяда яшәтмим. Менә бу, минемчә, дөреслеккә туры киләчәк. Закон, судның үз гаделлеге булса, минем дә үз гаделлегем бар. Дөньяга мине закон түгел, әти тудырган. Минем гаделлек аның яклы. Әти, син борчылма, өч ел үтә дә китә ул, баш исән булсын. Әз энекәш белән һәр вакыт әни янында булырбыз. Бер дә кайгырма, әни безнең өчен элекке кебек кызармас хәзер. Энекәш мәктәптән качып йөрү түгел, үзе теләп тугызынчыга китте. Менә ничек хәзер хәлләр! Мин үзебезнең поселокка көн дә кайтып йөрим. Кичке ундагы автобус белән китәм, иртән вахта машинасы алып килә. Йокы гына азрак эләгә. Анысына гына түзәрбез. Тулай торакта форма өчен генә торган булып кыланам. Паспортка шәһәр печате кирәк. Яңа ел узгач, әни белән, әлбәттә, синең янга киләбез. Эх, әти, әтием! Теге вакытта мин күпме ялынган идем. Вәгъдә бирмә, әти, бозлавык, «Жигули» түгел, өч күчәрле йөк машиналары юлда аркылы килеп ята, дидем. Үзең үк белә идең ич. Шул маймыл кыяфәтендәге йонлач художникның ялварулына каршы тора алмадың. «Бөреле» аэропортына гына илт инде, әни белән апа каршында авторитетны төшерәсе килми, изгелегеңне мәңге онытмам, имеш. Начальство кыяфәтендә күренәсе килеп, автобуста йөрергә ояла икән, такси яллаган иде. Сез чыгып китүгә үк, бер сәбәп-

сезгә күңелем тулып, елыйсы килеп йөдәтте. Җимерелгән машинаны күрше милиционер капка төбендә калдыргач, аның югалтып әни идәнгә ауды. Художник белән сине больницада диделәр, арткы утыргычта барган әнисе белән апасы моргта... Син төрмәгә киткәч, якын дустым дип йөргән художникның сары чәчле хатыны белән атна саен килеп йөри башладылар. Даулап, әнидән күпме акча каерганнардыр, әйтми. Шактый булырга тиеш. Әмма иң чиркангычы — күмү расходларын капларга дип, синең Ираннан алып кайткан «Москвич»ыңны дәгъвалыйлар икән. Әни әйтә, шуны сорап судка биреләр, ди. Әти, монда бит мин дә гаепле. Тыңлаучан, тәртипле бала булсам, шул вакытта минем сүзгә колак салыр, бер кая да чыкмас идең. Ә болай кул гына селтәдең. Кем белгән аны ул чакта мондый көннәр килерен. Менә хәзер күрәм инде. Дөньяда әле әнисенең үлеменнән дә акча ясап калырга тырышучы кешеләр бар икән. Шундыйларга каршы көрәшергә кирәк. Мин әйткәнне тыңлап та карамаячак ул маймыл, андыйдан узган, әгәр дә суд аның яклы булса, кабат суд ясыйм. Үземчә. Соңыннан бер-бер хәл килеп чыкса, әни кызганыч. Тагын түшәккә авачак. Ә башка мәсьәләдә безнең хакта аңа начар хәбәр ишетелмәс. Сүз бирәм, юк, ант итәм, әти!»

Киек каз юлына тәңгәл рәвештә җирдән асфальт юл үтә. Биргән почмагына җитәрәк ул үр менә башлый. Шул юлдан якты утларын балкытып, машиналар бертуктамый алга йөгерә. Әйтерсең аларга җирдәге юллар гына кыска, шуңа күрә үзләре ак, кызыл йолдызлар булып кабынганнар да җирдән күккә ашалар.

Вышка монтажлаучылар утырган «ЛАЗ» автобусы шәһәргә якынаеп килә.

## Зөһрә

Кичке сәгать өчкә конторада комсомол җыелышы билгеләнгәнлектән, махсус машина егетләрне төштән соң ук алып китте. Үзләрен җитәрлек җәфалаган буровойны корып бетереп, аны чын хуҗалары — бораулаучыларга тапшырганнар иде инде, яңа урында эшлиләр иде, яшьләрнең хәтта китәсе дә килмәде. Таш булып каткан карлы бияләйләрен вагон идәненә ыргытып, җылынырга утыргач та Галәү ага аларны кузгата алмыйча озак тинтерәде: «Җыелыш дип, балалар, начальникларның ачуын чыгара күрмәгез, соңга калганны яратмый алар. Анда утырмагыз, эшлисеңме дисәләр, эшлибез диегез. План аласызмы дисәләр, алабыз диегез. Начальство шуны ярата. Инде дә килеп сөйләргә кушсалар, карышмагыз, Риманны чыгарыгыз.»

Килеп төшкәч, Әндәм башта, вокзал түгелме бу дип, шикләнеп тә калды. Шул ук күренеш: яшьләр чүгәләгән көйгә шахмат уйныйлар, өчәр-дүртәр булып, дөнья хәлләрен сөйлиләр, тәмәке тарталар, кулларын артка куеп, берни дә эшләмичә тик йөриләр. Шул ук халык: йөзләре көзге суык җилдә каралган, өстә — калын кием, аякларда — озын кунычлы җылы итекләр.

Тышкы ишек өстендәге звонок шалтырады. Ашыкмыйча гына беренче этаждагы кызыл почмакка үтә башладылар. Президиумга партия оешмасы секретаре, контора начальнигы һәм иң соңгы мода буенча тегелгән костюмына «Почет билгесе» ордены таккан бер егет күтәрелделәр. Әндәм аны тиз таныды: комсомол оешмасы секретаре, эстон егете иде ул. Русчаны ничектер матур яңгырашлы акцент белән сөйли. Түмәндә начальник белән бергә эшләгән.

Халыкны шыплап тулган соңгы рәтләрдән буш калган алгы эскәмияләргә күчәргә чакырдылар. Бер мәлгә шау-шу китте. «Монда утырмыйлармы?» — Риман белән Әндәм каршысында күксел йон костюм-

нан, шомырт кара чәчләре иңнәренә таралып төшкән бер кыз басып тора иде. Соңгы минутта каядыр югалган Рәис урыны иде бу. Җавапны Риман бирде: «Юк, юк, сезнең өчен ул. Рәхим итегез!»

Секретарьның доклады шактый тәэсирле чыкты. Контораның еллык планы бүгенге көнгә нибарысы туксан процентка үтәлгән. Акланырга теләгәндә объектив сәбәпләр дә бар, иң җитдие: яңа маркалы күп кенә вышкалар кайткан, шуларның кайбер агрегатлары бик нык соңга калып алынган. Яшьләрнең төп бурычы — декабрьның калган егерме көне эчендә, хезмәт батырлыгы күрсәтеп, шушы вышкаларны сафка бастыру.

Тәкъдимнәр кертү, чыгып сөйләүләр башланып, трибунада паузалар ясала башлагач, Риман Әндәм ягына үрелде.

— Баш инженер сине дә чакыртмагандыр бит?

Әндәм күзләреннән шар ясады.

— Юк әле.

— Җыелыш аркасында өлгермәгәндер генә, чакыртырга тиеш.

Кыз болар ягына борылып, бармагын иреннәренә тидерде: «Тс-сс!».

Риманның бу сүзләре Рәис белән картларның исен җибәрү өчен кулланыла торган «этлек»нең бер варианты булырга охшый. Икенче оратор күтәрелгән арада Әндәм дәвам итәргә булды.

— Ризалык бирдеңме соң?

— Синең белән киңәшмичә, кыюлык итмәдем.

— Дөрес эшләгәнсең. Нык ялынамы?

— О-о, кая ул, табигать гадел түгел, ник соң минем родной уллары булмадыгыз икән, ди.

Кыз болар ягына ярым борылды. Чәчләре кебек үк чем-кара озын керфекләре эченә чип-чиста, үтә күренмәле ике зәңгәр күл яшеренгән; вакыт-вакыт әйтерсең аларны төнбоек яфраклары күмеп китә, йомылгалап алалар. Кыз читләтеп кенә егетләрне күзәтә, колак салып тыңлый башлады. Уңайлы моментны ычкындырырга һич ярамый иде, сөйләүче тынуга, Риман кабат башлады.

— Мәскәү тагын хат җибәргән бит.

— Нишлисең, алай бик каты ялвара башласалар, ул станокны сатарга туры килер, ахры.

— Билгеле, чит дәүләткә бирмибез ич, үзебезнекенә. Ләкин кисәтергә кирәк булыр, газетчиклар сизмәсен. Тагын тынычлык китәр.

Кызның кызыксынуы соң дәрәҗәгә җитте.

— Гафу итегез, сез әллә берләшмәдәнме?

— Ник алай уйладыгыз?

— Минем дә абый инженер. Берләшмә аппаратында нииндидер яңа машина ясыйлар. Әллә бергә эшлисезме дип уйлаган идем.

— Юк, без башка җирдәрәк эшлибез.

Кыз тагын нидер сорамакчы булуга, Әндәм ишарә ясап өлгерде: «Тс-с!» Өстәл артына торып баскан начальник сөйли иде.

Җыелыш бетеп урамга чыккач, кызны көтеп алдылар.

— Кичләрен дуска караганда дошманнар күбрәк очрый, сезнең тарафтан рөхсәт булса, кара, явыз көчләрдән үзебез саклап кайтыр идек. — Әндәм җавап көтеп, төлке бүреген әкрен генә, кирәгеннән артык төзәткәләп торды.

— Юк, юк, минем өчен мәшәкатьләнмәгез. Рәхмәт!

— Җавап мәсьәләсендә ашыктырмыйбыз. Ныклап уйларга киңәш итәр идек.

— Миңа монда, автобус тукталышына гына чыгарга кирәк.

— Оо-о! Безгә болай да бер якка икән ич.

Өчәүләшеп киттеләр. Кызның тавышы саф, гаҗәп ягымлы иде. Озын, чигүле итәкле зәңгәр пальтосы гәүдәсенә ятып тора. Әндәмгә ул яз иркенә чыккан беренче зәңгәр күбәләк булып тоела башлады.

— Менә килеп тә җиттек.
— Юк, миңа каршыдагысына чыгарга кирәк шул.
— Алай да була! Безнең өчен ураугыч юл әйбәтрәк тә әле ул. — Риман сүзен аста калдырырга теләмәде.
Көтеп торучылар күренми, димәк, автобус күптән түгел генә киткән.
— Әгәр дөрес аңласам, сезнең бик тә хикмәтле станогыгыз бар? Тыңлап тору килешми дә инде...
— Борчылмагыз, без, киресенчә, гадилекне яратабыз. Шулай бит, Әндәм. Күрәсез, исеме дә гадәти кешеләрнеке. Минеке тагын да гадирәк — Риман. Ә сезнең? Әйттем ич, батыррак, батыррак булырга кирәк тормышта! Кыюлык сезгә килешә.
Такт сакларга кирәк мондый очракта. Бу буровой будкасы түгел. ә культуралы әңгәмә. Бер кешегә генә сөйләп тору килешми. Сиңа җитеп торыр, минем чират. Әндәм шуны аңлатып, иптәшенең үкчәсенә басты.
— Матур исем. Зөһрә, сез бик ашыгасыз кебек тоела.
— Сеңелләремә дәрес хәзерләшергә вәгъдә биргән идем. Соңга калсам, үпкәләрләр.
Дәрес! Институтта дәресләр башланды ич инде! Ул һаман монда йөри. Ничек онытты соң әле ул бу турыда? Ник шундук өенә чапмады? Бер мәлгә Әндәм туктап ук калды. Хәзер нишләргә? Аңа артык эссе булып тоела башлады. Кесәсендәге кульяулыгын алгач, иркенәеп китте, авызы ерылды. Баш! Бүген бит чәршәмбе, институтта ял көне! Нәрсә булды аның белән? Гадәттә, ул бик дулкынланса гына онытылып китә, үз өстеннән контролен югалта иде. Ә бүген? Җебеп калма, кызурак атла, сэр!
— Безнең шәһәрдә, гадәттә, вакытлары күп булган кешеләр генә автобуста йөриләр. Ашыгыч булса, җәяү китәләр.
— Ерак булмасмы соң?
— Кая инде, аңа гына түзәбез. Сезгә уңай гына булсын.
Йөз илле метрлар үтүгә аларны автобус узып китте...
Мәсьәлә тагын станокка кайтып калды. Күрәсең, ныграк арттырып җибәрелгән. Җавап көтәләр, дәвам итәргә кирәк.
— Станок дип, кечкенә генә машина инде ул. Әбинең газы беткәч, Риман белән икәү ясаган идек.
— Газ плитәсенә охшаганмыни?
— Юк ла. Суның кислородын аерып ала ул! Шул кислородны баллонга тутырасың да плитәгә ялгыйсың. — Беткән баш бетсен инде, дип уйлады Әндәм.
— Яхшы янамы соң?
— Кислород бит. Әйбәт яна.
Кызга нык тәэсир итте кебек. Хәтта ул сикергәләп алды.
— Бу бит ачыш, егетләр! Берәрсенә әйттегезме соң?
— Шул инде, баш инженер белә. Безгә дан кирәкми ич, Зөһрә. Әбинең плитәсенә ягарга булса, без канәгать.
— Ой, күз алдына китерә алмыйм. Шундый ачыш ясасам, сезнең кебек түзеп торалмас идем. Өйдә генә түгел, бөтен шәһәргә шаулар идем. Ә сез гаҗәп, юк, алай гына да түгел әле, искиткеч тыйнаклар!
— Арттырасыз, Зөһрә. Мондый сүзләргә күнегелмәгәч тыңлап торуы читен. Оялтмагыз инде шул кадәр...
— Юк, Әндәм, барыбер хәбәр итәргә кирәк. Беләсезме, илнең экономикасын арттыруда нинди роль уйнаячак бу! Ягулык өлкәсендә революция булачак! Ә сез аны файдалануга кертәсе урында тыныч кына йөри бирәсез. Җинаятькә тиң бу! Бухгалтериядә эшлим мин. Теләсәгез, күпме экономия булачагын хисаплап бирермен. Цифрларын иртәгә үк кертә аласың, килештекме?

Әндәм килеште, Риман юк. Күренеп тора, кызый Әндәм ягына авыша башлады. Шулай да булсын. Ярый торган хәл. Әмма бик тиз була ич бу. Кызыгы югала.

— Карале, дус кеше, әйтергә онытканмын, кичә бит сине теге сары чәчле Гөлчирә дигән кыз тагын көне буе эзләп йөрде. Тулай торакка килгән. Табыгыз ди. Әндәмне күрмичә өйгә кайтмыйм, ди. Кыяфәте бик шикле күренгәч, куркып киттем. Син аны алдап йөртмә инде...

Әндәмнең күз аллары караңгыланып китте. Менә бу — удар! Классический! Көтмәгән иде. Эсселәнеп калды, яка төймәләрен ычкындырды. Вакыт бит бара, берничә минуттан соң соң булачак! Язгы суга төшсәң дә болай кызышмассың. Җавап кирәк, җавап!

— Кичә институтта булган идем шул. Безгә кардәш тиешле кыз. Станокның схемасы белән кызыксына. Ни сәбәптер, гел мин өйдә булмаган вакытка туры килә дә, синең янга чаба. Яхшы сәбәп булдым инде сезнең өчен.

«Узды, ахры. Ышанычлы чыкты сыман. Сулышлар ачылып китте».

— Институтта да буласызмыни?

— Эшләр күп әле бу арада. Туры килә.

— Укый идем мин анда. Шуңа кызыксындым.

— Кит әле! Ничәнче курста? — Әндәм гаҗәпләнүдән шаклар катты.

— Беренчедә генә әле. Экономика факультетында.

— Мин дә...— шулай да вакытында тыелып кала алды.

— Аңламадым.

— Мин еш булырмын әле институтта. Очрашырбыз!

— Онытмасагыз. Ой, кайтып та җиттек. Безнең йорт. Рәхмәт сезгә. Юл сизелми дә үтте.

— Иртәгә дәвам итә алабыз. Сәгатен генә билгелик тә.

— Юк, сезнең болай да тыгыз вакытны аласым килми. Безнең урам якты ич, курыкмыйм. Тагын бер кат рәхмәт. Сау булыгыз! — Ишектән кереп китәр алдыннан кул болгады.

— Иртәгә институтта очрашырбыз, Зөһрә! — Әндәм тавышыннан ишегалды мәйданчыгы яңгырап куйды.

Кыз ризалык белдереп, баш селкеде.

Егетләр эшлекле кыяфәт белән кире борылдылар.

— Карале, кыйммәтле кош күренсә дә, иңсәгә кунарга охшый. Миңа исәнлек теләп дога укы. Кадеремне белмәссең дә әле.

— Кунар, янда син булганда. Ярый әле, очып китмәде. Вакыт шактый соңарган, безгә генә кайтыйк. Әби өчпочмаклар пешергән булырга тиеш.

— Көне буе йөреп, синнән дә бер юньле сүз чыгар икән!

Төн күгелҗем элпә белән өртелгән. Салмак кына булып, тәңкә кар төшкәли. Биек йортләр, көзге суыкларда ябыгып, җыйнакланып калган агачлар фонында алар туктап калган кебек тоелалар. Әйтерсең каршыда чын урам түгел, ә аның сурәте төшерелгән полотно тора. Ике егет шул рәсемнең эченә кереп баралар. Берсе кинәт туктады да иптәшенең ерагаючы терсәгенә үрелде.

— Станок хакында нишлибез? Иртәгә миңа аңлатырга кирәк ич.

Бераз баргач, туктап калдылар.

— Почмактагы йортка кара. Өченче катта, сулдан алтынчы тәрәзәне күрәсеңме?

— Синең тәрәзәме?

— Юк, бер чуваш кызыныкы. Эльвира исемле.

## Ун процент

Прожекторларны кабызган вышка, кичке караңгыда көмеш каланчага әверелеп, тирә-юньгә нур, яктылык бөрки. Ояларындагы кырмыскалар кебек, көне буе хәрәкәтләнеп, әрле-бирле чабып такта, торба ташып, аларны кирәк урыннарына беркетеп хәлдән тайган бригада членнары эшләрен төгәлләп, инструментларын җыештырырга гына тотынганнар иде, буровой күперчеге каршысына өр-яңа газик килеп туктады. Мишинадан контораның баш инженеры белән прораб чыктылар.

Килүчеләр һәр эшче белән дә кул биреп күрешеп чыккач, Хәмитов барысын да вагонга дәште. Зур гәүдәле, пеләше беленә башлаган инженер түргә узгач, өстәл тирәли утырыштылар. «Яшел курткасы белән бигрәк шөкәтсез күренә иде, тун кигәч, кыяфәт кергән үзенә»,— дип уйлады Әндәм прораб хакында.

— Я, Даут Сөнгатович, хәлләр ничек, егетләрнең кәефе, сәламәтлекләре? Тормыштан зарланмыйлармы?

— Рәхмәт. Бу арада бераз тырышып алдык. Хәзер яңа елны көтәсе генә калды.

— Яхшы, яхшы. Тик яңа елны бик ашыктырмагыз әле, иптәшләр. Без әзер түгел бит. — Инженерның йөзе җитдиләнеп калды. — Бу буровойны иртәгә тапшырырга кирәк.

— Ачуланмасагыз, иптәш баш инженер, без аны бүген җыеп бетергән идек инде.

— Нуу! — Инженерның киң, итләч йөзен юмарт елмаю басып алды.— Менә бит, сезнең бригада хакында башта ук яхшы фикердә булдым. Әле начальник белән дә бәхәсләшкән идем. Рәхмәт, егетләр, ышанычны акладыгыз!

Аннары ул, блокнотын озак итеп актара-актара, янәшәсендәге прорабка ниндидер цифралар яздырды. Торып басты. Сирәгәйгән чәчләрен рәтләп куйды.

— Коллективыгыз үсә, ныгый. Игътибар белән күзәтәбез. Сезнең өчен шатбыз, иптәшләр! Әмма безнең контора алдында бүген бик зур, җитди сынау тора. Утыз беренче декабрьга кадәр менә бу яңа мәйданга бораулаучыларның тагын унтугыз бригадасы күчәргә тиеш. Димәк, бәйрәмгә кадәр безгә унтугыз буровой өлгертергә кирәк.

— Фюить! Менә бу корректный номер. Ә вакыт? Вакыт бетте ич. Җәмгысы тугыз көн калды. Шуның икесе ял.

— Хикмәт менә шунда шул. Вакыт бетте. Нефтьчеләрнең планын өзә алмыйбыз. Борыннан кан килсә дә, эшләргә кирәк. Шушындый авыр минутта беренче булып киңәшкә сезгә килдек. Администрациянең соравын кире какмассыз дип өметләнәбез.

— Эшләргә икән — эшләргә! Монда сүз куертмыйча да аңлашыла.— Әсхәт эшлекле карашы белән иптәшләренә борылды.— Тырышырбыз! Инженер иркенәеп киткәндәй булды. Болай да кызара төшкән киң маңгаен, бармаклары белән уа-уа, кабат сүз башлады.

— Иптәшләр, әле мин әйтеп бетермәгән идем. Читен булса да, дөреслекне ачарга кирәк. Мин санаган буровойларның унбере яңа маркалы, күптән түгел генә кайткан. Без, озак киңәшкәннән соң, шуларның берсен сезнең бригадага йөкләргә булдык.

Тынлык урнашты. Менә кайда икән чикләвекнең төше! Атна эчендә өр-яңа буровой тапшырырга. Бер тапкыр җыеп караганнар иде ич аны. Айдан артык азапландылар.

— Кирәк-ярак белән тәэмин итүне үз өстемә алам. Кайнар ашны тәүлеккә ике мәртәбә оештырырга булыр. Түләүдән тормыйбыз. Ял көннәренә артык язылачак. Иптәшләр, мине дөрес аңлагыз. Авыр булачак, әмма эшләргә кирәк. Даут Сөнгатовичны яхшы беләм, заманында

бергә дә эшләдек. Аның белән вышка җыю гына түгел, тау күчерергә була.

Җавап көтеп, бригадирга текәлделәр.

— Башкарып чыга алырбызмы икән, яшьләрнең бер дә тәҗрибәсе юк ич. Әллә үзләреннән сорыйбызмы? Ни уйлыйлар икән?

Рәис белән Риман, ике яклап, Әндәмне төрткәләделәр. Тегесе торып басты, Әсхәт сүзен җөпләде:

— Тырышырбыз.

Инженерның йөзе тагын аркылыга җәелде. Хәтта аның колаклары да көлә сыман иде. Учларын угалады.

— Рәхмәт, туганнар! — Күренеп тора, миссиясеннән ул нык канәгать иде.

Машина күрше буровойга таба китте, монтажчылар әйберләрен җыештырып, асфальт юлга таба юнәлде.

— Эх, бер килмәсә килми бит ул. Планны әйтәм. Ник инде шунда ун гына түгел, ә егерме процентка үтәлми икән! Әйтик, шушындый вариант: контора буенча бүгенге көнгә үтәлеш нибарысы сиксән процент... Калган бер атна эчендә безгә егерме процент бирергә кирәк. Менә бу безнең өчен бәйрәм булыр иде!

Зәңгәр кар яктысында аермачык күренеп тора: гаҗәпләнүдән барысы да туктап калган, шаккатып Риманның авызына карап торалар. Ә тегесе берни булмагандай дәвам итә:

— Егерме процент җитмәсә, баш инженер безнең алда хәзерге кебек акча түгел, я медаль, яисә орден тотып йөрер иде. Ун процент кына ерунда.

— Тәүбә диген. Әле реально итеп эшләп караганың юк. Җилегеңне суырыр әле ул ун процент. Көннәр тыныч торсын, буран чыкмасын, шуны теләгез, балалар.— Галәү ага егетләрне чын күңелдән жәлли иде...

Бәхетләре бар икән, яңа урын авыл башында, бик тә уңайлы, чокырсу җирдә булып чыкты. Көн тыныч, бу тирәгә җил бөтенләй үтми, ахры. Комарланып эшкә тотындылар.

Егетләр, өйрәнелгәнчә, парлашып башламакчылар иде. Алдагы вышкаларны корганда тыныч кына йөргән бригадир, бу юлы дилбегәне үз кулына алды. Сизми дә калдылар: бөтен буе белән сузылып яткан буровой каланчасы, аерым бүлемнәргә бүленеп, һәркемгә беркетелгән булып чыкты. Иң төптә, буровой мәйданчыгы булачак урында, Әсхәт кайнаша, икенче очында — Рәис.

Будканы сөйрәп, кранлы трактор да килеп җитте. Әле төш җитмәгән, көч блогына бергәләп электр моторлары күтәртә башладылар. Ул арада авыл ягыннан тракторлар гөрелтесе ишетелде. Алты машина, кара төтеннәрен чыгарып үкерә-үкерә, кырык тонналы трансформаторны сөйрәп киләләр. Менә темп бу! Әндәм шуңа сокланудан чүкеч белән ялгыш сул кулының баш бармагына эләктерде. Аның янында эшләгән Риман, йөзен чытып, сүгенеп куйды.

Кичкә каршырак кизәнеп суга-суга хәлдән тайган Әндәм кулыннан кувалдасын төшереп җибәрә язды. Сулыш алуы чамадан тыш ешайган, калак сөякләре утлы тимер баскандай кызышып тора. Тураеп басты да, кулын каш өстенә куеп, кырык икеле ачкыч белән торбаларның гайкасын беркетә-беркетә мышнап беткән Риманны күзәтә башлады. Тырыша егет. Курткасының аркасы юеш, пар күтәрелә. Саллырак реплика ыргытырга дип авызын ачкан иде, каршысында бригадир пәйда булды.

— Вакытың чыкты, студент. Хәзер синең якка кран күчә. Мотор оясы әзерме?

Әндәм кечкенә чүкечена үрелде. Я хода, аның бит әле тагын ярты сәгатьлек эше бар! Кызулык белән сизелмәгән икән, сугылган бармагы үтереп әрни башлады. Электриклар линияләрен ялгап та өлгерткәннәр.

Прожекторларын кабыздылар. Әсхәт кай арада маскасын кигән дә кай арада электродларын тапкан, моторның рамыннан лом белән каерган Рәис өстенә, чатыр-чотыр китереп, зәңгәр очкыннар сибә.

Вахта йөртүче шофер бригаданы, автобуска утырмасагыз, ташлап китәм дип башта куркытып карады. Аннары ялына башлады. Оялтырга теләде. Хәмитовның кашы җыерыла башлаганын күргәч, буровойны, контораны, язмышын кычкырып каһәрли-каһәрли, кабинасына кереп китте. Иске пальтосына бөркәнеп, йокларга ятты...

Әндәм өйгә соң, унынчы киткәч кенә кайтты. Авырлык белән чишенде. Юынмаска да уйлаган иде, әбисе бик кыстагач кына биреште. Аннан-моннан капкалап, сопроматтан конспектларын алды да яткан килеш кенә укырга булды. Институтка барыбер өлгерәмде. Программадан калышмас өчен, шушылай булса да шөгыльләнергә туры килер...

Ничек яткан булса, иртән шулай уянды: уң кулында китап, дәфтәре идәнгә төшкән.

Хәмитов икенче көнне нәрсәдәндер канәгать булмады, унда гына кайттылар. Өченче көнне — унбердә.

Ашыгалар, туктаусыз чабалар. Бер генә минутка тукталып тор, шундук Хәмитов пәйда була.

— Студент, блок күчәрен беркетә башларга кирәк. Яшьләр кызу була ул. Темп, егетләр!

Әндәм җан-фәрманга эшкә тотына.

— Рәис, верховой мәйданчыгын кичә үк җыя башладың түгелме соң?

— Кичә үк.

Рәис сорауның мәгънәсен аңлап җитмәде, аның өчен Галәү ага җавап кайтарды.

— Эшли ул, бик әйбәт эшли. Хәзер, бер-ике сәгатьтән бетерә.

— Риман, бусы булган. Баскычларга тотын.

Риман кия башлаган тунын салып ташлый. Бигрәк тә кичке якта нык сиздерә: егетләр талчыкты. Бирешүчеләр алардан башка да бар икән. Әндәм очраклы рәвештә шаһит булды. Агарынып калган Галәү ага билен ике куллап тоткан да вагон стенасына сөялгән. Әндәмне күргәч, берни булмагандай, каршы килә башлады. Мәктәптә укыганда, капиталистик илләрдә кулланыла торган конвейер хакында сүз булган иде. Егет ачык хәтерли. Тарих дәресендә шушы темага үзе чыгыш ясады. Прессинг, конвейер системасы эшчеләр өчен коточкыч методлар. Үз җилкәсендә татыгач, бу хакта бүген башкача сөйләр иде ул. Тик, кызганычка каршы, сорамыйлар, ә эшләттерәләр. Тормыш мәктәптән шулай аерыла икән! Прессингны капиталист кына түгел, бригадир Хәмитов та бик оста куллана белә булып чыкты. Әнә ни ялкау Рәис тулай торакка кайтып йөрүдән баш тарта. Каравылчы белән будкада кунып калырга рөхсәт сорый. Сүз юк, егет тырыша, берәүдән дә калышмый. Бергә-бергә күңеллерәк, җиңелрәк булыр. Риза булса, Әндәм аны өйләренә чакырып карарга булды. Прожектор яктысында эшчеләрнең гәүдәләре әзмәвердәй зур булып күренәләр. Бу минутта алар Әндәмгә сөйкемле, якын тоелдылар.

Әсхәт. Иңсәләре тагын да киңәеп киткән кебек. Тунының гына түгел, күлмәк якалары да ычкындырылган. Башын кыңгыр салган да, күзләрен кыскалап карый-карый, электрод сайлый. Бригаданың терәге. Шундый кешеләр була. Янәшәңдә йөри, бергә эшлисең, киңәш итәсең, бара-бара күнегелеп беткән. Әйтерсең ул мәңге шулай булырга тиеш. Көтмәгәндә, бер көнне ул килми кала. Аның да үзең кебек үк гади, җир кешесе булуы искә төшә, нәрсәдер җитмәгәндәй тоела, эш бармый, күңел юксына. Ашка тоз ничек кирәк булса, коллектив өчен шундый кешеләрнең булуы мәҗбүри, зарури. Шуларның берсе — Әсхәт...

Галәү ага. Гомер буе кырда, җилдә йөреп йөзләре купшакланып беткән. Сабыр, салмак холыклы. Эштә дә кабаланмаска ярата. Аның

белән эшләргә рәхәт. Көн сизелми дә үтә. Күпме деталь, механизм, вышка җыелган аның шушы каты, сөякчел куллары белән! Әгәр аларны бергә җыйсаң, урман хасил булыр иде. Күпме нефть биргәннәрдер алар илгә. Әгәр төптәнрәк уйласаң, бүгенге көн, дөнья шушындый кешеләр кулында ич. Министрлар түгел, алар хәл итә дөньяның язмышын. Гомер дәверендә тормышның нинди генә мәсьәләләрен чишмәдең, нинди генә язмышлы кешеләргә булышмадың, кемнәр генә синнән үрнәк алмады, охшарга тырышмады. Белемле, күзлекле кешеләргә кызыгып карыйсың. Я әйт, үзең соң кайсы академиктан ким, Галәү ага?!

Әндәм карашы белән бригадирны эзләде. Тегесе караңгыдан үзе килеп чыкты.

— Я, студент, хәлләр ничек? Бетердеңме? Ярый, Риман янына күч. Тормозны бүген очлап чыгарга кирәк.

Хәмитов ничек килгән булса, шулай юкка да чыкты. Буровой мәйданын капларга такталар килеп җитмәгән, көне килеп терәлгәч кенә соң булачак, шуларны ашыктырып, сорап язарга, документларын караштырырга утырды.

Вагон эче шыксыз, җылынырга керүче булмагач, мич кабызылмаган, суык иде. Бригадир зиһенен тиешле юнәлештә җигә алмый интекте. Күңеленә төрле уйлар килделәр.

«Хәзергә яхшы бара кебек. Башкорт радиосы әйтмешли, «яшь эшмәкәрләр» генә бирешмәсен. Баштагы чорда малайлардан рәт чыкмас шикелле күренгән иде, сизми дә калдым, тегеләр тәртәгә үзләре керделәр. Әллә Әсхәт, әллә Галәү ага тырышты шунда. Буровоен, планын, бөтен дөньясын онытып, туйганчы бер йокларга иде. Вышканың системасында үзгәрешләр шактый күп, шуларны карап, кичә дә икегә кадәр утырылган. Тәүлеккә өчәр сәгать йоклана. Сугыш вакытымыни. Планны ничек куабыз! Ә бит шуны тыныч кына, ватылмыйча гына да срогына өлгертергә мөмкин иде. Төннәр йокламыйча, атнасына, көненә хәтле туры китереп, план, график корабыз. Аннары ул бозыла, чәлпәрәмә килә. Нервылана, кычкырыша башлыйбыз. Аннары тагын йокысыз төннәр. Өч айлык эш калган икән ләбаса! Кайчан без нормаль шартларда нормаль итеп эшләргә өйрәнәбез. Үзебез гаепле ич. Күпме инженер, экономист утыра, чалбар төбе туздыралар. Моторлар хакында сентябрьдә кайгырта башласалар да, бу хәл булмый иде. Юк, декабрьга калдырырга кирәк. Әйтсәң, чыгып сөйләсәң, син начар. Болай ярамый. Кешеләрне кызганырга кирәк. Тагын сөйлим. Бригадирдан ары түбәнәйтә алмыйлар. Югарыга теләмим. Коллектив ярыйсы җыелды сыман, бер эшләп күрсәтергә кирәк. Әнә бит баш инженер нәрсә вәгъдә итә. Буровойны утыз беренче декабрьга кадәр тапшырсаң, элекке эшенә — прораблыкка кайтаруны үз өстемә алам,ди. Әйтерсең мин шахмат тактасындагы пешка. Начальник бирегә, инженер кирегә йөри. Юк инде, уйныйсыгыз килсә, башка кеше эзләгез. Курыкмагыз, буровойны күктән таш яуса да тапшырырбыз. Вәгъдә биргәнбез икән, ул намус, горурлык эше. Акчага, дәрәҗәгә түгел, эшче горурлыгына басым ясаса, инженер күбрәк отар иде. Теге вакытта ул ничек сөенгән иде, полный бәйрәм ясаган иде. Ә сәбәбе соң, нидә?! Прораб Хәмитов вышкасын сазга утырткан! Шул көннән үк элде приказны — «Моннан соң җыелышларда миңа каршы сөйләмәссен». Хезмәтне фәнни итеп оештыр, тәртип яса, аннары сөйләмәбез Әгәр шушы метод белән тагын ярты ай гына эшлик, ант итәм, контораның яртысы качып бетәчәк»...

Шимбә көн кичкә каршы инженерның машинасы кабат күренде. Бу юлы аңа кассир апа да ияргән иде.

— О-о, иптәшләр, алга китеш сизелә. Сәламәтлекләрегез? — Тагын барысы белән дә кул биреп күрешеп чыкты. — Булган ич, молодцы! Вышканы күтәртергә кирәк.

— Чаналары бик иплә утырмаган шикелле. Иртәгә ярты көн шуна

китмәгәе. — Бригадирның күзләре эчкә батып, борыны очлаеп калгандай тоелды.

— Бара бу. Иптәшләр, һәр минут алтын бәрабәренә тиң. Үтенеп сорыйм, юкка-барга вакытыгызны сарыф итмәгез. — Күзләрен серле итеп уйнатып алды да кассирга кул изәде. Калын иреннәре юкарып, колакларына хәтле җәелде. — Түләүдән тормабыз, дип вәгъдә иткән идем бит. Ял көннәре өчен шундук расчет ясарга булдык. Кеше башына егермешәр сум!

Егетләр кассир каршысына ябырылып төшмәделәр. Киресенчә, ул үзе алар артыннан йөрде.

Хәмитовның сүзе хак чыкты. Күтәртә башлагач, вышка бер якка янтая башлады. Чананың сул табаны җиргә батып кергән иде. Кире төшереп, төшкә хәтле шуны көйләделәр. Аларга тракторчылар да булышты.

Кырык метрлы вышка бөтен буена торып басты. «Мин — буровой. Суык, тәнем калтырый. Ник йокымнан вакытсыз уяттыгыз? Гәүдәм чүкеч, төрле ачкычлар боргалавыннан сызлый, сварка уты бәгыремә үтте. Кешеләр, миңа авыр, йокы килә, арыдым, зинһар, тынычта калдырыгыз», — дия кебек иде ул.

Утыз беренә кадәр башланмаган ике көн бар. Хәмитовның шешенгән күз кабаклары үзләреннән-үзләре йомылалар. Башы тәмам миңгерәгән. Күңелендә гел бер хәвефле уй: «Өлгермибез!»

Галәү аганың йөзе, чиста кәгазь бите кебек, ап-ак. Күптән билен кузгатканы юк иде. Бүген биреште. Рәис белән такта бушаттылар. Җайсыз күтәрде, ахры, сизми калды. Ничек тә иелмәскә кирәк. Балалар сизмәсен. Илле тугыз яшьлек Галәү ага шулай уйлый.

Баскыч ясаганда Риман арттырыбрак җибәрде. Курткасын ыргытып, свитердан гына эшләгән иде. Ютәл төште, тәне кызыша башлады. Гомер булмаган хәл: тез буыннары йомшарды. Риман боларга игътибар итмәскә тырыша. Рәис булып Рәис ажгыртып торба ташыганда, ул ярты үлеп ятканда да туктап тормас.

Буровой тирәсе сугыш кырына охшап калган.

Трр-рр-урр! — кечкенә чанага беркетелгән трансформатор дөнья ярып үкерә.

Стр-р-р-р! — Әсхәтнең сваркасы тирә-якка зәңгәр ут чәчә дә берничә секундка тынып кала. Янган металл исе борыннарны ярып керә.

Вз-з-з-з! — электрчылар моторларны сынап карыйлар.

Шаң! Шаң! Шаң-ң--ң-ң! — Әндәм стенага такта кага...

Тагын бер көн үтеп, кайтырга дип автобуска төялгәч, Хәмитов барысын да кисәтеп чыкты:

— Утыз бере, җәмәгать, бораулаучылар килә. Күрәсез, безнең әле дөнья эш калды. Шуңа күрә иртәгә куна калырга туры килер. Хәзерләнеп килегез...

Иртән бригада килеп төшкәндә, баш инженерның машинасы будка каршында тора иде. Үзе руль артында бераз йоклап алган, ахры. Күзләре, балан кебек, кып-кызыл. Болай да итләч бите, йөзе килгән күмәч кебек, күпереп чыккан, берничә көн кырынмаганлыгы әллә каян сизелеп тора.

— О-о, иптәш Хәмитов гвардиясе! Сәламәтлекләрегез? — Гадәттәгечә кул биреп, исәнләшеп чыкты. — Я, туганнар, бетерәбезме бүген?

Хәмитов алай бик сикереп төшмәде.

— Тырышып карарбыз. Әмма вак-төяк эшләре бик күп кала. Аптырадык инде.

Инженер күзгә күренеп алышынды. Җитдиләнде. Авыр сулап куйды.

— Сезнең нормаль. Барысы да шулай эшләсен иде! Куна каласызмы? Хуплыйм. Ашау мәсьәләсен оештырырбыз. Иң мөһиме, иптәшләр, бораулаучылар иртәгә эшкә башласын. Җитешеп бетмәгән урыннарын

күрсәтерләр, бергәләп эшләрсез. Мин әле тагы бер әйләнермен. Пока, Уңышлар телим!..

Бригада, соңгы көчен җыеп, хәлиткеч эш көнен башлады.

Куе томанны утлары белән кискәләп, үкерә-үкерә якынлашучы, торба һәм башка кирәк-яраклар төягән «Урал»лар күренде.

Бораулаучылар да ашыга икән. Ерактан шаулап, колачларын җәйгән килеш, буровой күперчегенә тезелеп басып торучы, йокысызлыктан шешенеп беткән монтажникларга каршы киттеләр. Күрешү, бер-берсенең иңсәләренә сугып, хәл-әхвал сорашу башланды.

— Кардәш-ыру, бәйрәм белән!

Әйтерсең, дошман боҗрасын өзеп, сугыш мәйданында ике отряд очрашты...

Бригадир егетләрне төшке ашка гына уятты. Кар белән юынырга чыккан җиреннән, Рәис тыны-көне бетеп, будкага кире чабып керде.

— Галәү ага, Әндәм, Риман, тизрәк чыгыгыз. Анда буровой эшли!

Аста, күперчектә, бораулаучы белән аның ярдәмчесе кайнаша. Верховой каланчасыннан кул изи, лебедка, моторлар гүли. Шуларга кушылып, сабый бала кебек, Рәис бии.

— Галәү ага, эшли бит, буровой эшли!

Каршыдагы кар белән Әндәмгә тондырган иде, Риманга тидерде.

— Ах, мишәр токымы!

Киттеләр куышып. Кулларын өскә сузып, киерелеп торучы Әсхәтне бәреп ектылар. Рәисне өскә чыгармакчы булып, кысылган иде, Әндәм үзе аста калды. Кабыргалары шытырдап куйды.

— Малайлар!

Җитте. Бригадир кайчан нокта куярга икәнлеген яхшырак белә.

Өсләрен кага-кага керсәләр, инженер утыра.

— Туганнар! Молодцы! Чын күңелдән рәхмәт. Булдырдыгыз. — Җәелгән йөзе җыелып, түгәрәкләнеп калды. — Иптәшләр, соңгы үтенечем: күрше бригада «яна», зинһар, кичкә кадәр булышыйк.

Тизрәк капкаладылар да автобуска утырдылар. Ара якын иде, тиз килеп җиттеләр. Хәмитов мондагы бригадир белән киңәшкәч, күперчеккә менеп басты, кулын алга сузды:

— Егетләр!..

Ул бригаданың да «янгынын» сүндерешеп, автовокзалга кайтып житәрәк, бригадир автобусны туктатты. Сабыр гына чемоданын ачты да муеныннан тартып ике шешә шампанское чыгарды.

— Иптәшләр, бәйрәм белән!

Алюминий кружкасын, беренче булып, Әсхәт күтәрде.

— Яшьләр хөрмәтенә! Яңа елда да бергә эшләргә язсын!

Озак бәхәсләштеләр. Дөресрәге, Рәис кайтып китәргә теләде, тегеләр калырга өндәде. Ахырда Әндәм тәкъдиме җиңеп чыкты. Институтта бәйрәм кичәсе оештырыла иде, шунда очрашырга булдылар.

Танцалар бетеп, Зөһрә белән Эльвира үзләренең өстәлләре янына килгәч, исләре китте. Егетләр утырган килеш рәхәтләнеп йоклыйлар иде. Беренче булып Риман уянды.

— Ой, гафу, кызлар. Паллиатив була язганбыз ич! Подъем!

## Булат Сөләйманов

### Себердән хатлар

*Туган якка кайтмасам*

Туган яктан иркен җир юк,
Чит җирләрдән йөреп кайттым.
Төн диңгезе төпләрендә
Үткәннәрдән учак яктым.

Яңа алар аждаһадай
Гомеремне йотар булып.
Йөрәккә кан сауган чаклар
Хәтеремне ала буып.

Куанамын, күңелем тула
Урманнарга кергән саен —
Нәселемнән үсеп чыккан
Чыршы, нарат, усак, каен.

Таптаса да бу җирләрне
Заман дигән усал атлар.
Аклыкларын, сафлыкларын
Югалтмаган туган яклар.

Үткәннәргә кире кайтам,
Гомеремнең тамыры шунда.
Яр буенда бөдрә таллар
Кер чайкыйлар агым суда.

Кер чайкыйлар агым суда
Әкрен генә көйләр көйләп.
Җиргә, күккә, йолдызларга
Сагынуымны бирдем сөйләп.

Туган якка гел кайтмасам —
Туган якка кайту кирәк!
Ягулыгы беткән мотор
Кебек сүнәр иде йөрәк.

## Самотлор

Йөзек кашы бит син Себернең!
Үзәгендә туган көмеш ай.
Астын өскә җирнең айка хет,
Сиңа тиңдәш күлләр юк бугай.

Бозлыклардан хасил булдыңмы?
Каян иңгән сиңа күк төсе.
Әкияттә түгел, чынбарлыкта
Себернең син сихри көзгесе.

Серле сандык серсез ачылсын!
Бар дөньяны әйдә сокландыр!
Киләчәккә синең күз белән
Туган илем карый, Самотлор.

## Буровойда

*Р. И. Кузоваткинга*

Вахтада һәркемнең посты бар.
Солдат күк сак, уяу бул, малай!
Тырнагын кыяга батырган
Каракош шикелле буровой.

Ничә йөз елларның күз яше
Бу җиргә боз булып тамган соң?
Шуңа ул мәңгегә каргалган —
Мәңге туң! Мәңге туң! Мәңге туң!

Без данын яңартыйк Себернең!
Һәм нигез ташы күк мәңгегә
Өметне, бәхетне, шатлыкны
Бораулап салыйк без бу җиргә.

Хет җире ярылсын салкыннан,
Хет сынсын үкереп тимерләр,
Салкынны эченә йотар да
Эретеп төкерер чын ирләр.

Җил кисә карашны, күзләрдән
Тамчылап-тамчылап нефть тама.
Буровой тизлеге йөрәктә,
Тамырлар буйлап та нефть ага.

Без данын яңартыйк Себернең!
Кояшка өстәрбез нурга нур.
Һәр вышка — ракета, күккә юл,
Һәм һәрбер буровой — Байконур.

## Түбән Варта

Парадмыни — тезелешеп
Йортлар кунган ап-ак карга.
Изүләрең җилгә ачып
Ашыгасың кайсы ярга,
Түбән Варта?

Яшь бөркетләр кыясы син,
Прописка юк «куяннарга».
Саз эченнән агып чыгып
Обька койган урамнарда
Ап-ак күбек.

Кар илендә уттай салкын,
Килә борын заманнардан
Кигән кием-толыбың да,
Ап-ак йонлы бураннардан,
Түбән Варта.

Әйтерсең Обь — водопровод,
Боз астыннан сулар ага.
Факелларда — таңдай ялкын,
Гомер җуйган тынлык яна.
Күктә яра.

Уяна да сүнә кояш,
Сүнми көрәш Самотлорда.
Буровойлар тишәр чорны
Иман барда, илһам барда,
Түбән Варта.

Девоннарга манып каләм,
Бар бит эшләр башкарасы.
Үз тарихың язасың син,
Кар иленең башкаласы,
Түбән Варта.

## Быел нинди яздыр...

Быел нинди яздыр!
Никтер үзгә сыман.
Гөрләвекләр ага
Күңелем дөньясыннан.

Куркак куян кебек
Соры төскә кереп,—
Җирдән китү авыр...
Карлар ята эреп.

Әле күптәнме соң?
Көрттән бура бурап
Йөри иде җилләр
Бөтен Себер буйлап.

Быел нинди яздыр!
Бигрәк сагындырган.
Уйлар чыга юлга
Дәрвиш сукмагыннан.

Иркәм каршы килер
Җирдә айдай тулып,
Ак төннәргә сердәш
Ак каеннар булып.

Күңелем кошы булып
Затоннардан чыгар
Ак болытлар кебек
Ап-ак пароходлар.

Быел нинди яздыр!
Никтер үзгә сыман.
Гөрләвекләр ага
Күңелем дөньясыннан.

1976, Төмән.

## Ренат Хәйри

### Юллар

Кара җиргә ялан аяк басып,
Тәүге тапкыр атлап киткәндә,
Белмәгәнмен — киләсемне сизеп
Күпме юллар мине көткәннәр!

Белмәгәнмен нинди юллар минем
Бала чакны алып китәсен.
Белмәгәнмен кайсын кылыч тотып,
Кайсын чәчәк кочып үтәсем.

Белмәгәнмен шул юлларның кайсы
Сөйгәнемә алып барасын.
Белмәгәнмен кайсы юлда сагыш,
Кайсы юлда бәхет табасым.

Белмәгәнмен... Хәер, бала чакта
Ни көткәнен алда кем белгән?!.
... Тик үтәргә язсын озын юлны
Халкым белән бергә, ил белән.

### Әллә нигә шулай...

Без тормышны, ахры, аз аңлыйбыз:
Бәхет булса — читтән эзлибез.
Ә ул исә туган туфрагыңда...
Без кайчакта аны күрмибез.

«Ерактагы кояш җылы була,
Эсселеге ничек, күр», — дибез.
Ә яныңда ташны эретерлек
Йөрәк торганлыгын күрмибез.

Хәйран калып ярсу диңгезләргә:
«Нинди иркен, нинди киң!» — дибез.
Ә яныңда бөтен дөнья сыйган
Күңел торганлыгын күрмибез.

«Ләйлә-Мәҗнүн» ничек яратканнар!
Юк аларга хезер тин дибез!

Ә яныңда сине өзелеп сөйгән
Ләйләң торганлыгын күрмибез.

Күп вакытта әллә нигә шулай
Күңел күзе белән күрмибез.
Бөтен нәрсә тик катлаулы булсын
Гадилеккә бәһа бирмибез.
Күрмибез...

●

Бу дөньяда шатлык кына түгел,
Кайгылар да кайчак кадерле.
Авырлыклар мине читләп үтсә,
Белмәс идем, Тормыш, ямеңне.
Ташламагыз мине, Бәхет, Шатлык,
Чит итмәгез, Сагыш, Кайгылар!
...Ярларында агачлары бетсә,
Елгалар да хәтта саега.

## Сусының арта бара

Як-ягымда ком чүледәй
«Сагыну» дигән дала.
Мин шуннан төшемдә күргән
Чишмәне эзләп барам.

Табаннарым кара көйде,
Иреннәр уттай яна.
Бер йотым су! Тик бер йотым!
Ул чишмәң кайда, дала?

Дала битараф, эндәшми,
Юл да күрсәтми дала.
Тик йөрәк һаман ышана
Кайдадыр чишмә барга.

Эзләнүләр нәтиҗәле:
Мин таптым аны, таптым.
Авыр юлдан хәлсезләнеп
Ярына килеп яттым.

Тик тылсымлы икән чишмә:
Исерткеч салкын суы...
Эчкән саен арта бара,
Һич киметми сусынны.

Ә тирә-якта чүл кебек
Кап-кара көйгән дала.
Сусынны басмый чишмәдән
Аерылып китеп кара!

Ә чишмәдән эчкән саен
Сусының арта бара...

## Тупыллар мамык очыра

Мамык очыра тупыллар...
Җәйге җил кочагында,
Бернидә гаме юк сыман,
Ак мамык оча гына.

Кайларга оча мамыклар?
Ерак булырмы ара? —
Кул болгап кала тупыллар,
Фатиха биреп кала.

Алар бүтән күрешәлмәс.
Еракка оча мамык.
Бер генә җәйлек яфраклар
Озаталар кул чабып.

Тупылның бераз моңсурак,
Бераз мөлаем чагы.
Шул мамыкларда бит аның
Өмете, киләчәге.

## Монолог

— Кичер син, дөньяда
«Юксың» дип йөргәнгә,
Башкалар «Бар!» дисә,
Мин, юләр, көлгәнгә.

Түзгәнсең, шулай да
Чиге бар түземнең:
Төреп ай нурына
Күрсәттең үзеңне.

— Юк, имеш... Акылсыз,
Күрдеңме, мин исән!
Мин җирдә, кояшта,
Җил булып мин исәм.

Теләсәм су булам,
Кирәксә ут булам.
Тик саксыз кагылсаң,
Шунда ук «юк» булам.

Югалдың, утларга
Салдың да янарга —
Чакырам, тик беләм
Килмәссең яңадан.

Синсез бит гөлләр дә
Сөюдән исерми.
— Кичер син, мәхәббәт!
... Мәхәббәт кичерми.

## Шомырт

Язлар җиткәч шатлыгыннан
Түбәсе күккә тия.
Ак шәлен ябына шомырт,
Яшел күлмәген кия.

Күлмәге уңар көз җиткәч,
Ябынып кара шәлен.
Тимәгез язгы шомыртка,
Аңлагыз аның хәлен!

1976

## ОКТЯБРЬНЫҢ 60 ЕЛЛЫГЫНА

**Җәмит Рәхимов**

# ТЫНГЫСЫЗ ЯК

*Чаллы язмаларыннан*

## Камада өченче

Ул, вахтеры белән саубуллашып, берләшмә бинасы каршындагы мәйданга чыкканда, Кама өстенә караңгылык сарышкан иде инде. Шулай да ярда төн якынлашуы сизелми: бихисап лампаларның тәрәзәләрдән төшкән яктылыгына плотина өстендәге прожекторларның ут көлтәләре өстәлгән. Шулар бары бергә баганалардагы неон лампаларның зәңгәрсу нуры белән кушылып, күңелгә ак төннәр тәэсире бирә иде.

Туп-туры өенә кайту, иркенләп ял итү иде исәбе Марат Габбасовичның. Ләкин гадәттәге тынычлыгы бүген аңа хыянәт итте. Аяклары үзеннән-үзе яр буена, актарылып ташланган ком-балчык өемнәренә тартты. Камага таба борылуга, йөзенә салкынча су җиле килеп бәрелде — бөтен тәненә ниндидер сихәтлек, көч йөгергәндәй булды. Бу минутта инде аның гәүдәсен изеп торган авырлык та, хәрәкәтләрендәге салмаклык та юкка чыккан, директор һәр вакыттагыча җыйнак, төз гәүдәле, ашкынып атлаучы Марат Габбасовичка әверелгән иде. Алай да берничә адым ясауга тукталып калды. Алкын елганың гомерлек халәтен үзгәртәчәк дамба менә бирердән — аның аягы очыннан ук башланып китә. Аның 623 метрлы сул як өлеше һәм 1777 метрга сузылган уң як ярдагысы инде әзер диярлек. Хәзергә су юлындагы берничә йөз метрлы ара гына — «китек» булып тора. Анысының да байтак өлеше — 486 метр озынлыгында ГЭС бинасы булачак җир бөя белән уратып алынган, Кама тәмам кысрыкланган. Шуңа да ул кешенең мондый әрсезлегенә ачуланып шаулый, башына йөгән кидерүне өнәмәгән кыргый аттай ярсый кебек.

Йосыпов елга өсте тигезлегеннән утыз метрлар биеклектә калкып торган дамбадагы күнегелгән сукмак буйлап алга атлады. Бу турыда әле су юк, бирегә Каманың тугае гына. Елга буыла гач киләчәк монда су, күп булып тулачак. Аннан инде судноларшушы тугай өстеннән уза башлаячак. Менә аларны үткәреп җибәрү җайланмасы — шлюз

дип атавы да кыен әлегә, шулай да булачак корылма тулысынча чамалана инде. Шлюздан суднолар берьюлы ике рәттә узачак. Сул якта — елганың түбән агымында — аңа якынлашу каналы, киңлеге 190 метр, озынлыгы дүрт чакрым ярым. Канал елганың үз юлыннан инде өелеп беткән биек дамба белән аерылып торачак. Бу турбиналардан чыккан суның гайрәте, зур дулкыннар булып, судноларга китереп бәрмәсен өчен шулай эшләнә. Плотинаның югары ягында исә шундый ук саклану дамбасы белән аерылып торган аванпорт. Аның сул як ярында өеп ясалган мәйданда — порт үзе һәм РСФСР Елга флоты министрлыгының ремонт-эксплуатация базасы. Болары әле проекттагы нәрсәләр. Хәзергә коры җирдә төзелеп ята торган менә шушы җайланмалар барысы бергә техник телдә гидроузелның суднолар үткәрү корылмалары дип аталалар да инде.

Директор шлюз кисеп алган дамбадан аска, машиналар йөрү өчен вакытлыча ясалган юлга төште дә куәтле краннарга таба атлады. Уң ягында тагы текә тау булып плотинаның дәвамы башланды. Шлюз белән ГЭС бинасы арасындагы бу «утрау» шулай ук тиешле биеклеккә күтәрелгән инде, аны бетон белән ныгыту эшләре бара. Технологик җиһазлар урнашачак шушы урынга субай да кагып каралды. Биредә ГЭСның «ОРУ-500» җайланмасы — эшләп чыгарылган энергияне бүлгәләү агрегаты менеп утырачак. Аның янәшәсендә үк административ бинаның ап-ак цилиндры калкачак. Узгынчы пассажирлар бу мәһабәт түгәрәк бинага карап сокланачаклар, әлбәттә. Шлюз кырыенда гына торган скульптура — кешенең көченә, акылына дан җырлаучы сәнгать әсәре дә алар игътибарыннан читтә калмас.

Атлый торгач гранит сыман каты такыр мәйданга килеп чыкты Йосыпов. Асылда исә зур бер калкулык — турбиналардан чыккан куәтле агымның гайрәтен кайтару өчен бетоннан коелган махсус корылма ул. Шул булмаганда, турбиналар әйләндергәннән соң да бик хәтәр булып калган Кама суы плотинаны умырыр, җимерер иде. Биргә күпме бетон түшәүләрен төзүчеләр үзләре генә белә. Хәзергә исә ул монтажчыларга ГЭС бинасын төзү өчен плацдарм ролен уйный. Аның өстендә ике катлы бина — төзелеш штабы. Бу тирә гадәттә кайнап тора, ыгы-зыгы, тавыш тынмый: монда зур төзелешнең дирижерлары — диспетчерлар утыра, шоферлар, электросварщиклар, тагы әллә кемнәр кереп-чыгып йөри. Ызгышлы планеркалар, төрле җыелыш-киңәшмәләр дә шушында — Кама уртасында үткәрелә. Штаб янында ук кырыкмаса-кырык типтагы машина-тракторлар, исемнәрен дә санап булмаган дистәләрчә механизмнар. Шулардан бер як читтә Каманың төп юлына аркылы ГЭС бинасы яткан. Хәер, хәзергә әле аны бина дип әйтеп тә булмый. Аның нигезе һәм шул нигез өстенә күтәрелгән тимер һәм тимер-бетон конструкцияләр, беләк юанлыгы корыч арматуралар. Шулай да һәркайсына икешәр турбина монтажланачак сигез секция күзгә күренә инде. Гидроузел эшли башлауга, һәркайсы 78 мең киловатт егәрлекле уналты турбина Бердәм энергосистемасына ток озатыр. Ә инде вакытлар үтеп, әлегә Төньяк боз океанына коя торган Печора елгасы суының бер өлешен Камага боргач, Чаллы янындагы ГЭСның куәте тагын да кырык процентка артачак.

Килеп йөрмәсә дә, биредә нәрсә эшләнүен, күпме бетон салынуын, күпме арматура ясалуын белеп тора Марат Габбасович. Шулай да төзелешне көнгә бер урамый түзми. Менә хәзер дә, тирә-як тынып калган, куәтле краннар башларын моңсу гына иеп торган чакта, монда бер эш тә юк аңа. Ул инде булачак ГЭС бинасын буеннан-буена көндез узган иде. Әмма, ни гаҗәп, күңеле һаман шунда тарта. Таеп егылмас өчен аркылы агачлар кадакланган авыш тротуар буйлап

аска төште дә Кама төбеннән егерме метрлар астарак яткан беренче секциянең турбинадан су агып чыгачак өлешенә килеп керде. Җай чыккан саен монда сугылмый калмый директор. Чөнки булачак ГЭСның үзенчәлеге нәкъ менә шушында. Хикмәт шунда ки, турбина үзе аша агып чыккан суның юнәлешенә, халәтенә бик сизгер. Агрегатның файдалы эш коэффициенты суның ничек һәм нинди көч белән агып чыгуына бәйле. Менә шуңа да конструкторлар һәм төзүчеләр су агып чыгу урынының геометриясенә зур әһәмият бирәләр дә инде. Биредә ул илебездә беренче тапкыр башкачарак итеп эшләнде. Баштагы исәпләүләр буенча, әлеге яңалык агрегатларның файдалы эш коэффициентын бер-бер ярымга артырачак. Бу исә ГЭС төзү эшендә бик зур нәрсә.

ГЭС бинасы белән рәткә үк буада су күтәрелгәндә аны агызып чыгару плотинасы монтажланып ята. Һәркайсы егермешәр метрлы өч пролеттан торган монолит тимер-бетон секция, кирәге чыкканда, ачылачак һәм гидроузелны хәтәрлекләрдән саклап калачак.

Йосыпов һәркайсы тәртә юанлыгы арматура тимерләренә, алар арасында катып калган меңнәрчә тонна бетон кантарларга байтак карап торды. Әйе, биредә һәр нәрсә нык, чыдам итеп эшләнә. ГЭС төзү эшендә брак ясау, хата җибәрү мөмкин түгел. Барысы да мәңгелеккә ята монда!

Танкларга каршы куелган киртәләрне хәтерләтүче шушы төзелеш мәйданын үтте дә төзелешне Кама суыннан саклап торучы биек бөя өстенә күтәрелде Йосыпов. Плотинаның уң як ярдагы дәвамы белән шушы бөя арасында ярсып, ыжгырып Кама агып ята иде. Ул үзен кысрыклаучы кешегә шул кадәр ачулы бугай, тавышында ниндидер янау, каһәрләү, каргыш яңгырый сыман. Шуңа да югарыга таба узучы баржаларга бар куәте белән ташлана, шуңа ярсый, шуңа дулый Кама.

Су өстендә кыя булып калыккан бөя өстенә басып, ташып аккан елгага шактый озак карап торды Марат Габбасович. Юк, карап кына тормады, бу минутта аның күңеле ярсу елга белән сөйләшә иде. Я инде, Кама иделем, борынгы Чулманым минем, гайрәтләнмә, сабыр ит! Беләм, син бөек, син горур, ләкин кеше синнән дә бөегрәк, гайрәтлерәк бит. Дөрес, син миллионнарча еллар буе үз дигәнеңчә котырып, тилереп актың, яр буендагы нарат-чыршыларны тамырлары белән кубарып чыгардың, салларны әйләндереп капладың, язын исә үзән тугайларны бастың. Тик ул заманнар үтteләр шул инде. Совет кешесе белән ике тапкыр «бил алыштың» син, агымсу: беренче тапкыр — Чайковский шәһәре янында, икенчесендә — Чусовая елгасы тамагында. Һәр икесендә дә чигенергә, баш бирмәс дуамаллыгыңны басарга туры килде сиңа. Хәзер югары агымыңда Воткинск һәм Кама ГЭСлары эшли. Монысы — өченчесе... Күпме генә дуамалланма, бу юлы да сиңа баш бирергә туры киләчәк ич, Кама!

## Яңа нигезләр

Җитез газик Чаллының олы-олы күперләр ярдәмендә элмәкләнеп беткән урамнарын урады-урады да, иркенлеккә килеп чыкты. Ләкин әле бу да шәһәр кырые түгел икән. Асфальт магистраль белән рәткә тимер рельслар, алар буйлап трамвайлар чаба. Ялан кырда трамвай күрү ничектер сәер, ул бер максатсыз басу түрендә адашып йөри сыман. Олы юл әле уңга, әле сулга тармакланып китә. Чатларда — КамАЗның бихисап заводлары исемнәре. Ә-ә-нә үзләре дә гигант корпуслар мәһабәт булып машинага каршы киләләр дә, салмак кына авышып, артка калалар.

Менә соңгы биналар, соңгы траншеялар үтелде, иген кырлары башланды. Зур каланың тәэсире әле бер, әле икенче якта күзгә чалынган авылларда аермачык күренә. Әнә стенасы ак кирпечтән салынган биек, мәһабәт бина — бөртек саклау урыны бугай. Аның материаллары, салыну рәвеше (архитектурасы дисәк, бик зурдан кубу булыр) үк, «мин КамАЗ очкыны» дип кычкырып тора кебек. Мондый шәп биналар исә юл буендагы һәр авылда диярлек.

Менә киң, иркен басу тараеп калды, юлның ике ягына да карт наратлар гаскәре басты. Бераздан аларны ак кырда каралып күренгән юкә урманы алыштырды, көязләнеп, кышкы фонда тагы да ялтырып торган каеннар безгә каршы йөгерде, өрәңгеләр, корыган боталарын офыкка төбәп, шоферга юл күрсәттеләр.

Олы юл сулга, Кама ярына салынган су кудыру станциясенә таба борылды. Монда аның соңгы ноктасы. Безгә исә арырак, Минзәлә якларына узарга кирәк.

Машина, җиңел тирбәлеп, текә үрне төште дә, Кама тугаена килеп керде. Хәер, бу тигезлекне нәрсә дип атавы да кыен. Аның без килгән юлдан шактый түбәндә булуы һәм уң яктан урманлы кашлак — текә яр белән чикләнүе, язын су астында кала торган тугай икәнлеген аңлатса, күз күреме җирдә күкрәп утырган имән урманы зур суга әле шактый ерак икәнен әйтеп тора. Шулай да бу тирәләрнең су астында каласы сизелә. Урманнар киселә һәм, әйтергә кирәк, тәртипсез киселә. Кая карама аударылган, киселгән агач аунап ята, ботаклары җыелмаган. Менә шулар инде хуҗасы ташлап киткән иске йортны күз алдына китерә дә. Соңрак, тирә-як авылларда яшәүчеләр белән сөйләшүдән мәгълүм булганча, чыннан да урманнарны кисүкыруга, таптау-җимерүгә юл куела икән бу якта. Барыбер су баса, янәсе. Яхшы хуҗа, иске өйдән күчеп китәм дип, беркайчан да булган мөлкәтен вәйран итми, гамәлгә ярардай һәр нәрсәне ала, инде үзенә кирәкми икән, башкаларга бирә. Бу яклардагы леспромхоз кешеләренә әнә шундый хуҗадан үрнәк аласы иде. Безнең Татарстан җирендә генә дә җитмеш мең гектар чамасы урман һәм әрәмәләр киселәсен истә тотканда, уйланырлык нәрсә бу.

Алда тип-тигез болын-печәнлек һәм көтүлекләр. Корыч арканга тагып агач сөйрәгән тракторлар юлны шул кадәр тигезләгән ки, аның яхшы асфальт магистральдән аермасы да юк. Тирә-якта шундый иркенлек, шундый хөрлек, ихтыярсыз җырлап җибәрәсе килә. Җәйләрен сәхрадыр монда, әй. Бил тиңентен булып сарут, тукранбаш үсәдер. Алар арасында меңнәрчә бөҗәк кыймылдый, болын өстендә аллы-гөлле күбәләкләр чәчәктән чәчәккә очып йөридер. Уң якта нидер пырхылдагандай булды, әйтерсең әнә теге күлдән бер төркем үрдәк күтәрелде. Нигәдер йөрәк сыкрап куйды. Әйе, язын алар тагы таныш күлләрен сагынып кайтырлар, ләкин «үз» күлләрен таба алмый интегерләр. Сандугачлар ел саен оя иткән урыннарын, куныш сайрый торган шомырт-болыннарын эзләп йөдәрләр. Бу иркен тугайны үз итми күчеп тә китәрләр бәлки. Шулай, су астында калачак болыннар болар. Болар гынамы?

Күңелдә — төзелә торган ГЭС директоры Марат Габбасович Йосыпов белән сөйләшеп утырган кич. Хәтердә инде оныта башлаган саннар калкып чыга. Нихәл итмәк кирәк, көрәш, ул нинди генә булмасын, корбансыз узмый. Бу очракта да шактый гына югалтуларга барырга туры килә. Гидроэлектростанция проект куәтенә эшли башлаганда, 218 мең гектар җир су астында калырга тиеш, шуның яртысы авыл хуҗалыгы җирләре. Дөрес, чәчүлекләр күп түгел — нибары 27 мең гектар чамасы. Аның каравы, сиксән мең гектарга якын печәнлек һәм көтүлекләрне, җитмеш мең гектарга якын урман һәм әрәмәләрне су баса. Югалтуларның иң зур өлеше — 63 проценты безнең

Татарстан өлешенә тия. Су басу зонасына кергән сөрү җирләренә килгәндә исә алар тулысынча диярлек безнең республикада. Әйе, зур саннар, күңелсез саннар болар.

Шулай да өметсезләнергә ашыкмыйк. Ул саннар турында бер без генә уйланмаган. Аларны мөмкин кадәр киметү, җирләрне кулдан килгәнчә саклап калу, инде котылгысыз булган югалтуларны кайтарып алу хакында йөзләрчә инженерлар, экономистлар, партия һәм совет оешмалары җитәкчеләре баш ваткан. ГЭС дирекциясендә меңә көннәр буе проектның калын-калын томнарын актарып, укып утырырга туры килгәне бар. Аның су астында калачак җирләр һәм югалтуларны кайтарып алу турысындагы өлеше аеруча җентекләп эшләнгән. Анда һәр гектардан күпме ашлык, бәрәңге, шикәр чөгендере, печән алынмый калачагы күрсәтелгән. Су астында никадәр терлек азыгы, никадәр азык берәмлеге ятып каласы килограммнарына кадәр мәгълүм. Шул азык берәмлегенә нихәтле ит, сөт һәм башка продуктлар җитештереп буласы, тагы әллә нәрсәләр бәйнәбәйнә саналган. Алар Татарстан буенча, башка республикалар буенча һәм гомуми су басу зонасы буенча күпме тәшкил итә — бар да бар. Проектчыларның һич иренми шул кадәр эш майтаруына хәйран каласың. Шул ук вакытта дүртәр, бишәр урынлы бу саннар йөрәккә шом сала.

Әмма алга таба укыган саен күңелдә нииндидер яктылык, өмет туа. Дөрес, алдарак та саннар, тик инде болары югалтуларны кайтарып алу мәгълүматлары. Укыган аен шатлыгың, сөенечең арта, күңел күтәрелә. Баксаң, югалтулар ике-ике ярым мәртәбә күбрәк кайтарып алыначак икән ич! Коры исәпләүләр генә түгел, җентекләп башкарылган, исбатланган.

Югарыда телгә алынган җирләрнең барысы да су төбендә калмый икән. Авыл хуҗалыгы ягыннан әһәмиятлерәк дип саналганнары һәм, билгеле инде, сайрак урыннардагылары саклана. Шул максат белән дүрт урында инженерлык корылмалары — дамбалар өелә. Иске Тәтеш, Ялгыз нарат, Янҗегет, Саузбаш исемнәре белән йөртелә торган түбәнлекләрдә бу корылмалар барысы егерме дүрт, Татарстанда исә тугыз мең гектарга якын чәчүлек һәм печәнлекләрне алып кала.

Инде килеп, котылгысыз югалтулар нәрсә хисабына кайтарып алыначак соң? Проектта бу сорауга да җавап бар. Булган чәчүлекләрне интенсив файдалану, яңа җирләр үзләштерү, печәнлек һәм көтүлекләрне яхшырту, җирләрне киптерү һәм сугару — киң күләмдә мелиорация һәм агротехника чаралары тормышка ашырылганда, матди югалтулар бөтенләй булмый, киресенчә, авыл хуҗалыгы продуктлары җитештерү нык арта. Су басу зонасына эләккән колхозларда һәм совхозларда хәзер башкарыла торган эшләр әнә шуны раслый. Хуҗалыкларда мелиорация чаралары үткәрелә, сугарулы көтүлекләр төзелә. Бу яктан караганда республикабызның Тукай районы узган ел аеруча зур уңышларга иреште.

Димәк, матди яктан караганда, югалтулар булмаячак. Әмма Кама, Ык, Агыйдел буйларындагы болын-әрәмәләрнең элеккеге гүзәллеге тулысынча сакланмаячак. Аларны башка пейзаж, башка матурлык алыштырыр.

Автомобиль сөзәк кашлакка җәелеп утырган авыл янына килеп туктады. Колыш авылы икән. Ул инде чабуларын җыярга — болындагы йортларын өскәрәк күчерергә өлгергән. Кама суы килеп җитәчәк җирләрдә кура каплаган нигезләр генә сураеп утыра. Безнең юл авылга керми, иске нигезләр арасыннан уза да, калкурак урынга күтәрелеп, алга сузыла. Өч-дүрт чакрым үтәргә өлгермибез, тагы бер

зур авылга килеп керәбез. Элеккеге Боерган авылы күршесе Чебенлене үз кочагына сыйдырган.

Яңа урам, яңа нигезләр. Киң, якты тәрәзәле гүрничәләр безгә елмаеп карый, кәрнизләр һәм тәрәзә йөзләре бизәкле, буяулы. Өйләрнең күбесе яңа, рәшәткәләре нык, матур. Күбесенчә машина кереп-чыгып йөрү өчен башсыз итеп махсус ясалган яңа төр капкалар, алар белән янәшә янбакчалар. Өйләр генә түгел, каралты-куралар да нык, барлык белән төзелгәннәре күренеп тора, салам дигәнең мунча башларында да юк хәтта. Йортлар төзеклеге һәм матурлыгы белән курчак өйләрен хәтерләтә. Тыкрык башы саен су колонкалары.

Машина туктауга, күзгә беренче чалынган капканы ачабыз. Иркен генә ишегалды җыйнак, пөхтә, абзар-кура тирәсендә дә тәртип. Янбакчада быел гына утыртылган алмагач, карлыган, кура җиләге куаклары. Тамыр җибәреп, тернәкләнергә генә өлгергән әле алар, киләсе җәйгә җимеш тә бирә башларлар. Калын бүрәнәләрдән салынган таза, күркәм өй күңелне тартып тора. Эчтән чисталык тышка ук чыккан, болдыр идәненә басарга кыймый торасың.

Минегаян апа белән Тимергали абзыйның, шактый олы яшьтә булып, хәзер икәүдән-икәү генә яшәсәләр дә, тормышлары нык, җитү, күңелләре көр, йөзләрендә елмаю.

Элек елга буйларында, болынлы-әрәмәле җирләрдә яшәүчеләр күченүдән бик зарланалар икән дип ишеткән бар иде. Шуңа да сүзне ерактан башларга туры килде: башта исәнлек-саулык, аннары — дөнья хәлләре. Ләкин Тимергали абзый үзе үк әңгәмәне без теләгән якка борып җибәрде:

— Хөкүмәткә рәхмәт укып кына яшәп ятабыз әле, — диде ул, безнең исән-саулык сорашуга җавап итеп. — Һич уйламаганда йортҗирне яңарттык, су капка төбенә килде, чәйне әнә газда гына кайнатабыз. Акчасын хөкүмәт, тракторын-мазарын дигәндәй колхоз биргәч, күченүе дә әллә ни кыенга туры килмәде.

Ул арада өстәлгә пар бөркеп чәйнек килеп утырды. Минегаян апа кызлар өлгерлеге белән маен-балын, бавырсагын-кортын, шикәр-конфетын тиздә. Чәй янында сүз тагы да җанлана төште.

Яңа урынга күчүнең башка бер бик әйбәт ягы да булган Закировларга. Авыл Советы белән киңәшеп, кызлары Гөлсинә өен дә янәшә күтәреп куйганнар — кереп-чыгып йөрергә, хәл белергә якын, бер яккан мунча ике йортка да җитә. Гөлсинәнең үз хуҗалыгы да әти-әнисенекеннән кайтыш түгел. Шулай булмыйни, шушы «Кама» колхозында егерме елдан бирле сыерлар сава икән Гөлсинә. Андый тырышларга кадер-хөрмәт зур инде ул.

Тимергали абзый үзе Ыкның Камага килеп кушылган җирендә, киң, иркен болын-әрәмәләр кочагында утырган Чебенле авылында туып үскән, шунда башлы-күзле булган. Бәхет эзләп калага да барып караган, Ижевск, Казан заводларында эшләгән. Тик Чебенледән дә ямьле җирне тапмаган. Гаҗәп тә түгел, ул Чебенле болыннарындагы хуш исле печәннәр, ул андагы балан-миләш, ботакларын сыгып утырган карлыганнар, аланнарда тәгәрәшеп пешкән җиләкләр тагы кайда бар?! Авыл түгел, җир өстендәге җәннәт инде. Шулай да балалары Чебенледә калмаган Тимергали абзыйның, канат чыгарган берсе оча торган. Укыганнар, белем алганнар, барысы да күркәм генә эшләрдә хәзер. Гөлфирә Пермь заводларының берсендә группа начальнигы, Гөлҗәүһәр дә шул ук калада балалар врачы. Гөлфия Казан заводларының берсендә инженер, Фәридә Минзәлә районы Хуҗиәхмәт авылында укыта. Фәрит исә Минзәләдәге механикалаштырылган күчмә колоннада диспетчер, апалары һәм үзе уйнап үскән әрәмәләрне кистерә. Менә бит ул ничек дөнья дигәнең! Алтысы алты җирдә гөрләшеп яшәп яталар. Чебенледә генә түгел икән бит матур-

лык. Аннан бер матурлык белән генә дә яшәми бит кеше. Тимергали абзый нигезен күчерүне дә бәла дип санамый. Шулай кирәк икән, кирәкнең кыйммәте юк.

— Шул авыл урынында йөзеп йөргән пароходларны күрәсе иде әле, — ди ул дәртләнеп.

Әйе, яңа нигезгә халык инде күнегеп килә, күпчелек күченүдән канәгать. Шулай булмыйни, башта кот очарлык булып тоелган нәрсә яхшы булып чыкты бит: авыллар баштан-аяк яңарды, аларга юллар, суүткәргечләр, хәзерге заман таләпләренә җавап бирерлек мәктәпләр, клублар, медпунктлар, кибетләр салынды.

Кыйммәткә, бик кыйммәткә төште бу эшләр. Су басу зонасыннан 134 авыл һәм поселокны, барысы 13200 йортны, 139 колхозны, 21 совхозны һәм ике йөзгә якын башка объектларны күчерергә туры килде. Алары инде эшләнде диярлек. Күченгән халыкның күбесе ул ыгы-зыгылы көннәрне онытып, Тимергали абзый кебек хөкүмәткә рәхмәт укып ятадыр.

## Йосыповлар

Без төзелештән әйләнеп кайтканда кич җитеп, гидротөзүчеләр поселогы ут диңгезенә чумган иде инде. Шулай да ГЭС директоры кабинетында ут яна әле. «Гадәттәге урынында, тәрәзә буенда Кама өстенә карап торадыр»,— дип уйладым мин, аның кабинетына узганда. Ялгышканмын. Марат Габбасович эш өстәле артында телефоннан сөйләшеп утыра, ә тәрәзә буенда аның кебек үк озын буйлы, тагы нindидер чалымнары белән директорның үзенә охшаган берәү басып тора иде. Марат Габбасович, сүзен тәмамлап, телефон трубкасын урынына куйды да миңа карады.

— Таныш булыгыз,— Марс Габбасович,— диде ул тәрәзә буендагы кешегә ишарәләп.

— Ике туган бергәләп төзисез, алайса, ГЭСны,— дидем мин, Марс Габбасович белән танышырга кул сузып, һәм исемемне атадым.— Бер гаиләдән ике гидротехник!

— Марс гидротехник түгел, ул Мәскәү автомобиль юллары институтын бетерде. — дип сүзен дәвам итте булмә хуҗасы. — Шулай да безнең системада эшли. Камгэсэнергострой киң колачлы берләшмә, бик күп профессия кешеләренә эш җитәрлек монда.

Йоыповлар сикереп төшә, үзләре турында җәелеп китә торганнардан түгелләр. Шулай да сүз арасында Марс Габбасович турында кайбер мәгълүматлар билгеле булды. Ул Мәскәүдә институт тәмамлагач, илебезнең төрле урыннарында төзелешләрдә эшләгән, аннары бер төркем совет белгечләре белән бергәләп, экономик яктан артка калган илләргә ярдәм йөзеннән, күрше дәүләтләрнең берсендә юллар, күперләр салышкан. Хәзер исә «Камгэсэнергострой»ның төзү индустриясе базасында. Ул Чаллы җылылык электростанциясен салуга зур өлеш керткән, КамАЗдан башка төзелешләрдә дә аның хезмәте бар.

Аннан Йосыповлар икәү генә дә түгел икән әле Чаллыда. Кече энеләре Чулпан Габбасович бар икән тагы. Ул белгечлеге буенча гидротехник, шушы ук берләшмәнең «Гидрострой» трестында сыйфат лабораториясендә начальник урынбасары.

— Димәк, ГЭС төзелешендә өч бертуган!

— Шулай булып чыга, — диде Марат Габбасович елмаеп, — Чаллыда өчәү. Ә барысы бишәү без: өлкәнебез — Айтуган Тольяттида автомобиль заводы салышты һәм шунда ук эшкә калды. Һөнәре шул бит — Ташкентта транспорт инженерлары институтын тәмамлаган

иде. Миннән кечерәк энебез Ринат исә Йосыповлар гаиләсендә өченче гидротехник. Ул Мәскәүдә Тимирязев исемендәге академиядә укыды. Хәзер Алма-Атада яши, ирригация эшләре белән шөгыльләнә.

Тууын зур су буенда да тумады Марат Габбасович, аның дөньяны танып белә башлаган җире — Әлки районының Алпар авылы. Ләкин малай Куйбышев затонында, Идел дулкыннары кочагында үсте. Шунда беренче тапкыр Иделнең зурлыгына, алкынлыгына, мәһабәтлегенә таң калды, суның куәтенә, гайрәтенә, аның эшчәнлегенә сокланды. Шунда нәни Маратның йөрәгендә елгага хөрмәт, мәхәббәт уянды.

Күп тә үтми, укытучы Габбас ага, үзенең ишле гаиләсе белән, Урта Азиягә чыгып китә һәм Әндижан шәһәрендә урнашып кала. Бу якларда диңгез һәм зур елгалар юк, ком да сахра, кайнар җилләр дә кояш кызуы. Әмма шушындый җирләрдә беленә икән дә суның кадере. Монда судан башка мамык, дөге үсми, алмалар кызарып пешми, йөземнәр җимеш бирми — бар яшеллек корый. Урта Азиядә су тереклек дигән сүз ул, ә ирригация эшләрен башкаручы гидротехник — алла. Мул сулы Идел буенда шыткан хисләр ком сахрасында тамыр җәеп, үсеп киттеләр — Марат гомерен су белән бәйләргә булды. Ләкин малай җиденче класска җитүгә сугыш чыкты, дөньяның рәте чуалды, уй-хыялларны тамак кайгысы күмеп китте, мәктәпне ташлап колхозда эшли башларга туры килде.

Һаман шунда эшләсә, егетнең хыялы хыял булып кына калган да булыр иде бәлки. Нигә дисәң, инде сугыш тәмамланса да, тормыш әле авыр, җитмәсә, эшче куллар җитешми. Бу хәлдә үз булып беткән колхозны ташлап китү килешми иде. Ә китәргә туры килде барыбер: егетне армиягә алдылар.

Язмышмы бу, ялгышмы: Маратка Куйбышевта хезмәт итәргә туры килде. Бу елларда исә барлык газета-журналлар илебезнең яңа төзелешләре, бигрәк тә ГЭСлар турында еш язалар иде. Өстәвенә, иң зур ГЭСларның берсе Куйбышев шәһәре янында, Жигули таулары районында салына башлады. Шуларны күреп, ишетеп торган егетнең яшьлек хыяллары яңарып, күңелендә гидротехник булу нияте үсте, ныгыды һәм катгый карар булып җитеште. Шул карары кулына дәреслекләр алырга мәҗбүр итте, солдат хезмәтендә аз-маз тигән буш вакытларында ул үзлегеннән укыды.

Армиядән кайтуга, бер җәй эчендә хәзерләнеп, өлгергәнлек аттестатына имтихан тотты, аннан ял да итеп тормастан, Ташкент ирригация инженерлары институтына китте һәм шул ук 1952 елда ГЭСлар төзү факультетында укый башлады.

Институтта яхшы укыды Йосыпов. Шуңа бугай, диплом алуга аны җаваплы эшкә җибәрделәр. Ач далада магистраль каналлар казытты Марат Габбасович, Янгы-өрдә беренче казыкларны кагышты. Аннан Сыр-Дәрьяда Чардалы ГЭСы салуда катнашты — баш инженерның ярдәмчесе булып эшләде.

1965 елда аны Чаллыга чакырып алдылар һәм төзү-монтаж идарәсенә начальник итеп билгеләделәр. Ул чакта әле булачак гидротөзүчеләр поселогында нибары бер йорт утыра, ә Кама үзенең язмышы турында берни белми тыныч кына ага иде. Йосыпов, яңа коллектив туплау белән мәшгуль булган хәлдә, эшчеләргә өйләр салуны тизләтте, бәяләр өйдереп, елганы кысрыклатты. Булачак гидроэлектростанция нигезенә бетонның беренче тонналары ятты.

1969 елда аңа төзелә торган ГЭС директоры постын тәкъдим иттеләр.

Бер гаиләдән биш инженер-төзүче. Шуларның өчесе Чаллыда бүген. Алар белән бергә Татарстанның бик күп егетләре һәм кызлары җиң сызганып гигант автозавод салалар, аңа тиң гидроэлектростанция коралар.

## Илдар Низамов

# КЫЗЫЛ УКЧЫЛАР



Казан истәлекләргә бик бай. Аның архив, музейларына кереп тормыйча, үзебез көн саен йөри торган гадәти урамнарына күз салып, аларның исемнәрен уйлап узсаң да, мавыктыргыч тарихи китап битләрен ачкандай буласың. Хәтта иң яшь урамнары да күп нәрсә сөйли икән.

Шәһәрнең яңа бер бистәсендә, элекке Танкодромда, Латыш укчылары урамы бар. Латвия, Рига моннан бик еракта, Балтика буйларында, ә латышлар — кызыл укчылар, Юдин, Азин, Лацис, агалы-энеле Межлауклар, туган якларындагы кебек, бездә дә телдән төшми. Ерак араларны оныттырган мондый якынлык кайдан килә?

«Латыш укчылары...» Урамның бер ягына аның үзе кебек үк яңа, яшел урамнар тоташып китә, ә икенче ягы чыннан да кораб бортына охшаган: киләсең-киләсең дә урам читендә кырт туктап каласың. Алдыңда ярты Казан диярлек җәйрәп ята. Әнә олылы-кечеле Кабан күлләре. Ярларында борынгы урамнар. Әнә Вахитов комбинаты, шул исемдәге станция. Бирерәк Павлюхин урамы, аннан янә яңа төзелешләр.

Вахитов... Павлюхин... Латыш укчылары... Бер-берсенә аерылгысыз бәйләнгән бу исемнәр Казан елъязмасының бөтен бер битен ачып җибәрәләр түгелме соң? Дәһшәтле 1918 ел битен.

26 июль. Владимир Ильич Ленинның гадәттәге бер эш көне — аның бүлмәсеннән иртәдән кичкә кадәр кеше өзелми. Чит илләрдән килгәннәре дә бар. Барысының да йомышлары мөһим, ашыгыч. Бөтен ил гражданнар сугышы утында яна. Ул укыган, кул куйган күп санлы, ашыгыч документлар да шул уңайдан.

Ленин, торып, карта янына килә. Карашын Мәскәүдән Петроградка күчерә. Бөтен ышаныч — эшчедә. Отрядларны тизрәк оештырып, тизрәк Казанга озатырга кирәк.

Питердан кузгалачак коммунистик отрядларны озата килгәндәй, Ленинның карашы Казанга төбәлә. Бирегә бәлки ярдәм килеп җиткәнче үк дошман белән йөзгә-йөз чәкәшергә туры килер. Ул көчле: бөтен дөнья империалистлары аның яклы, илнең икмәге, күмере, нефте аның кулында. Кыен, бик кыен булачак аның белән алышу. Бирешмәсләрме?

---

Очерк кыскартып басыла.

Нәкъ шул көнне Көнчыгыш фронт командующие сул эсер Муравьев, Казаннан качып китеп, Сембергә килеп төшкән була һәм эсерларның Советларга каршы әзерләгән заговорын дәвам иттерә. Икенче көнне Ленин Муравьевның сатлык җан икәнлеген белдереп барлык төбәкләргә адресланган радиограммага кул куя, Сембер большевиклары исә аны тиз генә кулга алуны оештыралар, каршылык күрсәткәндә юк та итәләр. Шулай итеп, авантюрага чик тиз куела. Әмма ул фронтта көтелмәгән кыенлыклар китереп чыгара. Шул ук кичне Халык Комиссарлары Советы утырышында командующий итеп И. И. Вацетис, ә фронтның Реввоенсоветы членнарының берсе итеп Латыш совет дивизиясе комиссары К. Х. Данишевский билгеләнә. Бу хакта үзенең истәлекләрендә Данишевский болай дип язып калдырган: «Бу билгеләү Владимир Ильичның үзенең турыдан-туры катнашлыгында булды... Бик кыен хәлләр туганда, үтә җаваплы бурычларны башкару латыш укчы полкларына йөкләтелә торган булды. Әле дә аларның барысы да диярлек Иделгә, Казан янына җибәреләчәк иде...»

...Владимир Ильич бәлки латышлардан тагын бер карт большевикны — Мартын Иванович Лацисны күз алдына китергәндер. Ул да хәзер Казанда. 16 июльдә Халык Комиссарлары утырышында Ленин председательлегендә Советның Көнчыгыш фронт буенча Гадәттән тыш комиссиясен булдыру хәл ителә. Аның председателе итеп М. И. Лацис билгеләнә. Ул Казанга чыгып киткәндә аның белән Ленин үзе сөйләшә, Идел буенда контрреволюциягә каршы хәлиткеч көрәш алып барырга кирәклеген кисәтә, бу комиссиянең ВЧК белән бәйләнеше нинди булырга тиешлеген аңлата, андагы хәлләрне язып торуын үтенә. Хәзер үз большевиклары, Лацис җитәкчелегендә Казан чекистлары эшне нык кына җанландырып килаләр. Тик бу эштә аларга массаларга — эшчегә, ярлы крестьянга таянырга кирәк. Вацетис бу яклап ничегрәк эшли икән? Шунсыз эшче отрядлар туплау, оештыру сузылачак. Партия җибәргән комиссарлар Вацетисның менә шушы ягына нык әһәмият бирергә тиеш.

Бәлки бу минутта Владимир Ильич шул комиссарларның берсен — һәр вакыт пөхтә, килешле киенеп, фикерен дә ачык, пөхтә итеп әйтә белүче, сөйләве дә, хәрәкәте дә бераз кискенрәк Мулланур Вахитовны күз алдыннан үткәргәндер. Идел буе халыклары, аеруча татарлар арасында аның абруе бар, оештыру сәләте зур...

Вакытлар үтү белән, вакыйгалар хәтердән ерагая баручан. Әмма бу — Бөек Октябрь революциясенә кагылмый. Бәхеткә юл ачкан вакыйганың һәр көне бөтен вагы-төягенә кадәр хәтердә яңара, якыная гына бара, кызыксынуны буыннан-буынга көчәйтә генә.

Латыш укчылары да мине архив, музейларга, ниһаять, Ригага алып китте.

...Анда бер-ике көн рәттән ишелеп-ишелеп кар яуды. Бу хәлнең көтелмәгән мәшәкатьләре күп булса да, кешеләр бер дә артыгын борчылмады, чөнки бил тиңентен мондый карның менә берничә ел инде күз башында түгел, ел башында да булганы юк икән. Кар шәһәрне бизи иде. Аңа төрәлеп үк утырган нарат, чыршы урманнары аеруча матур булып күренде. Бу тансык күренеш якты истәлекләр уятты. Күз алдына үзебезнең Казан тирәләре, шушындый ук яшел япмасы арасына табигать сөюче йөзләрчә дусларын сыендыра торган Биектау, Каменка урманнары килеп басты. Анда да нәкъ шушындый манзарадыр. Чаңгы бәйләп алырга да, күбек кебек җиңел карны очыртып-тузгытып, яшь наратлар арасыннан бер җилдерергә иде...

Ветераннар белән очрашырга дип музейга килеп кергәндә дә күңел әле шул тәэсирдән һаман утырып бетмәгән иде, беренче танышым Петер Юрьевич Гришко белән дә сүзне нәкъ шуннан алып киттек.

— Ә мин ул Биектау урманнарын яхшы беләм,— диде Петер Юрьевич һич көтмәгәндә.

Бу хакта җентеклэбрәк сөйләүне азаккарак калдырып, сүзне Риганың менә шушы музееннан башлыйк. Ул «Латыш кызыл укчыларына мемориаль истәлек музей» дип атала. Риганың үзәк бер урамында, киң Даугава ярында үзе бер мәйданны тотырып-бизәп утырган ансамбль ул. Мәйдан уртасында өч хәрбинең мәһабәт сыны калыккан. Аларның кырыс йөзенә күз салу белән, хәтергә «революция рыцарьлары» дигән канатлы сүз килеп төшеп, күңелне горурлык хисе тутыра. Шундый романтик исем белән халык күңеленә кереп калган латыш укчылары әле дә илебез сагында, революция казанышлары сагында торалар кебек.

Һәйкәлдән арырак — музей бинасы. Гаҗәеп зур тоташ бер таш плитәне хәтерләтә. Бер карыйсың, ул яу кырында ятып калган меңнәрчә батырлар каберенә куелган истәлек ташыдыр кебек, икенче карыйсың, космос корабларының старт мәйданчыгыдыр сыман.

Эчендә иркен. Кеше күп булса да, ыгы-зыгы сизелми. Олы тынлык. Экспонатларны күп итеп тутырырга, чуарларга тырышмаганнар. Тарихи кыйммәте бай булган, барлык кешегә дә кызыклы документ алынган да күп кеше карарлык итеп куелган, яхшы яктыртылган. Ашыгасы, барысын да күрәсе дип чабасы юк. Җай гына кара, тарих белән күзгә-күз очраш, уйлан. Якында гына Даугава дулкыннарының шавы ишетелеп-ишетелеп куя. Тора-бара ул Идел шавы булып тоела башлый, чөнки экспонатлар безне янә унсигезенче елгы Казанга алып китә.

Яңа командующий И. И. Вацетис Казанга уналтынчы июльдә килеп төшә. Егерменче июльдә казанлыларны Воскресенский урамы ягыннан ишетелгән оркестр тавышы әсәрләндерә. Дүртәр рәтле колоннада нык-нык басып, мылтык көпшәләрен сунарчылар кебек аска караткан гаскәриләр килә. Бу Бишенче Земгаль латыш совет полкы укчылары була. Аларның шундый ышанычлы атлавы, шулай бердәм, тупланган булулары, саллы кыяфәтләре Казанга зур бер көч килүен сөйли. «Латышлар килгән!», «Кызыл укчылар Казанда!» дигән хәбәр, телдән-телгә, урамнан-урамга күчеп, тиз арада бөтен Казанга тарала.

Икенче көнне үк полкка җаваплы бурычлар йөкләнә: дәүләт банкын һәм башка мөһим учреждение, предприятиеләрне саклау, шәһәрдә тәртипсезлекләр ясап яткан анархистларны авызлыклау, сул эсерлар төзегән хәрби отрядны нык контрольгә алу...

Әмма инде соң була. Дошман, күп көч туплап, куәтле флотилия белән шәһәр тирәсенә искәрмәгәндә килеп тә җитә. Казан камалышта дип игълан ителә. Аның гадәттән тыш коменданты итеп латыш халкының батыр улы Иван Межлаук билгеләнә.

...Дошман бишенче августта Идел ягыннан һөҗүмгә ташлана. Фронт штабы кушуы белән, пристань ягына Бишенче латыш полкы, Беренче татар-башкорт батальоны һәм партиянең губерна комитеты оештырган эшче отрядлар җибәрелә. Шулай да Казан өчен сугышның төп авырлыгы Дүртенче һәм Бишенче латыш полклары өстенә төшә.

Кызганычка каршы, мин Ригада бу сугышта катнашкан ветераннарның үзләрен күрә алмадым. Шулай да алар язып калдырган истәлекләр белән танышырга мөмкин булды. Менә Бишенче полк командиры ярдәмчесе В. Паварис язмалары: «Өйрәтелмәгән команда белән ашыгыч кына тупланган, начар коралланган берничә генә пароходтан торган кызыл флотилия җиңелеп, бишенче августта артка чигенде — ак гвардия судноларына Казанга юл ачылды. Кич белән аларның ике пароходы, туплардан һәм пулеметлардан Бишенче полк позицияләренә ут өермәсе яудырып, Казан турысына килеп җитте. Десант төягән шлюпкалары ярга ашыкты. Әмма шәһәрне саклаучыларның туплары, аларны тиз туктатып, чигенергә мәҗбүр итте. Шунда пароходлардан утны көчәйтеп, алар ышыгында яшеренеп килгән дистәләрчә көймәләр, өзлексез ата-ата, кинәт ярга ташландылар. Икенче батальон командиры Вальтер Брунинieкс: «Дошманны ярга чыкканда атакаларга!» — дип приказ бирде. Акларның көймәләре ярга җитәм дигәндә генә сигезенче рота командиры — салкын канлы кыю Янис Грегорс җәһәт кенә траншеядан килеп чыкты да: «Укчылар, алга! Уз приекшу, стрелниеки!» дип мылтыгын төбәп, ярга ташланды. Артыннан «Ура» кычкырып, иптәшләре купты. Дәһшәтле өндәүгә икенче батальон укчылары да кушылды. Бу ташкын десантка нәкъ су читендә ябырылды. Аяусыз кул сугышны башланды. Монда инде уңышны пулеметлар түгел, бәлки ихтыяры нык, кулы көчле, фидакарьлеккә гадел эш өчен барганын аңлаган кешеләр хәл итте. Алыш озакка сузылмады, әмма ул аяусыз булды, кан күп түгелде. Кызыл укчылар десантны Иделгә атып бәрделәр, тулаем диярлек кырып салдылар. Пароходлар чигенде, артларыннан төтен генә таралып калды».

Ләкин бу әле шәһәр өчен көрәшнең башы гына була. Төнлә бермәбер арткан дошман алтынчы августта Казанга төрле яктан ташланды. Ул — яралы ерткыч кебек мәрхәмәтсез, мәкерле...

«...Беренче колонна — комуч гаскәрләре — полковник Каппель кул астында шәһәрнең көнчыгыш ягыннан, икенчесе — полковник Швец җитәкчелегендә чехословаклар — көньяктан. Каппель колоннасы, Югары һәм Урта Кабан арасыннан үтеп, Горки авылы һәм Бутырки бистәсе аша Суконныйга бәреп керә. Швецныкы, Архиерей дачасына җиткәч, төньякка борыла да Урта Кабан ярыннан килеп, шәһәргә татар зиратының көнчыгыш ягыннан бәреп керә. Совет командованиесе бирегә Бишенче Земгаль полкы частьларын, Карл Маркс исемендәге батальонны, татар берләшмәләрен, эшче отрядларны җибәрә. Мулланур Вахитов җитәкчелегендә Мәскәүдән килгән аерым отряд та шушында сугыша...» диелә М. Мөхәррәмовның «Татарстанда гражданнар сугышы» китабында.

Идел буенда да сугыш ике юнәлештә кыза. Уң як ярда — Югары Ослан тавы өчен, сул як ярда — пристань өчен. Дошман пароходлары, туптан өзлексез атып, Бишенче полкның пристань тирәсендәге позицияләрен какшаталар, кара чебен өермәсе кебек ябырылган десантка карщы тору аз санлы укчыларга ифрат авырлаша — әмма алар тетрәмиләр, дошманны йөзгә-йөз каршы алалар. Иртә таңда Идел суына кызыл гөрләвекләр килеп кушыла. Төнлә аклар ягына таярга өлгергән бер ничә сатлык җан офицер безнекеләрнең оборонасы көчсезрәк урыннарны дошманга җиткергән булалар, ут шунда юнәлтелә, туплар пулеметларны сафтан чыгара. Безнекеләр чигенергә мәҗбүр була.

Ләкин пристань ул әле Казан түгел. «Казанга чаклы дүрт чакрым ара әле,— дип яза шул минутларда укчылар рәтендә булган В. Паварс,— ул араны латыш укчылары һәм эшче отрядлар каһарманнарча сугышып чигенде. Латышларның пулеметы атудан туктамады.

Полк комиссары Лундерс, взвод командиры Балтынь, рота командирлары Суйтынь, Брехманис, укчы Пулис һәм күп кенә башка сугышчылар яралансалар да, сугыш кырын ташламады. Сафтан чыгучылар күп булганга, һәр укчыга ике-өч кеше өчен сугышырга туры килде».

Бу сугышта аларга көч, гайрәт биргән сәбәпләрнең берсе шулдыр: иң кыен минутларда алар ялгыз түгел иде. Бирелә латыш укчыларыннан тыш Беренче татар-башкорт батальоны, элекке Алафузов һәм Крестовниковлар заводларының эшче отрядлары була. Казан өчен, яшь Совет республикасы өчен латыш частьларында да, башка отрядларда да күп милләт уллары, Рәсәйнең төрле почмагыннан килгән эшчеләр, солдат, матрослар иңгә-иң торып, үзләреннән алтыҗиде мәртәбә күбрәк санлы дошманга каршы бастылар. Алар берберсенең фидакарьлегенә шаһит булды, шуннан шөһрәт, көч алды. Бу сугышта катнашкан икенче бер латыш укчысы К. Я. Иокум истәлекләрендә мондый юллар бар: «...Пристаньгә җирле гарнизоннан берничә рота килде. Алар дошман десантын тоткарларга нык тырыштылар. Әмма көч бик тә аз иде, дошманны тоткарлап булмады. Татар ротасы аеруча каһарманлык күрсәтте, дошман белән ул искиткеч каты сугышты».

Югары Ослан өчен бәрелеш тә аяусыз була. Ничек кенә кыю, бердәм булмасыннар, ничек кенә арысланнарча сугышмасыннар, Беренче социалистик батальон морякларының язмышы фаҗигале бетә: батальон бөтенләе белән диярлек — 300 дән күбрәк егет... — Идел ярында һәлак була. Ослан тавына менеп алып, аклар анда артиллерия урнаштыруга ирешә һәм шәһәрне бирмәс өчен кан-тир түгеп көрәшкән батырлар өстенә ут явымын өчләтә арттыра.

Сугыш шәһәрнең берьюлы берничә төшендә барса да, хәрби частьлар арасында ышанычлы элемтә булмый, штабта оялаган ак офицерлар аларны таркату, хәлсезләндерү өчен барысын да эшлиләр: кирәксә-кирәкмәсә дә, командирларны штабка чакыртып йөдәтәләр, хәрби частьларның урыннарын иң җитди минутларда алыштыралар, итәк астыннан гына, «шәһәрнең фәлән төшен чехлар инде басып алган» дигән шомлы хәбәр тараталар.

Владимир Ильич дөрес сиземләгән: хәрбиләр белән җирле власть җитәкчеләре арасында бәйләнеш чыннан да тиешенчә булмый. Шуңа күрә эшче отрядлар оештыруга да игътибар кайбер очракта җитенкерәми, өйрәтергә вакыт бик аз кала.

Әмма, барыннан да бигрәк, Казанны сакларга тиешле төп көчләр вакытында килеп җитми.

Шулай итеп, ул көннәрдә әле оешып кына килгән яшь-яшь Совет Армиясенең болай да сирәк сафлары, күпләр егылып, күпләр камалышта калып, тәмам сирәгәя. Фролов җитәкчелегендә Адмиралтейство бистәсен яклап сугышкан эшче отряд бөтенләе белән диярлек һәлак була. Командир үзе дә. Ә Суконный өчен алышта шундый ук фаҗигага «Победа» фабрикасыннан А. Павлюхин җитәкчелек иткән отряд дучар була.

Шулай да Казанның бер карышы да акларга арзанга төшми. Сугыш урамнарда дәвам итә, Кызыл армиячеләр, эшчеләр төркем-төркем дә, берәм-берәм дә, ярдәм килеп җитәренә һаман өметләреп өзмичә, дошманга нык каршылык күрсәтәләр — Вацетис үзе дә, исән калган укчылар белән бергә, штабтан Кремльгә күчеп, яңа частьлар килгәнче ничек тә түзәргә хәл кыла. Нәкъ менә шул авыр минутларда Казан контрасы үзенең ерткыч йөзен күрсәтә. Бакчаларга күмелгән, чормаларда яшерелгән, йорт сакларга дигән булып дворникларга эсерлар тараткан корал оешкан төстә ходка җибәрелә, безнекеләрнең

һәр адымын күзәтеп торган дошман котырынып ата башлый. Кремльдәге частьлар да акларга сатылган булып чыга.

Шәһәр өстенә коточкыч дәһшәт белән яшенле яңгыр да ябырыла. Үзләре дә тәмам хәлдән тайган килеш, дошманны да шактый кыйнап, безнекеләр төн уртасында гына Казанны калдыралар.

...Совет Армиясе кадәр бай тарихлы, шанлы юл үткән армия дөньяда юктыр. Аның данлы җиңүләре хөрмәтенә чигелгән байракларны күпләр күрде. Бик күп музейларның горурлыгы, чын бизәге алар. Әмма бер байрак аеруча истә калган. Ул Татарстан Дәүләт музеенда саклана. Чия төстәге чуклы байрак. Кызгылт-сары ука белән: «Данлы Бишенче латыш укчы совет полкына. ВЦИКтан. Казан шәһәрен батырларча фидакарь саклаган өчен» дип язылган аңа. Ул — Совет власте кызыл частьларга бүләк итеп биргән иң беренче Кызыл байрак. Казан өчен көрәшкәннәр аңа чыннан да лаек булалар. Көнчыгыш фронт җитәкчелеге В. И. Ленинга болай дип яза: «Казанны ике көн буе батырларча саклауның стратегик һәм политик әһәмияте гаять зур. Бишенче августта чигенеп, дошман алтынчы августта Казанны алыр өчен сугышка бөтен көчен тупларга мәҗбүр булды. Шулай да чехословаклар алтынчы августта Свияжск станциясен һәм Идел күперен алырга җитәрлек көч туплый алмадылар». Латыш совет полкына, Коммунистик Казан һәм Мөселман коммунистик отрядларына ВЦИК Президиумының котлау телеграммасы нәкъ менә шушы җиңү өчен җибәрелә дә.

Ябалак-ябалак кар яуган көнне без, электричкага утырып, Ригадан унҗиде чакрымдагы Саласпилс дигән — хәзер инде күпләргә мәгълүм истәлекле урыннарга бардык. Бу тирәләрне яхшы белүче латыш дустыбыз, журналист Эвольд Папиньш станциядән безне урман сукмаклары буйлап турыдан гына алып китте. Бөтен дөнья ак иде, якты иде. Сөйләшә-сөйләшә, матурлыкка соклана-соклана атладык та атладык. Каршыбызда, кинәт кара койма булып, коточкыч зур шлагбаум калыккач кына туктап калдык. Без Саласпилска — заманында немец фашистлары корган иң зур үлем лагерьларының берсе урынына — хәзерге мемориаль ансамбльгә килеп җиткән идек. Шлагбаум рәвешендә ясалган йөз метр озынлыгында, уникe ярым метр биеклегендәге бу тимер-бетон корылма үлем белән яшәү арасындагы чикне тасвирлый. Бирегә, чыннан да, меңнәр кергән, әмма чыгучылар бик сирәк булган. Биредә фашистлар йөз мең кешене азаплап үтергәннәр. Шлагбаумга «Бу капканың теге ягында җир ыңгыраша» дип язылган.

Латвияне, Риганы, бу тирәләрне азат итүдә Татарстан егетләре дә катнаша. Өченче Балтик буе фронты составында Арчада, Биектауда, Столбищеда оешкан полклар сугыша. Отделениесе белән илле танкны, үзйөрешле тупларны кырып салып, иптәшләре кырылып бетеп, берүзе калгач та дошман белән сугышудан туктамыйча батырларча һәлак булган татар сержанты Никита Токарликов, Айвиэксте елгасын кичкәндә олы каһарманлык күрсәтеп, күпләрне җиңүгә дәртләндергән Әкрам Вәлиев кебек Советлар Союзы Геройларының, аларның йөзләрчә сугышчан якташларының якты истәлеген бу якларда онытмыйлар.

Онытырга хакыбыз юк! Саласпилс шуны әйтә. Юдин, Азиннарны онытмаганга күрә, Токарликов, Вәлиевләр тәрбияләнгән. Саласпилс кебек фашист мәхшәрләрен җир йөзеннән сөреп ташлый алган бу егетләр, бәлки, теге дәһшәтле унсигезенчедә латыш укчылары килеп

ач үлемнән йолып алган, якты юлга чыгарылган бәхетле балалардыр.

Ул чагында Казан дошман кул астында утыз дүрт көн булган. Әлбәттә, ак интервенция аны басып алу белән генә канәгатьләнми. Аңарга тимер юл, Идел күпере, Мәскәү кирәк. Бераз хәл алуга ук, ул яңа һөҗүмгә ташлана. Әмма безнекеләр бүтәнчә бер генә карыш җирне дә бирмәскә, тизрәк Казанны кире тартып алырга ант итәләр. «Бөтен кеше хәлне менә болай күз алдына китерә иде: — дип яза батыр разведчик, журналист Лариса Рейснер.— артка бер адым гына чигү дә «аларга» Нижнийга Иделне, Мәскәүгә тимер юлны бирү дигән сүз, тагын да чигенү ул бетүнең башы, Совет республикасына үлем хөкеме... Шул вакытта Иделне ташлап китү чын һәлакәт булса, күпергә арка терәп, бөтен яктан ташланган дошманны кире кагу киләчәккә өмет калдыра иде. Чигенү — чехлар Мәскәүдә һәм Нижнийда дигән сүз, Свияжскиның һәм күпернең бирелмәве — бу инде Кызыл Армия Казанны кире алачак дигән сүз...»

В. И Ленин үзе, аның җитәкчелегендә Үзәк Комитет һәм Совнарком үтә җитди, ашыгыч чаралар күрәләр. Алтынчы августта Свияжскига Петроград, Мәскәү һәм башка калалардан эшчеләр, яңа гаскәри берләшмәләр килә башлый, унберенче августка Бишенче армия оешып бетә һәм ул дошманга каршы актив хәрәкәтләр башлый. Утыз дүртнең бер генә көне дә тыныч үтми. Кызыл Армия, сугыша-сугыша, өйрәнә-өйрәнә, шушында оеша, шушында чыныга. Бишенче армиянең командующие итеп Славен, штаб начальнигы итеп Андерсон, элемтә начальнигы итеп Петерсон, комиссарлар итеп Лапиня, В. Межлаук кебек күренекле латыш хәрбиләре билгеләнә.

Башта армия Уңъяк Идел һәм Сулъяк Идел группаларыннан тора. Беренчесенә Дүртенче латыш полкы командиры Я. Саулит, икенчесенә элекке укытучы большевик Ян Юдин җитәкчелек итә. унберенче августта һәр ике группа һөҗүмгә күчә. Сулъяк группа Красная Горка станциясен, шул тирә авылларны ала, әмма ныгырга өлгерә алмый, аклар, көчле контратака ясап, безнекеләрне чигенергә мәҗбүр итәләр. Уникенче августтагы сугыш вакытында Ян Юдин һәлак була. Унөченче августта В. И. Ленин Совнаркомның Красная Горка тимер юл станциясен Юдино исеме белән атап, кызыл комбриг Я. А. Юдинның истәлеген мәңгеләштерү турындагы карарына кул куя. Гражданнар сугышы батырларының исемен мәңгеләштерү, шулай итеп, Татарстан җирендә латыш халкының сөекле улының исемен мәңгегә беркетеп калдыру белән башланып китә.

Кызганычка каршы, август уртасындагы һөҗүм Уңъяк Идел группасы сугышкан урыннарда да уңышсыз тәгәлләнә. Моркваш авылын яклаганда, мәсәлән, латыш халкының күп кенә батыр уллары ятып кала. Алар арасында Дүртенче полк комиссары Эдуард Петерсон, Латыш укчылары Советы башкарма комитеты председателе Юлий Заринь да була...

Ниһаять, латыш укчыларының үзләре белән танышырга да вакыт җиткәндер. Менә шуларның берсе — Биектау урманнарын белүе белән мине аптыраткан, шул урман яланында үзенә үзе кабер казыган, шулай да исән-сау килеш әле дә яшәп яткан хөрмәтле ветеран Петер Юрьевич Гришко.

Риганың борынгы тар урамнары буйлап җай гына атлыйбыз. Аларда машиналар йөрми диярлек, тыныч, ярым караңгы — ашыкмыйча гына сөйләшеп йөрергә моннан да уңай җир юктыр. Петер Юрьевичның сөйләве дә кызыклы. Латыш укчыларының Казан операциясендә катнашуы хакында язганда асылда аларның Бишен-

че армия составындагы частьлары, Уңъяк һәм Сулъяк Идел группаларындагы хәрәкәтләре тасвирлана, Икенче армия составындагы латыш укчылары телгә сирәк алына. Хәлбуки, Владимир Азин — үзе дә латыш була, ул туплаган, Вяткадан Арча якларына алып килгән отрядның беренче солдатлары да латыш укчылары булалар. Хәзер сүзне менә шуларның берсенә — Петер Юрьевичка бирик.

«Азинның разведка командасы бар иде. Күбесе — латыш атлылары, Азинның үзе кебек үк үткер, ут егетләр. Нәкъ егерме берәү идек, «очко» дип кенә йөрттеләр. Разведкага да йөрдек, атакаларга да башлап без ташландык.

Вятская Полянадан Казанга чаклы сугышып үткән арада отряд ишәйгәннән-ишәя барды, төрле частьлардан, төрле милләт кешеләреннән, аеруча шушы тирә-юньдәге татарлардан һәм башка халыклардан җыелган интернациональ семьяга әвереледек. Дошман белән бәрелешкән саен, ныгый, чыныга бардык. Курыкмаска, акларның күзенә карап ташланырга, аны хәйләләргә безне Азин үзе өйрәтте. Биектау тирәсендәге бәрелешләр бигрәк тә истә калган. Монда инде Казан өчен каты сугышларга чынлап торып әзерлек башланды. Безгә күрше Бишенче армия белән ничек тә бәйләнешкә керергә кирәк иде. Бу Азинны бик борчыды. Шул максат белән ул безне разведкага еш җибәрде, безнең белән үзе дә баргалады.

Һич онытасым юк, бервакыт шулай Казан елгасы буена киттек. Азин белән бергә алтымы-җидеме җайдак идек. Яңа гына таң атып килгән чак. Елга буйлап төшәбез дә төшәбез. Караш гел теге як ярда — күршеләрнең берәр разведчигы очрамасмы дип бару. Мавыгып, аклар позицияләренә тәмам якынайганыбызны сизми дә калганбыз. Хәер, Азин курка торганнардан түгел иде. Көтмәгәндә борын төбендә генә туп шартлады. Безнекеләр, атларын ялт борып, урман эченә сибелделәр. Бу атымны, элеккесе яраланганга, кичә генә алган идем, бактың исә, бөтенләй дары иснәмәгән булып чыкты, арт аякларына басты да, кая да атылырга белмичә, тыпырчынып бер урында тик биеп тора бит, юньсез. Сизәм, аклар якыная төшәләр. Атны берничә секунд эчендә юмалап та, ярып та карадым, әмма булмады, өмет өзелеп, өстеннән сикереп төштем дә агач арасына ташланган гына идем, атлы аклар килеп тә җиттеләр, камап та алдылар...»

...Без Даугава ярына чыгып, бетон коймага сөялгән идек. Мин Петер Юрьевичка текәлеп карадым. Аның таза, озын гәүдәсе бөрешебрәк калгандай булды, карашында нәфрәтле бер катылык чагылды. «Аклар кулына төшкән кызыл разведчикны ни көткәнен сорап төпченеп тормавың хәерле, күрсәттеләр алар миңа күрмәгәнне» ди иде төсле бу караш-кыяфәт. Шулай да мин аңардан сөйләвен үтендем.

...Разведчиктан бер сүз дә тартып ала алмагач, тирләп-пешкән, ачудан бүртенгән офицер, аягында чак басып торган егеткә күтәрелеп тә карамыйча, «мунчага!» дип кул селтәде. Димәк, атарга!

Көзнең кояшлы җылы көне иде. Күк зәп-зәңгәр, агачлар юган гөл кебек чип-чиста. Кояш нурларыннан, күк зәңгәрлегеннән күзләре чагылып киткән Петер шунда саф һава сулаудан үзенә хәл керә башлавын, хәтта күңеленең нечкәреп китүен тойды. Яңа унтугызы тулган бит әле аның. Их, аякларны хәлсез карт кебек болай өстерәмәскә, чип-чиста, сап-сары яфракларны таушатмаска иде бит әле, борыннан, яңаклардан аккан тир катыш җылы канны шушы якты кояшка, зәңгәр күккә күрсәтмәскә иде бит әле, офицер камчысыннан, тукмау, типкәләүләрдән, штык белән кадап-кадап алулардан

җәрәхәтләнеп беткән тәнне, сәләмә киемне кояштан, агачлардан яшерергә иде бит әле. Егет көчкә-көчкә бер кулы белән битен сөртергә, икенчесе белән сәләмәләрен җыярга маташты. Үзеннән-үзе адымы акрынайды. Төшке ашка соңга калмагаек дип куркып барган солдатлар сүгенергә тотындылар, берсе кинәт мылтык приклады белән аркага тондырды.

Шуннан соң егетне, култыклап алып, өстерәп диярлек тау башына алып менеп киттеләр. Бу аңа үзенә күрә янә ял булды. Урман читендәге каберләр янына китереп бастыргач, ул күзләрен ачып үз аягында тора алды.

Өч солдат урап алдылар да, кулына көрәк тоттырып: «Казы!» — диделәр. Ул казырга тотынды. Бөтен тәне, авыртуны, әрнүне оныттып, кайнарланганнан-кайнарлана башлагандыр, әлбәттә. «Кабер ич бу! Үтерәләр ич!» Каберне үзенә түгел, менә шушы дошманнарына казый диярсең, хәрәкәте кызуланганнан-кызулана бара. Йөрәге дә беркайчан да булмаганча ашыгып кага, уйлары да башны чәнчештереп кызу чаба. Менә хикмәт, бер башта ап-ачык булып, берьюлы берничә уй чаба алыр икән ләбаса. Беренчесе шул: ул якты дөнья белән саубуллаша — күз алдыннан кып-кыска гомере үтә: иң истәлекле, иң татлы көннәр генә үтә — бала чак хатирәләре, әнинең баштан сыйпавы, әтинең яратып карап беренче тапкыр заводка эшкә озатуы, туып-үскән Риганың иң мөкатдәс урыннары... Һәм шул ук вакытта ап-аек икенче уй йөгерә: яшисе килә, котыласы иде, шушы кабахәтләрне, аларның башлыкларын — хуҗаларын — эшләмичә ашаучы, ярлыларны, эшчеләрне кешегә дә күрмәүче капкорсакларны дөньядан сөреп бетерәсе иде бит! Ничек, ничек, ничек?

Солдатлар аның җәһәт эшләвен бераз карап тордылар да, бергә җыелып, тәмәке турында сөйләшә-тарткалаша башладылар. Боларда да тәмәке кайгысы икән. Безгә дә җитми тәмәке, тик безнең бит аны игә торган җирләребез дә, ясый торган завод-фабрикаларыбыз да әлегә болар кулында, безгә чит илдән дә керми. Бу мәхлуклар исә үзләре ярты дөнья малы безнең кулда дип мактанышалар, ә үзләре бер төрем тәмәке өчен тартышалар. Офицерлары алтын портсигардан хуш исле папирос кына тарта да бит, боларга — шиш. Бездә тәртип икенче — папиросны солдатларга Азин үзе позициягә илттертә, үзе өләшә.

Менә тегеләр ничек тә өчесенә бер тәмәке әмәлләделәр. Петер, алар ягына борылып, казуын дәвам итте. Шул чак солдатларның берсе мылтыгын икенчесенә тоттырды, өченчесенең кесәдән шырпы алганын көтә башлады. Чү, хәзер икәүләшеп, кабызачаклар, өченчесенең дә кулы буш түгел... Петя, көч тап, аң бул! Сугышып үлүгә ни җитә, ә бәлки...

Ике солдат башка-баш диярлек иелделәр. Шул мәлдә Петер, ялт кына турайды да, көрәге белән селтәнеп торып тегеләрнең баш турысына бөтен көченә тондырды, үзе, аткан таш кебек, агачлык ягына сикерде. Ул берни күрмәде, берни тоймады, агачларга бәрелде, куакларга буталды, әмма очты гына. Башта кычкыру, аннан мылтык тавышы колагын ярды, әмма ул сискәнмәде, чүкмәде — очты да очты гына! Сәләмәләре эләгеп, бөтенләй киемсез калды, тәннәре умырылып, каннары акты, әмма ул очты...

...«Бишенче, Икенче Кызыл Армияләрнең һәм Идел хәрби флотилиясенең һөҗүм операцияләре зур уңыш китерде. Унынчы сентябрьдә Идел флотилиясе Яңа татар бистәсе янында десант төшерде... Бу районны алып, ул шәһәргә һөҗүм башлады. Бер үк вакытта Бишенче армиянең Сулъяк Идел группасы да һөҗүмгә күчте. Ул дошман уты астында Казан елгасын уңышлы кичүгә ирешге. Казанга беренче булып көнчыгыштан һәм көньяктан Бишенче армия полклары

белән Идел хәрби флотилиясе моряклары, ә төньяктан В. М. Азин отрядлары бәреп керде. Уынчы сентябрьдә көндезге сәгать бердә Казан тәмам азат ителде» диелә тарих китапларында.

Казанга беренче булып аяк баскан азинчылар — отрядның кыю егетләре — атлы разведчиклар. Алар арасында — Петер Гришко да була.

Казанны дошман кулыннан тартып алу Көнчыгыш фронтта хәлне кискен яхшырта. Владимир Ильич Ленин бу хакта: «Казанны алу бөтен рус революциясе өчен безнең армиянең кәефе тамырдан үзгәрү, аның нык, ышанычлы, җиңүчән хәрәкәт итә башлауга күчүе белән әһәмияте бик зур», дип билгеләде. Ә «Правда» газетасы: «Казанны алу — Кызыл Армиянең беренче чын-чыннан олы җиңүе. Чехословак фронтындагы моңарчыгы җиңүләр очраклы бәрелешләрдә азмы-күпме очраклы җиңүләр иде. Биредә Кызыл Армия сугышырга өйрәнде; биредә алдан ук бер бурыч куелды һәм ул хәл ителде; биредә Армия беренче мәртәбә җиңәргә өйрәнде», дип язды.

Бу юлы менә көз башында ук Казанда бурап-бурап кар яуды. «Латыш укчылары» урамы ап-ак иде. Рига искә төште. Петер Юрьевичның ап-ак кар көнҗәләләре сарган куе чыршылар астындагы җылы өендә утырган сәгатьләр күз алдыннан үтте. Ә бит анда мин Татарстанны, Казанны уйлап утырган идем. Чөнки сәбәбе чыкты: мин премьера шаһиты булдым, әйе, әле беркайчан да күрсәтелмәгән кинофильмны беренче булып карадым. Петер Юрьевич һәвәскәр киночы икән. Җәй көне ул Латвиянең тарих укытучылары белән Татарстан буйлап гражданнар сугышы каһарманнары эзеннән, ягъни үзенең яшьлек эзләреннән сәяхәттә булган, шунда кино төшергән. Бүген без, беренче тамашачы буларак, кызыксынып һәм дулкынланып, шуны карадык. Дулкынландык, чөнки авторы, үзе үк латыш укчысы, үзенең үк данлы яшьлегенә кайта алган иде. Дулкынландык, чөнки Татарстаннан шактый ерактагы Даугава ярында, чал Риганың тыныч бер бистәсендә күз алдыннан Юдино, Биектау урманнары, чал Казанның тарихи урыннары, Себер тракты узды... Һәм менә шушы Латыш укчылары урамы үтеп китте. Рәхәт минутлар иде ул.

Бүген исә монда Рига искә төште. Шул ук сәбәп, шулай ук — кино. Әле генә Мәскәүдән, үзәк телевидениедән «Безнең биография» дигән күп серияле фильмның «1918 ел» өлешен карадык. Анда латыш укчыларының батырлыгы тагын бер мәртәбә зурлап, хөрмәтләп телгә алынды. Риганы, латыш укчыларына мемориаль истәлек-музейны, «революция рыцарьларының» горур сынын күрсәттеләр. Һәм шулар фонында, кем дисез, Петер Юрьевич басып тора иде. Дәһшәтле унсигезенчене, революция хакына, киләчәк хакына эшләнгән чиксез фидакарьлекне тагын бер кат искә төшереп, чал ветеран күңелләрдә яңа горурлык хисләре уятты.

Исән-сау алар — латыш укчылары. Мәңгелек каһарманлык турында безгә, киләчәк буыннарга алар үзләре дә сөйли, алар исеменнән архив документлары, музей экспонатлары, таш сыннар һәм менә шәһәр урамнары да сөйли.

Казан — Мәскәү — Рига — Казан.
1975—1976.

# «ФИКЕРЛӘРЕМ КИТАПЛАРЫМДА...»

Гариф ага белән очрашканда, миңа аның үз иҗаты турындагы фикерләрен сорарга туры килгәне бар. Ул бераз елмая төшеп: «Бөтен фикерләрем китапларымда», — дип җавап бирде.

Г. Гобәй балалар әдәбиятына утызынчы елларның беренче яртысында килә. Ул елларда авылда социализм дошманнары — кулак-корткычларга каршы авыр көрәш бара. Бу көрәштә совет пионерлары да әти-әниләренә зур булышлык итәләр. Герой пионерлар турында газета-журнал битләрендә дә еш язылып тора. Чорның героик көрәнешләре балалар язучыларын да тирән дулкынландыра — әдәбиятта батырлык тенденциясе, социалистик милекне сакларга чакыру мотивлары көчәя. Г. Гобәй беренче повесте «Каланча» (1934) белән үк менә шушы гомуми агымга килеп кушыла һәм шуннан соң батырлык аның иҗатында үзәк проблемага әйләнә.

Г. Гобәй әсәрләрендә илебез тарихы, героик көрәш этаплары ачыла. Бу яктан ул танылган рус балалар язучысы А. Гайдарны хәтерләтә. «Каланча» повестенда Г. Гобәй совет пионерының батыр образын сыйнфый көрәшнең кызган учагы — авыл тормышыннан алып сурәтли, социалистик милекне саклау идеясен күтәрә. Кечкенәләр өчен генә түгел, зурлар өчен дә шомлы булган караңгы бер төндә, күк күкрәп, көчле яңгыр килгәндә, Сәлим ялгызы колхоз кырыннан башак урлаучы караклар белән күзгә-күз очраша. Сәлим уйга кала: «Әгәр боларны колхозга алып кайтмасам, әтинең исерек икәнен белми калачаклар. Башакны шалашка илтеп куйсыннар да үз юлларына китә бирсеннәр. Әти колхозга кайткач, әйтер, тота алмадым, ташлап качтылар, диярШуның белән эш тә бетәр... ләкин пионерларча буламы соң бу?» Совет мәктәбендә тәрбияләнгән пионер үзенең эчке каршылыкларын җиңеп чыга, каракларны колхоз идарәсенә алып кайта.

Яшь авторның бала образын иҗат итүдә кайбер кыенлыклар кичерүе дә бу әсәрдә әле сизелеп тора. Сәлим олыларча сөйли. Баланы олылардан өстен, һәр урында башлап йөрүче итеп бирү, ягъни бала авангардлыгы тенденциясе әсәрнең ышандыру көчен азмы-күпме киметә.

Иҗат кешесе эзләнүләрен гомере буе дәвам итә, диләр. Шулай да Г. Гобәй үз стилен тиз таба. Икенче повесте «Маякчы кызы»нда (1938 ел) ул гражданнар сугышы вакыйгаларына мөрәҗәгать итә һәм әлеге кимчелекләреннән тулысынча дип әйтерлек арына. Утызынчы елларның урталарында Европада фашизм куркынычы көчәйгән, әдәбиятта Кызыл Армия, Туган ил темалары үзенә бер куәт белән яңгырый башлаган чорда «Маякчы кызы»ның басылып чыгуы Г. Гобәй иҗаты өчен генә түгел, татар балалар әдәбияты өчен дә зур вакыйга була. Язучы бу әсәрендә балалар психологиясен тирән аңлап эш итә. Анда тарихи вакыйгалар да ышандырырлык итеп гәүдәләндерелгән. Әдәби тәнкыйть күзенә дә Г. Гобәй беренче мәртәбә шушы повесте белән чалына. Матбугат битләрендә әсәрне уңай яктан бәяләгән рецензияләр басыла, автор укучылардан күп санлы соклану хатлары ала.

«Маякчы кызы»н язганда инде Г. Гобәй шактый тормыш тәҗрибәсе туплап өлгергән була. 1927—1930 нчы елларда ул Казан рабфагында укый. 1936 елны Казан дәүләт педагогия институтын тәмамлый. 1937 елда Язучылар союзына член итеп алына.



Гражданнар сугышы турында бай материал җыя. Агыйдел буйларында, сугыш барган урыннарда була.

Гражданнар сугышы һәм балалар. Бу теманы әдәбиятта ничек яктыртырга? Шул яктан язучыга А. Гайдарның «РВС», «Мәктәп», һ. Такташның «Караборынның дусты» әсәрләре ачкыч бирәләр. Г. Гобәй повестьта гражданнар сугышының ике сыйныф арасында яшәү яки үлем өчен барган канлы көрәш булуын күрсәтүгә нык басым ясый. Повестьның үзәгендә гражданнар сугышы вакыйгалары эчендә чыныккан кыз Илсөяр образы. Балалар образын иҗат итүдә Г. Гобәй А. Гайдар һәм һ. Такташлар юлыннан бара. Илсөяргә яше күтәрә алмаслык эшләр йөкләми ул, аны өлкәннәрнең героик көрәшендә булышчы итеп кенә куя. Илсөярдәге матур сыйфатлар — сер саклау, уяулык, кыюлык авыр тормыш мәктәбе үткән Мәрдән абзый, Бикмуш бабай, Андрей дәдә һәм партизаннар командиры Костинның тәрбияви йогынтысы астында формалаша. Маякчы кызы аңлы рәвештә зур көрәштә катнашу югарылыгына күтәрелә. Гражданнар сугышы еллары Илсөяр кебек күп кенә ярлы балаларында революцион аң тәрбияли, яңа кешеләр үстерә.

Илсөяр шул ук вакытта балаларча һәрнәрсә белән чын күңелдән кызыксына, әтисен һәм бабасын беркатлы сораулары белән интектереп бетерә. Агыйделнең кая коюын да, диңгезнең ни өчен зур булуын да, акларның кайдан килеп чыгуларын да, яхшы кешеләрнең кемнәр булуларын да — һәммәсен беләсе килә аның.

Повесть ифрат җылы тел белән лирик тонда язылган, андагы пейзажлар оста рәссам кулы белән эшләнгән гүзәл, лирик картиналарны күз алдына китерә. Вакыйга 1918 нче елларда Агыйдел буйларында бара. Табигать әсәрдә төп геройның эчке дөньясын баету чарасы булып, вакыйгаларга үзенең мөнәсәбәтен белдереп баручы актив көчкә әйләнә. Агыйдел буйларының ямьлелеге Илсөярнең күңелен күтәрә. Кызның батырлыгы да туган ягын яратудан, аны явыз кешеләрдән таптатырга теләмәүдән килеп чыга.

Утызынчы елларның икенче яртысында күтәрелгән фашизм куркынычы Г. Гобәй иҗатына тирән эз сала. Шушы чорда хәрби-патриотик тема өстендә иң нәтиҗәле эшләгән язучыларыбызның берсе иде ул. «Маякчы кызы»ннан башка аның тагын «Ялгыз йортта», «Аклар лагеренда», «Өч бөркет», «Без әле очрашырбыз» исемле повесть, хикәя, пьесалары басыла.

Сугыштан соңгы елларда Г. Гобәйгә героик характерлар иҗат итү өчен Ватан сугышы вакыйгалары бай материал бирде. 1949 елда аның «Замана балалары» дөнья күрә. Шуннан бирле бу темага күп кенә әсәрләр язылды, патриотик тәрбия балалар әдәбиятының традицион темасына әйләнде. Яшьләрне хәрби-патриотик рухта тәрбияләүнең мөһимлеге турында язучылар съездында, балалар әдәбиятына багышланган киңәшмәләрдә кат-кат басым ясап узылды. Бу җәһәттән әле бүген дә әдәбиятыбызда «Замана балалары» аерым урын тота. Хәлимне Володя Дубинин, Гуля Королева, Марат Казей, Леня Голиков кебек герой пионерларның татар балалар әдәбиятындагы иң зур вәкиле дип әйтергә мөмкин.

Г. Гобәй ул дәһшәтле елларның драматизмы һәм героизмын берлектә күрсәтергә омтыла. Сугышның иң кызган чагы. Фашист Сталинградка ыргыла. Колхозда атлар, кеше көчләре җитешми, фронтны икмәк белән тәэмин итү, ай-һай, кыен була колхозчыларга. Хәлимгә дә фронтта немец шпионын фаш итү җиңел генә бирелми. Әсәрдән аңлашылганча, совет кешеләренең фашизмны җиңеп чыгу сәбәпләре фронт белән тылның тыгыз бәйләнешендә, өлкәннәр һәм кечкенәләрнең тырыш хезмәтендә, батырлыгында һәм дошманга зур нәфрәтендә.

Бу повестьта инде Г. Гобәйнең хикәяләү, образлар иҗат итү алымнары тагы да

камилрәк. Аның стиленә ашыкмыйча тәфсилләп хикәяләү хас. Хикәяләүдә ул реалистик күренешләр белән янәшә маҗаралардан, гадәттән тыш хәлләрдән, очраклыклардан иркен файдалана. Әкият элементларының килеп керүе дә әсәрләренең романтик рухын көчәйтә генә. Гомумән, Г. Гобәйдә сюжет күп очракта киеренке вакыйгалардан төзелә.

Г. Гобәй урта яшьтәге мәктәп балалары өчен яза, һәр әсәренең үзәгендә бала образы. Әдипкә балада характер формалашу процессын оста чагылдыру хас. Ул үзәк геройның уңай сыйфатларын бераз күпертебрәк бирергә ярата, ләкин бу нәрсә һич кенә дә образның ышандыру көчен киметми, чөнки геройның һәрбер хәрәкәте төрле яклап нигезләнгән, дәлилләнгән була. Язучыны бигрәк максатына ирешүдә нык торучан, көчле ихтыярлы балалар кызыксындыра, аның кечкенә геройлары нәкъ менә үзләренең романтик күтәренкелекләре, тормышка оптимистик карашлары белән дә укучыны яраттыралар инде. Әдип үрнәк образ иҗат итү һәм киң масса укучыларын шул уңай үрнәк тәэсирендә тәрбияләү юлыннан бара.

«Замана балалары»нда Хәлим күп яклары белән классташларыннан өстен. Ул яхшы укый, күп белә. Иптәшләренә караганда физик яктан да көчлерәк. Хәрби комиссариатка каралырга килгәч, доктор: «Гәүдәгә әйбәт бит, пәһлеван була бу бер дүрт елдан»,— дип сокланып карый аңарга. Хәлимнең һәр сүзендә, һәр җөмләсендә үз көченә ышанучан кешеләрдә генә була торган оптимистик рух бар: «Мин синең өчен үч алырмын әле, абый, бик тә каты итеп, Гитлерның күзләре акаеп чыгарлык итеп алырмын үчне». Малайның сөйләме баштан ахырга кадәр шундый күтәренке тонда бара. Бу исә аңардагы эчке көчнең бетмәс-төкәнмәс икәнлеге турында сөйли.

Г. Гобәй иҗаты гуманистик образларга бай. «Ялгыз йортта» (1939) повестенда киң күңелле эчкерсез Мортаза бабай, аның оныгы Таҗи, «Маякчы кызы»нда Мәрдән абзый, Бикмуш бабай. Хәер, саный китсәң, андый образларны һәрбер әсәреннән табарга була. Г. Гобәйдә гуманизм илебез тарихындагы киеренке этаплар, совет кешеләренең бер-берсенә туганнарча ярдәме икеләтә көчлерәк кирәк булган чорларга туры китереп чагылдырыла.

«Маратның язмышы» (1956) повестенда, мәсәлән, Ленинград камалыш хәлендә. Татарстан делегаты Гөлсем апа ятим калган сабый Маратны бомбалар төшеп, ярылып торган вакытта камалыштан алып чыга, үзе белән Казанга алып кайта. Әлбәттә, сабыйны ул шәһәрдәге берәр балалар йортына урнаштыра алган булыр иде, ләкин алай эшләми. Үзенең ике баласы һәм тормышы авыр булуга да карамастан, сабыйны уллыкка ала. Гөлсем апаны моңа беркем дә мәҗбүр итми, бу изге эшне ул йөрәге кушуы буенча эшли. Менә шунда совет кешеләренә хас булган киң күңеллелек, авыр минутларда бер-берсе өчен кайгыртучанлык сыйфатлары ачыла. Монда геройлыкның мораль-этик ягы алгы планга чыга.

Г. Гобәй повестьларының бер үзенчәлеге: алар күп планлы, киң масштаблы. 1968 елда басылып чыккан «Сайланма әсәрләр»енә язган сүз башында Г. Иделленең Г. Гобәй повестьларын җыйнак кына романнар белән тиңләвендә хаклык юк түгел. «Маратның язмышы» повестенда да бала язмышы, кешелеклелек идеясе, Ватан сугышы елларында тылда калган хатын-кызларның героизмы, тәрбия мәсьәләләре Гөлсем апа образында бер ноктага җыела.

Г. Гобәй, гомумән, үзенең әсәрләрендә балалар образын гына түгел, зурларны да тулы канлы итеп бирергә, өлкәннәрнең кечкенәләргә рухи йогынтысын күрсәтергә тырыша. Менә шул күзлектән Гөлсем апа язучының аеруча матур эшләнгән образларыннан берсе.

Заман сулышын тоеп иҗат иткән язучы Г. Гобәйгә яңа гына булып узган зур тарихи вакыйгаларга үзенең мөнәсәбәтен белдерә бару хас. Югарыда искә алынган повестьлар шул турыда сөйли. 1963 елда чыккан «Без үскәндә» повестенда исә ул Октябрьгә кадәрге ерак үткәннәргә — үзенең бала чакларына әйләнеп кайта.

Г. Гобәй — тормыш төбеннән күтәрелгән, фәкать данлы Октябрь нәтиҗәсендә генә бәхетле язмышка ирешкән язучы. Ул 1907 елның 26 августында Казан шәһәрендә вак кустарь гаиләсендә туа. «Тәрәзә тиентен җиргә сеңгән кыйшык-мыйшык кечкенә генә

куыш. Тору да, эш тә шунда. Тыгыз. Бау тузаны. Бөтен гаиләбез белән көне-төне эшләсәк тә, ачлы-туклы, мохтаҗлыкта торырга туры килде», — ди әдип, балалык елларын хәтерләп. Язучы әлеге повестенда иң элек үткәндәге ямьсез тормышны бүгенге бәхетле яшь буын белән уртаклашу ниятен күздә тотса, ерак үткәнгә китүнең икенче сәбәбе дә бар. Әйтик, Ватан сугышында явыз фашизмны җиңеп чыгу туган илебезнең дөньякүләм авторитетын, совет кешеләренең горурлыгын көчәйтте. Бездә хәзер бүгенге бөек эшләрнең ерактан килә торган тамырларын эзләүгә, әдәбиятта үткәндәге матур гореф-гадәтләргә, йолаларга, әти-бабаларыбызның хезмәт һәм көрәш традицияләренә ихтирам артты. М. Горький сүзләре белән әйтсәк, «бүгенгене дөрес бәяләр өчен үткәнне яхшы белергә кирәк».

Язучының тормыш юлы белән зур уртаклык булса да, «Без үскәндә» автобиографик әсәр түгел. Әсәр кечкенә Гарәфетдин язмышы аша Казан шәһәренең бер почмагы — Бистә эшчеләрендә, вак кустарьларда революцион аң уянуын, революциягә хәзерлек елларын, аларны сыйнфый көрәшкә китергән сәбәпләрне сурәтли. Ярлы малае Гарәфетдиннең үсеш эволюциясе чорның иҗтимагый каршылыклары белән тыгыз бәйләнештә яктыртыла. Үзенең халыкка хезмәтен, диндарлар кыйнап имгәткән хәлфә абыйсы Рәхимҗанны кызганып, аңа бер сынык икмәк кисәге алып килүдән башлаган Гарәфетдин әсәрдә көрәшче булу, пролетариат алдында торган бурычларны аңлау югарылыгына күтәрелә. Икенче китапның эпиграфы итеп бер дә юкка гына Г. Тукайның:

> **Әйдә халыкка хезмәткә,**
> **Хезмәт эчендә йөзмәккә,—**

дигән сүзләре алынмаган. Гарәфетдин инде бу сүзләрне үзенең яшәү максаты итеп аңлау дәрәҗәсенә күтәрелә. Өлкән абыйлары листовкалар баскан чакта, коеп яуган яңгыр астында сакта тору, моны полицейскийлар белеп алгач, басу машинасын караңгы төндә дусты Клим белән бергә каберлеккә илтеп яшерү, листовкаларны кирәкле урыннарга илтеп тапшыру — болар барысы да малайны әкрен-әкрен ныгыта килә.

Повестьта көнкүреш һәм иҗтимагый хәлләр үзара үрелеп бара. Бер-берсенә дошман булган ике сыйныф вәкилләрен, революцион көрәш юлына аяк баскан империалистик сугыш инвалиды Сәхәбетдин һәм Рәхимҗан хәлфәләрне, көяз Алафузов һәм Кәрәмәтулла муллаларны автор үзенең әсәрендә үзара тыгыз мөнәсәбәткә кертә.

Повесть юморга бай. Дөрес, Г. Гобәйнең бу сәләте «Ялгыз йортта» повестенда Таҗи образында ук күренә башлый. Ә инде «Без үскәндә» повестенда әдипнең юморга сәләте бигрәк тә мул булып ачыла. Ул тормышның күңелле күренешләрен генә түгел, аерым драматик хәлләрне дә юмор белән оста гәүдәләндерә белә. Кечкенә Гарәфетдин — бераз гына хәйләкәр, бераз гына мактанчык, үткен, җор телле, тормышның авыр минутларын уен-көлке белән уздырып җибәрә алучы шаян малай. Кечкенә герое белән үз итеп, шаяртыбрак сөйләшү, гомумән, образы тормыштагыча табигый итеп бирүдә бер адым булып тора. Г. Гобәй әсәрләре гадәттә башыннан алып соңгы битләренә кадәр йөгерек, шома тел белән язылган була, үзенең фикерләрен укучыга җиткерүдә автор халык тапкырлыгын оста итеп эшкә җигә белә.

«Без үскәндә» — сыйнфый каршылыкларны тирән һәм реалистик яктырткан тарихи-революцион әсәрләрнең берсе. Сыйнфый көрәшкә мөнәсәбәттә бала образын нichек сурәтләргә кирәк булса — әсәр шуның матур үрнәген бирдә. Татар балалар әдәбиятында тарихи-революцион тема шушы повестьтан соң киңрәк яктыртыла башлады. Г. Бакировның «Утлы тегермән», Л. Ихсанованың «Очкын», «Гөлләр кояшка карый» h. б. әсәрләр шул турыда сөйли.

Тарихка күз ташласак, шуны күрәбез: әти-әниләрен, абый-апаларын борчыган социаль-иҗтимагый хәлләрдән балалар бер дәвердә дә читтә калмаганнар. Бу күренеш әдәбиятта да чагылып килгән. В. Гюгоның «Хокуксызлар» романындагы Гаврош Париж коммунасы көннәрендә баррикада сугышларында катнаша. Тормыш һәм балалар, күрүебезчә, Г. Гобәй әсәрләрендә үзенең тулы этаплы чагылышын тапты. Г. Тукай, Г. Ибраһимов һәм һ. Такташлардан килә торган аерым тәҗрибәләрне ул ныклы традициягә әйләндерде. Кыскасы, аның повестьлары, асылда, иҗтимагый конфликтларга корылган.

Алтмышынчы елларда әдип иҗатына яңа геройлар, яңа конфликтлар килеп керә. Сугышка кадәр Г. Гобәй балалар йортында тәрбияче булып эшли. Шул вакыттагы күзәтүләре нигезендә әсәр язу теләге аның уенда озак еллар йөри, күзәтүләрен еллар дәвамында эшкәртә, гомумиләштерә, яңа материаллар белән тулыландыра. Ниһаять, 1961 елда мораль-этик тема күтәргән «Ләйсән яңгыр» повесте дөньяга чыга. Повестьта кеше язмышының иң җаваплы вакытларыннан — балалыктан үсмерлеккә күчү чоры алына. Шушы хәлиткеч чорда гаилә, тышкы тирәлек һәм мәктәпнең шәхес язмышында тоткан урыны яктыртыла. Әлеге өч буынның берсе тарафыннан аз гына ялгышлык җибәрелсә дә, бала язмышында фаҗига килеп чыгарга мөмкин.

Әлегә кадәр Г. Гобәйнең иҗади сәләте күбрәк уңай образлар иҗат итүдә күренгән иде. Бу әсәрдә ул тискәре образлар тудыруда да көчле буяулар таба. Хәррәмов аферистны куңел кайтаргыч итеп сурәтли. Повестьта Гүзәлнең дөрес юлдан тайпылуы да үги әтисе булган шушы Хәррәмовның йомышларын үтәүдән — бер төргәк дәфтәрне мәктәпкә алып барып кыйммәт бәягә сатудан башлана. Соңыннан кыз, үзе дә сизмәстән, азгынлыкта йөрүче яшьләр шайкасына ияреп китә. Ләкин шушы кыз бераздан суд алдына басып аферистны фаш итәрлек шәхес булып үсеп җитә, бу исә, автор тарафыннан, совет мәктәбенең тәрбияви көче белән бәйләп күрсәтелә. Әсәрдә һөнәр мәктәбе Гүзәл һәм Җиһангир кебек яшьләрне мораль яктан савыктыручы ләйсән яңгыр итеп карала.

Алтмышынчы еллар әдәбиятында геройларның эчке дөньясына бермә-бер игътибар артты. «Ләйсән яңгыр» — татар балалар әдәбиятында шуның уңышлы мисалы. Повестьта Гүзәлнең үзенә хас эчке дөньясы ачыла, ул тәрбия объекты гына түгел, үзендәге кимчелекләр белән дә көрәшергә сәләтле кыз. Әсәрдә Г. Гобәй рухи конфликтка зур урын бирә. Гүзәл өзлексез үзе эшләгән ялгышлары өчен курку һәм борчылу, үкенү һәм тынычсызлану, икеләнү һм тетрәнү хәлендә яши. Аның башкалар шикелле намуслы, яхшы кеше булып үсәсе килә.

Баланың үз кимчелекләре белән үзенең көрәшен әдәбиятта тасвирлап бирүнең тәрбияви әһәмияте дә зур. Андый геройлар укучыны намусың өчен, бәхетең өчен иң элек үзең көрәшергә кирәк икән дигән нәтиҗәгә китерә.

Иске мәдрәсә тәрбиясе алган Г. Гобәй утызынчы еллардан бирле яшь буын алдында исламның реакцион ролен ачуны үзенең төп бурычы итеп саный. Руханиларның динне хезмәт ияләрен изү коралы итеп файдалануларын «Маякчы кызы» повестенда Мәрдән абзый белән Варвара тутәй язмышында ук күңелне тетрәтерлек күренешләрдә фаш итәлә. Дини аермалыкларга каршы чыгып, ул халыклар дуслыгы мәсьәләсен күтәреп чыга. Андрей дәдә, Мәрдән абзый, Бикмуш бабай, партизаннар командиры Костин — болар бары да азатлык өчен көрәштә уртак теләкләр белән берләшкәннәр.

«Без үскәндә» повестенда бу мәсьәләгә аерым бүлекләр багышланган. Ислам диненең чын асылын бүгенге укучыга тагын да җентекләбрәк төшендерү өчен Г. Гобәй 1967 елда «Корьән серләре» исемле махсус зур китап бастырып чыгарды.

Г. Гобәй моңа кадәр үзенең каләм көчен хикәя, драма, повесть жанрларында сынап карап, татар балалар әдәбиятында масштаблы повестьлар остасы булып танылган иде. «Корьән серләре»ндә ул яңа ягы белән ачылып китте. Бу әсәр аның иҗатында яңа жанр. Әсәр тәгәлләнгән бер бөтен сюжет-композициягә корылмаган, аны атеистик публицистика дип атарга мөмкин. Ләкин ул кызыклы, җанлы публицистика.

Бер әсәр дә тәрҗемә итмәгән кеше чын язучы була алмый, диләр. Тәрҗемә — Г. Гобәй иҗади эшчәнлегенең икенче тармагы. Ул балалар әдәбиятына да рус әдиб Серебряковка ияреп язылган «Көмеш канат» хикәясе белән килеп керә, тәрҗемәне үз өчен зарури эш, әдәби осталыкка өйрәнү мәктәбе итеп саный. Сугыш елларында фа шизмга каршы сатирик хикәяләр, сугыш кырларында һәлак булган герой пионерла турындагы очерклар тәрҗемә итеп, «Сукбай армия», «Яшь патриотлар» исемле җыен тыклар чыгара. «Гали баба һәм кырык карак», «Мең дә бер кичә» исемле гарәп халы әкиятләрен, В. Катаевның «Полк улы», С. А. Ковпакның «Путивльдән Карпатка кадәр Е. Н. Кошеваяның «Улым турында хикәя», А. Мусатовның «Бәхет орлыклары», Б. Сто

ның «Том агай алачыгы», А. Первенцовның «Намуслы яшьлек», Б. Полевойның «Чын кеше», М. Твенның «Том Сойер маҗаралары» әсәрләрен без Г. Гобәй тәрҗемәсендә укыйбыз.

Әйе, Г. Гобәй — олы һәм нәтиҗәле иҗат юлы үткән бәхетле әдип. Әгәр аңа көннәрдән бер көнне үткән гомер юлына борылып карап, үз-үзенә: «Мин кешеләр өчен нинди файдалы эш эшләдем?» дип сорау куярга туры килсә, борчылырлык урын юк. Аңарга шул ук вакытта зур иҗтимагый активлык хас.

Ул 1946 елдан бирле профессиональ язучы, озак еллар буена Язучылар союзының партоешма секретаре булып эшли, 1950—1953 нче елларда Татарстан Язучылар союзы председателе. Г. Гобәй утызынчы еллардан алып бүгенгә кадәр балалар әдәбияты секциясе эшендә актив катнашып килә. Бу дәвердә ул күпме яшь каләмнәргә әдәбиятның олы юлына чыгу өчен фатыйха биргән, үзенең иҗади тәҗрибәсе белән күпме ярдәм иткән!

Кайвакытта шулай була: әсәрне үз вакытында укучы кабул да иткән кебек, яратып та укый кебек. Әмма озак та үтми, әсәр онытыла. Г. Гобәй повестьлары искермиләр. Алар һаман безнең белән бер сафта, магистраль юлда, әдәби уку программаларында урын алып киләләр. Әдипнең әледән-әле «Сайланма әсәрләр»е чыгып тора. «Маякчы кызы»ның, мәсәлән, 7 басмасы, әле күптән түгел дөнья күргән «Корьән серләре»нең дә 3 басмасы бар инде. Г. Гобәй әсәрләре татар балалар әдәбиятының гына түгел, гомумсоюз балалар әдәбиятының уртак хәзинәсенә керделәр. «Маякчы кызы», «Ләйсән яңгыр», «Замана балалары», «Без үскәндә» русчага, «Замана балалары», «Маратның язмышы» уйгырчага һәм казакъчага тәрҗемә ителделәр.

Татар балалар әдәбиятын үстерүдәге хезмәтләренә югары бәя биреп, хөкүмәтебез аны ике мәртәбә Хезмәт Кызыл Байрак ордены һәм «Почет билгесе» ордены белән бүләкләде.

Гариф агага бу изге эшендә киләчәктә дә зур уңышлар, ныклы сәламәтлек, озын гомер телибез.

**ФАТЫЙМА ИБРАҺИМОВА.**

Тәуфикъ Әйди

# БЫЛБЫЛЛАР САЙРАТУЧЫ

**1958** елда Мәскәүдә казакъ әдәбияты һәм сәнгатенең икенче декадасы бара. Урамнарда Казагыстанның дәүләт гимны яңгырый. Зур театр сәхнәсендә «Абай» операсы куела. Башкалага килгән үзешчән артистлар «Алтын бодай», «Ватаным», «Мәскәүгә сәлам» җырларын җырлый. Кызлар хореографик ансамбле «Казакъ вальсы»н бии. Бибигөл Түләгәнева, Кормангазы исемендәге халык кораллары оркестрына кушылып, «Былбыл» җырын башкара. Алкышлар, алкышлар! Башкала җәмәгатьчелеге ул әсәрләрнең авторын — очкын карашлы, озынча йөзле, житез хәрәкәтле сөйкемле бу кешене «Егет икәнсез, Хәмиди!», «Былбыл»ыгыз искиткеч!», «һәр жанрда да иҗатыгыз былбыллар сайравына тиң!» дип күтәреп ала. Таләпчән Мәскәү тамашачылары аңа ихлас күңелдән кул чаба, күренекле композиторлар Казагыстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Латыйф Хәмиди әсәрләренә югары бәя бирә. Хөкүмәтебез композиторны икенче Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкли.

Хәзерге Татарстанның Апас районы Бүәле авылы крестьяны Габделхәй, җан асрауны кайгыртудан башы чыкмавына туеп, Донбасста шахтер, Кавказ заводларында тимерче булып эшләгәндә һәм, ниһаять, 1913 елда хәзерге Үзбәкстанның Кәттә Курган шәһәренә килеп урнашканда улы Латыйф шушындый дәрәҗәләргә ирешер дип уена да китерә алмагандыр. Бүәленең яшел чирәмендә аунап үскән, татар халык җырларының үзәк өзгеч моңына сихерләнгән малайның киләчәктә кем буласын күзаллау шактый читен була. Дөрес, ул зирәклеген бик иртә күрсәтә, кечкенәдән үк агасы Кәлимулладан укырга-язарга өйрәнә, Кәттә Курган мәдрәсәсенә аны турыдан-туры икенче класска алалар. Әмма, чәчәккә бөреләнеп тә җимеш бирә алмый калган үсемлек кебек, якты киләчәктән мәхрүм ителгән татар малайлары аз булганмыни ул чакта?!

Бәхеткә каршы, Латыйф иҗтимагый тормышта яңа дулкыннар күтәрелгәндә, саф җилләр исә башлаганда — 1906 елның 17 июлендә туа. Революцион хәрәкәт тәэсире Кәттә Курганга да килеп җитә. Зариф Кадыйровның җәдит мәктәбендә җыр дәресе гамәлгә кертелә. 1916 елда укыта башлаган Гыймат Тимербулатовның музыкага һәвәслек уятырга тырышуы шәкертләрнең сәнгать белән кызыксынуын тагын да көчәйтә. Латыйф аңардан мандолинада уйнарга өйрәнә, үзешчән түгәрәктә хор белән «Тәфтиләү», «Кара урман», «Зиләйлүк»ләрне җырлыйлар.

Революциядән соң Гыймат Тимербулатов шәһәр мәгариф бүлеге мөдире итеп билгеләнә. Аның инициативасы белән Кәттә Курганда балалар музыка мәктәбе ачыла. Латыйф шунда башта фортепьяно, соңрак скрипка классында өч ел укый.

1920 елда ул Ташкент татар мәгариф институтына (соңыннан азчылык милләтләр мәгариф институты) керә. Студентлар арасында сәләтле кешеләр шактый була. Скрипкачы Каюм Байбуров (ул соңыннан СССР Зур театры оркестрында уйный) композитор һәм пианиночы Исхак Хәмзин, гитарачы Сәлих Сәлихов, мандолина һәм гармунда уйнаучы Ибраһим Мөхтәров һәм башка татарлар да шунда укый. Институтта хор, сынлы сәнгать, драма, әдәбият түгәрәкләре эшли.



20нче елларда татар мәгариф институты (ул Белем йорты дип тә йөртелә) Ташкентта яшәүче татарларның мәдәни үзәге буларак танылa. Аның директоры Габдулла Биги югары культуралы, укымышлы кеше була. Монда татар теле һәм әдәбиятын Нигъмәт Хәкими, Габдрахман Сәгъдиләр укыта. Укучылар әдәби кичәләр, диспутларда катнашырга һәвәсләндерелә. Шигырь-хикәяләр, рефератлар язу, кульязма газета-журналлар чыгару, спектакльләр кую гадәти нәрсәгә әйләнә. Әдәби кичәләрдә Гыйбад Алпаров, Һади Такташ, Зариф Бәшири, 1921 елда Кәрим Тинчурин, Фатыйма Ильская, Мәрьям Сульва, гастрольгә килгән вакытларында Газиз Әлмөхәммәтов, Солтан Габәши һәм башка сәнгать эшлекләләре йөри. Пушкин, Гоголь, Лермонтов урамнары чатындагы Белем йорты кырмыска оясы кебек кайнап тора. Киләчәктә үзбәк совет матбугатында җигелеп эшләячәк Шәриф Булат, шәрык хатын-кызлары арасыннан «Правда»ның беренче үз хәбәрчесе булачак Әминә Абдуллина, ябык гәүдәле, иякләреннән бала йон төртеп чыгып килгән аксыл чырайлы Латыйф Хәмидиләр Ташкентның хозур урамнарындагы арык буйларыннан атлый-атлый, өрек агачлары төбенә утырып хәл ала-ала, үзләренең беренче мәкалә, шигырь, нәсерләрен иҗат итәләр һәм бергәләшеп «Кызыл укучы» кульязма журналын барлыкка китерәләр. Кайчак кулдан берничәданә күчереп язылган, кайчак ротаторда күбәйтелгән ул журналны укыр өчен шәһәрнең әллә кайсы тарафларыннан Белем йортына әдәбият сөючеләр килә.

Латыйфны әдәби тел хакындагы бәхәсләр дә кызыксындыра, ул ятактагы күршесе Кәшфи Бәдәйли белән ярыша-ярыша онытылган сүзләрне кертеп шигырьләр язарга — телне баетырга керешә! Алар шул кадәр мавыга, кайнарлана, моннан соң инде үз көчләрен — аз да түгел, күп тә түгел — поэма иҗат итүдә сынарга булалар! Такташтан калышырга ярыймы соң!

Тиктормас Латыйф, бер карасаң, ясаган сурәтләрен күтәреп рәсем укытучысы янында бөтерелә, икенче карасаң, тотлыгуын бетерер өчен җыр күнегүләре үтә яисә сәгатьләр буе күренекле әдәбиятчы галим Габдрахман Сәгъдигә ияреп йөри. Кичләрен исә аны театрда яки Белем йортындагы әдәби-музыкаль кичәләрдә очрарга мөмкин. Шуның өстәвенә, уйгыр һәвәскәрләренең «Күк күлмәкләр» сәнгать түгәрәген аякка бастыру, тулай торак коридорына вакытлыча куелган пианинода музыкаль күнекмәләр эшләү һәм иптәшләрен сәхнәдә чыгыш ясарга әзерләү... Ничек барысына да өлгерә ул?

Музыкаль түгәрәкләргә композитор Ф. П. Вынежнев җитәкчелек итә, ул татар, уйгыр көйләрен гармонияләштерә. Фортепиано, скрипка буенча да Белем йортына махсус белемле укытучылар чакырыла. Латыйф һәрнәрсәдә үзен сынап карарга тырыша: әле пианино уйный, әле кулына мандолина яки скрипка, әле каләм-карандаш, кыл-каләм ала. Нигъмәт Хәкими, Габдрахман Сәгъдиләр аңардан язучы чыгачагына өмет белдереп, гел үсендереп торалар. Хәер, алар Латыйфның озын камыш бармаклары клавишлар өстеннән җитез йөгереп, сихри моңнар чыгарганда тагын да күбрәк әсәрләнә төшә сыман. Әле ул аларга сүзен дә, көен дә үзе чыгарган «Ятим бала» җырын җырлап күрсәтмәгән. (Белем йортында ятимнәр ишле!) Тагын бераз үзгәртсә килә, тик вакыты бик кысынкы аның: татар мәктәпләрендәге үзешчәннәр түгәрәкләренә ярдәм итәргә йөри, Кызылкиягә һәм Ташкент янындагы татар авылы Нугайкорганга гастрольләргә бара. Казан, Уфа артистлары кунакка килсә дә, «Хәмиди, энһәр коткара күр!» дип, аны аккомпаниатор булырга чакыралар. Асия Измайлова шикелле бер фәрештә өндәсә, ничек карышмак кирәк? Әдәбиятка һәвәсләр әллә никадәр, ә музыкант булырга әзерлекләре җиткән укучылар бик аз. Вынежнев

абыйсы әле аны халык кораллары оркестрына җитәкчелек иткәндә үзенә ярдәмче итеп тә билгеләде, рояль, скрипка уйнавын да хуплап тора. Егетнең күңелендә әле тагын бер вальс һәм бер марш борынлап килә. Менә алар шушы 1922 елда беренче тапкыр яңгырарга тиеш.

«Беренче вальс»ны һәм «Комсомол, алга!» маршын Ташкенттагы татар яшьләре яратып каршылый, алар концертларда башкарыла башлый. Канатланган Латыйф, ниһаять, үзен музыкага багышларга карар кыла һәм 1924 елда, Солтан Габәши Казанга килергә тәкъдим иткәч, күп уйлап тормастан юлга да чыга.

Латыйф Хәмиди туган җиренә сагынып, дулкынланып, зур өмет һәм хыяллар белән кайта. Ташкенттагы татар мәдәни учаклары нинди генә җанлы һәм шаулы булмасын, Татарстан башкаласындагы колачка тиңләшә алмый, әлбәттә. Милли башкалага әйләнгәч, Казанга бөтен яклардан язучы, журналист, артист, рәссам, галим, музыкантлар агыла. Офыклар киңәйгәннән-киңәя, көчләр куәтләнгәннән-куәтләнә. Чөнки Октябрьның шифалы җилләре шәһәрне чын мәгънәсендә «Дәртле Казан! Моңлы Казан! Нурлы Казан!»га әверелдереп килә.

Әмма Казан музыка училищесында әлегә композиторлык бүлеге ачылмаган икән. Скрипкачы булыр иде — бармакларыката төшкән, диләр. Аннары үзе дә көй чыгарырга комарлана бит әле ул. Нишләргә? Казанга элегрәк кайтып урнашкан танышлары киңәшен тотып, ул татарның беренче музыканты Заһидулла Яруллин белән бергә музыкаль салоннарның берсендә пианино уйный, педагогия техникумының хор һәм музыка түгәрәген җитәкләүне өстенә ала, шул ук техникумның икенче курсында үзе дә белемен күтәрә торырга була.

Хәзерге педагогия институты бинасында урнашкан техникум ул чагында Казанның мәдәни әһелләре кайный торган төбәк була. Кави Нәҗми, Гадел Кутуй һәм башка язучылар студентлар алдында чыгыш ясарга килеп кенә тора, Салих Сәйдәшев еш күренә, артистлар өзелми. Солтан Габәши анда җыр дәресләре бирә. Тиз аралашып китүчән Латыйф һәммәсе белән таныша, Әнәс Камал, Газизә Әхмәтовалар белән бергә «Йодрык» исемле стена газетасын чыгара. Чәнечкеле-көлкеле материалларны төне буе язалар, иртән чыгарып эләләр. Өлгермәүче укучыга, чәч бөдрәләтеп, киенеп-ясанып җил куучы кызларга рәхим-шәфкать юк!

Әмма юка чалбар, кайры тун, кара ботинка кигән куе бөдрә чәчле, уртабуйлы «көньяк» егетенең дәрте боларга гына исраф ителеп бетәрлек түгел! Әле кульязма журнал чыгарырга, авыррак укучыларга дәрес аңлатырга, кичләрен техникумның салкын залында озак-озак рояльдә уйнарга да, Казан театрларына, мәдәният йортларына йөрергә дә вакыт җиткерә. Муса Җәлил һәм башка шагыйрьләр, җырчылар белән аралаша, «Күңелле яшьләр» көен иҗат итә, драма түгәрәгенә бер пьеса да язып бирә.

...1927 елның җәе. Ташкент татар мәгариф институтын тәмамлаган ике егет Куйбышев өлкәсенең Камышлы районы Яңа Ярмәк авылына кайтып бара. Киң җилкәле, озын буйлысы — шушы якта туып үскән Әхмәт Сафиуллин. Аның кунагы — кенҗәлә озын чәчле, юка гәүдәле. Тыкрыктагы авыл хатыннары:

— Әхмәт өйләнгән, ахры, янында хатынныдыр инде,— дип карап калалар.

Үзе белгәннән бирле гел читтә йөргән Латыйф дусты Әхмәт өендә бер ай кунак була, Идел буендагы татар авылы гореф-гадәтләре, табигате һәм кешеләре, җырлары һәм уеннары белән таныша, яланга чыгып таң аттыра, сандугачлар сайравын хәйран калып тыңлый. Кызларын күзли, мәҗлесләренә бара. Һавасы сулап туймаслык тәмле, чәчәкләре күз явын алырлык матур, кешеләре йомшак итеп, агымлы сузып сөйләшә. Балыклары кармакка мул каба, җылы суы иркәли, яшел урманы җиләк белән сыйлый. Композитор булырга омтылган татар егете Яңа Ярмәкне бөтен барлыгы белән күңеленә сеңдерә. Туган моңнар шытып чыксын өчен үз халкың күкрәгеннән көч-куәт алырга кирәк бит.

Әнә җигүле ат Яңа Ярмәктән тагын Богырысланга юырта. Әхмәт аннан кире Ташкентка, Латыйф исә Мәскәүгә юнәлергә тиеш. Алтмыш чакрым арада дилбегәне әле берсе, әле икенчесе тота. Хәзер олаучы урынында Латыйф. Текә тау кашына җиткәч, Әхмәт:

— Кая, атны үзем тотыйм? — ди.

Латыйфның дилбегәне бирергә исәбе юк, бик аз гына булса да үзен шушы тарафлардагы крестьян кешесе сыман хис итәсе, аның рухи халәтенә кирәсе килә. Ат дулый, арба торган саен катырак дөбердәп тәгәри, Әхмәт кычкыра, кунак егет көпчәккә уралган дилбегәсен ычкындырмаска азаплана һәм түзә алмыйча кычкырып җибәрә.

— Бармакларым! Бармаклары-ы-м!!!

Имтихан бирер алдыннан гына музыкантның бармаклары эштән чыкса, ирексездән ачыргаланырсың. Әмма сыдырылу, канау һәм суелу сәнгәткә зыян китермәгән икән. Арбага кысылып имгәнә язган кулы тиз арада савыга һәм Латыйф башкаладагы беренче музыкаль техникумның композиторлык бүлегенә кабул ителә. Монда ул журналистлыкка укырга килгән Муса Җәлил белән кабат очраша, алар бер үк йортта фатирда тора башлыйлар.

Хәмиди Мәскәүдә тагын да тынгысызрак тормыш белән яши. Мансур Мозаффаров белән бергә алар шәһәрдәге татар мәктәпләрендә җыр-музыка укыталар, татар эшчеләре аеруча күп булган «Урак һәм чүкеч», «Кызыл баһадир» заводлары, «Большевик» фабрикасы, метро төзүчеләр һәм коммунальчылар клубында агитбригадаларга ярдәм күрсәтәләр. Татар балаларының музыка репертуары ярлы булуы аны яңа әсәрләр иҗат итәргә этәрә. Бу эшкә Муса Җәлил дә ныклап тотына, уңышлы җырлар «Октябрь баласы»нда басыла. Аның «Беренче вальс»ы да Муса Җәлил шигыре белән шушында дөнья күрә. Иҗади дуслыкта утызлап җыр туа. «Комсомол, алга!» маршы Әхмәт Ерикәй шигыре белән «Ударниклар» журналында басыла. Композиторның беренче әсәрләре үк бик тиз халыклашып китә — демонстрацияләрдә җырлана, концертларда башкарыла, русча текст белән башка милләт тыңлаучыларына да җиткерелә. М. Җәлил сүзләренә чыгарылган «Ленин турында җыр»ы хәтта «халык көе» дип тәкъдим ителеп килә. Бу әсәр 1933 елда Мәскәүдә басылган «Ленин СССР халыклары җырларында» исемле җыентыкта «Татар пионерлары җыры» дип бирелгән.

1933 елда Хәмиди редакциясендә А. Затаевич җыйган «Казагыстан татарларының илле җыры» җыентыгы дөнья күрә. Казакъ музыкасына гашыйк А. Затаевич белән аңгәмәләр кардәш халык сәнгатенә Латыйфның да игътибарын җәлеп итә. Музыка техникумын тәмамлар алдыннан Казакъ драма театры яшь композиторны Казагыстанга эшкә чакыра.

Л. Хәмиди Алма-Атада Казакъ драма театрының музыка буенча җитәкчесе итеп куела. Аның беренче эше драматург Ә. Таҗетдинның (Рахманкулов) казакъчага тәрҗемә ителгән «Документ» пьесасына музыка язу була. Шуннан соң ул М. Әүэзовның «Төнге яшен», «Кубланды» пьесаларына көй иҗат итә. Кызыл Армиянең унбиш еллыгына «Кызыл лачын» җырын яза. Әлегә кадәр үзешчәннәр репертуарыннан төшмәгән бу әсәр Хәмиди иҗат иткән казакъ җырларының беренчесе була.

Л. Хәмиди радиокомитет хорын оештыруда да якыннан катнаша, казакъ халкының күренекле җырчылары Күләч Байсәетова, Корманбик Жандарбиков, Әмрә Качаубаев, күп кенә язучы, рәссам, думбрачылар белән таныша, казакъ фольклорын җыя башлый. 1935 елдан башлап Семипалат музыкаль драма театрында эшләү, башка шәһәрләргә һәм авылларга гастрольләргә йөрү аңа казакъ халкының тормыш-көнкүрешен, гореф-гадәтләрен тагын да тирәнрәк өйрәнергә мөмкинлек тудыра.

Зур күләм музыкаль әсәрләр язу өчен үзенең профессиональ әзерлеге җитмәвен һаман җитдирәк аңлаган Латыйф Хәмиди 1936 елда Мәскәү консерваториясенең татар опера студиясенә укырга керә. Монда ул теория һәм композиторлык буенча Г. И. Литинский классында Н. Җиһанов, Ф. Яруллин, М. Мозаффаров, С. Сәйдәшевләр белән бергә белем ала. 1938 елда диплом эше сыйфатында «Татар темаларына бию сюитасы» язып, студияне тәмамлый. Ленинградта «Аманкилде» фильмында кинога төшеп кайтып килүче артистлар Сиркә Кужамкулов, Калибәк Куанычбаев, Илубай Умырзаков, Мәскәүгә килгән язучы Мохтар Әүэзовлар аны Казагыстанга кайтырга, казакъ халкының профессиональ сәнгатен терпәкләндерүдә катнашырга өнди. Латыйф ага, татар халкының бүтән кардәш халыклар арасында мәгърифәт тарату, мәдәни үсүләренә булышлык күрсәтү традицияләрен истә тотып, бу мактаулы эшнең әһәмиятен тирән аңлап, Алма-Атага кайта һәм хәзергә Корманғазы исемендәге

халык коралалары оркестрының дирижеры хезмәтенә керешә.

Бу вакытта оркестр казакъ халык көйләрен генә уйный, башкаручылар әле нота грамотасын да үзләштереп җиткермәгән була. Латыйф ага үзенең хезмәтен әнә шул нота танырга өйрәтүдән, казакъ халык көйләрен оркестрга салудан башлый. Озакламый репертуар, «Киленкәй», «Кара юрга» кебек халык көйләре белән бергә, халык композиторлары Сәйтек, С. Көчекбаев, шулай ук мәшһүр Гайдн, Моцарт, Глинка әсәрләре хисабына баетыла.

Л. Хәмиди 1939 елда Казагыстан Композиторлар союзын оештыру комитетына сайлана, 1940 елда Казакъ дәүләт капелласының художество җитәкчесе һәм дирижеры итеп билгеләнә.



*Заһид Хәбибуллин белән Латыйф Хәмиди Мәскәүнең Кызыл мәйданында.*

Шул ук вакытта Латыйф Хәмиди композиторлык эшчәнлеген дә суындырмый. 1939 елда симфоник оркестр өчен биш өлештән торган «Беренче казакъ сюитасы»н, яңа җырларын иҗат итә. Ул музыка училищесында казакъ халкы уен кораллары бүлеген җитәкли, ә 1944 елда консерватория ачылгач, аның укытучысы булып эшли башлый.

1943 елда Латыйф ага Әхмәт Җобанов белән бергәләп «Абай» операсын язуга керешә, ә 1944 елда инде әсәр тәмамланып, сәхнәгә куела.

Авторлар халык иҗатына таянып еллар сынавын узарлык опера иҗат иткәннәр. Операның музыкаль теле гади һәм аңлаешлы. Абайның ышандыручан образы — композиторларның зур уңышы. Музыка бу образны төрле яктан характерлый. Беренче күренештәге ария бу җәһәттән аеруча уңышлы. Монда Абайның тыныч шәхесе ачык гәүдәләнә. Операда Айдар, Аҗар образлары да үсештә бирелә. Халык катнашкан күренешләр, хор, ария, ансамбльләр, яшьләрнең биюләре әсәрне баетып тора. Абай казакъ тамашачысының кайнар мәхәббәтен яулап, менә инде утыз елдан артык сәхнәдән төшми уйналып килә.

Латыйф Хәмидинең иҗаты елдан-ел колачын киңрәк җәя бара. Оперетта, симфония һәм камера музыкасы, яңа опералар, музыкаль спектакль, кинофильмнарга язылган көйләр...

«Түләгән Туктаров» операсы Бөек Ватан сугышы вакыйгаларын Советлар Союзы Герое Түләгәннең рус Жадаев, татар Зариф, уйгыр Саттар, кыргыз Баймат белән бергә явыз дошманга каршы күрәштә күрсәткән батырлыкларын, совет халыкларының дуслыгын гәүдәләндерүгә багышланган.

Матбугат битләрендә бу әсәрләр дә җәмәгатьчелекнең уңай бәясен алган. Әмма «Түләгән Туктаров» һәм бигрәк тә «Жанбул» операсының беренче редакциясе, либреттоның җитәрлек дәрәҗәдә сыйфатлы булмавы аркасында, Л. Хәмидинең бай фантазия һәм иҗади мөмкинлекләрен ачып җиткерә алмаган әле. Хәзер композитор «Жамбул» операсының яңа вариантын иҗат итү өстендә эшли.

Уйгыр, кыргыз, таҗик, үзбәк биюләренә язган лирикасы, фортепиано, думбра, хор һәм оркестр өчен иҗат иткән әсәрләре композитор хыялының байлыгын, аның чор һәм халкының рухи ихтыяҗларын дөрес сиземләвен исбатлый ала.

Л. Хәмиди күренекле казакъ шагыйрьләре сүзләренә олы хисле, ягымлы, матур бизәкле бик күп җырлар иҗат итте. «Ватанга ант», «Казагыстан», «Ватан» көйләрендә ул халыкның туган илгә, партиягә мәхәббәте хакында сөйли. «Сигезенче гвардия дивизиясе җыры»нда атаклы панфиловчылар батырлыгын данлый. Латыйф аганың СССР халык артисты Күләш Байсәетова башкаруындагы «Казакъ вальсы» бөтен дөньяга тарала. Казакъ сугышчылары аны җырлап Варшава, Будапешт, Берлин һәм вальслар ватанына — Венага аяк баса. «Казакъ вальсы»ннан соң композитор «Алма-Ата», «Яз», «Былбыл», «Аккош» — барысы уннан артык вальс иҗат итә. Бу әсәрләр яшь буын казакъ композиторлары иҗатына да билгеле йогынты ясый.

Йогынты... Латыйф Хәмиди өчен гаять зур һәм киеренке хезмәтнең нәтиҗәсен белдерә ул. Татар халык музыкасы тулаем пентатоникага нигезләнсә, казакъ көйләренә диатоника хас. Дөрес, аңарда да пентатоник әсәрләр бар, әмма шуның нисбәтләрен ничек килешле сакларга соң? Казакъ көе иҗат иткәч, «Син, Латыйф, татар җыры язгансың ич!» димәсләрме? Беренче адымнар әнә шундый газаплы була, шуннан соңгылары да җиңелрәк түгел.

1940 елда Казагыстанның егерме еллыгына Сабит Муканов «Ике туй» музыкаль радиопьесасын яза. Шуңа музыка иҗат итүне, ай ярым вакыт биреп, Латыйф Хәмидигә тапшыралар. Заказчы Максытбик Мәйшекин, Калибәк Куанычбаевлар эшнең барып чыгарына үзләре дә ышанып бетми. Әмма Казагыстанда профессиональ композиторлар әле яңа калка башлаган чор бу. Шуңа күрә алар төне буе тәрәзәсендә ут сүнмәгән Хәмиди квартирасына өмет һәм шөбһә белән күз салып йөриләр. Көн аралаш телефоннан шалтыратып хәлен белешәләр, Казакъта көй азмы, нигә инде шуларны файдаланмаска, дип үзара очрашкан саен тавышы-тыны чыкмаган «Латыйф абзый»га бәйләнәләр. Өенә кагылсалар — ишектән түргәчә бөтен җирдә аунап яткан өзек-ертык нота карамалалары күреп, көйнең инде кырык варианты язылуын ишетеп исләре китә. Композиторның өзлегүеннән куркып, театрдагы эшен туктатып торырга үгетлиләр. Ә вакыт көннән-көн кыскара бара. Ниһаять, көй әзер, дигән хәбәр! Майшекин ашыга-ашыга килеп кергәндә Хәмиди себерке тотып бүлмәсендәге кәгазьләрен җыештырып йөри. Кунак, кирәкле ноталарның да юкка чыгуыннан куркып, «абзый», яраклысын да аз ертмагандыр инде дип уйлап, хуҗаның себеркесен ташлата. Латыйф бик нык дулкынлана, көен башлап җибәрә алмый аптырый. Ниһаять, озын бармаклар клавишлар өстеннән йөгерә, көй яңгырый. Үз колагына үзе ышанмаган Майшекин телефонга үреле һәм Күләш Байсәетованы, тагын бер-ике иптәшен тиз генә Хәмиди өенә чакыра. Тузгыган бүлмәдә Күләш, Максытбик, Калибәкләр беренче казакъ вальсын тыңлыйлар. Соклану һәм хуплау авазлары яңгырый. Хәмиди исә башта аларга ышанмый тора, аннары үзе җыйнаган, Затаевич туплаган йөзләрчә казакъ көйләрен күңеленнән уздырып, көне-төне яңа аһәңнәр эзләвен, Җидесу һәм Семипалат якларындагы авылларда дистәләрчә очрашуларын, бетмәс-төкәнмәс шикшөбһәләрен хәтердән кичереп елмая. Димәк, тикмәгә генә көч түкмәгән, димәк, киләчәктә куанычлы минутлар аз булмас әле.

Композиторның казакъ музыкасы өлкәсендәге иҗаты әнә шулай башлана. Еллар үзу белән кыюлык, тәҗрибә һәм сиземләве арта. Бөек Ватан сугышыннан соң иҗат ителгән һәм совет кешеләренең иҗади хезмәтенә, тынычлыкны саклауга багышланган «Тынычлык байраклары», «Алтын бодай», «Казагыстан чирәм җирена» һ. б. көйләрендә төсмерләр байлыгы, ритмик ачыклык, дәрт бөркелеп тора.

Композитор казакъ балаларын да онытмый. Аның «Укыйк, балалар», «Ян, учак!» «Мәктәп турында җыр» һ. б. әсәрләре сәхнәдә, радио, телевидение аша да даими яңгырап тора. Алар калку аһәңнәре, тиз отышлы булуы, гади формасы белән популярлык казанды. Автор казакъ совет җырын яңа интонация һәм ритмик борылышлар белән баета. Аның «Балалар өчен фортепиано пьесалары» җыентыгы музыка мәктәпләренең башлангыч классларында киң файдаланыла.

Ике йөз илле җыр һәм көй — композиторның казакъ халык музыка иҗатын җыюга керткән өлеше әнә шундый. Абайның Латыйф ага язып алган унсигез җыры бөек шагыйрь һәм көйченең иҗади мирасын иң дөрес теркәгән вариант итеп бәяләнә. Композитор халык җәүһәрләрен эшкәртеп, баетып, оркестрга салып халыкның үзенә үк бүләк итә.

Бу уңайдан без аның татар халык көйләрен дә, хор, фортепиано өчен эшкәр-

түен һәм оркестрга салуын искә алып китәргә тиеш. «Каз канаты», «Галиябану», «Су өсте», «Ком бураны» һ. б. көйләр Латыйф аганың тылсымлы каләме ярдәменд бөтенләй көтелмәгән яклары белән җемелдәп китәләр, тыңлаучыларны әсир итәләр Аның бу эше әле дә тукталганы юк. Ул «Су буйлап», «Сарман», «Шомыртым»ны капелла өчен эшкәртеп, 1964 елны Мәскәүнең «Советский композитор» нәшриятын да аерым җыентык итеп бастырып чыгарды.

Л. Хәмиди өендә булган кеше иң мәртәбәле урынга эленгән Салих Сәйдәшев рәсеменә, җырчылар Фәридә Кудашова, Әлфия Афзалова портретларына, китап киштәләрендәге татар язучыларының том-том әсәрләр җыелмасына игътибар итми калмый. Боларның һәммәсе квартир хуҗасының туган халкына бетмәс-төкәнмәс мәхәббәт хисләре хакында сөйли.

**Алмасын, алмасын,**
**Өз, агачта калмасын.**
**Зур уңышның бәйрәме,**
**Дәртле җырлар яңгырасын!**

Бу сүзләрне уку белән ягымлы, йомшак бер көй күңелдә яңгырый башлый. Ул бик тиз хәтердә кала, җыйнак, гади, йөгерек булуы сәбәпле аны тавыш мөмкинлекләре әллә ни зур булмаган кеше дә рәхәтләнеп җырлый ала. Бүәледән ерак түгел Түбән Балтай авылы мәктәбендә укыганда без өйрәнгән беренче җырлардан иде ул. Класс тәрәзәсеннән яшел бакчалар, алтын иген кырлары күренә, «Аллы-гөлле гөлчәчәкләр бакчабызны ямьләде, килде язгы дәртле эшнең ямьле хезмәт бәйрәме» сүзләре телгә ирексездән үзләре килеп керә, көе чирәмле сукмактан атлаганда да колакта чыңлый иде.

«Уңыш бәйрәмендә» дигән бу җыр татар балаларының ничәмә буынына ләззәт бирде икән инде? Олылардан күпме кеше аны басу буйлап барганда көйләмәгән дә, берәр кая китте исә, туган якларын шул авазларга уралган хәлдә күз алдына китереп сагынмаган икән?!

Латыйф аны уналты яшендә иҗат иткән һәм «Беренче вальс» дип атаган. Бу чорда ул язучылык белән дә мавыккан һәм, әйткәнебезчә, беренче җырларының барысына да сүзләрне үзе язган. Казанда һәм Мәскәүдә укыганда күренекле татар шагыйрьләре белән дуслашкач, сүзгә кытлык бетә — Муса Җәлил, Әхмәт Ерикәйләр илһам кузгатырлык шигырьләрен композиторга үзләре китереп бирәләр. Л. Хәмиди шагыйрь Муса Җәлил белән аеруча якынаеп китә һәм аңардан элек иҗат иткән көйләренә дә яңа сүзләр яздырып ала. Әнә шулай, «Беренче вальс» көе Җәлил шигыре белән кушылып, «Уңыш бәйрәмендә» җырына әйләнә.

**Илебезне өзелеп сөйгән өчен**
**Зур төзелешкә көчне бирдек без...**
**(«Күңелле яшьләр».)**

Казан радиосы аша еш яңгырый бу җыр. Хатын-кызлар ансамбле башкара. Көй күтәренке рухлы, яшьләрнең дәртен, күңел омтылышларын матур тасвирлый. Моның да сүзләрен М. Җәлил язган. Хәмидинең музыка техникумында уку чоры истәлеге ул. Мәскәү консерваториясендә укыганда, Алма-Атада яшәгәндә, әле соңгы елларда гына да (әйтик, Хәсән Туфан сүзләренә чыгарган «Иртәләрен, кичләрен» әсәре) Латыйф ага байтак татар җыры иҗат итә.

Латыйф аганың әдәби иҗат белән мавыгуын шулай ук зурлап телгә алырга мөмкин. Аңарда бу хислекне революциядән соң Кәттә Курганга килгән шагыйрә Гыйффәт Туташ уята. Әле шундагы мәктәптә укыганда ук булачак композитор шигырьләр, мәкаләләр, бер хикәя яза, алар Сәмәркантта чыга торган «Балалар юлдашы» журналының 1919 елгы саннарында басыла. 1925 елда аның шигырьләре «Тулкыннарда» дигән җыентыкка туплана. Бу җыентык Хәмидинең әдәбиятка кереп китәргә дә зур мөмкинлеге булуы турында сөйли. Аның Татарстан матбугатында чыккан беренче шигырьләрен 1925 елда Галиәсгар Камал редакцияләп бастыра. Соңыннан бөтен көчен музыкага бирсә дә, ул ара-тирә әдәби әсәрләр язуын да дәвам итә. Муса Җәлилгә багышлап иҗат иткән бер шигыре казакъ яшьләр газетасында әле күптән түгел генә дөнья күрде. Казагыстанның халык артистлары игезәк

Абдуллиннарга багышланган «Сәнгатьтәге тормыш» китабын да укучылар яратты, быелтыр аның икенче басмасы чыгарылды. Казакъ, рус, татар матбугатында басылган күп санлы мәкаләләре, истәлекләре, Кормангазы исемендәге сәнгать институтының доценты буларак язган фәнни тикшеренүләре, дәреслекләре Латыйф аганың эрудициясенә, белем колачына дәлил булып тора. Ул төзегән «Думбра өчен этюдлар», «Кораллаштыру буенча мәсьәләләр җыентыгы һәм дәреслек», «Дирижерлык техникасы» музыка серләрен өйрәнүчеләргә файдалы кулланмалар булды.

Югары музыкаль уку йортында казакъ халкының милли уен коралы думбрадан беренче мәртәбә сабак бирү һәм аның дәреслеген язу безнең якташыбыз, Казагыстанның халык артисты Латыйф Хәмиди бәхетенә туры килә. Ул дәреслекнең инде дүртенче басмасы чыгарылу — авторга бирелгән иң югары бәя.

Л. Хәмидинең бер мәкаләсе «Казагыстан татарларының халык музыкасы» дип атала. Ул анда Казагыстанда җыелган татар җырлары, аларның үзенчәлекләре, Казан татарлары җырыннан кайсы яклары белән аерылулары турында кызыклы күзәтүләр ясый.

Латыйф Хәмиди исеме Казанда да, Алма-Атада да тирән хөрмәт белән телгә алына. Үзенең бөтен табигате белән интернационалист булган композиторның иҗаты илебез халыклары тарафыннан яратып кабул ителә.

Латыйф ага Урта Азиядә яшәүче татарларның культурасы үсеше һәм аның кадрлары, татар кульъязма журналлары яки фотография, архитектура яки этнография турында сәгатьләр буе бик кызыклы нәрсәләр сөйли ала. Аның әнә шулай кызыксыну диапазоны киңлеге, күпне белүе, һәр мәсьәләгә үз карашы булу, ачык йөзе, рухи юмартлыгы бик күп атаклы кешеләрнең игътибарын тартып килгән. Муса Җәлил, Һади Такташ, Хәсән Туфан, Хәйретдин Мөҗәй, СССР халык артисты, Мәскәү консерваториясе ректоры А. В. Свешников, Мохтар Әүэзов, Нәҗип Җиһанов һ. б. аны югары бәялиләр. Композиторның архивында аларның хатлары, бүләк иткән рәсемнәре, әсәрләре саклана. Алтмыш яшь тулуын бәйрәм иткәндә Татарстан һәм башка тугандаш республикалардан килгән котлаулар арасында СССР Композиторлар союзы идарәсе җибәргән адрес та бар. Аңа илебезнең Арам Хачатурян, Вано Мурадели, Тихон Хренников кебек атаклы музыка эшлеклеләре кул куйган. Ә җитмеш яшь тулу белән аның күкрәгенә өченче Хезмәт Кызыл Байрагы ордены тагылды.

Алма-Ата шәһәр советы депутаты, Казагыстан Композиторлар союзының идарәсе, Казагыстан башкаласындагы байтак иҗади оешмаларның художество советы члены булган бу кеше белән җентеклерәк танышырга теләүчеләр А. Юсфинның Мәскәүдә, Б. Гыйззәтовның Алма-Атада «Латыйф Хәмиди» дигән шактый күләмле китапларыннан да тулы мәгълүмат ала алмас. Чөнки композитор һәр көнне иҗат утында яна, шуңа китапның чыгып җитмәс борын ук күпмедер дәрәҗәдә искерүе табигый. Чөнки Хәмиди иҗаты аның тәрәзәсе каршындагы биеккә ургылган фонтан сыман һаман югарыга үрелә, ул иҗат композитор яшәгән Түләбаев урамындагы баһадир тирәкләр сыман күп тармаклы, туган авылы Буәле чишмәләренең суы кебек татлы һәм шифалы.

Якташыбызның «Былбыл»ын гына тыңлап карагыз. Аны СССР халык артистлары Күләш Байсеетова, Бибигөл Түләгенова, безнең Нәҗия Теркулова һ. б. бик яратып башкара. Колак салыгыз әле: көйнең тылсым көче сезне аллы-гөлле чәчкәләр белән капланган казакъ даласына алып китәр, шул чак сез юргаларның дәртле чабышын, думбра зыңлавын, даладагы кылган җырын ишеткәндәй, казакъның шигърият тормышын, аның ачык зәңгәр күген, кояш нурларында иркәләнеп очкан кошларын күргәндәй, Тукай әйтмешли, «ак көмеш белән ашарлык саф һава»сын сулагандай булырсыз. Менә шундый әсәрләр иҗат итә инде ул Латыйф Хәмиди.

· · · · · · · · · · · · · ·

# ҮЗ ШАГЫЙРЕБЕЗ

Дәһшәтле 1941 елның салкын кышы иде. 6 декабрь иртәсе. Туплар гөрселдәве тынып калган арада, дошманга нәфрәте ташып чыккан сугышчылар һөҗүмгә күтәрелделәр. Ниһаять, таланган, ялангач калдырылган, әмма илбасар алдында баш имәгән Ольшанец авылы азат ителде. Ә иртәгәсен яңадан сугышка — Елец шәһәре өчен көрәш башланачак.

Һөҗүм итү җиңел түгел. Кояшлы көннәр тору сәбәпле, ак кар өстендәге һәр предмет ерактан ук уч төбендәге кебек ялтырап күренеп тора, дошман разведкасыннан яшерену кыенлашканнан-кыенлаша бара. Ул гына да түгел, ике арадагы Сосна елгасында боз урыны-урыны белән шул кадәр юка булып чыкты, аның өстеннән пехота да зур саклык белән генә чыгарга мәҗбүр. Шулай да билгеләнгән вакытка без елганың аръягындагы плацдармнарга урнашкан идек инде...

Елецка безнең гаскәрләр көтмәгәндә бәреп керделәр. Урам сугышлары башланып китте. Бәрелеш шул кадәр аяусыз булды ки, һәр йорт, һәр адым өчен озак сугышырга, кан коярга туры килде. Фашистлар зур югалтуларга дучар булып йорт артыннан йортлар, урам артыннан урамнар, квартал артыннан кварталлар калдырып чигенергә мәҗбүр булды. Полклар каршылык күрсәтүче илбасарларны сытып алга хәрәкәт иттеләр. Елец шәһәре бу көннәрдә җәһәннәмнең үзеннән дә куркынычрак булгандыр, аны һәр яктан ут һәм кара-куючкыл төтен урап алган иде. Менә шул көннәрдә безнең 13 нче Армия газетасында басылган материаллардан түбәндәге шигъри юллар хәтердә калган:

**Ночь идет по Ельцу,**
**Не успевая за теми,**
**Кто в атаку идет,**
**Открывая задымленный город.**

Ул шигырьдә шәһәрнең безнекеләр кулына күчкән мизгелдәге халәте тасвирланып, анда декабрьның салкыннары һәм туган илен азат итү өчен көрәшкән совет солдатының йөрәк җылылыгы да күрсәтелгән иде. Шәһәр өчен барган сугышлардан арып ялга тукталган арада укылган әлеге шигырьнең авторы Михаил Луконин булуы да хәтердә калган. Хәер, әле ул вакытта бу шагыйрь турында мин ишетеп кенә белә идем.

Барыбыз өчен дә уртак һәм кадерле булган башкалабыз Мәскәүне саклау өчен барган дәһшәтле көрәшләрдә безнең гаскәрләр Калининнан Елецка кадәрге зур фронтта җиңүгә ирештеләр. Бу безнең Бөек Ватан сугышы фронтларында зур җиңүнең берсе булган кебек, фашистларның беренче җиңелүе дә иде. Көннәрдән бер көн, хәрби өйрәнүләр вакытында, мине үзебезнең газета редакторы Григорий Федорович Корниенко чакырып алды. Аны Брянск урманнарында чолганышта калып, ут боҗрасыннан чыгу өчен барган авыр көрәш көннәреннән үк белә идем.

— Сержант, мин сезне художник дип ишеттем, бу дөресме? — дип мөрәҗәгать итте ул.

— Әйе, иптәш батальон комиссары, сугышка кадәр мин Казанда художество училищесында укыган идем.

— Бик яхшы, инде өзәнең үзенә күчик, — дип, кулын иңбашыма салып дәвам

итте ул.— Беләсеңме, туганкай, сугышчан дусларыбызның батырлыгын мәңгеләштерә барырга вакыт җитте. Тиздән «Безнең геройлар» дип исемләнгән китап чыгарырга уйлыйбыз, менә шуның өчен иллюстрацияләр ясарга кирәк, ризамы?

Әлбәттә, икеләнүсез ризалаштым. Бер атна буе баш күтәрми рәсем ясарга туры килде. 148 нче укчы дивизия политотделы бу китапны берничә ай эчендә, төгәлрәк әйтсәк, 1942 елның февралендә бастырып чыгарырга да өлгергән иде инде. Менә шул китап өстендә эшләгән көннәрдә миңа тагы Михаил Луконин иseme белән очрашырга туры килде — аның берничә шигыренә иллюстрацияләр ясадым. Әле дә онытасым юк, ул шигырьләр мине тирән дулкынландырды. Хәер, башкача мөмкин дә булмагандыр, чөнки шагыйрьне алгы сызыкта үзе күргән, үз башыннан һәм бер үк вакытта безнең баштан да узган вакыйгалар илһамландырган. Әлеге китапка М. Луконинның «Батырлык» дип исемләнгән поэмасыннан да өзекләр кертелде. Поэмада Елец шәһәре өчен барган урам сугышлары тәэсирендә язылган эпизодлар аеруча оста һәм тормышчан язылган иделәр. Ул юлларны укып дулкынланмый калу мөмкин түгел иде. Иллюстрацияләр өстендә эшләгәндә мин үземнең сугышчан иптәшләремне, конкрет кешеләрне яңадан күз алдыннан уздырдым. Поэманың аерым урыннары сугыш турында ишетеп кенә белгән укучыны да тетрәндерерлек көчле язылганлыгын хәтерлим. Мәсәлән, солдат егет Федоровның кул сугышы вакытында авыр яраланып егылганда да немец солдаты өстенә, көнбатышка табан бер адым алга атлап егылуы шагыйрь тарафыннан аеруча оста тотып алынган һәм хәтергә сеңеп калырлык итеп сурәтләнгән шундый урыннарның берсе дип әйтергә була.

Озакламый шагыйрьнең үзе белән дә очраштык. Без землянкада идек. Ишектән бераз җилкәсен салындыра төшеп, арыган һәм шактый туңган, уртача буйлы чандыр кеше килеп керде. Ул дәшмичә генә калай мичкә якынрак килеп утыргач кулларын җылытырга кереште. Бераз утыргач кына без аның шагыйрь Михаил Луконин булуын белдек. Таныштык... Аңарга ул вакытта 23 яшь, мин аннан да бераз яшьрәк идем. Ләкин килеш-кыяфәте белән ул үзенең яшенә караганда шактый өлкән күренә иде. Күшеккән кулларына ымлап, мин аңа авылдан әни бәйләп җибәргән йон бияләемне тәкъдим иттем. Аннан чәй һәм кайнар мичтән чыккан бәрәңге белән сыйладык үзен. Сөйләшеп утырганда Казаннан икәнлегемне белгәч, Миша җанланып китте: «Мин дә Иделдән бит. Үземне татар егете дип әйтерлегем дә бар».

Михаил Луконин Астрахань янындагы татар авылларыннан Киленчедә туып-үскән икән. Тагы шунысы кызыклы, аның кулына кечкенә чакта ук Габдулла Тукайның шигырьләр җыентыгы килеп керә. Шул җыентыкның үзенә гаять дәрәҗәдә көчле тәэсир итүе турында да мавыгып сөйләде Миша әлеге очрашу вакытында.

Сүз иярә сүз чыгып, ул минем рәссам икәнлегемне белгәч, үзе эшли торган «Ватан солдаты» исемле газетага мәкаләләр язышырга, иллюстрацияләр бирергә киңәш итте. Хәтерлим, Михаил Луконин чакыруы мине канатландырып җибәргәндәй булды, аның икенче килүенә берничә рәсем һәм хәтта бер мәкалә дә язып куйганмын. Мәкаләдә сүз сугышка кадәр художник булырга, иҗат итәргә хыялланып йөрүем һәм бу хыялларымның тормышка ашуына фашист илбасарлары башлап җибәргән кан койгыч сугышның аяк чалуы хакында иде. Мәкалә һәм рәсемнәр тиздән газетада басылды. «Ватан солдаты»ның бу саны миндә әле дә булса саклана. Рәсемнәрнең берсендә солдат көнелендә озак саклана торган вакыйга — тылдан посылкалар алган вакыт сурәтләнгән, ә икенчесе исә — карикатура. Карикатурада Гитлер, үзенең эше мөшкел булуны аңлап, «Россияне яшен тизлеге белән яулау» дигән лозунгны «Вакытлыча чигенү»гә алмаштырып маташа, янында ачуыннан маймылга әверелә башлаган Геббельс тора. Карикатура астында дүрт юллык шигырь, аны Михаил Луконин язды.

Миша безнең янга — алгы сызыкка әледән-әле килә торды, аның чыгышларын солдатлар һәр вакыт зур түземсезлек белән көтеп ала иделәр. Икәүдән-икәү генә калып хәл белешергә, сәнгать һәм әдәбият яңалыклары турында фикер алышуларга да табыла иде вакыт. Ләкин үзара дуслыгыбыз ныгып килгән бер чорда, Воронеж өчен барган сугышлар вакытында Михаил Луконин безнең дивизиягә килүеннән туктады. Аны башка җиргә җибәргәннәр икән. Мишаның, кайда гына булмасын, элеккечә батыр солдат, курку белмәс хәрби журналист, сугышчыларның яраткан шагыйре булып калуына без икеләнми идек. Һәм ялгышмаганбыз!..

Михаил Луконин белән без яңадан сугыш тәмамланып 12 ел вакыт үткәч кенә очраштык. Ул инде бөтен ил күләмендә танылган шагыйрь иде. Татарстан Язучылар союзының Габдулла Тукай исемендәге клубы шыгрым тулы... Михаил Кузьмич белән очрашуга өлкән буын кешеләре дә, яшьләр дә бик күп килгән иде ул кичне. Ул элеккечә бөтен дөньясын онытып үз шигырьләрен укыды, заман поэзиясе турындагы кайбер фикерләре белән уртаклашты. Кичә бик җанлы һәм зур уңыш белән үтте, әдәбият сөючеләрнең алкышына буйсынып, ул сәхнәгә кабат-кабат чыгарга мәҗбүр булды...

Тукай клубыннан чыккач, без озак кына кичке Казан урамнары буйлап шәһәр белән танышып йөрдек. Еллар фронттагы дуслык эзләрен аз гына да юкка чыгармаган булып чыкты. Әле өйгә кайткач та без әдәбият-сәнгать мәсьәләләре һәм көндәлек тормыш турында сөйләшеп утырдык. Миша минем сугыш елларына караган иллюстрация һәм рәсемнәрем белән танышып чыкты, ә аннан үзенең сугыштан соң һәм сугыш вакытында язылган шигырьләрен укыды. Мәсәлән, шушы очрашу вакытында яңгыраган шигырьләрдән берсе 1973 елны Татарстан китап нәшриятында басылган «Рус шагыйрьләре» җыентыгында да урын алган. «Сугыштан кайтканнарга» дип исемләнгән әлеге шигырь мондый юллар белән башланып китә:

**Без сугыштан кайттык. Безгә**
**Мактау сүзләре кирәкми,**
**Аяк астына сибелгән**
**Чәчәк күзләре кирәкми.**
**Юк, болар кирәк түгелләр!**
**Вакыт түзсен, ә без чыдыйк...**
**Атлыйк без иген кырына,**
**Чәчәкле болынга чыгыйк.**
**Җәлләмәгез. «Кайттылар бит!**

**Инде ял бирик!» димәгез.**
**Без яуда да яшәдек бит**
**һәм исән кайттык менә без.**
**Ял кирәкми. Чөнки кайттык:**
**«Күтәр безне, эш, күтәр!» дип.**
**... Хезмәттә яңартыйк данны,**
**Медальләр һәм орденны без.**
**Күңелләр тик шуңа тарта,**
**Җырлыйк бары шул җырны без.**

**(Зәки Нури тәрҗемәсе.)**

Икенче көнне кич без Муса Җәлил исемендәге опера театрында Нәҗип Җиһановның «Алтынчәч» операсын тыңладык. Опера аны үзенең рухы һәм музыкаль эмоциональлеге белән тәэсирләндерде. Пәрдә төшеп кайтырга чыккач Миша Сибгат Хәким белән икебезне үзе торган гостиницага чакырды. Бу юлы без күбрәк поэзия турында, бүгенге татар поэзиясе турында фикер алыштык...

Шул рәвешчә фронттагы дуслык яңадан яңарып китте. Мин Мәскәүгә барып төшкәч тә иң элек Михаил Луконинга шалтыратып алырга, яисә кереп чыгарга гадәтләндем. Әлеге очрашуларның тагын берсе минем хәтергә аермачык булып кереп калган. Татар әдәбияты һәм сәнгатенең Мәскәүдә үткәреләчәк декадасына хәзерлек көннәре иде. Безнең янга «Мәскәү» гостиницасына Михаил Кузьмич бер төркем иптәшләре, кинорежиссерлар белән килде. Шагыйрь ишектән килеп кергән көйгә минем белән бер номерда урнашкан Лотфулла Фәттаховның «Сабан туе» дип исемләнгән картинасын күреп үзенең соклануын белдерергә ашыкты. һәм бераздан рәссамның үзе белән әңгәмәгә кереп, аңа кайбер фикерләрен әйтте, бу эшне әле дәвам иткәндә, «Сабан туе»ның төсләргә бай киң панорамасын күрсәтергә омтылу кирәклеген киңәш итте.

Шул көннәрдә генә вакытлы матбугат битләрендә Игорь Грабарь һәм Павел Соколов-Скаль кебек сәнгать белгечләренең импрессионизмга мөнәсәбәттә үзара бәхәсләшү рухында язылган мәкаләләре басылган иде. Аларның беренчесе импрессионизм казанышларын мөмкин кадәр киңрәк файдалануны яклап чыкса, икенчесе рәсем сәнгатендә төп нәрсә — эчтәлек дигән фикердән чыгып, форма һәм художество үзенчәлекләренә җитәрлек игътибар биреп бетермәде. Михаил Луконин исә, эчтәлек игътибар үзәгендә булырга тиеш дигән фикер белән килешкән тәкъдирдә дә, рәсем сәнгатендә форма һәм төсләрнең дә гаять зур роль уйнавын кат-кат билгеләп үтте. «Грабарь белән килешми мөмкин түгел, тормыш үзе күрсәтә, ул хаклы»,— дип мавыгып сөйләде ул, мисалга Александр Иванов, Суриков һәм Константин Коровиннарның форма ягыннан гаять кыю һәм оста эшләнгән полотноларын искә алып. Оригиналь һәм күзгә ташланып торган якты төсләргә бай форма рәсем сәнгатендә эчтәлекне тагы да тирәнәйтеп килә дигән ныклы фикердә иде ул. Гомумән, аның рәсем сәнгате турындагы фикерләре һәрчак тирән һәм ышандырырлык бул-

дылар, шуңа күрә ул минем якын дустым гына түгел, киңәшчем һәм еш кына әсәрләремә беренче бәя бирүче дә була иде. Аның киңәшләрен һәрвакыт игътибарга алып килдем һәм хәзер дә аларны әледән-әле искә алам, файдаланам.

Михаил Луконин шигырьләре, кайсыдыр яклары белән миңа Владимир Маяковскийны хәтерләтә. Маяковскийга бигрәк тә аның Бөек Ватан сугышы чорындагы шигырьләре якын, бу хакта үзенә дә берничә тапкыр әйткәнем булды. Ләкин ул үзен мактап, зурлап әйткән мондый сүзләрне тиз генә читкә бора һәм: «Маяковский — поэзиядә искиткеч зур фигура. Мин үзем дә шигырьләремдә аның кебек үк көчле образлар тудырырга теләр идем. Ләкин, ни эшлисең бит, миннән Владимир ясап булмас, Михаил булып туганмын»,— дип шаяртып куя иде.

Михаил Луконин шигырьләре җаныма һәр вакыт якын булдылар. Сугыш елларында ук аның хәрби газеталарда басылган һәр әсәрен кат-кат укып чыга һәм шулардан көч, күңел көрлеге ала идем, ул шигырьләр мине еш кына иҗатымда да илһамландыручы булдылар. Һәм бу очраклы хәл түгел, чөнки аның әсәрләрендә олы җанлы совет кешесенең тормышка, туган иленә һәм кешеләргә булган сүнмәс мәхәббәте чагылган. Аның поэзиядә үз урыны булган олы шагыйрь икәнлегенә ышану өчен «Эш көне» поэмасы белән генә дә танышу җитәр төсле. Күңел җылылыгы белән сугарылган ул әсәрдә сүз хезмәт вахтасына баскан кичәге фронтовиклар турында бара. Яхшы әсәр! Шагыйрь шундый гүзәл поэма һәм шигырьләрне язмы язды?..

Михаил Луконинны искә алганда, аның иҗтимагый активлыгына игътибар итми узу мөмкин түгел. Ул СССР Язучылар союзы секретаре иде. Соңгы елларда РСФСР Язучылар союзының Мәскәү оешмасы башлыгы булды. Ул һәрчак илебезнең әдәби һәм мәдәни тормышы үзәгендә кайнады, олы мәшәкатьләр һәм зур эшләр белән яшәде. Шунысы аеруча куанычлы, Михаил Луконин татар әдәбияты һәм татар язучыларының бик якын һәм аерылмас дусты иде. Әле узган ел гына илебез Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты, шагыйрь Муса Җәлилнең 70 еллык бәйрәмен билгеләгәндә, Михаил Луконин Бөтенсоюз юбилей комиссиясенең председателе буларак зур эш башкарды. Ул Җәлил батырлыгы һәм аның поэзиясен гаять югары бәяләп ялкынлы сүзләр сөйләде, бу олы шагыйрь алдында үзенең баш июен әйтте. Минем уйлавымча, Луконин үзе дә Муса кебек үк патриот-шагыйрь, чын гражданин һәм кыю солдат иде. Аның бөтен тормышы һәм иҗат юлы туган ил һәм социалистик җәмгыять идеаллары өчен янып яшәүдән гыйбарәт булды, ул безнең күңелләргә шундый булып кереп калды.

Шул ук 1976 елның язында Габдулла Тукайга 90 яшь тулды. Татар халык шагыйренең олы юбилее күп милләтле илебез халыкларының уртак бәйрәменә әверелгән шушы көннәрдә, Бөтенсоюз юбилей комиссиясенең председателе буларак, Михаил Кузьмич яңадан Казанга — Татарстан җиренә килде. Ул үзенең чыгышларында кайтып-кайтып Тукай поэзиясенең халыкчанлыгы, интернациональ рухы, тормышчанлыгы һәм туган җиргә, Россиягә зур мәхәббәт белән сугарылган булуына сокланып бәлдерде. «Габдулла Тукай — шагыйрь нинди булырга тиеш дигән сорауга җавап булып тора. Ул — шигърият күгендә янучы йолдызларның иң яктыларыннан, ул — Пушкин йолдызлыгыннан, — дип сөйләде М. Луконин. — ... Әйе, кызганычка каршы, мондый бөек шагыйрьләр бик сирәк туа. Ләкин алар үз вакытында һәм мәңгегә туалар. Тукай да яз көнендә туып, яз көнендә китеп барган. Нибарысы 27 яз. Ләкин ул бүген — 90 еллык бәйрәме көннәрендә шул ук яшендә, һаман 27 дә».

Аннан Михаил Луконин Тукай бәйрәменә килгән бүтән бик күп кунаклар белән бергә шагыйрьнең туган ягына — Кырлайга барды. Шагыйрьне кырлайлылар ипи һәм тоз белән каршылады, тантаналы митингта ул Россия язучылары исеменнән ялкынлы речь белән чыкты...

Әдәбиятыбызның якын дусты — шагыйрь Михаил Луконинның Татарстан җиренә соңгы тапкыр килүе иде бу. Аның иseme, аның эшләре һәм ялкынлы хисләре белән сугарылган шигырьләре безнең күңелләрдә мәңгегә урын алды, аларны оныту мөмкин түгел.

**ХАРИС ЯКУПОВ,**
**РСФСР халык художнигы, СССР һәм РСФСР Дәүләт премияләре лауреаты, СССР Художество академиясенең член-корреспонденты.**

Тәлгат Галиуллин

# ҺӘР ШАГЫЙРЬ—ТРИБУН...

## Әдәбият һәм язучы иҗаты турында

Әхмәт Фәйзи мәдәният тарихына татар шигъриятенең фәлсәфи-романтик традицияләрен дәвам иттерүче тынгысыз шагыйрь, үзенчәлекле драматург, күренекле прозаик һәм балалар язучысы, ялкынлы публицист булып кереп калды. Ләкин ул «коеп куйган» әдип кенә түгел, актив җәмәгать эшлеклесе, әдәбият фәненең үсешенә зур өлеш керткән киң карашлы галим һәм тәнкыйтьче дә иде. Моңа ышану өчен, аның әдәбият мәсьәләләренә багышланган мәкаләләре, истәлекләре һәм хатлары тупланган «Әдипнең эрудициясе» исемле китабын укып карау да бик җитә[1]. Бу җыентыктагы материаллар Ә. Фәйзи исемен татар әдәбиятының иң күренекле галимнәре һәм тәнкыйтьчеләре белән бер рәткә куя. «Иҗат кыюлыгына — юл!», «Халык шагыйре», «Осталык мәктәбе», «Иҗат дуслыгы өчен», «Әдипнең эрудициясе» кебек иң яхшы мәкаләләрендә әдип татар әдәбиятының үсеш этаплары, аның уңышлары һәм күләгәле яклары турында уйлана, Г. Тукай, Һ. Такташ, М. Гафури һәм М. Җәлилләрнең шигъри мирасын пропагандалый, бөтен совет әдәбиятын борчыган актуаль мәсьәләләрне күтәрә.

Әдип һәм тәнкыйтьче буларак, Ә. Фәйзи утызынчы елларда җитлегә. Шул чорда ул татар поэзиясен «Флейталар», «Дала һәм кеше», «Көрәш бара», «Кара таш ник дәшми?» шикелле гаять үзенчәлекле поэма-балладалары, берсеннән-берсе гүзәлрәк лирик парчалары һәм җырлары белән баета. Халык иҗаты ачышларын язма поэзия казанышлары белән баетып, Ә. Фәйзи яңа әдәбиятның, социалистик реализм әдәбиятының үсү мөмкинлекләре чикләнмәгән булуын раслый. Ул поэзиядә интеллектуаль-фәлсәфи башлангычны үстерүгә, хисне фикер белән үреп сурәтләүгә зур көч куя.

Шагыйрьнең әдәби тәнкыйть эшчәнлеге поэзиясе белән бергә атлый. Әдәбият һәм сәнгать мәсьәләләренә караган мәкалә-рецензияләрендә ул үзенең шигъри принципларын теоретик яктан дәлилли, үзенә якын иҗади эзләнүләрне яклап чыга, җитешсезлекләргә каршы көрәшә. Болардан тыш, шагыйрь әдәби иҗат мәсьәләләрен дистәләрчә шигъри этюдларында, фәлсәфи миниатюраларында, шаян парчаларында, сатирик һәм юмористик әсәрләрендә кузгата. «Безнең шеренгада бер урын буш», «Шигырь турында», «Шагыйрь», «Тукай кабере янында», «Сайладым», «Тышта яз...», «Юксыну» һәм башка шигырьләрендә Ә. Фәйзи халыкчанлык һәм гуманизм идеалларын яклап чыга, поэзиянең халык тормышында, халык язмышында тоткан урыны турында тирән фикерләр әйтә. Шагыйрьне сәнгать белән чынбарлык арасындагы катлаулы мөнәсәбәт, поэзиянең матурлык хисе тәрбияләүдәге, укучының характерын форма-

[1] Әхмәт Фәйзи. Әдипнең эрудициясе. Төзүчеләре З. Фәйзиева һәм Н. Юзиев. Казан, 1973 ел.

лаштырудагы роле, традиция белән яңачалык арасындагы диалектик бәйләнеш мәсьәләләре борчый. Ә. Фәйзи иҗат методы, әдәби осталык мәсьәләләрен үзәккә ала, эчтәлек белән форма арасындагы мөнәсәбәт хакында булган фикерләре белән уртаклаша. Поэзия турында шагыйрь зур кайгыртучанлык һәм җаваплылык хисе белән, әгәр шулай әйтергә ярася, дәүләт кешесе буларак яза. Ә. Фәйзи шагыйрь шәхесенә гаять зур таләпләр куя. Аның өчен поэзия — халык бәхете өчен көрәш һәм социалистик төзелеш коралы. Шулай булгач, аның иҗатчысы да чорның алдынгы кешесе булырга, укучыларда тормышка мәхәббәт һәм ихтыяр көче, иҗади ялкын тәрбияли белергә тиеш.

Гражданлык рухы белән сугарылган югары поэзия үрнәген ул Г. Гейне, А. Пушкин, В. Маяковский, Г. Тукай һәм Һ. Такташ иҗатларында таба, үзенең бик күп шигырьләрен әдәби остазларына багышлый.

«Әхмәт Фәйзинең гомере буе тугрылык саклаган, гомере буе табынган язучысы — Габдулла Тукай. Тукай образын әдәби образларда гәүдәләндерүгә, Тукай иҗатын пропагандалауга, өйрәнүгә ул гаять зур өлеш кертте», — дип яза әдәбият галиме Н. Юзиев[1]. Ә. Фәйзинең «Тукай» исемле тарихи романы, халык шагыйре турындагы сәхнә әсәрләре укучыларга мәгълүм. Шигырьләрендә исә беренче адымнарыннан ук ул Тукай иҗатын, Тукай шәхесен якты маяк итеп ала. «Эшләсәң генә тешләрсең», «Кар кеше», «Икмәк исе» кебек 1916—1917 елларда язылган беренче әсәрләрендә үк Ә. Фәйзи Тукай шигырьләренә ияреп, ул күтәргән темаларны, аның интонациясен кабатлый.

Егерменче еллар урталарыннан Тукай поэзиясенә аңлы, иҗади мөнәсәбәт урнаша. Тукай традицияләренә таянып, Ә. Фәйзи замандашының революциягә хәрәкәтен, тормышта үз урынын, үз юлын эзләвен сурәтли.

Элекке мираска, революциягә кадәр иҗат ителгән әсәрләргә карата, тискәре мөнәсәбәт киң таралган, үткән гасырларда яшәгән әдипләр иҗатын «тарих чүплегенә» ыргытырга чакырулар модада булган бер чорда Тукай традицияләрен яклап чыгу, сүз дә юк, мактауга лаек эш була. Без, әлбәттә, Ә. Фәйзине үз чорыннан өстен куярга җыенмыйбыз. Н. Юзиев бик хаклы рәвештә язганча, аның бу еллардагы аерым мәкалә-рецензияләрендә РАПП установкалары тәэсирендә туган хата карашларны да очратырга мөмкин[2]. «Сәхнәдә йөрүче аяклы плакатлар белән тамаша залында утыручы геройлар турында» (1933) исемле мәкаләсендә, мәсәлән, Ә. Фәйзи, аерым сәхнә әсәрләрендә очраган схематик фикерләргә каршы чыгып, түбәндәгечә яза: «Чын кешене безгә реалистик итеп бирергә кирәк. Ләкин нинди реализм белән? Моның өчен буржуа реализмы ярыймы? Юк, ярамый. Чөнки буржуа реализмы тормышны тыштан караганда дөрес кебек тасвир итсә дә, аны хәрәкәтсез, катып калган рәвештә, статика хәлендә тасвир итә»[3]. Яңа әдәбиятның бурычлары хакында күп кенә кызыклы фикерләр әйтсә дә, элеккеге реализмны аңлауда ул чикләнгәнлек күрсәтә, РАПП теоретиклары алга сөргән догмаларны кабатлый. Аның бу фикерен дәвам иттергәндә, читкә ыргытылырга тиешле «буржуаз реализм»га Тукайны да кертергә туры килер иде. Үз иҗатында Ә. Фәйзи традиция белән яңачалык арасындагы дөрес мөнәсәбәтне тизрәк таба. Поэзиясе белән тәнкыйте, эстетик фикере нигездә бергә атласалар да, вакыты белән шагыйрь Ә. Фәйзи теоретик Ә. Фәйзидән сизгеррәк, алдан күрүчәнрәк булып чыга.

Г. Тукай иҗаты Ә. Фәйзигә халыкчан рухы һәм демократик характеры белән якын була. «Синең урының кабер түгел, безнең йөрәкләрнең ачык, киң түре. Син җырлыйсың һаман безнең белән, җырың белән бүген син — тере», — дип яза ул «Тукай кабере янында» шигырендә. Тукай традицияләре Ә. Фәйзинең эстетик идеалын, шигъри зәвыгын камилләштерүдә, халык тормышы белән бәйләнешен ныгыту юлында хәлиткеч роль уйный.

Мәсьәләнең икенче ягы да бар. Тукай образында, Тукай эшчәнлегендә ул шагыйрьлек идеалы күрә. Шул югары үлчәүдән чыгып, ул замандашлары иҗатына эстетик таләпләр куя, шигърият өлкәсендәге чүп үләннәренә каршы көрәшә, совет әдәбиятының үсешенә аяк чалучы тискәре күренешләрне көн яктысына чыгара.

---

[1] Шунда ук, 5 бит.
[2] Шунда ук, 5 бит.
[3] Шунда ук, 129 бит.

Ә. Фәйзи, әлбәттә, үзен Тукай традицияләре белән генә чикли алмый. Яңа чор, яңа кеше аңында барган грандиоз үзгәрешләр сурәтле фикер чараларының да яңаларын табуны, кыскасы, новаторлыкны таләп итә. Никадәр генә киң һәм тирән булмасын, Г. Тукай традицияләре алдынгы идеология белән коралланган совет шагыйрен ахыргача канәгатьләндереп җиткерә алмый. Бу хакта Ә. Фәйзи язып та чыга. «Ватаным мине тарихи яктан сыналган алдынгы революцион теория белән коралландырды, — ди ул. — Бик күпләр арып һәм гаҗизләнеп егылган заманда, капитализм хөкем сөргән караңгы заманда Тукаебызга шушындый компассыз капшанып бару никадәрле кыен булганны мин бик ачык күз алдына китерәм»[1].

Революцион чынбарлыкның шигъри гәүдәләнешен, аның сынын чагылдыру юлында тагын бер югары үрнәкне Ә. Фәйзи В. Маяковский белән һ. Такташлар иҗатында күрә. «Революция шагыйрьләре»нең иҗаты аңа әдәбиятта партия политикасын үткәрүнең, халыкчан рухны һәм социалистик идеалны сәнгатьчә нәфислек белән сурәтләүнең югары үрнәге буларак якын. «Бер йөрәктән бөтен телләрдә» шигырендә Ә. Фәйзи үзен, Маяковский белән Такташ шикелле үк, партияле шагыйрь, тенденциоз шагыйрь дип атый («Әйдә мине иң-иң партияле пропагандист икән дисеннәр»). Иҗатында коммунистик тенденциялелекнең матур үрнәген биргән Владимир Маяковскийның фаҗигале үлемен ул бик авыр кичерә. Авыр хис, тирән кайгы шигырь юлларына күчә. 1931 елда язган «Безнең декларация» исемле шигырендә Ә. Фәйзи, көрәш мәйданыннан вакытсыз киткән өчен, әдәби остазына үпкә белдерә:

**Безгә ачык бүген:**
**— Син эшләдең**
**Кичермәслек**
**Авыр җинаять**[2].

Маяковский таланты — бөтен ил, бөтен халык байлыгы. Шуңа күрә дә, Ә. Фәйзи фикеренчә, дошман коткысына бирелеп, ул олы гомеренә нокта куйган «кургаш тамчы»ны кабул итәргә тиеш түгел иде. Шагыйрь В. Маяковскийны фаҗигале финалга алып килгән сәбәпләрне берьяклырак, дөресрәге, РАПП «теоретиклары» тараткан версияләр буенчарак аңлата. Бәхеткә каршы, «Безнең декларация»нең төп пафосын андый берьяклы карашлар билгеләми. Ә. Фәйзи Маяковскийның революцион поэзиясенә гаять югары бәя бирә. Ул яраткан остазын «даулы илнең бөек быргычысы», атаклы җырчысы дип атый һәм аның мирасына, ул салган «баганалы» юлга турылыклы булып калырга ант итә[3].

һ. Такташ үлеме уңае белән язылган «Безнең шеренгада бер урын буш» (1931) шигырендә шагыйрь: «Җырлар коя торган домнаның бер эшчесе бүген югалганны без тешләрне кысып тыңладык», «яшереп булмас бүген, Такташ тудырыр күңелләрдә тирән юксыну», — ди. һади Такташ поэзиясе авторга оптимистик рухы, яңа тормыш һәм социалистик төзелеш өчен барган киеренке көрәшнең катлаулы конфликтларын, иҗтимагый коллизияләрен кабатланмас характер аша, югары осталык белән сурәтли белүе, халыкчан интонациясе, кешелекле лиризмы белән якын. Шагыйрь әдәби шеренгадан төшеп калганга аның йөрәге әрнесә дә, ул пессимизмга бирелеп, кулын салындырып утырмый. Балавыз сыгуны, сыкрануны оптимист рухлы Такташ үзе дә гафу итмәс иде.

Такташ татар поэзиясен социалистик реализмның магистраль юлына чыгарып калдыра. («Ул күрсәтте ничек борылыш ясау кирәклекнең тере үрнәген».) Шуңар да аның шигъри мирасы чордашларын һәм киләчәк буын шагыйрьләрен яңа үрләргә, иҗади эзләнүләргә әйдәп, рухландырып, илһамландырып торачак. Ә. Фәйзинең шигъри логикасы түбәндәге нәтиҗәгә алып килә:

**Без ялгадык сафны,**
**Юк өзеклек,**
**Чөнки юлыбызда**
**Йолдыз иттек**

[1] Шунда ук, 328 бит.
[2] «Яңалиф» журналы, 1931 ел, 1 сан.
[3] Соңрак ул Маяковскийның үз иҗатына һәм гомумән татар поэзиясенә ясаган йогынтысы турында махсус мәкалә дә язып чыкты. («Дружба народов» журналы, 1950 ел, 2 сан.)

Большевикның
Бөек сәнгатен!

«Юксыну» (1947) шигырендә Ә. Фәйзи яңадан Такташка әйләнеп кайта. Такташ үлгәннән соң ике дистәгә якын вакыт узган, «революция шагыйре»нең әдәби мирасы заманның авыр сынауларын үткән. Шагыйрь инде үзе дә олыгайган, остазыннан алган эстафетаны дәвам итеп, татар әдәбияты тарихына уеп куелырдай шигырь-поэмалар, драмалар иҗат иткән. Әмма ул үзен әле һаман Такташның укучысы итеп саный һәм кыска, образлы детальләр аша остазының җанлы образын күз алдына бастыра:

...Тагын яуды карлар... Әле һаман
Яңа шигырен тотып кулына,
Салкын тыштан җылы өйгә Такташ
Килеп керер төсле тоела.

Еллар үткән саен, «юксынуның ачы хисләре» ныграк сизелә, йөрәкне ныграк ярсыта. Шигырь юлларына үкенечле, аянычлы хисләр, элегик интонацияләр килеп керә. Кеше физик яктан табигать законнары каршында көчсез... Такташ кире кайтмас... Ләкин буыннарга калдырган эстетик байлыгы елдан-ел тулырак ачыла барыр, яшәрә барыр. Аның иҗаты үлемсез.

Әйе, Ә. Фәйзи А. Пушкин, Г. Гейне, Г. Тукай, В. Маяковский, Һ. Такташ кебек поэзия титаннары турында тирән ихтирам белән яза, алар иҗатында кеше акылы ирешергә мөмкин булган казанышларның югары үрнәген күрә. Шагыйрь хәзерге поэзия белән үткәннең гүзәл традицияләре арасындагы катлаулы мөнәсәбәтне гадиләштереп аңлауга каршы. Ул үткәндәге үрләрне гади кабатлау юлына чакырмый. Шул ук вакытта классиклар поэзиясен вакыт-вакыт бил бөгеп, юбилейларны уздырганда табынып ала торган пьедесталга әйләндерүне хупламый. Хәзерге поэзия, Ә. Фәйзи уенча, халык тормышына, шәхеснең мең тармаклы рухи дөньясына якынайганда, элгәрләренең уңай тәҗрибәсенә таянып эш итәргә, кыю эзләнүләрен шул уңдырышлы җирдә алып барырга тиеш. Шигырь техникасын баету, сурәтләү алымнарын, композиция төзү ысулларын төрләндерү юлында классик мирас теләсә кайсы сүз остасы өчен алыштыргысыз таяныч һәм бетмәс чыганак була ала. Ниһаять, әдәби остазлар иҗтимагый эшчәнлекләре, тормышларын тулысынча халыкка хезмәт итүгә багышлаулары белән дә яңа буын шагыйрьләре өчен үрнәк булып торалар.

Г. Тукай һәм В. Маяковскийлардан алган сатира камчысын кулына тотып, Ә. Фәйзи поэзия учагында кул җылытучы һәр төрле кәсепчеләргә, халтурщикларга, талантсыз, зәвыксыз һәм белемсез килеш шагыйрь исеменә дәгъва итеп йөргән «мәрәкәйләргә» каршы чыга. Аның сатирик каләме елдан-ел үткенәя, чарлана бара. «Бер шагыйрьнең йөрәк тарихы» (1936), «Мәрәкәй» (1939), «Минме тормышны белмим?» (1952), «Эх, шагыйрь булсаң иде!» (1952) кебек сатирик-юмористик шигырьләрендә автор иҗат кешеләре алдына гаять югары этик-эстетик таләпләр куя.

Ә. Фәйзи егерменче еллар поэзиясенә һәм тәнкыйтенә хас җитешсезлекләрне механик рәвештә кабатлауга каршы чыга. Әзер схемалар, догматик фразалар белән яңа иҗат методының мөмкинлекләрен чикләргә омтылучыларны юмор ярдәмендә фаш итә, көн яктысына тартып чыгара. Поэзия, тормышның үзе шикелле үк, нәкышларга бай, күп төрле булуы белән кадерле, ди ул. Туктаусыз үзгәреп-яңарып торганда гына әдәбият тормышның әйдәүче көче, халыкның рухи таянычы була ала. Совет поэзиясенең дәрәҗәсенә, абруена зыян китерүче урта кул әсәрләрне, җирдән сөйрәлүче канатсыз натурализмны, риторик купшылыкны фаш итү белән бергә, Ә. Фәйзи укучыда эстетик зәвык тәрбияләүгә дә зур әһәмият бирә.

Мәгълүм булганча, поэзия—иҗтимагый аңның гаять үзенчәлекле төре. Шигърият, диңгез уртасындагы утрау шикелле, ялгызы яши алмый, ул укучылар массасы белән даими элемтәдә генә үсә ала. Яхшы шигырь язу бер хәл. Шагыйрьнең кайгысын һәм шатлыгын, мәхәббәтен һәм нәфрәтен, фәлсәфи уйлануларын һәм хисләрен аңларлык, йөрәге белән тоярлык укучысы булу да шарт әле.

Сүз дә юк, революциядән соңгы елларда укучының эстетик зәвыгы, фикерләү дәрәҗәсе үсте, поэзия сөючеләр саны бермә-бер артты. Халык алдында әдипләрнең авторитеты күтәрелде. Ләкин шигырь язу социалистик төзелеш өчен хаҗәте булма-

ган «вак-төяк» эш дип, аңа кимсетеп, үзләренчә түбәнсетеп караучылар да очрап куя. Бу тип мещан үзен югары культуралы кеше саный, кирәксә-кирәкмәсә фәнни-фәлсәфи темаларга сафсата сатарга ярата. Чынында ул — тарихи прогресстан артта калган, ялган фикерләр белән алданып яшәүче, туң җанлы, табигый матурлыкны аңлаудан мәхрүм «чеп-чи бюрократ». Ә. Фәйзи менә шундый мещаннарга, обывательләргә каршы сатирик каләме белән һөҗүмгә ташлана. Берничә эре штрих белән, диалог һәм сүз уйнатулар аша, шагыйрь «йөрәккә сай» шул бәндәнең сатирик образын рәсемләп бирә:

**— Шагыйрь!.. Эһем... По-эт!..**
**«Акыллы баш!»**
**Юха көлү яшерә күзендә, —**
**Әйтерсең лә акыл тонналап**
**Үзендә.**

(«Бер тип».)

Сәнгатьне практицизм фәлсәфәсеннән генә чыгып бәяләүче «акыллы баш» мещаннарны халык алдында фаш итүнең бердәнбер ышанычлы юлы — әдәбиятның олы миссиясен аклардай, җан азыгы булырдай яхшы шигырь язу. Әдәбият — намус эше. Шагыйрь намусында халык намусы чагыла. Шуңа күрә кулына каләм алган язучының халкына әйтер сүзе булырга тиеш. Димәк ки, ул, үз хезмәтенә җаваплылык хисе белән карап, туктаусыз үсәргә, «гел яктыга, югарыга» үрләргә, язганын тәнкыйть иләге аркылы уздырырга, «чорга торырлык» сүзен эзләгәндә «меңәр тонна руда» актарудан да курыкмаска тиеш. «Эх, шагыйрь булсаң иде!», «Шигырь турында», «Язучы» кебек шигырьләрендә Ә. Фәйзи менә шул хакта уйлана. Язучыга иң кирәкле сыйфатлар нидән гыйбарәт соң? Беренчедән, ул үзе яхшы белгән, йөрәге белән тойган вакыйга-күренешләр, ахыргача ышанган хакыйкатьләр һәм төшенчәләр турында гына язсын. Икенчедән, поэзияне газета информациясе белән бутарга ярамый. Шигырь бар белгәнеңне, күргәнеңне түкми-чәчми, эзмә-эз сөйләп бирүне яратмый. Поэзия иҗтимагый тормыштан бик күпләрне борчыган төенләнеш моментларны сайлап алуны һәм аны чорның югары идеалларына тиң сурәтләү чаралары ярдәмендә, кабатланмас индивидуаль колориты белән укучыга җиткерә белүне шарт итеп куя. Өченчедән, шагыйрь заман тавышын, тормыш материалын зиһен көче, тойгысы белән баетырга, кыскасы, йөрәге аркылы уздырырга тиеш. Поэзия пыскып януны өнәми. Үзеңне кызганмыйча эшләп, янып-көеп, кыскасы, авыр газап белән туган шигырь генә ләззәт бирә, укучы күңелендә җавап хисләре уята ала, ди шагыйрь.

Ә. Фәйзи шагыйрь хезмәтен идеаллаштырып, романтик буяуларда сурәтләүдән ерак тора. Язучы «табип та түгел, күрәзә дә» түгел. Иң кызыгы шунда, ул кеше турында, аның иң интим, иң тирән эчке серләре турында язса да, үзен-үзе белми икән. Шагыйрь белән аның лирик герое бервакытта да тулысы белән тәңгәл килми, шагыйрь белән укучы арасындагы мөнәсәбәт шактый катлаулы һәм четерекле:

**Һәй, син, кеше, ирме, хатын-кызмы,**
**«Ник текәлеп миңа карыйсың!» —**
**Дип сорама аннан, сиңа карап,**
**Аның үзен килә танысы...**

(«Язучы».)

Шагыйрь шәхесе һәм поэзия хакында уйлануларын, шигъриятнең иҗтимагый тормышта, халык рухында билгеләгән урыны турындагы фикерләрен Ә. Фәйзи «Кайчак яңлыш», «Шагыйрь», «Тышта яз...» шикелле күп санлы әсәрләрендә дәвам иттерә. Төрле елларда иҗат ителгән бу шигырьләрне полемик рух, дәртле аһәң, поэзиянең үткәне, хәзергесе һәм киләчәге өчен борчылып уйланулар якынлаштыра. Үзәктә сыйфат мәсьәләсе тора.

Ә. Фәйзи җитешсезлекләрне күпертеп, шуларны тәнкыйтьләүдән ләззәт таба торган шагыйрь түгел. Ул уңай күренешләрне дә читләтеп үтми, талантлы замандаш-

ларын хупларга һәм рухландырырга да җылы сүзен таба. Әдәбиятта үз сүзен әйткән, аны яңа геройлары белән баеткан һәр талантлы һәм намуслы художник ихтирамга лаеклы. Нәкый Исәнбәт — шундый сүз осталарының берсе. Халыкның талантлы улына мәхәббәте мәгърур кыяфәтле, тирән тамырлы карт имән образы аша җиткерелә:

**Каршы ала сине җиз яфраклы**
**Карт имәннең мәгърур килбәте.**
**Ул сәламли башын ими генә,**
**Таңкаләрен генә тибрәтеп.**

(«Көзге урман».)

Ә. Фәйзи татар әдәбиятына бөтенсоюз таләпләре биеклегеннән килеп бәя бирә. Шул җәһәттән, заманында «Литературная газета»да басылып, киң җәмәгатьчелекнең игътибарына лаеклы булган «Әдипнең эрудициясе» исемле теоретик мәкаләсенә кагылып үтәсе килә. Язучы исемен йөртергә җөрьәт иткән кеше, Ә. Фәйзи фикеренчә, төпле һәм тирән белемле булырга тиеш. Культура дәрәҗәсен, теоретик белемен һәм зәвыгын үстерү, камилләштерү өстендә даими рәвештә эшләмичә, табигать тарафыннан бирелгән сәләтенә һәм шәхси интуициясенә генә ышанып яшәсә, язучы елдан-ел үсә барган фәнни һәм эстетик таләпләрдән артта калачак. Эрудицияңне баету, «дөньяга үзеңнең төпле карашыңны, булдыру өчен», сәнгатьнең чиктәш төрләрен, андагы ачышларны ныклап өйрәнергә кирәк. Чөнки «сәнгатьнең төрле төрләре бер-берсе белән аерылгысыз бәйләнгән, һәм сәнгать эшлекләре бер-берсеннән башка яши дә һәм иҗат итә дә алмыйлар. Архитектор, скульптор, нәкышче, шагыйрь, композитор, график һәм романист — барысы-барысы бергә иҗат итәләр» [1].

Сәнгатьнең башка төрләренең ачышларын үзләштерү, иҗатка «алып керү» әдәбиятның үз спецификасын югалтуга китерми. Чөнки «әдәбият арадашлыкның иң универсаль коралына — сүзгә ия. Әдәбият барлык чиктәш сәнгатьләрнең тәнкыйтьчесе дә бит»[2]. Шул ук фикерләрен ул шигъри әсәрләрендә дәвам иттерә, ачыклый. «Шигырь турында» әсәре бик күп теоретик һәм практик мәсьәләләрне калкытып куюы белән аерылып тора. Шагыйрь композиция, форма, әдәби техника өлкәсендә туктаусыз һәм төрле юнәлешләрдә алып барылган кыю эзләнүләрне яклап чыга. Ләкин моннан чыгып, шагыйрь, форма үсешенә, техникага, рифма-ритм чараларына таләпне арттырып, эчтәлек турында онытып, формализм тегерменәнә су агызмыймы дигән шик туарга тиеш түгел. Ул гомере буе формализм агуына каршы көрәште. «Бер тәнкыйть үңәе белән» исемле мәкаләсендә ул форма белән эчтәлек арасындагы мөнәсәбәтне бик ачык итеп аңлатып күрсәтә. «Әгәр дә ул (форма) безнең эчтәлекне оештыручы булып, идеяне ачарга ярдәм итсә, бу яхшы форма була. Әгәр дә ул эчтәлекне ачуга комачауласа, эчтәлек белән исәпләшмәстән форма өчен форма булып калырга теләсә, бу инде зарарлы күренеш, бу формализм булып чыга» [3].

Олы поэзияне заман темасы, халыкчан рух бизи. Шагыйрь язарына азыкны бишьеллыклар төзелешеннән, сыйнфый көрәш мәйданыннан, кыскасы, замандашлары тормышыннан эзләргә тиеш. «Дала һәм кеше» балладасында язганча, «легендалар, кыю мифларны артта калдырып, безнең чынлык бара». «Тема эзләп борын казыма. Ә син тормыш казы, менә кайда син эзләгән төпсез хәзинә», — ди Ә. Фәйзи каләмдәшенә сүз катып.

Җыр-шигырь язуны ул эшче хезмәтенә тиңли. Шагыйрь алдынгы сыйнфның бер әгъзасы.

**Сыйныф.**
**Синең кустарьларың бит без,**
**Сындырмасын безне ялгызлык.**
**Бөек артелеңә безне дә ал,**
**Өйрәнчегең итеп ал безне.**

В. Маяковский «Во весь голос» поэмасында совет хөкүмәтеннән үзенә шигъри план бирүне таләп иткән иде. Ә. Фәйзи дә шул рух, нийт белән яши:

---

[1] Әхмәт Фәйзи. Әдипнең эрудициясе, 219 бит.
[2] Шунда ук, 224 бит.
[3] Шунда ук, 176 бит.

**Техниканың соңгы сүзен даешь.**
**Даешь шигырьгә дә бишьеллык.**

Хезмәттә ул эстетик матурлык, шигъри рух таба. Менә шул идеалыннан, партиялетенденциялелектән чыгып, Ә. Фәйзи тормышны бизәп, матурлап сурәтләгән төче лириканы кире кага. Ул җирдән шытып чыккан, «тупас», кырыс шигырьне, пропагандист, трибун шагыйрьне пьедесталга күтәрә:

**Кичә:**
**Шигырь — көмеш җилбәзәк.**
**Шигырь — сәма; шигырь — аракы.**
**Бүген:**
**Шигырь — «тупас» җир җыры.**
**Ә һәр шагыйрь — трибун, оратор.**

Тикшерә, өйрәнә башласаң, поэзия алдында торган проблемалар, чишелешен көтеп яткан мәсьәләләр күп икән. Шигъри бакчабызда чүп үләннәре юк, анда хуш исле гөл-чәчәкләр генә үсә, борчылырга, хәвефләнергә урын юк дип, тынычландырып йөрүгә чик куярга вакыт, ди шагыйрь. «Шигырь турында» әсәренең лейтмотивы, юнәлеше һәм нәтиҗәсе — менә шул.

1939 елда иҗат ителгән «Шагыйрь» әсәре Ә. Фәйзинең эстетикасын һәм әдәбиятка карашларын аңлау юлында аерым урын тота. Тирән фәлсәфи фикерле, хыял уенына, метафорик сөйләмгә нигезләнеп язылган бу шигырь еллар буе «тиргәлә» килде. Кемнеңдер «җиңел кулы» белән әйләнешкә кереп киткән тәнкыйть фикере дистә еллар буена мәкаләдән-мәкаләгә, автордан-авторга күчеп килә. Мисал эзләп ерак барып торасы юк. «Татар совет язучылары» (1958) исемле био-библиографик белешмәдә Ә. Фәйзинең «беренче чор иҗатында аерым йомшаклыклар да булды» дигән фикер әйтелә һәм шул фикергә дәлил буларак «Шагыйрь» әсәре китерелә. Шуңар да игътибар итегез: беренче адымнарын революциягә кадәр үк атлаган, егерменче елларда киеренке эзләнүләр чорын үткән, утызынчы еллар башында поэзиябезнең алтын фондына кергән «Флейталар» һәм «Умырзая» әсәрләрен иҗат иткән шагыйрь 1939 елда да әле «беренче чор иҗат» дәверен генә кичерә икән.

Ә. Фәйзи поэзиясе турында иң төпле мәкаләләрнең берсен язган Г. Кашшафның да бу шигырьгә бәясе алда телгә алган норматив фикерләүдән әллә ни аерылмый. «Шагыйрь» турында сүз йөртеп, ул түбәндәгечә яза: «Шул рәвешчә Әхмәт Фәйзи үзенең ролен һәм бурычларын ачык итеп күрсәтмәде. Шактый буталчык фәлсәфәсе белән мавыгып, ул, поэзиягә карата дөрес фикерләр әйтү белән бергә, язучының ролен романтик сүзләр болыты астына яшерде»[1].

«Шагыйрь» — фәлсәфи эчтәлекле, киң һәм тирән мәгънәле, метафорик фикерләүгә корылган катлаулы әсәр. Аның тирән эчтәлегенә төшенү, фикер юнәлешен күзаллау өчен, мәгълүм бер әзерлек тә кирәк. Диңгез төбеннән «адәм йота торган әкәм-төкәм әкиятләрен алып чык син безгә», «я, киресенчә, диңгез эңгеренә электры белән якты бөркеп, йөзә торган балык турында...» сөйлә син, шагыйрь, кебек метафорик юлларны укыгач, шигырь артык катлаулыланып китмәдеме икән, дигән фикер дә туа. Әсәрнең эченәрәк кергәч, төп мәгънәви юнәлешенә төшенгәч, әлеге фразаларның реаль эчтәлеге тулырак ачыла. Шигырьнең төп фикере ифрат файдалы һәм кирәкле.

Ә. Фәйзи, социалистик реализмның киң иҗат мөмкинлекләренә таянып, эзләнүләрне төрле юнәлешләрдә алып барырга чакыра. Тормыш — катлаулы һәм күп кырлы. Сәнгать, шул исәптән, аның үзенчәлекле һәм сизгер бер төре булган поэзия дә, чынбарлыкны образлы өйрәнү чарасы буларак, бер урында таптана алмый, ул туктаусыз үсәргә, төрләнергә, яңа юллар барларга тиеш. Ирешелгән ачышларны кабатлап, үтелгән үрләр белән масаеп, кул кушырып утыру поэзиягә зур зыян китерергә, социалистик реализм методының барыр юллары чикле һәм алдан билгеләнеп, ачыкланып куелган дигән ревизионистик нәтиҗәгә алып чыгарга мөмкин. «Шагыйрьләр яхшы һәм төрле» булсын. Берәүләр тормышны үз табигый формаларында, традицион калып һәм үлчәүләр ярдәмендә тасвирласалар, икенчеләр хыял уенына, фантазиягә киң юл ачалар, ачык метафорага, төсле буяуларга өстенлек бирәләр. Тормыш мате-

[1] «Совет әдәбияты» журналы, 1947 ел, 6 сан, 97 бит.

риалы таләп иткәндә, хаҗәт булганда, шагыйрь үтә шартлы алымнарны да эстетик арсеналына алырга, гротеск, гипербола шикелле күпертү ысулларын да эшкә җигәргә мөмкин. Һәр очракта да шагыйрьнең тынгысыз фикере, көчле прожектор шикелле, тормыш тирәнлегенә юнәлсен, йөрәге, Данко йөрәге шикелле, халыкның юлын яктыртып торсын. Бу таләп реалистик поэзиягә дә, романтик алымнарга өстенлек бирүче шагыйрьләргә дә бер үк дәрәҗәдә карый.

Каләмдәшләренә катгый эстетик һәм практик таләпләр белән мөрәҗәгать итү бу әле һич тә аларга әзер рецептлар өләшү дигән сүз түгел. Талант көчләүне яратмый. Язучының индивидуаль фикерләвен, чынбарлыкны шәхси күремен дә инкарь итәргә ярамый. Һәр талантның рухына якын темасы, үз кыйбласы бар. Бер шагыйрь колач җәеп океан киңлегенә ташлана. «Фрегат Паллада»сын өскә күтәрә, икенчесе «безнең ирешелгән өметләрнең гаҗәп гармониясенә» каршы төшкән диңгез акулаларын сатира утында көйдерә. Шагыйрьнең күңелен биләгән идея, шул идеяне ачу юнәлешендә табылган тема үзенә бәрабәр образлар, буяулар һәм аһәң таләп итә. Публицистик, романтик интонация, масштаблы поэтик фикерләү белән рәттән, шәхси, интим мөнәсәбәтләрне җырлаучы шигърияттнең йөрәге тибә.

Эпик җырга көчең җитми икән:
Ташла аны.
Чум һәм алып чык син
Диңгез төбендәге кабырчыклар
Эченә кереп яткан энҗеләрне —
Лирикаң энҗесен.

Әлеге юлларны истә тотып, заманында Ә. Фәйзи «поэзиянең диапазонын тарайта, аны кабырчыклар эченә, димәк ки, артык субъектив, интим кичерешләр эченә бикли» дигәнрәк фикерләр дә әйтелде. Шагыйрьнең әлеге фикерләрен аңлау өчен, бер мизгелгә булса да әсәр язылган чорга әйләнеп кайтыйк.

Утызынчы еллар ахырында поэзиядә риторика шактый нык тамыр җәя, кайбер шагыйрьләрнең җегәре бер шәхесне мактауга, ода характерындагы әсәрләр язуга сарыф ителә. Индивидуаль, шәхси башлангычны югалтуга алып барган коллектив поэмалар язу модага керә. Шул обстановкада, бигрәк тә яшь шагыйрьләргә, шәхеснең эчке хисләрен, рухи матурлыгын җырлау поэзия үсешенең үтелгән чоры кебегрәк булып тоела башлый. Әлбәттә, интим лирика юкка чыкмый. Г. Туфан, М. Җәлил, Ф. Кәрим, Ш. Маннур, С. Хәкимнәр аның югары үрнәкләрен бирәләр. Шулай да Ә. Фәйзинең интим-хисси лириканы яклап һәм раслап чыгуы, кешенең күңел төрләрендә туган бай кичерешләрен, эчке дөньясын кыюрак сурәтләргә чакыруы бик урынлы иде. «Эпик җырга көче җитми икән», шагыйрь рухына, табигый сәләтенә якын жанрда эшләсен, кеше халәтенең бер мизгелен алып, шуның аша гомумине чагылдырсын. «Ике күбәләкнең сөешеп кушылу сулышыннан алып, дөньяларның тетрәвенә чаклы синеке», — ди ул шагыйрьгә...

Ә. Фәйзи тар субъектив хисләрне җырлаучы, халыкның социаль һәм эстетик таләпләреннән читләшкән элитар поэзия тарафдары түгел. Бер яктан, ул сентименталь, бөлмә поэзиясенә, юк-барга балавыз сыгуга каршы килсә, икенчедән, аның югары зәвыгы, гений позасына басып, гигантомания белән чирләүчеләрне дә кабул итми. Ул тормышка «бик күп елларның ыс катлавы белән капланган» тәрәзә аша карап, җанлы чынбарлыктан читләшкән поэзияне дә инкарь итә.

Чынбарлык күренешләрен сынландыру алымнары, индивидуаль стильләре, язу ысуллары һәм жанрлары төрле булса да, совет шагыйрьләрен уртак идеал якынлаштыра. Идея-эстетик якынлык, уртак тирәлек, дөньяга карашның бердәмлеге төссезлеккә, тышкы охшашлыкка алып килми. Революцион тәгълимат һәм прогрессив иҗат методы совет язучыларының эзләнүләренә көч өсти, киңлек, тирәнлек рухы бөрки.

Бу фикерләрен Ә. Фәйзи «Тышта яз...» шигырендә дәвам иттерә һәм ачыклый төшә. Шунысы кызыклы, тормышчан пафослы, тирән хисле, ачык фикерле поэзияне раслау рухы белән язылган бу әсәр, «Шагыйрь» шикелле үк, тәнкыйтькә юлыга. Мәсәлән, Х. Хәйри аны, «безнең поэзия өчен ят һәм ялгыш, иске индивидуализм рухында язылган бер шигырь», дип атый[1]. Бу «гаепләүләр» чирек гасыр элек әйтелгән.

[1] Хәсән Хәйри. Әдәбият һәм тормыш. Казан, 1953 ел. 111—112 битләр.

Тәнкыйтьче бәлки бу фикерләрен бүген кабатламас та иде. Хәер, тәнкыйтьченең фикерләре белән бәхәскә керешеп, кылыч чәкәштереп торуның да хаҗәте юк шикелле. Аларны заманында Ә. Фәйзи үзе үк кире кага[1].

Чынында «Тышта яз...» шигырендә бернинди «томанлы символик образлар» да, Такташның башлангыч чорына хас индивидуализм да юк. Безнең алда — үзенчәлекле, романтик рухлы шигырь. «Тышта яз...» — яшьлекне, иҗат юлын искә алу, уйлану җимеше. Шигырь элегик настроение-хис белән башланып китә: «Тышта яз... мин боегып өйдә утыра идем, илһамымны көтеп, сагынып яшьлегемне...» Шагыйрь, әлбәттә, тормышны алсу төсләрдә генә күреп, тоташ оптимист булып яши алмый. Ул иҗат юлында авырлык кичереп, югалып, тукталып-тәртелеп калырга да мөмкин. Башка кешеләр шикелле үк, аның моңаерга да, сагышланырга да хакы бар...

Лирик геройның авыр кичерешләрен бүлдереп, «әллә кайсы» ишекне кага. Бакса, аны күк күкрәве, яшен яшьнәве булып, яшьлек чоры, дәртле чоры борчый икән. Яшен яшьнәвен, күк күкрәвен яшьлеккә һәм иҗади уңышка тиңләү шигырьнең интонациясен тамырдан үзгәртә, яңарта. Шагыйрь минутлык йомшаклыгы өчен үзен әрли. Илһамы һәм яшьлеге аны «урамга, кырга — төзелеш мәйданына», шундагы «бөек тантанага чакыра». Нәтиҗә ачык, шагыйрь тормыш пульсын, халык сулышын тоеп яшәргә, вакытын төзелеш мәйданнарында уздырырга тиеш. Шул вакытта гына ул ирешелгән үрләреннән кайтышрак язмаячак, яшьлегенә, идеалларына һәм тормыш принципларына турылыклы калачак. Бу фикер хәзер дә актуаль һәм урынлы яңгырый.

Ә. Фәйзинең әдәби-эстетик карашлары югарыда телгә алынган моментларга гына кайтып калмый, әлбәттә. Аның поэзиядә аналитик башлангычны көчәйтү, шигъри жанрларның бөтен мөмкинлекләреннән файдалану, композицияне камилләштерү турындагы фикерләре дә игътибарга лаеклы. Ул гомере буена озын һәм буш язуга каршы көрәште. Халык иҗаты байлыкларын өйрәнү һәм язма поэзия казанышларын иҗади үзләштерү юлындагы практик һәм теоретик эзләнүләре, шигырьне җанлы сөйләм теленә якынайтуга өндәгән шигырьләре, тәнкыйть мәкаләләре киләчәктә махсус сөйләшүне көтеп калалар.

Ә. Фәйзинең иҗат тәҗрибәсендә, эстетик карашларында бик күп сүз осталары тәрбияләнде. Соңгы елларда аның мирасына игътибар үсте. Әдип яшәгән һәм иҗат иткән еллар бездән ераклашкан, тарихка табарак үткән саен, Ә. Фәйзи иҗатының кыйммәте, сәнгатьчә көче, фәлсәфи-этик тирәнлеге һәм, иң мөһиме, хәзерге әдәбиятыбызга һәм культурабызга тәэсире ныграк сизелә. Шагыйрь, үз халкының эстетик мирасына таянып, чорының алдынгы идеалларына һәм гуманизмга намус белән хезмәт итсә, ул һәр вакытта да укучының ихтирамын казана һәм киләчәккә, гасырларга үтә. Ә. Фәйзи иҗаты шул хакыйкатькә ачык мисал була ала.

· · · · · · · · · · ·

[1] Ә. Фәйзи. Әдипнең эрудициясе. 170—176 битләр.

# ФАТИХ ӘМИРХАН ИҖАТЫНДА ХАТЫН-КЫЗЛАР АЗАТЛЫГЫ ТЕМАСЫ

Татар халкының иҗтимагый-политик аңы, әдәбияты һәм мәдәниятe тарихында мәңге җуелмас эз калдырган шәхесләр бар. Г. Тукай, Г. Ибраһимов һәм Г. Коләхметовларның замандашы һәм якын дусты Ф. Әмирхан шундый мәшһүрләрнең берсе. Аның иҗаты, барыннан да элек, үзенең күпкырлы һәм тирән булуы белән җәлеп итә. Ул күренекле язучы һәм драматург кына түгел, бер үк вакытта зур эрудицияле әдәби тәнкыйтьче, ялкынлы публицист һәм җәмәгать эшлеклесе дә.

Ф. Әмирханның актив иҗаты Беренче рус революциясенең җиңелүе һәм караңгы реакция елларына туры килә. Өзлексез патша жандармнары күзәтүе астында торуына да карамастан, шушы гаять катлаулы һәм авыр бер чорда ул кешелек дөньясының, шул җөмләдән үз халкының азатлыгын һәм бәхетле тормышын идеал итеп, бөтен көчен һәм иҗат энергиясен прогрессив идеяләр өчен көрәшкә юнәлтә. Аның әсәрләрендә XX йөз башында татарлар арасында аеруча кискенләшкән фикри-иҗтимагый каршылыклар, яңаның искегә, прогрессның реакциягә, консерватизмга, милли чикләнгәнлеккә каршы көрәше, бу көрәшнең көчле һәм зәгыйфь яклары ачыктан-ачык чагылыш таптылар. Ул татар милләтен урта гасырчылык, мещанлык, социаль һәм милли тигезсезлек фаҗигасеннән коткаруны үзенең төп бурычы итеп карады.

Безнең гасыр башында прогрессив җәмәгатьчелекнең игътибарын аеруча җәлеп иткән проблемаларның берсе — хатын-кызлар азатлыгы мәсьәләсе була. Яшәп килүче иҗтимагый-политик формация белән турыдан-туры бәйләнештә торган әлеге социаль проблеманы гуманист язучы Ф. Әмирхан читләп уза алмады, әлбәттә.

Кешелекнең иң гүзәл яртысын тәшкил иткән хатын-кызлар ирләр кебек үк материаль байлык тудыра. Ул гына да түгел, алар ана дигән бөек исем йөртүчеләр. Шуңа да карамастан, Октябрь революциясенә кадәрге чорда хатын-кызларның хәле гаять дәрәҗәдә кыен була. Бер яктан нигезе байлыкка корылган ямьсез һәм тынчу урта гасырчыл тормыш кысса, икенче яктан ислам диненең караңгы кануннары газаплый аларны. Хатын-кыз ана һәм хатын булудан тыш дөньядагы барлык хокуктан, хәтта теләгән вакытында зәңгәр күккә карау мөмкинлегеннән дә мәхрүм ителгән була, юкса, йөзенә ир-ат күзе төшүе бар. Бу исә зур гөнаһ саналган. Әдәбият мәйданына 1905 нче ел революциясе тудырган бәрәкәтле шартларда килеп кергән, азатлык, демократия һәм гуманизм идеяләре белән янып яшәгән язучылар, әлбәттә, хатын-кызларның шундый авыр хәлләтенә күз йомып үтә алмыйлар.

Шулай да хатын-кызлар азатлыгы темасы әдәбиятка шушы революциядән соң гына килеп керде дип санау дөрес булмас. Бу мәсьәлә халык авыз иҗаты әсәрләренең бик борынгы җәүһәрләрендә дә әледән-әле чагылыш табып килгән. Мисал өчен «Нәүруз бәете»н генә алыйк. Аңарда ике татар кызының гыйлем алу максаты белән малайлар булып киенүе һәм ата-анадан качып мәдрәсәгә укырга керергә йөрүләре турында җырланыла. «Хәерниса бәете» белән «Фәйрүзә кыз бәете»ндә дә сүз татар хатын-кызларын зур газапларга ташлаган хокуксызлык турында бара. Алар һәркайсы үзләре яраткан кешегә тормышка чы-

гудан мәхрүм булулары аркасында гомерлек бәхетсезлеккә дучар ителгәннәр...

Татар хатын-кызларының тоташ караңгылыктан гыйбарәт булган авыр язмышы XIX гасырда яшәгән шагыйрә Газизә Сәмитова шигырьләрендә дә киң чагылыш таба.

Ә инде Беренче рус революциясе хатын-кыз хокукы, хатын-кыз азатлыгы мәсьәләсен татар җәмәгатьчелеге алдына аеруча бер кискенлек белән куйды. Шул чорда туган милли театр сәхнәсендә һәм вакытлы матбугат сәхифәләрендә дә хатын-кызларның азатлыгы һәм тигезлеген таләп итү зур яңгыраш тапты. Әдәбиятта исә хатын-кыз азатлыгы өчен көрәш аеруча көчле чагылды.

Бу темага беренчеләрдән булып иң җитди әһәмият бирүче Г. Тукай була. 1906 елның 2 нче июлендә «Уклар» журналында басылган «Татар кызларына» шигырендә ул болай ди: «Туып алтын булып, туфрак буласыз, мәгърифәттән сукыр-чукрак буласыз». Бераз соңрак язылган «Фәрьят» шигырендә шагыйрь татар хатын-кызлары тормышының бөтен ямьсез якларын гына күрсәтеп калмыйча, әлеге ямьсез тормышны тудырган шартлар һәм аңарга китергән сәбәпләрне дә ачып сала. Татар кызы ата-ананың үтә таләпчән һәм томана булуы аркасында гына иза чигәме, аның 11 яшеннән дүрт стена артына бикләнүе һәм үсеп буйга җиткәч тә юан корсаклы бер байга көчләп бирелүенә кем гаепле? дигән сорау куела шигырьдә...

Шулай таный бит дөньяны сукыр тычкан,
Шул иманда мулла, хәзрәт, ахун, ишан.
Безнең әткәй-әнкәй инде — шуларга кол,
Алар кушкач, син дә буйсын, син дә ышан!

кебек юллар җавап булып яңгырый әлеге сорауга.

Г. Ибраһимовның «Татар хатыны ниләр күрми», М. Гафуриның «Кара йөзләр» повестьларында да татар хатын-кызларының кызганыч тормышы зур дөреслек белән, тетрәндергеч итеп тасвирлана. XX йөз башында иҗат иткән шагыйрьләр Маһруй һәм Мәхмүдә Мозаффариялар дә үз әсәрләрендә әлеге ямьсез тормышның моң-зарын җырладылар.

XX йөз башы татар әдәбиятында хатын-кыз азатлыгы темасына аеруча зур әһәмият биргән язучы, бәхәссез, Фатих Әмирхан була. Ул һәр әсәрендә диярлек хокуксыз татар хатыннарының авыр язмышын тасвирлап кабатланмас образлар галереясен тудырды. Хатын-кыз азатлыгы, хатын-кыз хокукы мәсьәләсен иске тормышка каршы гомуми көрәшнең бер өлеше итеп карады Ф. Әмирхан.

Әдип хатын-кыз образларын аеруча яратып, төрле сәнгатьчә сурәтләү алымнарыннан киң файдаланып иҗат итте. Алар һәр очракта да тормышчан һәм әдәби әсәрнең үзегендә булалар. Ләкин, шуңа да карамастан, бу образлар бер-беренә аз гына да охшамаган, һәркайсының үз дөньясы, үзенә генә хас характер үзенчәлекләре бар.

Ф. Әмирхан иҗатына, мәгълүм булганча, психологик тирәнлек хас, һәм ул хаклы рәвештә әдәбиятыбызда социаль-психологик прозага нигез салучы язучыларның берсе булып санала. Шул яктан аның «Хәят» повесте аеруча зур игътибарга лаек.

Сентименталь рухта язылган «Кадерле минутлар» хикәясе, көчле сатирага корылган «Фәтхулла хәзрәт» һәм «Танымаганлыктан таныштык» әсәрләрендә дә язучы геройлар психологиясен ачып салуда үзенең гаҗәеп зур осталыгын күрсәтә. Әлеге әсәрләрнең үзегендә булган Хәят, Разия һәм Ләйлә образлары шул турыда сөйли.

Әмма Ф. Әмирхан татар хатын-кызларының гүзәллеге һәм тыйнаклыгына соклану белән генә чикләнеп калмый. Бер үк вакытта ул аларда иске, караңгы тормыш шартларыннан килгән ямьсез һәм кызганыч якларның да җитәрлек икәнлеген яхшы белә һәм шул ямьсез сыйфат һәм гадәтләргә, аларны тудырган сәбәпләргә ачы сатирасын юнәлтә. Шулай да «Рәхәт көн» хикәясеннән Гайниҗамал, «Фәтхулла хәзрәт» повестеннан Миңсылу, «Яшьләр» драмасыннан Фәхернисалар дөньяга килгәндә үк ямьсез гадәтләргә дучар ителгән булмаганнардыр бит... Юк, әлбәттә! Аларның бүгенге кызганыч халәте табигатьтән түгел, яшәп килүче иҗтимагый шартлар һәм тирәлектән дигән нәтиҗәгә килә укучы. Шуңардан чыгып Ф. Әмирхан сатирасының йөзе билгеләнә, ул, барыннан да элек, социаль-психологик сатира.

Язучының татар хатын-кызларының кызганыч тормышын күреп тирән ачынуы һәм шуңарга протесты аның «Татар кызы» хикәясендә аеруча зур социаль яңгыраш таба. Хикәянең башына: «Тереләй күмелергә теләмәгән мөселман шәрык кызларына багышлыйм», — дигән эпиграф куелган. Һәм очраклы рәвештә генә түгел. Тарихи язмалардан билгеле булганча, элекке заманнарда семьяда беренче булып кыз бала дөньяга килсә, аны тереләй җиргә

кумү йоласы яшәгән. Буржуаз-патриархаль чынбарлыкта туган татар кызлары язмышында да Ф. Әмирхан шушы куркыныч картина белән уртаклык күрә.

«Туды...

Туганда ул кеше иде: аякларын, кулларын үзе теләгәнчә селкетергә ихтыярлы, муенын теләгәнчә борудан, күзләре белән теләгәне җиргә караудан аны берәү дә тыя алмый иде», — кебек юллар белән башланып китә хикәя. Әйе, татар кызы туганда әле малайлар кебек үк тулы хокуклы бала була. Әмма бернечә ел вакыт үтүгә, инде аны күп кенә «ярамый»лар белән тыя башлыйлар. Ул акрынлап иске гадәтләр белән агуланган ата-ана тәэсире астында тере курчакка әверелә бара, аны җәмгыятьтән тулысынча читләштерүгә юнәлтелгән тәрбия башлана. Алты яшькә җитәр-җитмәс аны малайлар белән уйнаудан тыялар, янәсе, кызларга килешми. Ни өчен? Әби-бабайлардан шулай килгән, дип җавап бирәләр. Татар кызына өйдә курчаклары белән уйнау мөмкинлеге кала бит әле. Ләкин кыз бала бу уенында да азат түгел икән, аның курчаклары да тормыштагы типларга әйләнә: «...Татар кызы уйный, уйный да уйный. Кара көч, почмакка басып, елмаеп карап тора:

— Менә бу синең киләчәккә хәзерләнүең: бу киләчәктәге үз тормышың!».

Татар кызы малайлар белән бер мәдрәсәгә йөреп белем алу хокукыннан да мәхрүм ителә. Инде унөч яшькә җиткәч ул өстенә капчыкны хәтерләткән буй-буй халат кия. Шул халат аны кеше күзеннән, кояш нуры һәм саф зәңгәр күктән дә яшереп торырга тиеш. «Синең чәчләрең, йөзең, бөтен гәүдәң гаурәт. Гаурәтне каплап йөртелә. Сиңа ирләр шәһвәт белән карыйлар, шуңа күрә син алардан качарга тиеш!» — дип өйрәтәләр аны. Ә ул — күзеннән «канлы яшьләр» агызып булса да буйсынырга мәҗбүр. Шул рәвешчә ул үзенең язмышы хәл ителгәнне көтеп өйдә ятарга тиеш... Яшәп килүче җәмгыятьтәге шушы кыргый тәртипләргә, кара көчләргә кискен протест белән тәмамлана Ф. Әмирханның әлеге әсәре.

Г. Тукайның югарыда искә алынган «Фәрьят» исемле шигыренә аваздаш әлеге хикәядә, шул рәвешчә, татар кызының туганда ирекле кеше булып, үсә барган саен хокуксызлана барып, ахырда бөтен ихтыяры тартып алынган һәм дүрт стена арасында яшәргә мәҗбүр ителгән җанлы курчакка әйләнүе сурәтләнә. Хикәядә конкрет кешеләр юк, символик образлардан файдалана язучы. Бер якта, татар кызын һәр адымда эзәрлекләп, аны җанлы курчакка әверелдергән кара көч тора. Бу образда бөтен татар тормышын баскан дини фанатизм һәм иске гореф-гадәтләр гәүдәләнә. Икенче якта, татар кызлары, аларның язмышы бу очракта «татар кызы» символ аша күрсәтелә. Безгә калса, конкрет исеме булган татар кызы түгел, ә символик образ белән эш итүе, бу очракта, язучының художник буларак зур осталыгы турында сөйли. Чөнки мондый образның социаль яңгырашы гына түгел, укучыларга тәэсир итү көче дә бермә-бер артыграк.

Әдипнең иҗатын өйрәнүче галимнәрдән Х. Хисматуллин билгеләп үткәнчә, «Татар кызы» хикәясен үз чорында татар җәмәгатьчелеге һәм вакытлы матбугат гомумән һәртөрле хаксызлыкларга, җәбер-золымга каршы протест итеп кабул иткән. Аның рус һәм гарәп телләренә тәрҗемә ителүе дә очраклы хәл түгел, чөнки әсәрдә гомуми кешелек җәмгыяте өчен актуаль булган мәсьәлә күтәрелгән.

1912 елда Ф. Әмирханның әлеге темаын дәвам итеп, яшьләр тормышында дини чикләнгәнлек тудырган трагик күренешләрне тасвирлаган «Хәят» повесте дөнья күрә. Хәят, бер карашка, татар кызларына хас булмаган дәрәҗәдә ирекле, матур тормышта яши. Ул рус яшьләре белән аралаша, алар белән театрга, бакчаларга йөри, бию кичәләренә барудан да тартынмый. Кыскасы, үзенең замандашлары төшенә дә кермәгән мөмкинлекләрдән файдалана Хәят. Ләкин шуңа карамастан, ул татар хатын-кызларын гасырлар буена кысып килгән искелектән тулысынча азат түгел әле. Ф. Әмирхан повестьта Хәятның икеләнү һәм психологик каршылыкларын зур осталык белән ачып сала. Хәят рус егете Михаилны сөя. Ләкин кызның рус егетенә булган хисләренә, азатлыкка омтылышына милли чикләнгәнлек, искедән килгән гореф-гадәтләр каршы тора. Бу көрәш искелекнең җиңүе белән тәмамлана — Хәят, ата-ана кушуы буенча, сөйгән егетен ташлап, үзенә чит кешегә кияүгә чыгарга мәҗбүр була. Шул рәвешчә кызның яшьлек чәчәге сүнеп кала, тормыштагы барлык хыял һәм омтылышлары юкка чыга.

Хәят җиңелә, һәм бу табигый. Ул да шул ук чынбарлыктан, дин сөреме белән томаланган шул ук сазлыктан ич. Татар кызларын сөю-сөелү хокукыннан мәхрүм

иту һәм шул характердагы күптәрле башка кыргыйлыклар, гореф-гадәтләргә каршы протест бу повестьта Хәят образы аша дулкынландыргыч картиналарда күрсәтелде.

«Җанлы курчак»ка әверелгән татар кызы Гайниҗамал образында тагы да тирәнәя һәм конкретлаша төшә («Рәхәт көн» хикәясе). Әсәрнең сюжет сызыгы итеп алынган кечкенә генә эпизод аркылы язучы бу очракта да геройның теләк һәм омтылышлары, психикасын үзенә хас нечкә художество осталыгы белән ачып бирә. Ярлы семьядан чыккан Гайниҗамалның, Мөхип әбигә ияреп, Ташаяк ярминкәсенә баруы кыз өчен зур вакыйга. Ул анда үзен бөтенләй башка дөньядагыдай чиксез зур бәхетле итеп хис итә. Кеше-кара күрмәгәндә егетләргә күз төшереп алырга да өлгерә Гайниҗамал һәм аңа үзен бәхетле хис итү өчен шул җитә кала... Нәтиҗәдә, язучы дүрт стена артында тәрбияләнгән татар кызларының рухи дөньясы никадәр тар һәм аларның тормыштагы роле ни дәрәҗәдә кызганыч икәнлекне исбатлаучы тагы бер типик образ тудыра, хокуксыз хатын-кыз образлары галереясенә яңа бер тип өстәлә.

Әйтеп киткәнебезчә, Фатих Әмирхан хатын-кыз азатлыгы, хатын-кыз хокукы мәсьәләсен искелеккә каршы көрәшнең бер өлеше итеп карады. Дәлил итеп язучының «Яшьләр» пьесасында Газиздән әйттергән сүзләрен искә алып үтү әһәмиятле булыр. «Сез, хатыннар, бу сугышта — искелек һәм яңалык сугышларында, безнең тарафта булырга, яңалар тарафында булырга тиешләрсез»,— дип сөйли бу герой. Шул рәвешчә, язучы хатын-кызларның үзләрен дә азатлык өчен турыдан-туры көрәшкә чакырды дип әйтергә урын бар. Моның исә үз заманы өчен нинди зур әһәмияткә ия булуы турында әйтеп тә торасы юк.

Бәхәссез, XX йөз башы татар әдәбиятында Ф. Әмирхан хатын-кызлар азатлыгы мәсьәләсенә иң җитди әһәмият биргән язучы булды. Ул нинди генә әсәр өстендә эшләмәсен, бу мәсьәләне һәрчак игътибар үзәгендә тотты, хатын-кызларның кызганыч халәте өчен борчылып, өзлексез чаң сукты. Ләкин шунда ук Ф. Әмирханның ялкынлы публицист буларак та вакытлы матбугат сәхифәләрендә бу әһәмиятле социаль мәсьәләне яктыртып әледән-әле чыгыш ясап килүен күрми үтү мөмкин түгел. Мәсәлән, 1907 елда язылган мәкаләләренең берсендә традициягә кереп баручы әдәбият кичәләренең зур кимчелеге итеп, ул анда хатын-кызларның юк дәрәҗәсендә аз булуларын күрсәтеп чыга. Әдипнең 1910 елда кызлар һәм малайларны бер мәктәпләрдә укыту кирәклеген даулап язган мәкаләсе дә татар җәмәгатьчелегендә зур гына шау-шу кузгата...

Дөрес, бер мәкаләдә генә күренекле әдипнең хатын-кызлар азатлыгы мәсьәләсен көн тәртибенә куюы һәм хәл итү юлында кылган барлык эшләрен, язган әсәрләре һәм мәкаләләрен искә алып бетерү мөмкин түгел. Автор әле Октябрь революциясеннән соң да бу мәсьәләгә әледән-әле әйләнеп кайтып, яңа шартларда, аны хәл итү юлларын яктырткан махсус мәкаләләр белән чыгыш ясап килде. Шунысы куанычлы, Ф. Әмирхан әсәрләрендә яктыртылган азатлык идеяләре туган илебездә тулысынча тормышка ашты. Әдәбиятыбызның классигы иҗатында шул кадәр зур урын алган бу мәсьәләнең хәл ителүен һәм татар хатын-кызларының да ирләр белән бер сафка басып коммунистик җәмгыять төзүдә актив катнашуларын, аларның күп миллätле бөек илебезнең тулы хокуклы гражданнары булуын күреп, бүген без чын күңелдән куанабыз һәм горурланабыз.

**ГАЛИЯ ХАНТЕМИРОВА,**
**филология фәннәре кандидаты.**

Разил Вәлиев

# НИ ЧӘЧСӘҢ, ШУНЫ УРЫРСЫҢ

Балалар әдәбияты турында сүз башлауга иң элек бер сорау туа: нәрсә соң ул балалар әдәбияты, бу әдәбиятка нинди әсәрләр керә? Әлеге сорау безнең татар әдәбиятына гына кагылмый, ул турыда русларда да, чит илләрдә дә бәхәсләр бара. Күп кенә бәхәсләрдә: «Балалар әдәбияты ул — талантлы әсәрләр, һәр талантлы язылган әсәрне балалар яратып укый»,— дигән фикер алга сөрелә. Бу сүзләрдә өлешчә хаклык бар, билгеле. А. Пушкинның «Евгений Онегин», Л. Толстойның «Сугыш һәм тынычлык», М. Шолоховның «Күтәрелгән чирәм» әсәрләре балаларга атап язылмаган бит. Ә шулай да бу әсәрләрне балалар да йотылып укый, китапханәче бирмәсә, урлый-урлый, кача-кача укыйлар. Ләкин әле бу факт — качып уку факты гына «һәр талантлы әсәр балалар өчен» дип әйтергә нигез бирми. Ни әйтсәң дә, әдәбиятның алтын фондына кергән әлеге әсәрләр — балалар әдәбияты түгел. Аларның балалар арасында да шундый популяр булуының үз сәбәпләре бар. Беренчедән, бала кеше һәрчак олы булырга, олыларга охшарга тырыша, алар кыланганны кылана, алар эшләгәнне эшли. Икенчедән, монысы инде төп сәбәптер, әлеге классик әдәбият үрнәкләренең, чыннан да, балалар әдәбияты үрнәкләреннән камилрәк һәм талантлырак иҗат ителүендә.

Дөрес, балаларның зурлар өчен язылган әдәбият үрнәкләрен укуына килгәндә, бик талымлы һәм аерата сак булырга кирәк. Бакчага яисә беренче елларда мәктәпкә җитәкләп алып барган кебек, без балаларны олы әдәбиятка да җитәкләп алып керергә, аларга юл күрсәтергә, юнәлеш бирергә тиеш. Юкса, әле дөньяга үз карашы формалашмаган баланы әдәбият карурманына ялгызын гына кертеп җибәрсәң, ул анда югалып, адашып калырга мөмкин. Һәр сүзгә, һәр вакыйгага баланың реакциясе искиткеч көчле, әгәр дә бу реакциягә үз вакытында дөрес юнәлеш бирелмәсә, гомер буена төзәтелмәслек хата җибәрелергә мөмкин. Лев Толстой юкка гына, яши башлавымның беренче биш елында мин калган бөтен гомерем буена алган тәэсирләргә караганда күбрәк тәэсир алдым, дип әйтмәгәндер. Һәрберебезнең дә самолетта очкан малай күргәне бардыр. Малай кеше иллюминаторга капланган да шаккатып-гаҗәпләнеп җирне күзәтә. Аңа йортлар шырпы кабы булып күренә, кешеләр кырмыска төсле, басу-кырлар төрле төстәге ашъяулыкка охшаган. Малай әле тегене, әле моны сорый; аңа бары да яңа, бары да кызыклы...

Классик әдәбият үрнәкләрен укучы бала нәкъ менә шушы самолетта очучы малайга охшаган. Аңа һәр нәрсәне аңлатып, төшендереп бирергә кирәк. Ә бу малайның өендә үз дөньясы: үз уенчыклары, агач аты, үзенең яраткан песие, үзенең дуслары бар. Боларга инде ул үзе хуҗа. Балалар әдәбияты да менә шулай — баланың үз уйларын, үз хисләрен, аның әле яңа формалашып килүче карашын, кыскасы, баланың матди һәм рухи дөньясын чагыл-

дырырга тиеш. Мондый әдәбият баланы зур тормышка әзерли: аны яшәргә, яратырга, нәфрәтләнергә, шатланырга, үз Ватаны белән горурланырга өйрәтә.

Балалар өчен иҗат итүче язучыларыбыздан күбесенең үз бала чаклары сугыш чорына һәм шуннан соңгы елларга туры килгәнгәдерме, Бөек Ватан сугышы тематикасы узган елгы балалар әдәбиятыбызда да зур урын алган. Алардан аеруча игътибарга лаеклылары дип А. Гыйләҗевнең «Язгы кәрваннар», «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят» повестьларын һәм Ш. Рәкыйповның «Кипарислар җыры» исемле документаль повестен санарга була.

Аяз Гыйләҗев һәр вакыт диярлек үзенең әсәрләрендә тормышның әле моңа кадәр ачылмаган ягын күрсәтергә омтыла. Күңелне иң нык борчыган, бимазалаган проблемаларны күтәрә. «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят» җыентыгындагы өч әсәр дә шундый максат кыйбласына каратып иҗат ителгән. Миңа калса, повестьлар арасында иң уңышлысы, иң камиле — «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят». Автор монда Ватан сугышы чоры авылын бөтенләй яңа яктан күрсәтә, бик тә колоритлы типлар, персонажлар аша шул чор драматизмын, шул чорның ачы романтикасын тасвирлый. А. Гыйләҗев әсәренең иң отышлы сыйфаты — аның тулысы белән гуманлык нигезендә корылуы. Язучы ач-ялангач, хәерче, шыксыз тормышны сурәтләп килә-килә дә, Искәндәр белән Арзуны күрсәтеп, бөтен тирә-юньгә сафлык, җылылык иңдереп куя. Ул һәр урында этлек эшләргә әзер торган Сирай күңеленнән дә яхшылык эзли һәм таба. Язучы үзе белгән, үзе күргән нәрсәләр турында бик тәфсилләп сөйләсә дә, үзе шаһит булмаган хәлләрне йөгертеп кенә уза — фронт күренешләрен схематик рәвештә генә тасвирлый. Бу исә әсәрдә үз-үзен аклый, әдәбиятның тормышчан булуы турындагы таләпләргә турыдан-туры җавап бирә.

Ш. Рәкыйпов соңгы елларда хәрби-патриотик тематика өлкәсендә иң күп эшләгән язучыларыбызның берсе. Күптән түгел без аның «Кызлар-йолдызлар» повестен укыган идек. Инде хәзер шуның дәвамы — «Кипарислар җыры» повесте басылып чыкты.

Бу әсәрдә автор, А. Гыйләҗевтән аермалы буларак, үзе күрмәгән, үзе шаһит булмаган нәрсәләр турында яза. Ләкин Ш. Рәкыйпов уңышлы алым тапкан — ул вакыйгалар турында үзе сөйләми, геройның үзеннән, Советлар Союзы Герое легендар очучы Мәгубә Сыртлановадан сөйләтә. Әсәр совет халкының батырлык елъязмасы булу ягыннан да, конкрет мисаллар ярдәмендә яшь буынга тәрбия бирү ягыннан да искиткеч зур әһәмияткә ия. Автор очучы кызларның сугыш кырындагы халәтен гаять табигый һәм истә кала торган итеп тасвирлый. Коточкыч мәхшәр, атыш-үтереш уртасында гүзәллек, яхшылык символы булган шул кызларны күргәч, сугышның ил өчен, җир өчен, кешелек өчен никадәр кирәксез, ят нәрсә икәнлегенә тагын бер кат ачынып инанасың.

Язучы Рафаэль Мостафинны без моңа кадәр әдәбият белгече һәм М. Җәлил иҗатын өйрәнүче галим буларак белә идек. Яңа китабында да автор үз өлкәсеннән читкә тайпылмаган. «Кечкенә Муса турында хикәяләр» герой-шагыйребез турындагы әдәбиятны тагын да тулыландырды, баетты. Юкса, моңа кадәр күбрәк шагыйрьнең Моабит чоры гына игътибар үзәгенә куела иде. Р. Мостафин Мусаның кечкенәдән үк батырлыкка әзерләнеп үсүен, Бөек Октябрь революциясе утында чыныгу алуын бик гади һәм балаларга аңлаешлы итеп тасвирлый. Әсәр нәни-нәни хикәяләрдән тора, һәр хикәянең үзәгенә шагыйрьнең малай чагындагы бер гыйбрәтле вакыйга алынган. Автор бу вакыйгалардан геройшагыйрь киләчәктә күрсәтәсе сыйфатларның яралгысын эзли, таба һәм аны бик үтемле итеп укучыга да ирештерә.

Ләкин кайбер очракта язучы, онытылып китеп, матур гына барган парчаның ахырына дидактик нәтиҗә китереп ялгый, авторның әдәбият белгече булуы калкып чыга. Мәсәлән, «Сугыш» дигән парчада җанлы вакыйгалар турында образлы тел һәм сурәтләр белән сөйләп килә дә азактан, һич кирәкмәгәндә: «Җырның, шигъриятнең халык күңелендә нинди зур урын алып торуын, аларның нинди көчкә ия булганын Муса шул чакта аңлый», — дип, бик акыллы итеп өчләп куя. Уйлап карасаң, бу җөмлә хикәягә бернинди яңалык өстәми. Автор укучыга үз фикерен чәйнәп каптырырга тырышып, аны яңалык ачу, үзе шул фикергә килү мөмкинлегеннән, ачыш шатлыгыннан мәхрүм итә.

Ф. Шәфигуллинның «Әлфинур» исемле повесте (китап та «Әлфинур» дип исемләнгән) бик кирәкле, бик үтемле темага — производство темасына язылган булса да, кызганычка каршы, әдәбиятка яңалык алып

килми, бүгенге яшьләр тормышын, алар-ны борчыган проблемаларны тулысынча чагылдырмый. Әсәрнең сюжеты да примитив, геройлары да юк нәрсә өчен янып-көеп йөри сыман, уй-хисләре саф булса да, ничектер, 70 нче еллар яшьләренеке кебек түгел, ә бик беркатлы. Повестьта кирәксә дә, кирәкмәсә дә, «магазин», «цех начальнигы», «лента» кебек сүзләр очрый, югыйсә, аларны бик гади, кешечә «кибет», «цех башлыгы», «тасма» дип әйтеп булыр иде. Автор шигъри тасвирлар, матур чагыштырулар белән әсәргә җан өрергә тырышса да, повесть тернәкләнә алмаган һәм шуңа күрә аның «үз аягы белән» укучыга барып ирешәсенә шик зур.

Инде шул ук китаптагы хикәяләргә килгәндә, алар повестьтан җир белән күк кебек аерылып торалар. Автор монда сюжетны да оста кора, теле дә матур, йөгерек. Хикәяләрнең «Ликандр», «Сизгәк тәкә», «Зәңгәр шугалак», «Солдатлар кайта» дип исемләнгәннәре — арада иң уңышлылары.

Тирә-юньдәге мөхиткә, табигатькә дөрес мөнәсәбәт тәрбияләү — әдәбиятның иң мөһим бурычларыннан берсе. Бала, песи белән тычкан арасындагы мөгамәләне күреп, иң элек яхшы белән яманны, явызлык белән яхшылыкны аңларга өйрәнә, урман-сулар гүзәллеген күреп, сокланырга өйрәнә. Әдәбият балаларда табигатькә карата гуман караш тәрбияләргә бурычлы. Юкса, моңа кадәр без үзебезне табигать хуҗасы, аны ничек телисәк, шулай үзгәртә алабыз, дип уйлый идек. Хәзер балаларга кешенең әллә каян күктән төшмәгән, ә шушы гади җир баласы, җирнең, табигатьнең аерылгысыз өлеше икәнен аңлатырга кирәк. Язучы Г. Шәрәфинең «Аккошлар кайтыр әле» повестенда сүз шул турыда бара. Әсәр йөгерек тел, нечкә тойгы, кешеләргә ихтирам белән, ачык күңел белән язылган.

Шулай да табигатькә мөнәсәбәт проблемасы повестьта әле өстәнрәк, җиңелрәк чишелә кебек. Табигать трагедиясе дә җанны тетрәтерлек итеп бирелмәгән. Болын-елгаларның элекке гүзәллеген сурәтләгән юллар бик шигъри, бик матур булса да, аның бүгенге шыксыз хәлен тасвирлаганда авторның хис киеренкелеге, җан ачысы тулы көчендә ачылып бетмәгән. Шуңа күрә үткән гүзәллеккә мәхәббәт хисе олы булса да, бүгенгегә мөнәсәбәт өшшыну дәрәҗәсендә генә калган.

Язучы Г. Хәсәнов, шагыйрь Х. Халиков, Э. Шәрифуллина китаплары да шул ук темага багышланган. Г. Хәсәновның «Чүл Сайрар кошым оя тибә...» китабындагы парчалар табигатьне танып-белүдә кош-кортның, җәнлек-җанварның, үсемлекләрнең холкы-гадәтен, төс-кыяфәтен өйрәнүдә балаларга зур ярдәм итә. Парчаларның җанлы вакыйга нигезендә эшләнгәннәре бигрәк тә уңышлы чыккан. Китап ахырында кайбер исем-атамалар сүзлеге биреп тә автор бик дөрес эшләгән.

Х. Халиковның «Эшләпәле дуслар» китабы да табигатьне яратырга өнди. Агулы һәм агусыз гөмбәләрне бер-берсенә каршы куеп, автор кызык кына сюжет оештырган. Бу әсәргә композитор И. Якубов нәни генә опера да язды. Аны телевидение тамашачылары яратып карадылар, тыңладылар. Ләкин бер генә шик бар: агулы гөмбәләрне гел начар итеп күрсәтү дөреслеккә туры килә микән? Белгәнебезчә, табигатьтә бер артык нәрсә дә юк бит.

«Безнең зоопарк» китапчыгы үзенә иң элек рәссам Тавил Хаҗиәхмәтов ясаган төсле график рәсемнәре белән җәлеп итә. Э. Шәрифуллина, һәр җәнлек-җанварның үзенчәлекләрен истә тотып, матур шигырьләр язган. Ләкин М. Зарецкий тәрҗемәләренең оригиналга адекват түгеллеге, һәм, гомумән, шигъри эшләнеш ягыннан бигүк камил булмавы гына күңелдә ризасызлык хисе тудыра.

Балалар дөньясы ул — маҗаралар дөньясы. Бала һәр нәрсәдән могҗиза, маҗара эзли. Яшерен-батырын түгел, кулына газета-журнал алгач та иң беренче маҗаралы әсәрләрне укый, китапханәчедән дә фантастик әсәрләр сорый ул. Чөнки мондый әсәрләр аның хыял офыгын киңәйтә, аңбелемен, мәгълүматын арттыра.

Узган ел «Ялкын» журналында ике фантастик повесть дөнья күрде. Аның беренчесен инде укучыларга күптән мәгълүм фантастыбыз А. Тимергалин иҗат итсә, икенчесен әле бу өлкәдә яшь автор М. Хәсәнов язган. Мәхмүт Хәсәновның «Динозаврлар өнендә» повесте бик гади башланып китә. Бер класс укучылары, укытучылары белән бергәләп, сәяхәткә чыгалар. Башта барысы да гадәти: алар табигать белән хозурланалар, гербарий җыялар. Шулай урманда йөргәндә, көтмәгәндә, җир убылып, Камил белән Мәрсия җир асты патшалыгына килеп төшә. Шушы өлешенә кадәр повестьтагы хәлләр реаль җирлектә барганлыктан, укучы инде үзенең геройларына ияләшеп, алар белән дусла-шырга өлгергәнлектән, җир астындагы ма-

җаралар да чын тормышта булган хәл кебек кабул ителә. Җир асты елгасы буйлап сәяхәт иткәндә автор үзенең геройларын төрле кыен хәлләр белән очраштыра, бары тик бала хыялына гына сыярлык могҗизалар сурәтли, укучының белем маясын ишәйтә. Әсәр турында сүзне озынга сузмыйча, редакциягә килгән бер хатны гына укып китик.

«Хөрмәтле редакция!

Мин «Динозаврлар өнендә» дигән фантастик повестьны укыдым. Укыганда инәй елый-елый тыңлап торды. «Балалар әрәм була», — дип борчылды ул.

Бүтән мондый повестьлар язмагыз, юкса, инәй елый».

Гомумән, редакциягә килгән йөзләрчә хатлардан күренгәнчә, повесть үз укучыларын тапкан.

А. Тимергалиннең «Әүлия ташы» повесте инде балалыктан чыгып баручы буынга — студентлар тормышына багышланган. Әсәрдә буыннар эстафетасы да, халкыбыз тарихына хөрмәт тә, туган җиргә мәхәббәт тә бар. «Әүлия ташы» фәнни информациягә бик бай. Шунысы мөһим, аның геройлары — үзләре шул фәнни дөньяның аерылгысыз бер кисәге, алар һәр даим фәнни ачыш турында хыялланалар, уйланалар, баш ваталар, ялгышалар, тагын табалар. Повесть вакыйгаларга бик бай булмаса да, менә шул фикер һәм уй киеренкелеге аңа эчке динамика бирә, шуңа күрә әсәрне кызыксынып укыйсың.

Үткән ел «Яшь ленинчы» газетасы хикәяләргә аеруча бай булды. Газетада иң яхшы хикәягә уздырылган конкурста, гадәттәгечә, Г. Сабитов җиңеп чыкты. Конкурска килгән һәм, гомумән, газетада басылган хикәяләр тематик яктан төрле. Алар арасында Ф. Шәфигуллин, К. Кәримов әсәрләре гомум фоннан камиллекләре белән аерылып торалар.

Балаларның төп эше — уку, белем алу. Балалар арасындагы иң катлаулы, иң төп проблемалар мәктәп чорында туа. Моңа кадәр гаилә атмосферасында һәм берничә дусты арасында үскән бала катлаулы мөхиткә килеп керә. Укытучыга мөнәсәбәт, дуслар-иптәшләр, коллектив белән мөгамәлә, октябрят булу, пионерга керү, дружина, отряд сборлары һ. б. һ. б. Менә шушы катлаулы мөгамәләләрне, бала җанының үтә катлаулы халәтен бирү — балалар язучысы өчен иң катлаулы өлкәдер. Песи һәм эт, яңгыр яву һәм буран улау, йокы килү һәм физзарядка ясау турында язу — чагыштырмача җиңел эш. Чөнки аларга анык бәя биреп була, алар гомер-гомергә шулай булып килгән. Ә мәктәп тормышы, пионер тормышы көн саен үзгәреп тора, анда көн саен яңа проблемалар, яңа традицияләр туа. Соңгы елларда бүгенге мәктәп-пионер тормышыннан язылган әсәрләрнең сирәк күренүе — балалар тормышын, аларның уй-хыялларын тирәнтен белмәүдән, өйрәнмәүдән килеп чыгадыр. 1976 ел бүгенге балалар тормышының нәкъ менә бүгенге проблемаларын чагылдырган берничә әсәр бирде. Ф. Яруллинның «Яшел утрау хуҗалары», Н. Дәүлинең «Каракай — йорт эте», М. Мәһдиевнең «Ай нигә йөри?», Р. Хафизованың «Без әле кайтырбыз», Г. Минскийның «Фәридә» повестьлары, Т. Миңнуллинның «Кайда хаклык, кайда дөреслек?» пьесасы — бер ел эчендә аз түгел бу. Алар һәрберсе балалар тормышының аерым бер өлкәсен күтәрә. Мәсәлән, «Яшел утрау хуҗалары»нда пионерларның җәйге ялы, пионервожатыйлары җитәкчелегендә үз көчләре белән лагерь төзүләре турында сөйләнсә, «Каракай — йорт эте» повестенда кеше белән җәнлек-җанвар, табигать арасындагы бәйләнеш, дус мөнәсәбәт, күңел пакьлыгы, ярдәмчеллек бәян ителә. М. Мәһдиевнең «Ай нигә йөри?» әсәрендә бала психологиясе бик оста бирелгән. Авторның теле бик тә балаларча, вакыйгалары натурадан алгандай, ышандыргыч. «Кечкенә сәяхәт» хикәясендә әтисе кечкенә Искәндәргә әкият сөйләгәч, малай аннан риза булмый:

— Әти, төлке нигә тавыкны ашый ул?

— Төлке тавык ярата ул, — диде әтисе берни дә уйламыйча.

— Юк, яратмый ул аны, — диде Искәндәр кайгырып.

— Нигә алай дисең?

— Яратса, ашамас иде ул аны, — диде ул авыр сулап.

Мондый сүзне бары тик бала гына әйтә ала һәм мондый юлларны бала күңелен аңлаган балалар язучысы гына яза ала.

М. Мәһдиев шәһәр малае турында язса, Р. Хафизова авыл балалары турында, күбрәк аларның эшчәнлеге, олыларга хөрмәте, аларда туган җиргә мәхәббәт хисе тәрбияләү турында сөйли, пионер хәрәкәте проблемаларын күтәрә. Әсәрдә малайлык шуклыгы да, кызлар нәзберeклеге дә, авыл атмосферасы да, мәктәптә пионер оешмасы эше дә бик җанлы итеп тасвирланган. Повестьның иң отышлы якларыннан берсе — соңгы елларда бездә оны-

тылып баручы пионер романтикасын, балалык, мәктәп романтикасын күрсәтүендә. Әсәр җиңел укыла. Аны балалар да үз итте.

Олы һәм тәҗрибәле язучы Г. Минский «Фәридә» повестенда дөньяга бала күңеле белән, бала күзе белән карый. Шуңа күрәдер, аңа бар дөнья гүзәл, бар кешеләр яхшы булып күренә. Повестьта сурәтләнгән вакыйгалар барысы тик безнең илдә генә булырга мөмкин. Әсәрдә советча яшәү рәвеше бик образлы итеп алынган. Әгәр дә автор шушы фикергә басым ясаган булса, повестьның тәрбияви әһәмияте тагын да арткан булыр иде.

Т. Миңнуллинның «Кайда хаклык, кайда дөреслек?» пьесасы маҗаралы сюжетка корылган. Тылсымчы карт укытучы сүзен, әти-әниләре сүзен тыңламаган малайның үзен, әфсен укып, укытучыга әйләндерә, ә укытучыны малай итә. Мәктәп сәхнәләре өчен атап язылган бу әсәр мавыктыргыч һәм сәхнәдә кую өчен гади дә.

Менә ничә еллар инде Шәүкәт Галиев балалар шигърияте бөтенләе белән диярлек үз җилкәсендә күтәреп бара. Аның шигырьләрендә балалар тормышының төрле яклары урын таба. Ул — әле лирик, әле юморист, әле драматик шагыйрь.

Балалар әдәбиятына кертеп сөйләсәк тә, безнең күп әсәрләребез ул миссияне үтәп бетерми әле. Дөрес, алар балалар турында да була, балалар тормышын да чагылдыра. Әмма андый әсәрләрдә баланың үз уй-кичерешләре, үз хисләре, дөньяга карашы бирелми, ә бала турында олы кешечә уйлап языла. Балалар әдәбияты исә ул дөньяга бала күзе белән карап, вакыйгаларны бала йөрәге аша үткәреп иҗат ителгән әдәбият. Ш. Галиев нәкъ менә шундый шагыйрь дә.

«Керпе таптык» шигырендә балалар урманнан керпе алып кайталар. Ләкин ул аларга иялəшә алмый, үлә. Бала моны менә болай кичерә:

Әтисе дә, әнисе дә көтәләрдер,
Кайтыр диеп сагынышып бетәләрдер...
Алар безгә, мөгаен, гел рәнҗеп тора,
...Керпе һаман йөрәгемне чәнчеп тора...

Бу инде чын балаларча итеп, чын күңелдән әйтелгән юллар.

Шәүкәт Галиев иҗаты әле киләчәктә җентекләп өйрәнелер һәм тиешле бәясен алыр дип ышанасы килә.

Газетада һәм журналда чыккан М. Әгъләмов, Ф. Сафин, М. Галиев, Р. Миңнуллин шигырьләре арасында бик матурлары очраса да, алар олы бер вакыйгага була алмыйлар. Моның сәбәбе, минемчә, яшьләр арасында үз иҗатын бөтенләе белән балалар әдәбиятына, балалар өчен иҗатка багышлаган язучылар аз булуда. Яшьләр нәниләргә багышлаган әсәрләрне олы иҗат тәнәфесендә, я булмаса, кирәге чыкканда һәм конкрет заказ биргәндә генә язалар. Бу нәрсә әсәрләренең сыйфатына, тирәнлегенә, тәэсир көченә бик зур хилафлык китерә. Югыйсә, балалар өчен иҗат итүнең иң зур потенциаль мөмкинлеге әлеге шул яшьләр кулында бит. Беренчедән, яшь язучылар әле үзләре дә яңа мәктәп партасыннан аерылган, мәктәп формасын салган. Димәк, алар бүгенге балалар тормышын, балаларны ни кызыксындырганны, балаларның нинди уй-хыяллар белән яшәвен яхшы белә. Сүз уңаенда әйтеп үтәргә кирәк, балалар өчен язылган күп әсәрләрдә әле һаман да трафарет геройлар, дежур конфликтлар тулып ята. Безнең балаларыбыз әле һаман көне-төне чана шуа, Кар бабай ясый, мылтык тотып урманга ауга йөри. Чынлыкта исә хәзер авылда да чана шуган баланы бик сирәк күрәсең — алар хәзер боз өстендә хоккей уйный. Кызганычка каршы, Кар бабай тәгәрәтеп ясаган малай я кызны да бик еш очратмассың — алар хәзер күзләре талганчы телевизор карый, ә ауга чыгуга килгәндә, беренчедән, бала-чагага мылтык тотарга рөхсәт ителми, икенчедән, хәзер аның урманда ауга йөрерлек куяны да юк.

Күтәрелмәгән чирәм балалар әдәбиятында шактый зур әле. Форма һәм тема бертөрлелеге, фикер сайлыгы һәм хис ясалмалылыгы — бүгенге көндә балалар әдәбиятының иң зур кимчелекләре шулдыр.

Алтмышынчы елларда әдәбиятка яңа өермә алып кергән Равил Фәйзуллин, Рәдиф Гатауллин, Гәрәй Рәхим, Рөстәм Мингалимовлар балалар шигъриятенә дә яңа сулыш өрә башлаганнар иде. Ләкин бу шифалы җил нишләптер балалар әдәбиятын бөтенләе белән үз артыннан ияртә алмады. Бәлки моңа әлеге дә баягы игътибар, яңалыкны күреп алып, куәт биреп җибәрү җитенкерәмәгәндер. Үзәк матбугатта балалар әдәбияты мәсьәләләренә, аның теориясенә караган мәкаләләр, китапларга рецензияләр бик еш басыла тора. Мәскәүдә хәтта «Детская литература» дип аталган теоретик журнал да чыгып килә. Ә бездә бу өлкәгә багышланган ник бер проблемалы мәкалә күренсен! Басылган

китапларның, әсәрләрнең дә күбесе игътибардан читтә кала.

Соңгы елларда «Идел» альманахы чыга башлагач, яшьләр кинәт активлашып киттеләр. Ләкин бу активлашу күбрәк яшьләрнең үз замандашлары, үз кордашлары турындагы әсәрләр хисабына булды. Бәлки әлеге дә баягы «Идел» альманахында балалар һәм бигрәк тә яшүсмерләр өчен язылган әсәрләрне дә урнаштырырга кирәктер? Бүгенге көндә аның контингентын күбесенчә студентлар, эшче һәм авыл яшьләре хасил итә.

Әйтелгәнчә, яшь буын язучыларның балалар өчен эшләрлек көч-куәте дә, белеме дә, мөмкинлеге дә җитәрлек. Бу эшнең никадәр мөһим һәм кирәкле икәненә тирәнтен төшенеп, җиң сызганып тотынганда, яшь язучылар киләчәктә татар балалар әдәбиятына үз өлешләрен кертә алырлар. Кыскасы, яшьләр иҗатын бик нык активлаштырырга кирәк.

Яшь буынны тәрбияләү эшендә әдәбият тоткан рольнең никадәр мөһим һәм аның никадәр нәтиҗәле икәнен барыбыз да бик яхшы беләә. Бу турыда партиябез, хөкүмәтебез дә һәрчак кайгыртып, эшләгән эшләрне барлап, киләчәккә бурычларны билгеләп, алга юл күрсәтеп тора. Шушы елның январенда узган иҗат союзларының берләштерелгән пленумы — бу кайгыртучанлыкның тагын бер зур мисалы булды.

Алдагы елларда заман рухын, бүгенге балаларны борчыган проблемаларны чагылдырган әсәрләр күбрәк язылыр, әлбәттә. Повесть һәм хикәяләрдә, поэма һәм шигырьләрдә балалар мәктәп һәм пионер тормышын, отряд һәм дружина эшен, гомумән, үз яшьтәшләрен, үз ишләрен тапсыннар иде.

Безнең халыкта: «Ни чәчсәң, шуны урырсың»,— диләр. Миңа калса, балалар әдәбияты турында сөйләшү вакытында әлеге мәкальне искә алу дөрес булыр. Безгә алмашка килүче яшь буын яхшырак, инсафлырак, белемлерәк булып үссен дисәк, бүген үзебез шул сыйфатлар белән сугарылган талантлы әсәрләрне җиң сызганып иҗат итәргә тиешбез.

# ҖӘЛИЛ БЕЛӘН ЯҢАДАН ОЧРАШУ

**1955—1956** елларда Татарстан китап нәшрияты Муса Җәлилнең өч томнан торган «Сайланма әсәрләр»ен бастырып чыгарган иде[1]. Шагыйрь иҗатын мәктәпләрдә, югары уку йортларында өйрәнү һәм төрле фәнни эзләнүләр алып бару өчен ул күп еллар буена төп чыганак булып килде. Тик аннан бирле М. Җәлилнең әдәби мирасы, җәмәгать эшчәнлеге, татар совет әдәбиятын үстерүдәге роле, дошман тылында фашистларга каршы каһарманнарча көрәше турында бик күп яңа мәкаләләр, истәлекләр басылып чыкты, зур-зур монографияләр, диссертацияләр язылды. Муса Җәлил исеме, республика һәм илебез чикләрен үтеп чыгып, дөньякүләм яңгыраш алды. Шагыйрьнең иҗаты һәм тормышы белән кызыксыну елдан-ел киңәя, тирәнәя бара. Шуңа бәйле рәвештә аның яңа җыелмасы кирәклеге дә күптән сизелә иде. Ниһаять, 1975—1976 елларда Татарстан китап нәшрияты, тууына 70 ел тулуга багышлап, Муса Җәлилнең дүрт томлык әсәрләр җыелмасын бастырып чыгарды.

Әгәр өч томлыкны, алда әйтелгәнчә, нибары өч кеше хәзерләгән булса, дүрт томлык — тулы бер коллективның хезмәт җимеше. Аны СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Галимҗан Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтының әдәбият секторы чыгарган. Шул секторның мөдире, филология фәннәре докторы Н. Юзиев — томнарның фәнни редакторы, дүртенче томны төзүче, андагы әсәрләргә аңлатмалар һәм искәрмәләр язучы да. Табигый, шагыйрь әсәрләренең яңа җыелмасын хәзерләүгә нәшрият хезмәткәрләре дә якыннан торып катнашкан. Шулай да бу эшкә иң зур өлеш керткән кешеләрнең берсе шагыйрьнең дусты, Муса Җәлилнең тормыш юлын һәм иҗатын өйрәнүгә күп көч түккән күренекле әдәбият галиме мәрхүм Гази Кашшаф дисәк, һич тә ялгышмабыз.

Күргәнегезчә, безнең кулда — житди оешмалар катнашында чыгарылган коллектив иҗат нәтиҗәсе. Димәк, аңа иң житди, академик фән югарылыгындагы таләпләр нигезендә якын килергә мөмкин. Дүрт томлык ул таләпләргә җавап бирәме соң?

Сүзне томнарны төзү принципларыннан башлыйк. Беренче том тулысынча 1921—1941 елларда язылган лирик шигырьләрдән һәм балаларга багышланган әсәрләрдән тора. Икенче томда шагыйрьнең Бөек Ватан сугышы чорында язган шигырьләре һәм либреттолары тупланган. Өченче томга аның өйрәнчек әсәрләре һәм тәрҗемәләре, төрле елларда төрле кешеләргә язган хатлары, шулай ук шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлына караган биографик материаллар кертелгән. Ниһаять, дүртенче томда әдәбият-сәнгать мәсьәләләренә караган мәкаләләр һәм рецензияләр урын алган.

Бу кыскача күзәтүдән шундый нәтиҗә ясарга мөмкин: яңа дүрт томлыкта М. Җәлил иҗаты нигездә әдәби жанрларга бүлү принцибыннан чыгып урнаштырылган. Һәрбер томда, һәр бүлектә материаллар хронологик тәртиптә бирелгән. Гомумән алганда, томнарның төзелеше әллә ни бәхәс уятмый. Бу бигрәк тә беренче, икенче һәм дүртенче томнарга карый. Өченче томның эчтәлеге һәм ан-

[1] Төзүчесе Ә. Җәлилова, сүз башы һәм аңлатмалар язучы Г. Кашшаф, редакторы А. Гумеров.

дагы материалларның урнашу тәртибе исә бераз уйландыра. Әйтик, томның «Шигырьләр һәм поэмалар» бүлегендәге «Ятимнәр» шигыре 1925 елның октябрендә, ә «Абыема да, сеңелемә дә» дигәне 1926 елның ноябрендә язылган. «Беренче тәҗрибәләр» бүлегендәге шигырьләр хәтта 1918—1920 елларга карый. Хронологик принцип ягыннан караганда, бу әсәрләрнең барысы да беренче томга керергә тиеш иде. Һәрхәлдә, Җәлилнең өйрәнчек әсәрләре беренче томда урнаштырылса, отышлырак булыр иде.

Шагыйрьнең төп әсәрләреннән тыш, һәр томда искәрмәләргә һәм фәнни аңлатмаларга, башка төрле материалларга да зур урын бирелгән. Мәсәлән, икенче томның «Шагыйрь архивыннан» дип исемләнгән бүлегендә «Алтынчәч» либреттосының беренче редакциясе урнаштырылган. Муса Җәлил «Алтынчәч» әсәрен язу турында 20 нче елларда ук уйлый башлаган икән [1]. 1935—1936 елларда опера либреттосының беренче варианты язылып бетә. Шагыйрьнең архивында либреттоның уннарча варианты, өем-өем кульязмалары сакланып калган. Шул кульязмаларны ныклап өйрәнү, либреттоның төрле редакцияләрен бер-берсе белән чагыштырып карау җирлегендә әсәрнең язылу тарихын, авторның фикере тирәнәя, осталыгы камилләшә баруын күзәтергә мөмкин. Дүрт томлыкны төзүчеләр, шул эшне башлап җибәреп, либреттоның беренче һәм соңгы вариантларын чагыштырып карау мөмкинлеген ачалар.

Янсә шул ук икенче томдагы «Телдәнтелгә күчеп...» (Тоткыннар хәтерендә сакланган һәм Җәлилгә нисбәт ителгән әсәрләр) бүлеген алыйк. Аны барыннан да бигрәк Гази Кашшафның күп еллар буена алып барган тынгысыз эзләнүләре нәтиҗәсе дип карарга кирәк. Бүлектәге әсәрләр нигезендә гаять җитди нәтиҗәләр ясарга була. Алар фашист тоткынлыгында Җәлил әсәрләренең ничек иҗат ителүе, әсирләр арасында таралу шартлары, аларның коллектив иҗат җимеше булып әверелүе, бу яктан халык иҗаты әсәрләренә якынаюы кебек мәсьәләләрне өйрәнергә мөмкинлек бирәләр.

Мондый өстәмә бүлекләр башка томнарда да бар. Әйтик, өченче томдагы «Биографик материаллар» шундый характерда. Бирелә шагыйрьнең «Тормыш юлым» дип исемләнгән автобиографиясе, комсомол һәм партия оешмаларына язган гаризалары, төрле язмалары урнаштырылган. Боларның берсе дә сәнгать әсәре түгел. Әмма алар шагыйрьнең тормыш юлын, үзенең эшенә һәм вазифаларына мөнәсәбәтен ачыкларга ярдәм итәләр.

А. С. Пушкин, М. Ю. Лермонтов кебек шагыйрьләрнең талантлы рәссамнар да булулары, үзләреннән соң күп кенә рәсемнәр калдырулары яхшы билгеле. Төрле истәлекләр буенча, без Муса Җәлилнең дә талантлы рәссам булуын белә идек. Ләкин әлегә кадәр аның рәсемнәре басылып чыкканы булмады. Дүрт томлык бу бушлыкны да тутыра. Томнарда күрсәтелгәнчә, «Муса Җәлил 16 яшьтә чагында абыйсы Ибраһимның туена махсус атап шигырьләр яза, акварель белән рәсемнәр ясый һәм шуларны аерым китап итеп үзе төпли» (III том, 257 бит). Өченче томда аның шул рәсемнәре урнаштырылган.

Нинди генә китапны кулга алмыйк, укучыны яки фәнни хезмәткәрне барыннан да бигрәк аның никадәр тулы һәм киң булуы кызыксындыра. Мәсьәләгә шул ноктадан карап якын килгәндә, яңа дүрт томлык Муса Җәлилнең иҗатын ни дәрәҗәдә киң иңли, никадәр тулы чагылдыра? Бу яктан алдыбыздагы басма элекке өч томлыктан нихәтле аерыла?

Аңлатма язуыннан күренгәнчә, яңа дүрт томлык шагыйрьнең 1955—1956 еллардагы «Сайланма әсәрләр»енә нигезләнеп төзелгән. Чөнки ул моңа кадәр чыккан басмаларның иң тулысы санала. «Анда шагыйрьнең укучыларга яхшы таныш әсәрләре белән бергә, үз вакытында газета-журналларда гына басылып, җыентыкларда урын алмаган янсә басылмыйча архивларда гына сакланып калган байтак әсәрләре беренче тапкыр» дөнья күргән иде.

Дүрт томлыкны хәзерләгәндә геройшагыйрьнең әсәрләр җыелмасын тагы да тулырак итеп туплап чыгару, фәнни яктан тагы да камилрәк рәвештә укучыларга тәкъдим итү күздә тотылган. Әнә шул максатка ирешү юнәлешендә төзүчеләр зур һәм җаваплы эш башкарганнар. Шагыйрьнең әдәби мирасын тагы да тулырак туплау нияте белән матбугат һәм архив материаллары тикшерелгән; тән-

---

[1] М. Җәлил. Әсәрләр. II том, 578 бит. Алга таба җәяләр эчендә басманың томы һәм битләре генә күрсәтеләчәк.

кыйди текст булдыру йөзеннән чыгып, кульязмадагы беренче нөсхәләр төрле басмалардагы чыганаклар белән чагыштырылган. Әнә шундый катлаулы һәм авыр хезмәт нәтиҗәсендә дүрт томлык бүгенге көн таләпләренә җавап бирерлек басма булып чыккан.

Югарыда томнарга кергән материаллар турында беркадәр сөйләнде. Биредә аларның һәркайсына тукталып, тәфсилле анализ ясап тору кирәкмәс. Чөнки бу хакта моңа кадәр дә байтак язылды. Шуңа күрә без томнарда урын алган өстәмә материаллар турында гына берничә сүз әйтү белән чикләнергә булдык.

Өстәмә материаллар арасында төрле характердагы әсәрләр бар. Шигырьләрдән генә торган беренче томда, әйтик, «Байнәлмиләл», «Тәбрик», «Киңәш урынына» һәм башка байтак әсәрләр уңае белән «Беренче тапкыр басыла» диелгән. «Ерак иллərдән», «Боз ага» кебек шигырьләргә «кульязмадан алынды» дигән искәрмә бирелгән. Беренче тапкыр басылган әсәрләр икенче томда да бар. Анда «Балыкчы кыз» («Дулкыннар») дип исемләнгән опера либреттосының планы һәм бер пәрдәдән, өч картинадан торган шул ук исемдәге операның либреттосы урнаштырылган. «Беренче тапкыр басыла» яисә «М. Җәлил томнарында беренче тапкыр урнаштырыла» дигән искәрмә белән басылган әсәрләр өченче һәм дүртенче томнарда аеруча зур урын алган. Алар арасында М. Җәлил иҗатының башлангыч чорында язылган «Тартыш», «Ил корбаннары», «Кызыл таң нурлары», «Ил батыры авызыннан» кебек шигырьләр, төрле кешеләргә адресланган хатлар, «Без партия һәм комсомол чакырган фронтта», «Революцион әдәбият өчен киң походка», «Яшьләр әдәбиятын — югары баскычка!» кебек мәкаләләр бар. Әмма дүртенче томда беренче тапкыр басылган материалларның иң җитдиләре, миңа аеруча ошаганнары авторның күп санлы либреттоларга язылган әчке рецензияләре булды. Билгеле булганча, Бөек Ватан сугышы алдыннан М. Җәлил Опера һәм балет театрында әдәби бүлек мөдире булып эшли. Театрга тәкъдим ителгән һәр либретто башта әдәби бүлек мөдиренә килеп керә. М. Җәлил аларга рецензияләр яза. Һәрбер либреттоның уңышлы һәм йомшак якларын күрсәтеп бара. Опера һәм балет театрының репертуары, киңрәк мәгънәдә алганда, аның киләчәге белән бәйләнгән бу мәсьәләгә М. Җәлил зур әһәмият бирә, өметле булган һәрбер либреттоны яхшырту, камилләштерү юлларын күрсәтеп бара. Иң әһәмиятлесе шунда, либреттоларны бәяләүгә ул опера сәнгатен һәм сәхнә закончалыкларын яхшы үзләштергән белгеч буларак якын килә. Бу материалларны томнарга кертеп, төзүчеләр бик яхшы эшләгәннәр. Әйтергә кирәк, алар М. Җәлил җыелмасын күркәмләндереп, тулыландырып торалар.

Күрәсез, дүрт томлыкка байтак кына яңа материаллар урнаштырылган икән. Әйтелгәнчә, аларның шактый өлеше архивтан алынган һәм матбугатта беренче тапкыр басыла...

Ләкин сүзне тик сан һәм күләм турында гына алып бару дөрес булмас иде. Дүрт томлыкны төзүчеләр сыйфат ягын да игътибарсыз калдырмаганнар. Беренче тапкыр басылган әсәрләр арасында «нигә инде моны китапка керткәннәр» дип әйтерлек бер генә шигырь, бер генә мәкалә дә юк, минемчә. Аларның һәркайсы билгеле бер әһәмияткә ия һәм шагыйрьнең биографиясен, иҗат юлын, җәмәгатьчелек эшчәнлеген, әдәбият-сәнгать тәнкыйте өлкәсендәге хезмәтләрен киңрәк, тулырак күзалларга ярдәм итә.

«Искәрмәләр» дип исемләнгән бүлекләр элекке өч томлыкта да бар иде. Яңа басмада аларның исеме киңрәк мәгънә алган («Аңлатмалар һәм искәрмәләр»). Шуның белән бергә, эчтәлеге дә беркадәр киңәйгән. Беренче томдагы «Аңлатма һәм искәрмәләр»дә нигездә әсәрнең кайда, кайчан язылуы, беренче тапкыр кайда басылуы һәм томга кайдан алып кертелүе күрсәтелгән. Ләкин күп кенә әсәрләр уңае белән шактый киң мәгълүматлар бирелә. Мәсәлән, «Төрле парчалар» әсәренә бирелгән аңлатмада аның Ибраһим һәм Зөбәйдә Җәлиловларга багышлап язылуы, беренче тапкыр Мусаның үзе төпләп ясаган китапта урнаштырылуы һ. б. турында сөйләнә. Башка кайбер әсәрләргә карата язылган аңлатмаларда шагыйрьнең әсәр өстендә ничек эшләве, аны ничек үзгәртүе турында әйтелә. «Эш карты», «Дулкыннар итәгендә», «Еларгамы, көләргәме?» һәм башка күп кенә әсәрләргә әнә шундый киң һәм тулы аңлатмалар бирелгән.

Икенче һәм өченче томнарның аңлатма һәм искәрмәләре турында да шул ук сүзләрне кабатларга туры килә. Әйтик,

II томда «Моабит дәфтәрләре»нә карата язылган аңлатма аеруча матур тәэсир калдыра. Анда әлеге дәфтәрләрнең барлыкка килүе, аларның бер яктан мажаралы, икенче яктан трагик язмышы, коточкыч киртәләрне җимереп, озын юллар үтеп, туган илгә кайтуы яктыртыла. Яки «Телдән-телгә күчеп...» бүлегендәге әсәрләргә бирелгән искәрмәләрне алыйк. Алар тирән кызыксыну уяталар. Бу аңлатмаларны укыгач, шигъри сүзнең тәмен яхшырак тоясың, аның идея-эстетик әһәмиятен тирәнрәк аңлыйсың... «Язлар килер» шигыренә бирелгән аңлатмада мондый юллар бар: «...Әсирлектә газап чиккән һәм фашизмга каршы көрәш алып барган шагыйрьләрнең төп максаты дошманны җиңү булган, билгеле. Шигырь шул көрәштә зур корал исәпләнгән, шуңа күрә авторлыкны саклау максат итеп куелмаган, бәлки һәркем җиңү коралын коюга (шигырь иҗат итүгә) үз көчен салган. Шунлыктан кайбер шигырьләрнең күмәк иҗат җимеше булып туулары гаҗәп түгел. Ул Гыймранов блокнотында да, Әбдерәшитовта да... теркәлгән» (II том, 583—584 битләр).

Муса Җәлил искиткеч тырыш һәм эшчән, ару-талуны белми торган әдип булган. Яңа басылып чыккан дүрт томлык шуны тагы бер тапкыр раслый. Чыннан да, томнарның искәрмәләре күрсәтүенчә, М. Җәлил һәр әсәренә кат-кат әйләнеп кайта, яңадан эшли, аның телен шомарта, мәгънәсен тирәнәйтә, үзе өчен кадерле булган һәм җитди вакыйгаларга багышланган әсәрләрен аеруча яратып эшкәртә. Моның бик ачык мисалы төсендә «Алтынчәч» драматик поэмасын алырга мөмкин. Бу әсәр өстендә шагыйрь 15 ел дәвамында эшли. Янсә икенче бер мисалны — М. Җәлилнең иң матур, җырлап торган әсәрләреннән «Хат ташучы» поэмасын алыйк. Ул 1935 елларда ук языла башлый. Поэма өстендә М. Җәлил 1938 елның ахырына кадәр эшли. Шагыйрьнең бу әсәрне аеруча яратып эшләвен аңлатмадагы сүзләрдән дә күрергә була: «Шагыйрьнең архивында бик күп каралама вариантлар саклана. Аерым строфаларның уннарча варианты бар. Караламадан акка күчергәндә дә яңадан төзәтүләр ясаган. Шунысы характерлы, акка күчергәндә дә ике данә итеп күчергән: берсе — латин хәрефләре белән, берсе — рус хәрефләре белән» (III том, 604 бит).

Басыла торган һәр әсәргә төрле характердагы аңлатмалар бирү махсус эзләнүләр, фәнни тикшеренүләр алып баруны таләп итә. Моның шулай икәнен дүртенче томдагы «Аңлатма һәм искәрмәләр» тагы да ачыграк күрсәтә. Югарыда әйтелгәнчә, бу томда әдәбият һәм сәнгать мәсьәләләренә багышланган проблематик мәкаләләр һәм күп санлы рецензияләр урнаштырылган. М. Җәлил иҗатының бу юнәлеше әлегә ныклап өйрәнелмәгән. Дөрес, аның әдәби тәнкыйтьче буларак эшчәнлеге турында аерым мәкаләләр чыккан иде. Ләкин, тулаем алганда, бу мәсьәлә әлегә кадәр әдәбиятчылар игътибарыннан читтәрәк калып килә. Әнә шул яктан караганда, томдагы материалларның әһәмияте искиткеч зур. Андагы мәкаләләрнең проблематикасы гаять бай: яшь шагыйрьләр иҗаты; татар совет балалар әдәбияты; халык иҗатын җыю, бастырып чыгару һәм әдәби әсәрләрдә файдалану принциплары; татар совет драматургиясе; язучылар союзының эше һәм бурычлары; татар опера театрының репертуарын булдыру һ. б. бик күпләр...

Дүрт томлыктан күренгәнчә, М. Җәлилнең халык иҗатына карашы искиткеч бер эзлеклелек белән үсә барган. Иҗатының башлангыч чорында ук ул фольклорга зур ихтирам белән карый. Еллар үткән саен бу ихтирам тирәнәя бара... Дөрес, әдәбият тарихының кайбер мәсьәләләренә мөнәсәбәттә ул чор, заман белән бәйле тайпылулар да кичерә (РАПП, ТАПП принциплары белән мавыгып ала; Ф. Әмирхан, һ. Такташ әсәрләрен бәяләүдә кайбер ялгышлыклар җибәрә). Шагыйрь иҗатының бу моментлары томнарны төзүче һәм аңлатмалар язучы кешедән аеруча бер җитдилек, объективлык сораган. Әйтергә кирәк, Н. Юзиев бу бурычны нигездә уңышлы башкарып чыккан.

Теләсә нинди җитди басманың фәнни аппараты составында төрле характердагы күрсәткечләр, шул исәптән, алфавит тәртибендәге эчтәлек тә булырга тиеш. Мондый эчтәлек, әсәрнең исемен белгән очракта, аның кайда, ничәнче биттә басылуын ачыклауны һәм тиз арада эзләп табуны җиңеләйтә. «Алфавит тәртибендәге эчтәлек» М. Җәлилнең өч томлыгында да бар. Тик анда ул һәр томның ахырында бирелгән. Шуңа күрә шагыйрьнең берәр әсәрен эзләп табу өчен әлеге томнарның өчесен дә карап чыгарга туры килә иде. Дүрт томлыкта фәнни аппа-

ратның бу өлеше дә шактый камилләштерелгән. Биредә әлеге күрсәткеч соңгы дүртенче томда бер урынга җыеп бирелгән. Берәр әсәрне эзләп табу өчен һәр томны актарып торуның кирәге юк.

Муса Җәлилнең дүрт томлыгына гомуми бер караш ташласак, шактый җитди нәтиҗәләргә килергә тиеш булабыз. Бу җыелма М. Җәлилне шагыйрь, драматург, әдәбият-сәнгать өлкәсендәге югары квалификацияле белгеч һәм тәнкыйтьче, ару-талуны белми торган җәмәгать эшлеклесе, Бөек Ватан сугышында тиңдәшсез батырлыклар күрсәткән көрәшче буларак күз алдына китерә. Аннан соң шагыйрьнең әсәрләре, төрле характердагы биографик материаллар, рәсемнәр, хатлар, аңлатма һәм искәрмәләрдә китерелгән күп санлы һәм кызыклы мәгълүматлар М. Җәлилне шәхес буларак та күз алдына китерергә ярдәм итә. Гомумән, бу дүрт томлык хәзерге әдәби хәрәкәт өчен җитди яңалык һәм, әйтер идем, зур казаныш булып тора. Бүгенге көндә ул безнең әдәбият белеменең һәм әдәбият текстологиясенең ярыйсы ук югары дәрәҗәгә күтәрелүе турында сөйли.

Рецензияне тәмамлар алдыннан җитди бер теләк белдерәсе килә. Соңгы елларда Татарстан китап нәшрияты берсеннән-берсе матуррак җыелмалар чыгарып тора. Нәшриятның бу җитди эшенә Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтының әдәбият секторы якыннан торып катнаша. Бүгенге көндә М. Җәлилнең дүрт томлыгы, Г. Тукайның дүрт томлыгы чыкты, Г. Ибраһимовның сигез томлыгы басылып килә. Әдәбият-сәнгать белгечләре өчен генә түгел, киң катлау укучылар өчен дә бу — искиткеч матур күренеш. Аны һәрьяклап хупларга кирәк.

Шуның белән бергә, бу юнәлештәге киләчәк эшләр турында да уйласы бар. Н. Г. Чернышевскийның 1939—1953 елларда басылып чыккан тулы җыелмасы (Полное собрание сочинений) 16 томнан тора. 1960—1968 елларда И. С. Тургеневның 28 томлык тулы җыелмасы басылып чыкты. Ә инде Л. Н. Толстойның юбилей уңае белән 1928—1958 елларда басылып чыккан тулы җыелмасы 90 том тәшкил итә...

Безнең әдәбият белеменең һәм текстологиянең киләсе адымы әнә шундый тулы җыелмалар, чын мәгънәсендә күп томлыклар чыгару булыр дип уйларга кирәк. Бездә тулы җыелмаларын чыгарырга лаеклы әдипләр юк түгел. Иң элек Г. Тукай, Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, һ. Такташ һәм М. Җәлилне күрсәтәсе килә. Әлегә кадәр без бу әдипләрнең иҗади мирасы белән киң катлау укучыларны тулысынча таныштыра алганыбыз юк. Н. Исәнбәт, Г. Бәширов, С. Хәким кебек әдипләрнең мөмкин булган кадәр тулы җыелмалары кирәклеге дә сизелә.

Димәк, эшләнгән эшләр зур һәм җитди, алда торган бурычлар тагы да җитдирәк.

**ФАТИХ УРМАНЧЕЕВ,**
**филология фәннәре кандидаты.**

# ЯЗГЫ УРМАН ЯШЕЛЛЕККӘ АТЛЫЙ

Әдәбият мәйданына ышанычлы адымнар белән яңа көчләр килә. Шулардан берсе — яшь шагыйрь Разил Вәлиев. Моннан берничә ел элек аның «Зәңгәр кабырчыклар» исемле беренче шигырьләр җыентыгы дөнья күрде. Автор шул китабында ук күп санлы шигырь сөючеләр аудиториясен заман таләбе югарылыгында язылган «Авылда туй», «Әнкәйгә хат», «Сүзләрдән дисбе» кебек шигырьләре белән сөендергән иде инде.

Разил Вәлиев бүгенге яшьләр арасыннан аерата актив һәм уңышлы эшләүче, яшьлек дәрте белән кайнарланып иҗат итүче автор булып санала. Шунысы куанычлы, шагыйрь үзенең көчен төрле өлкәдә сынап карый. Аның әдәбият-сәнгать эшлеклеләренең иҗат һәм тормыш юлларын яктыртуга багышланган очерклары укучылар тарафыннан җылы кабул ителә, тәрҗемә әсәрләре дә матур гына: мәшһүр классиклар — С. Экзюперинең «Нәни принц», К. Дойльнең «Бексервельләр эте» исемле повестьлары нәни укучылар күңеленә хуш килде. Тиздән Р. Киплингның «Маугли» повесте да аның тәрҗемәсендә дөнья күрәчәк. Әледән-әле радиотелевидение тапшыруларында, концерт залларында Разил язган җырлар яңгырый. Бүген аның «Бер алманы бишкә бүләек», «Сагынам», «Дулкын», «Иделем акчарлагы» кебек җырлары халык арасында популярлык казанды.

Бу юлы сүз шагыйрь иҗатының үзенчәлекле бер тармагы — балалар өчен язылган шигырьләре турында бара. Р. Вәлиев балалар әдәбиятында бөтенләй яңа яктан ачыла. Менә 1976 елда Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан «Хыялый Мияубикә» исемле шигырьләр китабы. Ул зур күләмле түгел — нибарысы егермеләп шигырьдән генә төзелгән.

Автор һәр әсәрен зур зәвык һәм ихласлык белән, нәни укучыларга аңлаешлы, кызыклы итеп язарга тырыша. Шагыйрьнең теле шома, егәрле, җор һәм нәфис. Ул һәр шигырен үсештә, динамикада бирергә омтыла. Укучы күңелен кызыктырырлык сюжет-композицияләр тәзи, көтелмәгән гомумиләштерүләр ясый. Моның ачык мисалы — «Балык», «Хыялый Мияубикә» шигырьләре.

Туган илгә, үзең туып-үскән туфракка мәхәббәт, Ватаның белән горурлану һәм патриотизм хисе бала вакыттан ук тәрбияләнә. Шул уңайдан шагыйрьнең «Туган ил» шигыре игътибарга лаек. Ул монда әтиәниләрнең олы хезмәте нәтиҗәсендә илебезнең куәтле булып үсүен, күкрәп чәчәк атуын шигъри нечкәлек белән ачып бирә.

Чүлләрдә үсте чәчәкләр,
Бакча булды далалар,
Калкып чыкты зур калалар:
Бу — безнең абыйлар эше,
Беләсезме, балалар? —

дип язганнан соң, автор тирән мәгънәле гомумиләштерү ясый:

Зур заводлар, фабрикалар,
Ап-ак йортлы калалар,
Кыюлар, батырлар иле:
Бу — безнең туган илебез,
Беләсездер, балалар?!

Шагыйрьнең «Әлифба» шигыре дә югарыда әйтелгән фикергә аһәңдәш. Анда лирик геройның үзенә тормышта беренче адымны атларга ярдәм иткән, кояшлы илбелем дөньясын ачкан әлифбага булган иң изге хисе шагыйрьләрчә самимилек белән сурәтләнә.

Өйрәттең син мине
Ватанны сөяргә,
Рөхсәт ит, зур рәхмәт,
Мең рәхмәт! дияргә.

Җыентыкта күңелне үзенә тарткан әсәрләрдән берсе — «Санарга өйрәнгәндә» шигыре. Яу кырында зур каһарманлык күрсәткән, әмма үзе сугышта ике кулын кал-

дырып кайткан ил батырына дан җырлана ул шигырьдә. Автор моны турыдан-туры әйтеп бирми, санарга яңа өйрәнеп килүче биш яшьлек малайдан сөйләттерә. «Бабай ничек саный икән, аның бармаклары юк бит»,— дип баш вата ул. Малайга әнисе бабасының сугышта дошманнарны кыруын, шунда ике кулын берьюлы снаряд ярчыгы өздереп китүен аңлатып бирә. Малай шулай итеп җирдә сугыш дигән явыз көчнең булуын аңлый.

Берәү, икәү... Миңа биш яшь...
Санар нәрсә җирдә күп...

Шагыйрь белән килешми мөмкин түгел. Әйе, җирдә санар нәрсә күп. Яхшылыкларны, явызлыкларны санарга була. Әмма яхшы эшләр барыбер өстен чыга. Җыеп әйткәндә, шигырьнең идеясе тирән, мәгънәсе киң һәм ачык.

Бармакларым унау минем.
Ун саны бит түгәрәк.
Бабай җиңгән дошманнарны
Санайк, әйдә, бергәләп,—

кебек юллар белән тәмамлана шигырь.

Шагыйрь табигать турында язылган шигырьләрендә дөньяга рәссам күзе белән карый. Образларга бай ул шигырьләрне укыган бала күңелендә табигатьне ярату хисе уянуга икеләнмим. «Язгы урман» шигырен алыйк.

Ак каенның күзенә
Күренә тик яшеллек...

Алтын кояш нур җебеннән
Күлмәк тегә аларга.

Бу юллардан нәфислек, сафлык бөркелә кебек.

Авторның «Табигать балалары», «Хуш, иске ел!» шигырьләре дә нәк шундый җылылык белән язылган. Бу әсәрләрдә табигатьнең матурлыгын бөтен нечкәлеге белән тоясың. «Кечкә кояш», «Оча карлар» шигырьләре җылы язылган.

Оча карлар, мамык карлар,
Очар талганчы...
Кошлар кайтып, каурыйларын
Җыеп алганчы.

Күрүебезчә, авторның укучы балалар күңеленә хуш килерлек шигырьләре аз түгел. «Елаудан үзе туктады», «Ни өчен», «Барысын да яратам» дигән әсәрләрен дә уңай яктан телгә аласы килә. Алар тәрбияви яктан да бик әһәмиятлеләр. Кыскасы, Разил Вәлиевнең балалар өчен чыккан бу китабы күңелдә яхшы гына тәэсир калдыра.

Ләкин җыентыкка кергән барлык шигырьләр дә бердәй югарылыкта язылган дип әйтеп булмый әле. Мәсәлән, «Уенчыклар» шигырендә ул «машинама бар гаражым, анысын үзем ясаган» дип яза. Рифмага туры килсен өчен генә «үзем ясаган» дияргә кирәк булмагандыр, әлбәттә. Шул ук шигырьдә нәни малай: «Ир-егет булып җитешсен, үссен дә малай чагым» ди. Сабый балага «Ир-егет булып җитешсен» дип фикер йөртү хас микән? Еш кына тел-стиль һәм рифма кытыршылыгы да сизелеп китә. Ә балалар өчен иҗат итүче кешегә мондый мәсьәләләрдә үтә сак һәм таләпчән булырга кирәк түгелме икән? Чөнки бала күңеле һәрчак матурлыкка, камиллеккә омтыла бит.

Шагыйрь — үсеш баскычында. Әлеге җыентыгында тасвир ителгән язгы урман кебек аның иҗаты шаулап яфрак атар, яңа төсмерләр, моңлы аһәңнәр белән баный барыр диярге тулы нигез бар. Чөнки язгы урман җәйгә таба, яшеллеккә карап атлый.

**ГОСМАН САДӘ.**

# ҺАМАН ЮЛДА...

Диңгездә бер җилкәнле кораб чайкала. Аның капитаны җир тирәли сәяхәткә, бу көнгә кадәр ачылмаган утрауларны эзләп юлга чыккан.

Кулымда — шагыйрь Рәдиф Гатауллинның 1976 елда дөнья күргән «Йолдыз җиле» дип исемләнгән шигырьләр җыентыгы. Диңгез турындагы уйлар белән җыентыкның беренче битен ачтым һәм шунда ук йөземә бүгенге һәм киләчәк тормыш белән янып яшәүче лирик геройның кайнар сулышы килеп бәрелде. «Алибилар булмас» дип аталган шигырьне укыйбыз:

**Дөнья өчен янып яшәмәсәк,**
**тарих гафу итмәс безне,**
**алибилар булмас,**
**чордашларым.**

**Үзе гаеп бүген:**
**— Мин гаепсез, намусым пакь,— диеп,**
**үз-үзеңне юатып яшәү,**
**җирдәшләрем! —**

ди шагыйрь үзе белән бер планетада яшәүче замандашларына мөрәҗәгать итеп.

Шул ук рухта язылган «Ялкыны тия» шигырендәге:

**Кемнәр яный тынычлыкка анда**
**янган факел тотып!!**
**Геростратларга бирелмәсме**
**Прометейның уты!! —**

кебек юллар да «Алибилар булмас»ның дәвамы булып яңгырый.

Шагыйрьнең моңарчы дөнья күргән «Бүген ачулы мин», «Язмыш кинаясе», «Трагикомедия» кебек кырыс хакыйкатьне ачып бирүче шигырьләренә «Йолдыз җиле» җыентыгыннан тагы берничә яңа әсәр өстәлде. «Дөнья бит...» — шундыйларның берсе:

**Әйтерсез: «Кемнәр ул!»**
**Сорарсыз: «Ул кайда!»**
**...Казанда көчекләр**
**Өргәннәр Тукайга.**

Әйе, Тукайга күпне күрергә туры килгән. Аңа һәр яктан — газетадан да, почмактан да, Болактан да һөҗүм иткәннәр, шагыйрь әйтмешли, «һау-һаулап йөргәннәр».

Тик шагыйрь үткәнне генә сөйләп чыкса, бу әле шигырь булмас иде. Автор Тукай заманын бүгенге көн белән бәйли.

**Этләргә бәхәскә**
**урын юк бугай да;**
**Дөнья бит... Кайвакыт**
**Өрәләр шулай да.**

Рәдиф Гатауллин — Башкортстанда, ерак Марс авылында туып-үскән шагыйрь.

**Мин — Марстан. Юк, йолдыздан түгел,**
**Җирдәге бер матур авылдан.**
**Әмма миңа барыбер йолдыз җиле,**
**Йолдыз җене, диләр, кагылган, —**

ди шагыйрь «Йолдыз җиле» шигырендә. Мин бу шигырьне шагыйрьнең визит карточкасы дип атар идем. Зур идеяле, югары художестволы һәм нечкә лиризм белән сугарылган бу әсәр хәзерге поэзиябездә мактаулы урыннарның берсен тотарга лаеклы.

Шагыйрьнең бу шигыре 1970 елда басылган «Күңел ташлары» җыентыгында да урын алган иде, бу юлы инде ул шактый гына үзгәрешләр кичергән.

Әмма «Мин-Җирский: тузан бер, бала» дигән юлларны «Мин — Җирдәге тузан бер, бала» дип үзгәртү кирәк тә булмагандыр. Башка телдән кергән «марсиян» сүзенә каршы автор тарафыннан уйлап табылган «Җирский» сүзен куллану отышлырактыр бәлки.

Р. Гатауллин поэзиягә көчле романтикасы, шашкын хисләре белән килеп керде. Тик шагыйрь үсә барган саен тормышка һаман якынрак килә, димәк, тормышчанлык элементлары да көчәйгәннән-көчәя. Хәзер шагыйрьнең иҗади эзләнүләр чоры. Моның шулай икәнен җыентыкка кергән шигырьләрдән дә күреп була. Гражданлык пафосы бөркелеп торган «Җырның җире», «Күзләрендә — тормыш», «Авылым Марс малайлары», «Заман китабына», «Шагыйрьгә» шигырьләре белән беррәттән «Бәллүр илдә» кебек чынбарлыктан аерылган романтика да очрый әле шагыйрь иҗатында.

Җыентыкка кергән лирик шигырьләрдән бигрәк тә «Уйларымда Лаура» күңелне җәлеп итәрлек итеп язылган. Әйе, Рәдиф Гатауллин классик образларны ярата һәм мул куллана. Шагыйрь шуларда бүгенге шәхеснең чагылышын, алар арасында уртак якларны күрә һәм шуңардан шигырьләрендә матур гына файдалана да белә.

**Ләкин, үз Мадоннам, бу җанымны**
**хисләреңдә җылытса идең.**
**Юккамыни уйларымда Лаура,**
**Беатриче — җырымда минем!! —**

ди шагыйрь. «Уйларымда Лаура» — үзенең художество эшләнеше, композицион төзелеше ягыннан җыентыкка кергән иң камил шигырьләрнең берсе. Мәхәббәт хисләре һәм фәлсәфи уйланулар да бар бу шигырьдә.

Җыентыкта мәхәббәт шигырьләре үзләре бер бүлек тәшкил итәләр. «Мәхәббәттән башка» ... дип аталган шигырь белән башланып киткән бу бүлектә шагыйрь, чыннан да, үзенә иярәп әйтсәк, **«Мәхәббәтнең** Мәҗнүн премиясе»нә лаек әсәрләр тудырган. «Хатлашудан бәлки башладык без», «Кызыл яулыгың бик килешә сиңа», «Шигыремнең юк исеме», «Авылдан хат», «Синең яктың» кебек шигырьләр һәркемнең йөрәгенә барып җитәрлек итеп язылганнар. Гомумән, Рәдиф Гатауллинның мәхәббәт лирикасы — үзе бер дөнья.

**Кызыл яулыгыңдай кызарма тик,**
**Кызыл гөлем, дисәм.**
**Кемнең генә күзе бездә булмас,**
**Син янымнан китсәң! —**

кебек хис ташып торган юлларны шагыйрь иҗатыннан бик күпләп китерергә мөмкин булыр иде.

Шагыйрьнең «Бөеклек» турында дигән шигырендә:

**Әмма бәла:**
**Нидер миңа җитми, нидер һаман ерак, биек.**
**... Шуны уйлап, «бөек» күңелем бүген боек, —**

кебек юллар бар. Әйе, «Йолдыз җиле» җыентыгында матур каләм белән язылган әсәрләр белән беррәттән, художество ягыннан эшләнеп бетмәгән шигырьләр дә очрый әле. Алыйк «Гафу үтенмә син» шигырен.

**Мин дә — хәзер яшерү нигә! —**
**янып, шашып яратмадым.**
**Якын килгәч,**
**иң кадерле сүз әйтелгәч,**
**кире чигенү кыен иде —**
**оялдым да, тик уйнадым.**

Чынбарлыкта мондый хиснең булуы мөмкин микән?! Мәхәббәттә ничек булса да естен чыгарга тырышып кына язылган әсәр түгелме бу?!

Шагыйрьнең кайбер шигырьләрендә прозага тартым юллар да очраштыргалый. Мисал өчен «Парижда» дигән шигырьне алыйк. Әсәр Назыйм Хикмәткә иярәп язылган. Ләкин Н. Хикмәт шигырьләрендә һәр юл, һәр сүз үз урынында. Андагы бер генә сүзне урыныннан күчерсәң дә, шигырьнең ритмы бозылачак. Ә менә Рәдиф Гатауллинның:

**Ә син миңа сыенырсың шунда**
**куркынып,**
**гаҗәпсенеп,**
**тын гына елап,**
**шатлык белән... —**

кебек юлларындагы сүзләрнең урыннарын төрлечә үзгәртергә мөмкин. Аңа карап шигырьнең ритмы да, мәгънәсе дә үзгәрми. Димәк, бу — шагыйрьнең киләчәктә игътибар итәргә тиешле бер җитешсез ягы әле.

—Диңгездә бер җилкәнле кораб чайкала. Аның капитаны җир тирәли сәяхәткә, бу көнгә кадәр ачылмаган утрауларны эзләп, юлга чыккан. Ә без — аны озатып калучылар — капитанга зур уңышлар телик, Магелланнар булып, кире әйләнеп кайтуын көтик.

Газинур МОРАТОВ,
КДУның I курс студенты.

# БЕЗНЕҢ САФКА

*
* *

*1976 елда СССР Язучылар союзына яңа членнар итеп Татарстаннан тагын берничә иптәш кабул ителде. Шуларның икесе — яшьләр. Членлыкка тәкъдим иткәндә аларга өлкән язучыларыбыз әйткән хәерле юл теләү сүзләренең дә берәрсе белән без (аларны һәркемгә өч кеше бирә) укучыларыбызны киләчәктә дә таныштыра барачакбыз.*



Мин аны күптән беләм. Исеме аның — Адлер. Фамилиясен дә кушып әйтсәк — Адлер Тимергалин. Адлер немецча «бөркет» дигән сүз. Әтисе белән әнисе, улларына шундый яңгыравык исем кушканда, бу сүзнең чын мәгънәсен белделәр микән, юк микән — әйтеп булмый. Ләкин «адлер»ның бөркет икәнлеген белмәгән очракта да алар үз улларын киләчәктә бөркет кебек көчле һәм батыр итеп күрергә теләгәннәрдер, билгеле.

Ләкин Сарман районының Иске Минзәләбаш авылында туган Адлер шулай да гап-гади бер малай булып үсә: башкалар кебек үк балык тота, җиләккә йөри, кышкы суыкларда битен-борынын туңдырып та кергәли. Әмма аның бер үзенчәлеге була: тышта кар атышып, аяк-кулларын туңдырып кергәннән соң, малай, бер дөньясын онытып, китап укырга ярата.

... Хәзер дә ул ерактан ук күзгә ташланып торган «әллә кем» түгел. Уртача буй, аксыл-саргылт чәч, зәңгәрсу күзләр, Уйчан, моңсу күзләр... Сөйләшкәндә ул дусларча, җиңелчә шаяртырга ярата, көтелмәгән тапкыр сүз әйтеп көлдереп ала. Менә аның бик үк тулы булмаган тышкы кыяфәте.

Эчке «кыяфәтенең» иң беренче сыйфаты — тыйнаклык дип әйтер идем. Аның бу тыйнаклыгы еш кына ихтыярсызлык булып та күренергә мөмкин. Шуңа күрәдер, ахрысы, илленче елларның азакларында Татарстан китап нәшриятының фән-техника әдәбияты редакциясендә редактор булып эшли башлаган яңа танышым Адлер белән бик тиз генә якынаеп китә алмадым. Без — дипломлы әдәбиятчылар, Адлер — фән-техника әдәбияты редакторы. Өенә барсаң, өстәлендә тимер-томырлар... ниндидер транзисторлар, диодлар, чыбык ураган кәтүкләр... Укыган китаплары да физика, астрономия, техника һәм гомумән шуның ише баш катыргыч нәрсәләр.

Ләкин яңа танышым белән ныграк аралашкан саен мин аның «чын» әдәбиятчыларда булмый торган кайбер хикмәтле якларын да күрә башладым. Иң элек аның фәнтехника белән кирәк булган өчен генә түгел, яраткан өчен дә мавыкканлыгын аңладым. Аннары шунысы да мәгълүм булды: фән-техниканың нинди генә тармагы турында сүз чыкмасын, ул үзен һәр нәрсәдән хәбәрдар итеп танытты һәм озакламый безнең арада үзенә күрә бер аяклы энциклопедиягә әйләнде.

Адлер авыл мәктәбендә укыган чагында ук инде барлы-юклы детальләрдән детекторлы радиоалгыч ясый, эретеп ябыштырырга, юнарга, кисәргә, чүкергә һәм башка шундый һөнәрләргә өйрәнә. Физика дәресендә аңа иң кызык, иң җиңел фән булып физика тоелса, химия дәресендә ул, бар нәрсәсен онытып, химик әверелешләр дөньясына чума. Шундый «чуму» вакытларының берсендә (мәктәп лабораториясендә тәҗрибәләр ясаганда) ул терекөмеш парлары белән агуланганын да сизми кала... Йомшак күңелле, уйчан малай, төннәрен күккә карап, айны, йолдызларны күзәтергә дә ярата. Чит планеталарга барып җитү өчен канатлар кирәклеген малай бик яхшы аңлый. Үзе яраткан, үзе теләгән китапларны укый, аннары аларны читтән эзләп тә таба башлый. Унынчы классны тәмамлаганда Адлер инде катгый фикергә килә: берничә карамыйча ул астроном булырга тиеш! Шундый теләк белән Казанга килә,

университетның физика-математика факультетына керү имтиханнары тапшыра. Аны астрономия бүлегенә кабул итәләр.

Әмма Адлерга университетны тәмамлау насыйп булмый — ул икенче курстан укуын ташларга мәҗбүр була. Йолдызлар, планеталар серен ачарга хыялланган егет астрономияне үзлегеннән өйрәнүен дәвам итә. Хәер, өйрәнүдән аның беркайчан да туктаганы юк. Менә әле дә аның эш бүлмәсендә Ай глобусы, кечкенә телескоп тора, өстәлендә күк йөзе карталары.



Әгәр дә мәгәр аның физика, математика, астрономия, химия, геология, биология кебек төгәл фәннәр белән мавыгуы турында сөйләп тә, тел һәм әдәбият белән, тарих белән кызыксынуы турында берни әйтми калсак, портрет тулы булмас иде. Адлер Тимергалин нәшриятта редактор булып эшләү дәверендә «Русча-татарча техник терминнар сүзлеге»н, «Русча-татарча астрономия терминнары», «Русча-татарча авыл хуҗалыгы терминнары» сүзлекләрен төзүдә катнаша, физика, астрономия һәм гомумән техникага кагылышлы татарча терминнар булдыруда, аларны кулланышка кертүдә зур тырышлык белән эшли. Шул ук вакытта ул төзелешкә, агач, тимер эшләренә караган халык сүзләрен-атамаларын җыйнау белән дә шөгыльләнә.

1965 елда Татарстан китап нәшриятында «Ял сәгатьләрендә» дип аталган бер китап басылып чыкты. Анда төрле башваткычлар, табышмаклар, кечкенә фокуслар, чайнворд-кроссворд кебек нәрсәләр, төрле уеннар, математика һәм логика мәсьәләләре тупланган. Китапны Ә. Кәримуллин белән А. Тимергалиннар төзегән. Монда урнаштырылган материалларның күбесен алар үзләре иҗат иткәннәр иде.

Адлер Тимергалин төрле сүзлекләр, табышмаклар, башваткычлар, логик мәсьәләләр авторы буларак та, яхшы юморист буларак та билгеле. «Чаян» журналында аның оста, үткер тел белән язылган кыска-кыска юмористик парчалары, фельетоннары күренгәләде. Аның менә шушы күп төрле мавыгуларына, кызыксынуларына тагын бер әһәмиятле детальне өстәргә кирәк. Сүз аның китап «җене» кагылган кеше булуы хакында бара. Адлер китапны укырга гына түгел, җыярга да ярата. Дөрес, китап җыю белән китап уку бер-берсенә бәйле нәрсә — укырга яратмаган кеше китапны җыярга да яратмый. Адлерның өй китапханәсендә берничә мең китабы бар. Шулар арасыннан Ш. Мәрҗани, Р. Фәхертдин әсәрләрен, атаклы философлардан Әбүгалисина, Платон, Аристотель томнарын, татар, рус һәм дөнья тарихына кагылышлы китапларны табарга мөмкин. һәм, әлбәттә, сүзлекләр, энциклопедияләр, белешмәләр... Аннары — классик матур әдәбият. Татарча, русча, немецча...

Әмма әйтергә теләгәнебезнең иң кирәге шул: Адлерның якын дуслары чынында физика да, химия дә, астрономия дә түгел. Аның якын дусты — әдәбият, фантастика. Күп төрле төгәл һәм гуманитар фәннәрне ул галим яисә инженер буларак түгел, фантаст буларак, язучы-художник буларак өйрәнә.

Фантастик әдәбиятта реаль булмаган тормыш, башлыча киләчәк тормыш турында сүз бара. Фантаст язучы реаль булмаган дөньяны булган итеп күз алдына китерә һәм реаль итеп, ышандыргыч итеп сурәтли. Бу очракта ул чын мәгънәсендә күрәзәлек итә. Ләкин бу дини-мистик күрәзәлек түгел. Фантаст язучының «күрәзәсе» тулысынча фәнни логикага нигезләнгән була. Фантаст язучы, әгәр ул арттa калырга теләмәсә, күп төрле, күп тармаклы, катлаулы һәм туктаусыз хәрәкәттәге фәнне күзәтеп барырга, аның үсеш тенденцияләрен дөрес аңларга тиеш. Бөтен дөньяга атаклы фантаст язучыларның «коеп куйган» әдәбиятчы гына булмыйча, берәр төрле фән өлкәсендә белгеч-галим дә булуларын искә төшерсәк, мәсьәлә тагын да ачыкланыр дип уйлыйм. Мәсәлән, Американың атаклы фантасты Айзек Азимов — химия һәм микробиология профессоры, инглиз Артур Кларк — астроном, поляк Станислав Лем — медик, рус совет фантасты Иван Ефремов — геолог һәм палеонтолог һ. б. Шулай итеп, фантаст язучы... язучы булуы белән бергә, күпмедер дәрәҗәдә галим дә һәм, әлбәттә, хыял остасы да булырга тиеш икән. Бу — бик авыр нәрсә. Бик аз кешеләр генә мондый бәхеткә, мондый югарылыкка ирешә ала.

Адлер Тимергалин шундый бәхетлеләрнең берсе. 1960 елда аның «Пәһлеван кабере» дип аталган беренче китабы чыга. Китапка барлыгы өч хикәя тупланган һәм аның титул битенә: «Маҗаралы һәм фантастик хикәяләр» дип куелган. Күрәсез, «фантастик» сүзе икенче урында тора. Авторның әлегә үзен фантаст дип уйларга кыюлыгы җитми сыман. Чыннан да, «Пәһлеван кабере» — авторының серле, хыялый жанрда беренче

алымы гына. Каушабрак атлаган беренче адымы. Бала чакта ят һәм караңгы урманга килеп кергәч, һәрвакыт шулай куркып-сагаеп атлыйсың. Йөрәгең җитсә, туктаусыз алга барасың, йөрәгең җитмәсә, кире борыласың я булмаса, ят җирне әйләнеп үтмәкче булып, урман буйлап китәсең.

Адлер Тимергалин кире дә борылмый, әйләнеп тә үтми — үзе сайлаган авыр юлдан эз ярып турыдан китә. Беренче китаптан соң икенчесе, өченчесе дөнья күрә. 1965 елда басылып чыккан икенче китабы — «Ике хикәя, бер хыял» дип, 1967 елда чыкканы — «Ерак планетада» дип атала. Икенче китаптагы өч хикәянең бары берсе генә фантастик булса, өченче китапның титул битенә инде автор курыкмыйча: «фантастик хикәяләр» дип куя. Моннан соң ул үз-үзенә нык ышанып иҗат итә, эзләнә, яңадан-яңа «дөньялар», геройлар тудыра. 1969 елда аның «Мәңгелек хатирәләр», 1972 елда «Кохау ронго-ронго», 1974 елда «Космостан кунаклар» дип аталган җыентыклары басыла.

Адлер Тимергалин иҗаты, кайбер өйрәнчек хикәяләрен исәпкә алмаганда, тулысынча фәнни-фантастика таләпләренә җавап бирә. Билгеле, аның хикәяләрендә дә шаккатыргыч нәрсәләр тасвирлана. Аның геройлары, мәсәлән, ракеталарга утырып, башка планеталарга барып чыгалар, андагы ят, сәер тереклек ияләре белән очрашалар, я булмаса үзебезнең җирдә акыллы машиналар, төрле аппаратлар ярдәмендә искиткеч могҗизалар ясыйлар. Ләкин аларның һәрбер адымы, һәрбер эше-кыланышы һәр яктан фәнни мәгълүматлар, фәнни гипотезалар һәм логика белән ныгытылган.

Катлаулы законнарны, логик мәсьәләләрне, төрле машина-аппаратларны, ят профессия кешеләрен автор укучыга ничегрәк итеп аңлата соң, ничегрәк итеп сурәтли һәм ничегрәк итеп җиткерә соң? Бит монда, теләсәң дә, теләмәсәң дә, коры формулалардан, аңлаешсыз чит терминнардан котылып булмаячак кебек. Аннары шунысын да онытмыйк: фәнни-фантастик әсәр ул фән-техника турында белешмәлек була алмый. Барыннан да элек ул — әдәби әсәр, махсус әзерлеге булмаган укучы өчен дә яхшы аңлашыла торган саф әдәби әсәр булырга тиеш.

Адлер Тимергалин менә бу авыр һәм катлаулы мәсьәләне дә уңышлы чишә алган дип әйтәсе килә. Аның фантастик хикәяләре һәркемгә аңлаешлы татарча әдәби тел белән язылган. Махсус терминнарны автор кирәк кадәр генә, чамасын белеп кенә куллана, һәм хикәяләрне укыганда бу бөтенләй сизелми дә.

Хикәя җиңел укылсын өчен аның аңлаешлы тел белән язылуы гына җитми, әлбәттә. Әсәрнең сюжеты, идеясе тиешле дәрәҗәдә эшләнгән булмаса, бернинди «аңлаешлылык» та аны чын сәнгать әсәре итә алмаячак. Адлер Тимергалин хикәяләрен ихлас бер кызыксыну белән ялыкмыйча, йотлыгып укыйсың. Фантастика жанрында автор үзен чын мәгънәсендә хыял остасы да, сюжет остасы да итеп таныта. Сюжет корылышы, конфликтларның кискенлеге буенча аның кайбер хикәяләре («Рибб Локсның үлеме», «Җинаятьче», «Кайтыр юллар», «Кабул булсын теләгең») дөнья әдәбиятының иң яхшы фантастик әсәрләре белән янәшә куеп каралырга хаклы.

Күтәргән проблемалары буенча да Адлер дөнья әдәбиятының иң яхшы традицияләре — гуманистик идеяләрне яклау традициясе эзеннән бара. Язучының геройлары космик киңлекләрдә дә, кибернетик аппаратлар белән идарә ителә торган Җир тормышы шартларында да һәр төрле яманлыкка, вәхшилеккә каршы көрәшәләр һәм җиңеп чыгалар. «Рибб Локсның үлеме» дигән хикәядә, мәсәлән, капиталистик җәмгыять тарафыннан ялгызлыкка, бәхетсезлеккә дучар ителгән талантлы галим язмышы тасвирлана. Үзен җәберләүчеләрдән үч алмакчы булып, ул бөтен кешелекне юк итә алырдай бактерияләр үрчетә. Ләкин, гаделсез җәмгыять белән бөтен кешелекне бутарга ярамаганлыгын аңлап, үзеннән соң яшәячәк кешеләр хакына, бу куркыныч уеннан кире кайта...

Гомере буена күккә, биеккә ашу турында хыялланган Беркет-Адлер тыштан карaганда бик юаш, тыйнак кеше. Җыелышларда ул беркайчанда алда утырмас, беркайчан шаулап, даулашып трибунага күтәрелмәс. Ләкин без — Адлерның дуслары да, тәнкыйтьчеләр дә — арабызда талантлы язучы барлыгын һәр вакыт истә тотарбыз дип уйларга кирәк. Шуның белән бергә, изге теләк тә белдерәсе килә: хыялый каләмдәшебез киләчәктә дә әдәбият дөньясында яңадан-яңа йолдызлар-планеталар яулап алсын.

**НУРИХАН ФӘТТАХ.**

* *
*



Габделхәй Сабитов әдәбиятка өйрәнчек булып килмәде. «Ялкын» журналына беренче китергән хикәясе — «Туган җир туфрагы» ук җитлеккән, күңелне кузгатырлык хикәя иде. Шуннан соң газета-журнал битләрендә зурлар һәм балалар өчен язган хикәяләре чыгып килде. Габделхәйнең әдәби күнегүләре матбугат битләрендә түгел, эш өстәле артында бара булса кирәк, чөнки дөнья күргән әсәрләре тел тидермәслек итеп эшләнгән була. Ул тормышчан, реалистик буяулар белән эш итә, әдәби тел нечкәлекләренә сизгер, кечкенә штрихлар белән дә портрет тудыра белә. Мәсәлән, «Бизәкле чиләк» хикәясендәге малайны болай сурәтли: «Янәшәмдә, кулына мылтык тотып, базык кына гәүдәле бер малай басып тора. Аның аягындагы резин итекләре, юка сатин чалбары тез тиңентен үлән чыгына баткан. Өстендә сары майка, башы ялангач».




Саран буяулар белән бирелгән портрет бу. Ләкин шул юлларны укыгач һәркем аны үзенчә тулыландыра. Малайның кояшта агарып беткән чәчләрен, юеш чалбар аркылы беленеп торган сөякчел тез башларын күргәндәй буласың. Шулай тәэсир көче һәр хикәядә бар. Хикәяләре күләм ягыннан артык зур түгел. Әмма геройларының эчке дөньясын ачуда, бүгенге көн кешеләренең омтылышын күрсәтүдә бу мәйданны ул шактый уңышлы файдалана.

Яшь китап сөючеләр аның «Туган җир туфрагы», «Карурманның күзләре бар», «Үлемсез Акылгали» исемле әкият һәм хикәя китаплары белән таныштылар. Соңгы елларда исә Габделхәй Сабитов драма әсәрләре дә яза башлады. Республикабызның Минзәлә театры аның «Кичерелмәс гөнаһ» һәм Лена вакыйгаларыннан алып язылган «Гарасат» пьесаларын куйды. «Үлемсез Акылгали» дигән әсәре Казан һәм Уфа курчак театрларына кабул ителде.

**ЛӘБИБӘ ИХСАНОВА**

*
* *



Әхәт Гаффаровны аның университетта укыган вакытыннан, журналистика өлкәсендә эшләгән эшләре, иҗади парчалары, зарисовкалары аша беләм. Университетны тәмамлаганда ул диплом эше итеп иҗади хезмәтләрен тәкъдим иткән иде. Ул дипломны ГЭК иң югары бәягә лаек дип тапты. Хәзер менә аның «Әҗәт» исемле беренче китабы басылып чыкты. Журналист буларак вакытлы матбугатта актив катнашып килүче Әхәтне шушы җыентыгы белән Язучылар союзына член итеп алырга ярый дип уйлыйм.

Җыентыктагы дүрт әсәр үзләренең эчке мәгънәләре, фәлсәфи фикерләре белән бер-берсенә кушылалар: Әхәт Гаффаровны сугыш яралары борчый, сугыш

фаҗигаләре кеше язмышын котелмәгәнчә үзгәртеп җибәрә, кеше күңеле кайгы, моң, хәсрәт һәм сагыш белән тула, аңарда тирән психологик кичерешләр сурәтләнә. Әхәт үзе сугыш маҗараларын да, андагы хәлләрне дә күрмәгән, әлбәттә. Аталар-аналарның ачынып сөйләгән истәлекләрен ул бала чактан ук ишетеп үскән һәм — иң мөһиме — йөрәктә сүрелми торган нәфрәт утының көчен-куәтен аңлаган. Шуның көче аның хикәяләреннән бик нык сизелеп тора. «Яра» исемле күләмле генә хикәя-повестьта Әхәт Гаффаров сугыштан соң дөньяга килгән совет яшьләре карашы белән үткән көннәрне актарып чыга. Аталарның хаталары, уңай һәм кире адымнары аңарда бик күп сораулар тудыра, төрле фәлсәфи уйлануларга алып керә. Һәрбер сорауга да Әхәт дөрес җавап тапкан димәс идем мин, аның белән бәхәсләшүчеләр булыр һәм ул кирәк тә. Шулай да яшь авторның кеше күңеленә керә белүен, кешенең катлаулы, вакыт-вакыт үтә дә каршылыклы хисләр өермәсендә яшәвен сурәтләү осталыгын әйтми булмый.

Ә. Гаффаровның хикәяләү теле дә бик матур, сурәтләүдә параллельлек, фигыльләрдән котыла белү, экспрессияләр — аны өлгереп, үсеп бара торган художник итеп танытала. Шуңа өстәп аның композиция төзүдәге оригинальлеген күрсәтергә кирәк.

**ГАЗИ КАШШАФ.**

*
* *



Озын гына буйлы, җитди-усал күз карашлы, гаять аз сүзле бу егет, ягъни Азат Ганиев, моннан ун еллап элек миңа автобиографик повестен күтәреп килгән иде. Башлап язучыларга хас әзер-штамп сурәтләү чараларын күп куллану, сюжет-композицияне тиешенчә оештыра белмәү кебек җитешсезлекләре булса да, повесть авторның үзенчәлекле фикер йөртүе, Азатның чат үзенеке генә булган кайбер әдәби табышлары белән игътибарымны шунда ук җәлеп итте.

Берәр елдан соң без Язучылар союзының Әлмәт бүлегендә А. Ганиевнең хикәяләрен тикшердек. Бу хикәяләрдә инде Азатның югарыда әйткән сыйфатлары — берәүне дә кабатламый торган үзенчәлекле, образлы фикерләве, тынгысыз эзләнүе тагы да калкурак күренде. Бу җәһәттән аның күләмле генә «Янәшә» хикәясе аеруча уңышлы иде һәм ул «Казан утлары»нда басылып та чыкты. Озакламый А. Ганиевнең «Тагын күченәбез» дигән хикәяләр җыентыгы дөнья күрде һәм ул әдәби тәнкыйтьтә уңай бәя алды.

«Казан утлары»нда басылып чыккан «Сүзсез җыр» повесте белән А. Ганиев үзен инде җитлеккән, эзләнүчән, әдәбиятта үз сүзен әйтергә омтылучы язучы итеп танытты.

Әнә шул сыйфатлары һәм, боларга өстәп, егетнең сирәк таланты, армас тырышлыгы һәм тыйнаклыгы өчен мин Азат Ганиевне СССР Язучылар союзына лаеклы кандидат дип саныйм һәм рекомендациямне аңа зур ышаныч, якты өметләр белән бирәм.

**РАФАИЛ ТӨХФӘТУЛЛИН.**

# ФӘХРЕЛИСЛАМ АГИЕВКА 90 ЯШЬ

Фәхрелислам Агиев Нигъмәтулла улы 1887 елда Пенза губернасы, Краснослободский өязе, Тенишево авылында туа. Башлангыч белемне туган авылында иске мәдрәсәдә ала. 14 яшендә ул, бер купецка ялланып, бәхет эзләп, Көнчыгышка чыгып китә. Харбин шәһәрендә була. 1906 елны яшь егет татар культурасы үзәге Казанга килә. Монда, үзлегеннән хәзерләнеп, урта мәктәп күләмендә имтихан тота. 1908—1915 елларда Казан шәһәрендә балалар укыта.

Октябрь революциясеннән соңгы елларда Ф. Агиев — үзләренең туган ягында ярлылар комитеты председателе, Пенза шәһәрендә «Сабанчы» газетасын оештыручы. Соңыннан ул Мәскәүдә РСФСР Мәгариф халык комиссариатында методист-инспектор булып эшли. СССР халыклары үзәк нәшриятында татар секциясе секретаре, Үзәк татар күчмә драма театрының җаваплы җитәкчесе вазифаларын үти. Ф. Агиев 1938 елда үлә.

Ф. Агиев — күпкырлы иҗат кешесе: Г. Тукай һәм Ф. Әмирханнарның замандашы. Пролетариат язучысы Г. Коләхметовның якын дусты. Әдипнең тормыш иптәше врач Суфия ханым — Г. Коләхметовның сеңелесе. Ф. Агиев Г. Коләхметов иҗатына гомере буе тирән ихтирам саклый. Аның биографиясен төзеп, әсәрләренең беренче җыентыгын чыгаручы да ул була.

Ф. Агиевның публицистик мәкаләләре, шигырьләре «Әхбар», «Әльислах», «Кояш» газеталарында, «Мәктәп», «Аң» журналларында басылалар.

Әмма әдип иҗатының иң зур өлешен балалар әдәбияты алып тора.

Ул 1913—1916 елларда балалар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш керткән демократик эчтәлекле «Ак юл» журналын чыгара. Н. Исәнбәт, З. Ярмәки, С. Сүнчәләй, Б. Рәхмәт кебек танылган язучыларыбыз олы әдәбиятка шушы «Ак юл» аша киләләр. Ф. Агиев үзе дә журналның һәр санында диярлек шигырь, хикәя һәм әкиятләр бастыра. Көнбатыш Европа әдәбияты классикларының әкиятләрен тәрҗемә итә.

Ф. Агиев стиленә фантастик һәм реаль күренешләрнең аерылгысыз бергә үрелеп килүе хас.

Әдипне белүчеләрнең әйтүләренә караганда, ул үзе дә йомшак күңелле, бала җанлы кеше булган. Журналда да балаларга «сөекемлеләрем», «кадерлеләрем» дип кенә эндәшә. Педагог буларак, Ф. Агиев ата-аналар арасында да тәрбия эшләре алып барган. Шул чордагы газета-журнал битләрен актарганда, аның Казан шәһәре клубларында педагогик темаларга лекцияләр укуы турында хәбәрләр очрый. Октябрь революциясеннән соң да аның «Кызыл йолдыз» исемле әлифбасы, «Хикәяләр җыентыгы» дөнья күрә. Кыскасы, Ф. Агиевның татар балалар әдәбияты үсешендә үз эзе, үз урыны бар.

**И. ФАТЫЙМА.**

# Зәет Мәҗитов



*Тәнкыйтьче, галим, СССР Язучылар союзы члены шагыйрь Зәет Мәҗитовка 50 яшь тулды. 1927 елның 25 августында Актаныш районы Иске Айман авылында туган Зәет Мәҗитов, урта мәктәп тәмамлаганнан соң, Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый, аспирантурада калдырыла. 1955 елда «Фатих Кәрим поэзиясе» дигән темага диссертация яклый, филология фәннәре кандидаты дигән гыйльми исем ала, шул ук бүлек кафедрасында укытучы булып эшли. Бүгенге көндә ул — университет доценты.*

*1953 елда Зәет Мәҗитовның «Таңгы җыр» исемле беренче шигырь китабы дөнья күрде. Аннары башка китаплары («Чәчәкләр бирәм сиңа», «Яшь каеннар», «Ярсу Ык» һ. б.)... Шулай ук укучылар аның күп санлы тәнкыйть мәкаләләре, рецензияләре, Фатих Кәрим турында аерым монография булып басылган (1963) хезмәте белән яхшы таныш. Зәет Мәҗитов берничә ел Татарстан Язучылар союзы каршындагы тәнкыйть секциясен җитәкләде. 1975 елда аның Бөек Ватан сугышы чоры татар шагыйрьләре иҗаты турында «Сугышчан поэзия» исемле күләмле хезмәте басылды.*

## Яшь шытымнарга карап...

Көтмәгәндә болыт китте куерып.
Әллә ничек җиләс булып җил исте.
Аннан кинәт калды гаҗәп тын булып
Әле генә бодай шыткан җир өсте.

Яшел уҗым күрә иде тәүге кат
Яңгыр алды, давыл алды тынлыгын.
Сыный иде әле аны табигать
Һәм өйрәтә иде яшәү чынлыгын.

Шунда минем, карап яшь шытымнарга,
Бик әйтәсем килде киңәш-сер итеп:
— Сыналмыйча эсседә, давылларда
Алтынланып өлгерми һичбер бөртек.

## Килде болыт...

Килде болып күкрәп, давыл белән.
Сукты яшен япь-яшь имәнне.
Күрдем шунда яшь имәнне жәлләп
Карт имәннәр башын игәнне.

Күрдем шунда: алар, үзләренә
Яшен уты капкан шикелле,
Сынган яшь имәнне күтәрергә
Теләгәндәй ярсып селкенде.

Давыл шунда җинаяте өчен
Үкенгәндәй кинәт сүрелде.
Чал урманның яшел күзләрендә
Мөлдерәгән яшьләр күренде.

## Юатма

Син юатма мине, юатма, дус,
Төзәлерлек түгел яраны
Сүтеп тагын кабат бәйләгәннән
Авырту соң бетә аламы?

Бетә аламы соң йөрәккә үк,
Бәгырьгә үк төшкән сызлану?
Ир кешенең горур күкрәгенә
Дәвамыни, дустым, кызгану?

Юатма син, син эш китер миңа,
Ярдәм сора, боер кирәксә.
Син заманның олы йөген йөклә,
Тынгы бирмәс хис бир йөрәккә.

Бүтәннәргә килгән сагышны бир,
Өстемә өй бүтән кайгысын.
Зур хәсрәтен дусның бүлештем дип,
Шунда гына әйтә алырсың.

●

Эт ияртеп, куян куып йөргән җирләр.
Әнә кылый посып яткан үзән, үрләр.

Бер ялгызым карап йөрим әкрен генә,
Юлдаш булып атлый миңа хәтерем генә.

Әй, малай чак, кайда калдың, кайларда син?
Кайда дуслар? Рафак кайда, Әдһәм, Рәсим?

Әй, чыксалар икән кинәт үр артыннан
Я Риф килеп шунда, я Тәрҗеман!

Бер сугышсак икән хәзер Рәфгать белән?..
... Ялгыз гына зиреклеккә кереп киләм.

Монда тынлык. Челтери тик чишмә генә.
Дус малайлар куян куа... истә генә.

## Өметләр

Өметләр әле бетмәгән,
Юк, алар арта бара.
Өметләр безне кояштай
Иярттә, тарта бара.

Бар иде өмет өзәрдәй
Күңел сүрелгән көннәр...
Юк, имәдек башларны без,
Юк, булмадык мескеннәр.

Давылга каршы бардык без,
Кичтек ташкын суларны.
Кара урман, шомлы төннәр
Буалмады юлларны.

Инде җиттек киң үзәнгә,
Кояшлы көнгә кердек.
Инде чын сүзләр ишеттек,
Шәфкатьле йөзләр күрдек.

Инде таптык олы дуслар,
Эчтек саф чишмә суын.
Инде күздә яшьләр кипте,
Ныгыды җилкә-буын.

Көрәшкә әйди өметләр,
Өметләр балкып яна.
Кит, югал син, өметсезлек,
Бирелер дип уйлама!

1977

## Габдулла Шәрәфи

# ДӘГЪВА

*Хикәя*



Керәле урамы белән Чыгалы урамы чатында авылдан китереп бәрәңге саталар. Сатсыннар, бик әйбәт. Югыйсә, безнең тирәдә базар юк. Кайсы гына якка китмә — җәһәннәм асты. Тагын шунысы да бар, базар ише җирләрне күңелем өнәп бетерми. Ник дисәң, сатулаша белмим. Ә бит сатучының һәркайсы үз малын үтереп мактаучан була. Шул кадәрле мактыйлар, шундый да үз итеп карыйлар сиңа, эрим дә китәм. Ә өйгә кайткач:

— Базар тикле базарга барып соң, биш бәясенә алып кайтмасаң соң, моның ишенең поты бер тиендер әле анда, — дип теңкәгә тияләр. Менә ни өчен яратмыйм мин ул базар дигәннәрен. Исеме үк килешсез янгырый шуның, колагыма ятышсыз — ба-зар, имеш. Тапмаганнар бит нәфисрәк, нечкәрәк билле бер сүз.

Әнә шул ике урам чатына чыктым бер көнне. Бәрәңге алырга. Капчык тотып. Әмма хәлем чүт кенә «тот капчыгың» булып куймады. Бары бер генә җирдә, тик бер генә агай ду китереп бәрәңге сатып ята. Ул халык, ул халык, якын килерлек түгел. Инде борылып китәм дип кенә торганда, сатучының кемгәдер: «Сайланып маташма, нәнә, бәрәңге булгас бәрәңге инде ул, шалкан түгел ис»,— дигән сүзләрен ишетеп, сагая калдым. Туктале, дим, безнең як кешесе түгелме соң бу? Сөйләшүе безнеке, кайсы авылдан икән? Якынрак килдем дә карыйм үзенә. Менә сиңа мә, үзебезнең авылныкы ук икән ләбаса! Яшьтәш минем, Әптери. Түгел лә, Габдери. Буксир. Соңгысы кушаматы. Кем кушкандыр, алла белсен. Мөгаен, олыраклардан чыккандыр. Без, малайлар, буксирның ни икәнен белми идек, югыйсә, аны күреп караган кеше түгел идек. Корсагы зур иде шул Габдеринең. Көчле дә иде үзе, шайтан. Хәер, корсак дигәне безнең һәркайсыбызда ходайга шөкер иде анысы. Нишләсен ди ул бичара корсак, умач белән гел бәрәңге, гел әче катык тутырып... Әчегән шул, күпергән инде. Алай да Габдеринеке барыбер зуррак иде шикелле. Әйдә ярар, чуртымамы әллә кайчандагы корсаклар. Хәзерге Габдерине онытып җибәрдем бугай. Әйе, килдем мин моның янына. И дәшәм:

— Нихәл, авылдаш, исәнме?! Булышчы кирәк түгелме? — дим.

— Ә-ә, исәнме, җәшти, саумы! — ди бу да, мине танып. — Тушь жусыкта торасың дип ишеткән ием аны. Бәрәңге кирәк мәллә сиңа да?

— Шулайрак иде шул. Үз туфрагыбызныкы да булгач...

— Шулай шул. Шәп ис безнең бәрәңге, иптә. Ярмалы!

Дөрес, ярмалы безнең бәрәңге. Тик шул ярмалы бәрәңгене алырга дип нихәтле кеше чират тора. Ә авылдаш инде соңгы капчыгын чишкән. Сүзне тагын да озайту җайсыз иде. Моны Габдери дә сизде бугай, чираттагыларга карап:

— Җәмәгать, үпкәләштән булмасын, авылдашны бәрәңгесез калдыра алмыйм,— дип, минем капчыкка бер чиләк бәрәңгесен аударды.

Менә бит ул авылдашың мәне белгәч. Сатулашу түгел, акчаны бөтенләй дә түләтмәде. Җитмәсә, ни ди бит әле тагын: «Икенче бер юл төшкәндә капчыгы белән китерермен», — ди.

Сатып бетергәч чәйгә керергә кушып кайтып киттем.

Кайттым да уйланам, ни белән сыйларга икән якташны, дим. Нидер әмәллисе иде бит. Иң ансаты инде аның, әлбәттә, йомырка куыру. Тик якташым аны күрмәгәнме? Ә колбаса турасам, бал, май куйсам, кичә генә пешкән алма бәлешен? Һәммәсе дә үзләрендә бар шул, шаккатмас. Их, егетләр, кара инде син, ә? Бәйрәм сые белән яшибез икән ләбаса! Авылында да, шәһәрендә дә.

Тора торгач, кәттә дә бер уй килде минем башка: бәрәңге пешерергә кирәк. Ярып, әрчемичә генә, элеккечә иттереп. Май да эретеп куйсаң, мана-мана ашаулары ни тора! Тотындым мин бәрәңге юарга. Их, ул безнең авылның бәрәңгесе, исе үк икенче җанашымның, кабыгына кадәр үзенә бертөрле. Артык шома да түгел, әллә ни кытыршы да булмас. Бәрхет инде менә, чын бәрхет...

Озак та үтми, якташым да килеп җитте.

— Нәстә, тансыклаттымыни, кайту белән җабышмасаң, — ди бу керә-керешенә. — Исе каридурга ук чыккан бәрәңгенең. Бичура басуыннан ул, белеп тор, каз көткән җирләрең...

Өйдә берәү дә юк. Хатын эштә, малайлар укуда. Рәхәтләнәбез сөйләшеп икәү генә. Яшьлеккә дә кайтып килдек, бала чакларга да сугылдык. Барысын да үзебезнең авыл бәрәңгесенә кушып кинәнәбез генә. Шулай сөйләшә-сөйләшә минем язу-сызу хәлләренә дә килеп җиттек.

— Матлашам инде шунда, әллә ни майтарган юк, — дим.

— Җук, дип... Укыйбыз ис, кайчагында хәйран гына кашартасың. Әле теге ни... Каз көткән чакларны да җазгансың.

— Ничек соң, дөрес чыкканмы?

— Дөресме дип...

Якташым, сүзен әйтеп бетермичә туктап, бәрәңгеле кулын тастымалга сөртә-сөртә, иренен чапылдатып куйды. Аннары хәйләкәр генә елмая төшеп дәвам итте:

— Кызык син, малай. Мәкалә җазганда синең барысы да дөрес ие. Сәмигулла бабай хакындагын әйтүем. Әллә кайчан бер җазган иең ис. Тырышсаң, булдырасың. Дөрес ие, сүзләре дә үзенеке ие. Хикәя җаза башласаң, бутыйсың да бетерәсең.

— Соң, — дим, — җанрлары төрле ич. Тегесе — мәкалә, бусы — хикәя.

— Жанр-манрларыңда эшем җук, бутама син, кашартма. Мине таладымыни ул чакта каз? Үзеңне талады ис!

— Әй, Габдери дус, исемнәрне үзгәрттем бит мин, кем белә аның хәзер синме, минме икәнен.

— Үзем беләм. Әнә Серчек[1] Сабир белә. Безне җазган дип авызын җырган ие беркөнне. Җарый, казы каз инде. Нигә дип алмаштырттың син безнең кәләпүшләрне? Сәлихҗан белән? Ник кием ди мин аның кәләпүшен, таз ие ис ул!

— Ялгышасың, дускай, кәләпүш түгел, түбәтәй дип язганмын-дыр.

— Анысы шулай, түбәтәй дигәнсең. Барыбер кәләпүш инде ул бездә. Син бозгас та. Үзең теләсәң ничек сөйләш. Безнекен бозма. Ну, малай, сөйләшеп тә карыйбыз соң без синең хикәяңдә. Каян килгән кала малайлары! Апак урынына апа дип, пысмак, пысак ишеләрне почмак, пычак дип сиптерәбез генә.

Башта мин Габдеринe шаяртып кына сөйләшә дип уйлаган идем, ә ул чынлап торып үпкәләгән кебек кылына.

— Соң, Габдери дус, — дим, — язган бер нәрсәңә үз шивәңне тутыра башласаң, кая китә ди ул.

Якташым нәкъ малай чагындагы күк сул колагын тарткалый башлады. Берәр сүз әйтер алдыннан шулай итә торган бу гадәтен әле дә ташламаган икән.

— Шулай инде ул, үз җагыңнан бизгәс. Көне буе иләдем, иләдем дә, иләк өстен, иләк астын бергә кушып, тегермәнгә киттем, дип әйтте ди берәү. Бөтенегез дә бер төрле җормаслыйсыз. Кемнең кайсы җусыктан икәнен дә белмәссең.

Габдери берчама турсаеп утырды да тагын тезеп китте:

— Әллә кая җәһәннәм асларына барып әллә кемнәр турысында җазасың. Җук бит, үзебезнекеләрне җазарга...

— Язган идем ич инде, — дим.

— Шул Сәмигулла бабай турысында бер булды инде. Җегерме җыл элек. Һей, бездә хәзер... Үзең дә беләсең ис, кайткалыйсың анысы. Авылның бер башыннан керәсең дә икенчесеннән яшен ташыдай чыгып китәсең. Онытмыйсың, җугыйсә, элеккене, сизәм, авылны да онытмыйсың. Әнә, бәрәңгене ничеккәй итеп пешергәнсең. Җугыйсә, әллә ниләрең бардыр әле. Кемдә җук ул хәзер, — дип, Габдери урыныннан кузгалды.

Тагын бераз утырырга кыстап карадым. Ләкин авылдашым, әйтеп үк бетермәсә дә, каядыр ашыга иде.

— Җарый, җәшти, җүнле торасың икән, рәхмәт. Үзебезчә сыйладың, кашартып маташмадың. Җазганда да шулай кылан. Ни пешерсәң, шуның исе чыксын. Ату бит... Бәрәңге дип ымсынасың, ә аннан төсе күмәс исе килә, — дип, коридорга атлады. Инде ишек төбенә җиткәч, тагын өстәп куйды:

— Кайт әле бер иркенләп, җаз әле авылыбыз турысында. Үзебезчә итеп. Күрсеннәр әле безне дә.

— Ярар, — дидем. — Насыйп булса.

Габдери китте. Ә миңа моңсу да, рәхәт тә булып калды. Сулышларым иркенәеп, бүлмәләрем үк яктырып киткәндәй булды.

Белмим, Габдери теләгәндәй итеп кәм язар. Минме, башкамы. Зарланмыйм, моңарчы язганнарым игътибарсыз калмады. Баштан сыйпаучылары да, чәбәкләүчеләре дә байтак булды. Тик Габдери кебек: «Кашартма!.. Төче күмәч!..» дип йомарлап үк томыручысы очрамаган иде әле. Рәхмәт, авылдаш, онытмам.

Шушының белән беткән дә булыр иде. Ләкин уйлап куйдым: туктале, дим, Габдери дус тагын үпкәләмәсме? Әлеге язманы җибәреп, үзеннән укытып алдым. Менә шундый җавап килде: «Җарый инде, кыйты керис. Бу җулы, исмасам, минем сүзләрне бозмагансың. Түлке онытма, вәгъдә — иман. Кәтәм әле, имансыз. Кайт, Бичура керис!»

---

[1] Серчек — чикерткә.

# СҮЗ ӘРМӘН ФОЛЬКЛОРЫ ГЕРОЙЛАРЫНА БИРЕЛӘ

*Әрмәннәрдә халык иҗатының барча жанрлары — эпик, поэтик әсәрләр һәм сатира — борын-борыннан яшәп килә. Әмма анда мәсәл жанрының чәчәк атуы XII—XIII гасырларда гына чын-чынлап башлана. 1976 елда Мәскәүдә «Наука» нәшрияты бастырып чыгарган «Әрмән халкы тормышыннан кызыклы һәм гыйбрәтле күренешләр» дигән китапта шул чор иҗатыннан да шактый күп үрнәкләр бар. Халык аны чит ил баскыннары әледән-әле кабатлап торган һөҗүмнәргә каршы юнәлтә, урта гасыр кешесенең дөньяга карашындагы төрле төсмерләрне тасвирлау, дингә каршы фикерләрне образлы итеп әйтү, аерым затларның теге яки бу кимчелегеннән көлү өчен иҗат итә һәм файдалана. Ул чакларда дөнья күргән ике мәсәл җыентыгының берсен күренекле фикер иясе, атаклы «Суд кенәгәсе» авторы Мхитар Гош, икенчесен — берничә кулъязма циклны берләштергән «Төлке китабы»н Вардан Айгекци җыеп бастырган. Кайбер мәсәл сюжетларының бүтән халыкларныкы белән охшашлыгы булса да, аларда әрмән халкының үз тормышы чагыла, үз геройлары сурәтләнә (илбасарларга каршы сугышлар, баш күтәрү, һөнәрчеләрнең феодаллар һәм ростовщиклар белән сыйнфый килешүнең һич булачак түгелен аңлавы һ. б.).*

*Шулардан кайбер үрнәкләр белән танышыйк.*

## Бер тамчы бал

Берәүнең бал сата торган кибете була. Шунда аның җиргә бер тамчы балы тама, һәм шул тамчы өстенә бер шөпшә килеп куна, һәм бер мәче йөгереп килеп шул шөпшәне эләктерә, ә мәчене бер эт куып тота, ә кибет хуҗасы шул этне сугып үтерә.

Бу авылга якын гына икенче авыл бар икән — этнең шуннан килеп чыкканы беленә. Этен кибетче үтергәнен белгәч, аның хуҗасы тиз генә килеп җитә дә кибетчене үтерә.

Шунда ук ике авыл крестьяннары үзара бик каты кыйнаша башлыйлар. Нәтиҗәдә нибары бер кеше исән кала. Ни өчен кырыштылар соң? — Бер тамчы бал өчен.

Мәсәл шуны аңлата: бу дөньяда, без әйткән ике авыл кешеләре кебек, бер тамчы бал өчен әле күпләр сугыша.

## Үгез белән ат

Үгез белән ат очрашып үзара сүз башлыйлар. Ат әйтә: «Кем син һәм нәрсәмә ярыйсың? Ә менә мин, ичмасам,— ат. Патшалар, князьләр һәм бароннар мине алтын-көмешләр белән бизиләр дә өстемә атланып йөриләр». Ә үгез болай ди икән: «Ә мин — бөтен илнең

муллыгын булдыручы: көне-төне диярлек эшлим, арып бетәм һәм газапланам. Ә аннары син үзең һәм синең патшаң мин эшләгәнне ашыйсыз, һәм бүтәннәр дә ашый. Әгәр мин эшләмәсәм — үзең дә, патшаң да «эһ» дигәнче җан бирәчәксез. Болай миһербансыз булма».

Бу мәсәл менә нәрсә турында сөйли: үгез урынына эшләүче кешеләр дә, һаман атка атланып йөреп илне туздыручылар да бар әле. Әгәр эшче халык ашатмаса, ат та, аның җайдагы да үләчәк.



## Урман тавыгы һәм сунарчы

Бер сунарчы урман тавыгы тота һәм аны суярга була. Тавык исә елый-елый ялвара икән: «Зинһар суйма мине, мин сиңа менә хәзер китеп, бер көтү тавык-чебеш куып китерә алам һәм алар барысы да синеке булачак». Ә сунарчы аңа үзенекен өздереп әйтә: «Син минем кулдан җан бирергә тиешсең, чөнки үзеңнең бөтен якыннарыңа, бөтен нәсел-ыруыңа үлем телисең икән бит».

## Карганың акыллы бала кошлары

Карга үз балаларына акыл өйрәтә икән: «Сак була күрегез, оланнар, кешедән куркыгыз — бигрәк тә ул таш алырга дип җиргә иелгән чакта». Ә оланнары аңа сорау бирә: «Әнкәй, әгәр ул кеше ташны кулына инде алган булса, без нишләргә тиеш?» Ана әйтә: «Сезнең беркайчан да хур булмасыгызны менә хәзер белдем инде».

## Үрмәкүч

Табигате шундый булганга, үрмәкүч һәр вакыт пәрәвез үрә һәм шуның белән нәрсәдер аулый — үзенә ризык таба. Ә кайчакны ул, мавыгып китеп, пәрәвез үрә-үрә сырхаулый һәм үлеп тә китә икән. Ә бөтен хезмәтенең җимеше — нинди дә булса бер чебен.

## Арыслан, бүре һәм төлке

Арыслан, бүре һәм төлке дуслашалар да бергәләп ауга чыгып, бер тәкә, бер сарык һәм бер бәрән эләктерәләр. Сынар өчен бүрегә әйтә икән арыслан: «Менә шул өч җан иясен барыбызга бүл». Ә бүренең җавабы инде әзер үк булган диярсең: «И падишабыз, моны ходай тәгалә үзе үк бүлгән ич инде: тәкә — сиңа, сарык — миңа, ә бәрәне — төлкегә».

Арыслан, яман ачуланып, бик каты суга да бүренең ике күзе атылып чыга... Инде хәзер арыслан төлкегә куша: «Бүл әйдә тизрәк шул өч малны икебезгә». Әйтә аңа төлке: «И падишабыз, моны бит ходай үзе бүлгән инде: тәкә — сиңа иртәнге ашка, сарык — төшкегә, ә бәрән — кичен ашарга». Һәм шунда арыслан сорый аңардан: «Әйт, кызганыч хәйләкәр, кем өйрәтте сине шундый гадел бүлешкә?» Төлке: «Бүренең тәгәрәп чыккан ике күзе өйрәтте»,— дигән бик кыска җавап бирә.

## Сарыклар һәм бүре

Бүре тау башына менеп баса һәм аның итәгендә сарык көтүе күреп, шул якка таба кычкырып әйтә икән: «Тыныч яшәгез!»

Ә карт бер тәкә үзенең көтүдәге иптәшләренә әйтә: «Туганкайлар, таудагы җан иясе безнең тыныч яшәвебезне бик теләсә дә — кем ничек булдыра алса, шулай тиз генә качып котылыгыз!»

## Аю белән төлке

Бер арыслан, кинәт сырхаулап, аяктан егыла, һәм җәнлек-җанварлар аның хәлен белергә килә башлыйлар. Төлке, ни сәбәптәндер, соңгарак кала һәм аю аның өстеннән арысланга инде әләк җиткергән була. «Хәерле сәгатьтә килмәдең син, юньсез җан, бирегә, — ди арыслан,— ник соңгардың?» «Үпкәләмә, падишаһым, менә синең үз исемең белән антлар итәм, авырганыңны ишетүгә, синең саулыкны кайгыртып, берничә яхшы врачны йөреп чыктым, дару эзләдем мин». Ә арыслан әйтә аңа: «Рәхим ит, акыллым минем, нинди дару таптың соң?» «Ул бик файдалы һәм бер дә кыйбат тормый! Врачлар менә нәрсә диде: «Бер аю тотып, тиресен тереләй тунагыз да шул тирене, җып-җылы килеш, арыслан өстенә каплагыз һәм шул тире аның бөтен чирен суырып алачак». Арыслан аюны тотарга, тиресен тунарга куша. Аю күз яшьләре түгә-түгә улый, әлбәттә, ә төлке аңа әйтә: «Менә сиңа һәм, падиша сараена килеп, бүтәннәргә нәкъ синең кебек яла ягып йөрүчеләргә шул сабак булсын».

Гыйбрәт: «Кешене гаепләргә һәм әләкләргә ашыкма, күбрәк үз гөнаһларыңа күз сал, үз кайгыңны кайгыртырга өйрән».

## Көнче

Бер патша үз гаскәренең бер-берсеннән бик яман көнләшкән ике сугышчысы турында ишетә дә шуларның берсенә әйтә икән: «Миннән үзеңне теләсә нинди дәрәҗәгә күтәрүемне үтен, әмма мин синең иптәшеңә ул дәрәҗәне икеләтә зур итеп бирәчәкмен»... Һәм менә нинди була сугышчының патшага биргән җавабы: «Минем бер күземне бәреп чыгар!» Ул моны икенче көнче иптәшенең ике күзе дә сукырайтылсын өчен әйтә.

## Бозаулар һәм эш үгезләре

Койрык чөеп чапкан бозаулар эш үгезен үгетлиләр: «Шул эштән һәм шундый эзәрлекләүләрдән һич кенә котыла белмәссез икән!» Көннәрнең берендә шул якларга патша килеп чыга да аңа һәм аның гаскәренә әбәт әзерләү өчен бөтен бозауларны җыеп суя башлыйлар. Шул чакны үгезләр әйтә икән: «Менә, оланнар, шул көнгә калыр өчен бернинди эшсез чабып йөрдегез һәм симердегез бит сез».

## Шалкан һәм кишер

Шалкан сорый икән: «Нишләп син, кишер, җиргә бик тирән килеп үсәсең?» Ә кишер әйтә: «Синең урынсыз кыюлыгыңа минем исләрем китә — үзең ап-ак булган килеш, кеше күзенә күренеп үскән буласың!» Шалкан исә тагын үзенекен итеп аңа болай ди: «Бәлки мин чыннан да яхшы эшләмимдер. Әмма синең куркаклыгың да бик начар бит!»

## Лачын белән күгәрчен

Артыннан лачын куып килә башлагач, бер күгәрчен әйтә икән: «Мин бит илаһка ирешергә тиешле җан иясе, зинһар, миңа тия һәм зыян итә күрмәгез!» Ә лачын аңа үзенекен тукый: «Илаһка дигән нәрсә күптән аның өстәлендә булырга тиеш, ә син монда без оча торган күкләрдә болай буталып йөрмә!» Шулай ди дә лачын күгәрченне тиз-тиз ботарлап ашап та куя.

### ӘДӘБИЯТ ҺӘМ ӘХЛАК МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

Герой-шәһәр Волгоградта 16 һәм 17 майда РСФСР Язучылар союзы идарәсе секретариатының «КПССның XXV съезды һәм хәзерге Россия әдәбиятында әхлак мәсьәләләре» дигән темага багышланган күчмә утырышы булды. Татарстан Язучылары оешмасыннан анда Гариф Ахунов белән Сибгат Хәким катнашты. Күчмә утырыш тәмамланганнан соң язучылар промышленность предприятиеләрендә, колхоз-совхозларда эшчеләр, авыл хезмәтчәннәре белән очрашуларда катнаштылар.

### ЯЗУЧЫЛАР — ДЕПУТАТЛАР

19 июньдә җирле советларга сайлауларда шагыйрь Зәки Нури — Казан шәһәр советына, Татарстан Язучылар союзы идарәсенең җаваплы секретаре, тәнкыйтьче Фәрваз Миңнуллин Казан шәһәренең Бауман районы советына, шагыйрь Әдип Маликов Әлмәт шәһәр советына депутатлар итеп сайландылар.

### ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ ТУРЫНДА

Бөек татар әдибе, энциклопедист-язучы Галимҗан Ибраһимовның 90 еллык юбилее илебез матбугатында киң билгеләнеп үтелде. Аның юбилее турында «Правда», «Советская культура» газеталарында хәбәрләр басылды, иҗаты һәм тормыш юлы турында «Литературная газета»да Габдрахман Әпсәләмов, «Литературная Россия»дә Рафаэль Мостафин, «Молодая гвардия» журналында Әмир Мәхмүдов мәкаләләре чыкты.

Казагыстан, Үзбәкстан, Кыргызстан, Таҗикстан, Башкортстан республикаларының газета-журналлары Г. Ибраһимов юбилеен күләмле материаллар белән билгеләп үттеләр. Әдипнең иҗатына багышланган мәкаләләр якут, авар, алтай, мордва, удмурт, тува, хаккас, адыгей, черкес һәм башка телләрдә басылды.

### МУСА ҖӘЛИЛГӘ БАГЫШЛАП

Ташкентта хәрби частьта Муса Җәлилнең тормыш юлы һәм иҗатына багышланган кичә булды. Хәрбиләр алдында М. Җәлил һәм аның көрәштәшләре тормышын, көрәш юлларын өйрәнүче галим, филология фәннәре кандидаты Исхак Зәбиров чыгыш ясады. Совет Армиясе офицерлары һәм солдатлары шагыйрьнең «Моабит дәфтәре»нә кергән шигырьләрен сөйләделәр. М. Җәлил портреты янына канәфер чәчәкләре куелды.

Шундый ук кичә Ташкентның Н. К. Крупская исемендәге балалар санаториенда һәм 235 нче мәктәбендә булды. И. Зәбиров аларга М. Җәлил һәм аның көрәштәшләре турындагы китапларын бүләк итте.

* * *

Республикабызның Җәлил поселогында шагыйрьнең музее ачылды. Биредә аның үз әсәрләренең төрле басмалары, иҗатына, тормыш юлына багышланган китаплар тупланган.

* * *

ТАССР Министрлар Советы каршындагы физкультура һәм спорт комитеты республика шәһәрләрендәге футбол командаларының Муса Җәлил призына турнирын уздырды. Быелгы призны «Синтез» командасы яулап алды.

* * *




*Северодвинск шәһәрендә яшь җәлилчеләрнең «Кызыл канәфер» клубы эшли. Алар Казанда булып, шагыйрь һәм аның көрәштәшләре истәлекләре белән таныштылар, язучылар белән очраштылар. Икенче рәттә сулдан икенче — «Кызыл канәфер» клубы җитәкчесе Лидия Леонтьевна Дряхлицына.*

## ИЖАТ СЕКЦИЯЛӘРЕНДӘ

*

*   *

Шагыйрьләр секциясе утырышында Марсель Галиев белән Роза Хәлиуллина иҗатлары тикшерелде. С. Хәким, И. Юзеев, Р. Фәйзуллин, Р. Мингалимов, М. Вәлиев аларның әсәрләренә анализ ясадылар. Уңышлы дип табылганнарын нәшриятка тәкъдим итәргә диелде.

*

*   *

Проза секциясендә Нәбирә Гыйматдинованың повестьлары тикшерелде, яшь авторга киңәшләр бирелде. Н. Гыйматдинованың «Китмә, улым» исемле повесте «Идел» альманахының 1977 ел санына басарга тәкъдим ителде.

## ОЧРАШУЛАР, КИЧӘЛӘР

Татарстан шәһәрләрендә һәм авылларында 17 апрельдән 15 майга кадәр Октябрьның 60 еллыгына багышланган китап айлыгы булып узды. В. И. Ленинның 107 еллыгы көннәрендә «Ленин әсәрләрен — һәр йортка», Тукай туган көнгә багышлап «Шигърият атналыгы», Май бәйрәмнәре уңае белән «Китап — тынычлык, демократия, прогресс һәм бердәмлек өчен көрәштә» һәм «Китап — бишьеллыкка хезмәттә» дигән темаларга багышланган атналыклар зур уңыш белән барды. Казанның М. Горький исемендәге культура һәм ял паркында оештырылган шигъри кичәдә язучылардан Р. Гатауллин, Р. Батуллин, М. Зарецкий, Р. Миңнуллин чыгыш ясады. Культура сарайларында, тулай торакларда, уку йортларында, предприятиеләрдә узды-рылган «Казан язы» дигән әдәби-музыкаль кичәләрдә язучылардан А. Расих, В. Нуруллин, М. Хәбибуллин, Р. Батуллин, Р. Гатауллин, М. Әгъләмов һ. б. катнашты.

*

*   *

25 майда Питрәч районы китапханәсендә РСФСР Дәүләт премиясе лауреаты С. Хәким иҗатына багышланган кичә булды. Анда автор үзе, шагыйрь Н. Беляев, Татарстанның халык артисты А. Арсланов, җырчы В. Гыйззәтуллина катнашты.

## ЯЗУЧЫЛАРНЫҢ Г. ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ КЛУБЫНДА

*

*   *

Татар дәүләт опера һәм балет театры үсеше әдипләребездән М. Җәлил, Ә. Фәйзи, Н. Исәнбәт, Х. Вахит, Ә. Исхак һәм башкаларның иҗади эшчәнлеге белән бәйләнгән. Шушы матур традицияләрне яшь буын язучылар белән дәвам иттерү, опера һәм балет сәнгатебезне бергәләп үстерү турында клуб кичәсендә театрның баш режиссеры, РСФСРның халык артисты, Тукай бүләге лауреаты Н. Даутов чыгыш ясады. Ул Октябрьның 60 еллыгына «Җиһангир» операсы (Х. Вахит һәм Р. Гобәйдуллин әсәре) әзерләнүен әйтте. Кичәдә шул опе-радан арияләрне Татарстанның халык артисткасы Гөлшат Сәйфуллина, җырчылар Алла Фадеичева, Зилә Сөнгатуллина, Рафаэль Сәхабиев, Сәет Рәенбәковлар башкарды.

*

*   *

Союзның чуваш язучылары секциясе оештырган чуваш әдәбияты кичәсе булды. Секция председателе В. Юдин Татарстанда яшәүче чуваш язучылары иҗаты турында доклад сөйләде. Зал тулы тамашачылар алдында консерваториядә һәм Казанның башка югары уку йортларында белем алучы чуваш яшьләре көче белән концерт бирелде.

## Г. ИБРАҺИМОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ ТАРИХ ИНСТИТУТЫНДА

*

*   *

Яшь галимнәрнең Октябрьның 60 еллыгына багышланган конференциясе үткәрелде. Конференция тарих һәм филология секцияләренә бүленеп эшләде. Филология секциясендә Г. Сөләймановаың «Татарстанда монументаль-декоратив сәнгатьнең беренче адымнары», Г. Арслановның «Режиссер Х. Уразиковның эш методы», Р. Халитовның «Татар халык иҗатында музыка инструментларының чагылышы», М. Хәбибуллинның «К. Тинчуринның беренче комедияләре», Р. Әхмәтовның «XIX йөз татар поэзиясенең кайбер үзенчәлекләре», Ф. Хәкимҗановның «Идел буе болгарларында тел ситуациясе», З. Хисамиеваның «Кадир Алибек дастаннарын өйрәнү тарихыннан» исемле докладлары тыңланды. Конференциядә тыңланган иң яхшы докладлар Почет грамотасы белән билгеләп үтелде.

*

*   *

Күренекле совет әдәбияты галиме, СССР Фәннәр академиясе член-корреспонденты Г. И. Ломидзе үзенең күп милләтле совет әдәбиятларының теориясенә, тарихына караган хезмәтләре белән әдәбият белгечләренә һәм язучыларга, укучыларга яхшы таныш.

Күптән түгел ул, институтның эше белән якыннан танышу теләге белән, Казанда булды.

Ул шәһәр филологлары, югары уку йортларындагы әдәбият укытучылары һәм республика яшь иҗат көчләре семинарында катнашучылар белән очрашып, хәзерге әдәбият фәненең актуаль бурычларына кагылышлы мәсьәләләр турында сөйләде, татар әдәбиятының алты томлык тарихын язу-

ның барышы белән, 1978 елда Казанда хәзерге әдәбиятта социалистик реализмның эстетика һәм поэтика проблемаларына багышланып үткәреләчәк бөтенсоюз конференциясенә хәзерлекнең торышы белән кызыксынды.

*
* *

Әдәбият секторының чираттагы утырышында татар әдәбияты классикларының әсәрләр җыелмасын басу буенча оештырылган махсус текстологик группаның эш планы турында сүз барды. 1977—80 еллар планына М. Гафури әсәрләренең дүрт томлыгын, Г. Камал әсәрләренең өч томлыгын, һ. Такташ әсәрләренең өч томлыгын әзерләү кертелде.

## ТАТАРСТАН ТУРЫНДА БАШКА ТЕЛЛӘРДӘ

Мордовия китап нәшриятында И. Д. Воронинның «Мордовиядә әдәбият эшлекләләре һәм әдәби урыннар» (рус телендә) дигән китабы чыкты. Автор Мордовиядә туган татар язучылары Ш. Камал, һ. Такташ һәм Г. Әпсәләмовларның кыскача биографиясенә һәм иҗатына тукталa.

*
* *

«Большая советская энциклопедия»нең (3 нче басма) 25 нче томы чыкты. Әлеге томда Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасының картасы, табигате, дәүләт төзелеше, халкы, тарихы, халык хуҗалыгы, сәламәтлек саклау, укыту-агарту эшләре, фән һәм фәнни учреждениеләре, матбугаты, радио-телевидение, әдәбият, архитектура һәм сынлы сәнгате, музыкасы, театрлары турында кыскача мәгълүматлар урнаштырылган.

Шулай ук бу томда Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры, М. Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театры, татар теле һәм татарлар хакында белешмә материаллар бар. Бу материалларда Идел буе шәһәрләренең урта гасырда ук югары культуралы булуларын күрсәтелгән. Җыентык — Идел буенда археологик экспедиция эшләренең 3 нче чыгарылышы.

*
* *

Мәскәүдә «Советский композитор» нәшриятында «Россия музыкасы» дигән китапның 2 нче чыгарылышы дөнья күрде. Анда Татарстан музыка сәнгатенә дә зур урын бирелгән.

## ТАТАР ХАЛЫК ӘКИЯТЛӘРЕ

Югославия Социалистик Федератив Республикасының Люблянадагы «Младинска книга» нәшрияты татар халык әкиятләрен словен телендә бастырып чыгарды. Китап зур форматта, 222 биттән тора. «Алтын кош» (Планетабыз халыклары әкиятләре) сериясендә чыккан бу китапны атаклы словен язучысы Нада Крайгер тәрҗемә иткән. Җыентыкка «Камыр батыр», «Үнберенче Әхмәт», «Гөлчәчәк», «Алпамша», «Шүрәле», «Саламторхан», «Алтын балдак» һәм башка бик күп татар халык әкиятләре кергән.

## «МИНЕМ ЯРАТКАН ШӘҺӘРЕМ»

Казан телевидениесенең кинодокументчылары төшергән төсле телевизион фильм шулай атала. Республикабыз башкаласы Казанның үткәне, бүгенгесе турындагы бу фильм Татарстан тамашачыларына инде күрсәтелде. Үзәк телевидение аша аны Бөек Октябрьның 60 еллыгына багышланган «Илебез шәһәрләре» циклында төсле программа буенча күрергә мөмкин.

## РӘССАМНАР — МӘСКӘҮДӘ

Бөтенроссия театр җәмгыятенең Мәскәүдәге күргәзмә залында Татарстан театр художниклары күргәзмәсе булды. Күргәзмәдә унсигез художнигыбызның йөзгә якын декорация, костюм һәм курчак эскизлары күрсәтелде.

Театр художникларының күргәзмәгә куелган эшләрендә милли үзенчәлек калку чагылган. Художник М. Сутюшевның «Галиябану», «Миләүшәнең туган көне» спектакльләренә, художниклар Ә. Тумашев, Э. Гельмс тарафыннан Җ. Фәйзинең «Башмагым» музыкаль комедиясенә ясалган эскизлары, Сперанскаяның Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле өчен ясаган костюм үрнәкләре зур кызыксыну белән каралды. Мәскәү сәнгать белгечләре ул костюмнарны аерата билгеләп үттеләр.

## КУРЧАКЧЫ АРТИСТЛАР ТОРМЫШЫННАН

*
* *

Партия Үзәк Комитетының иҗади яшьләр белән эшләүне яхшырта бару турындагы карарын тормышка ашыруда Казан курчак театры коллективы эшлекле чаралар күрә. Театр училищесы студентлары көче белән планнан тыш спектакль чыгару шуның бер дәлиле. Театр дирекциясе яшьләрнең беренче хезмәтен — «Ал чәчәк» әкият-спектаклен КамАЗ төзүчеләргә күрсәтүдән башлады. Студентлар бер уңайдан завод төзелешләрендә, Түбән Кама, Зәй, нефтьчеләр шәһәрләрендә кызыклы очрашулар уздырдылар, шефлык тәртибендә концертлар бирделәр.

*
* *

Бөек Октябрь социалистик революциясенең 60 еллыгы уңае белән курчак театры коллективы ветераннар кичәсе үткәрде. Театрда 40 еллап эшләгән һәм бүген дә коллективка актив ярдәм күрсәтүче вете-

раннар Татарстанның атказанган артистлары В. Гаффаров, М. Хисамова, Татарстанның атказанган культура работнигы А. Юрусов, артистлар С. Йосыпова, Н. Кириллов, Р. Хәбибуллина, баянчы А. Низаметдинованы Татарстан Культура министрлыгы исеменнән театр директоры Мансур Шиһапов котлады, аларга Почет грамоталары һәм истәлекле бүләкләр тапшырды.

## КАЗАН МӘКТӘБЕНДӘ БАРАТЫНСКИЙ МУЗЕЕ

Ленин районындагы 34 нче мәктәпнең бер бүлмәсе безне XIX гасыр белән таныштыра. Ул музейга ике мең ярым чамасы экспонат куелган: рус шагыйре Евгений Баратынский замандашларының рәсемнәре һәм гравюралары, шул заман китаплары һәм грамоталары, инде күптән саргайган кулъязмалары... Аларны укытучы Вера Загвоздкина җитәкләгән түгәрәк — Баратынский поэзиясен сөючеләр түгәрәге членнары дүрт ел буе җентекләп җыйган. Музейны ачканда, Казанга килеп, шагыйрьнең оныкларының оныклары, аның тормышы һәм иҗатын өйрәнүче галимнәр катнашты. Шул оныклардан — зур белемле, мәгърифәтче Ксенья Николаевна заманында Казан тирәсендәге Шушара авылында мәктәп ачкан һәм крестьян балаларын укыткан, 1918 елда һәлак булган Александр Баратынский Казан рәссамы Фешин шәкерте булган.

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ ӘЛМӘТ БҮЛЕГЕНДӘ

*

* *

Нефтьчеләрнең Техника йортында шигырь бәйрәменә багышланган әдәби-музыкаль кичә булды. Кичәне кереш сүз белән Әлмәт шәһәр советының культура бүлеге мөдире М. Атнагулов ачты. Алга әйдәүче поэзия турында шагыйрә Сажидә Сөләйманова сөйләде. Кичәнең әдәби өлешендә шагыйрьләрдән С. Сөләйманова, К. Булатова, Дм. Матвеев, И. Винокуров һәм Әлмәт берләшмәсе членнары үзләренең яңа шигырьләрен укыдылар. Концерт өлешендә Г. Тукай, М. Җәлил, Ф. Кәрим һәм хәзерге татар совет шагыйрьләренең шигырьләре, алар сүзләренә язылган җырлар яңгырады.

Кичәдә язучыларның автографлары белән китап сату оештырылды. Шәһәр хезмәт иияләре, язучылар һәм мәктәп балалары көндез Ленин, Тукай һәйкәлләренә чәчәкләр куйдылар.

*

* *

Чаллыдагы «Ләйсән» әдәби берләшмәсендә шагыйрә Сажидә Сөләйманова белән очрашу булды. Ул берләшмә членнарыннан төзүче Сәлимә Шәрипова, укытучы Рәйсә Фәхразиева, Фирая Хәлиуллинаның шигырьләренә анализ ясады. Утырышта яшь тәнкыйтьче Равил Лотфуллин, яшь шагыйрьләрдән Мәхмүт Газизов, Хәниф Хөснуллин һәм «Якты юл» газетасы хезмәткәрләре чыгыш ясады. Икенче көнне С. Сөләйманова һәм «Ләйсән» әдәби берләшмәсе членнары Тукай районы Биклән авылы клубында әдәби кичәдә катнаштылар. Биклән урта мәктәбе каршында оештырылган Габдулла Тукай музеена китаплар бүләк иттеләр.

*

* *

Язучы Ә. Маликов Алма-Ата, Ташкент шәһәрләрендә иҗат командировкасында булды. Ул Көньяк Сахалинны япон империалистларыннан азат итүдә катнашкан сугыш ветераннары белән очрашты, яңа әсәре өчен материаллар җыйнады.

*

* *

Баулыдагы «Зәңгәр офыклар» әдәби берләшмәсе утырышында Җәмит Рәхимов һәм Альберт Хәсәнов яшь авторларның әсәрләрен тикшерделәр. Баулы эшчеләр поселогыннан һәм авыллардан килгән авторлар үзләренең хикәя, шигырьләрен укыды. Иң яхшы дигәннәре әдәби биткә тәкъдим ителде.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМ

Совет сынлы сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен СССР Художниклар союзы члены Илдар Касыймович Зариповка Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1977 ел, 11 май Указы нигезендә Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исем бирелде.

1978 ел башыннан бастыру өчен редакция проза осталарыбызның түбәндәге әсәрләрен әзерли:

**Габдрахман Әпсәләмов. «АГЫЛА БОЛЫТ»** — роман.
**Фатих Хөсни. «КАРТАЯ БЕЛМӘС КАРТЛЫК»** — повесть.
**Шәйхи Маннур. «ЧЫН СӨЮ БАРМЫ!»** — лирик повесть.
**Ренат Суфиев. «КӨЙМӘ УТЫНГА КИТӘ»** — повесть.
**Батулла Турай. «КИТЕК КҮҢЕЛ»** — хикәя.

Журнал битләрендә урын аласы бүтән яңа әсәрләр турында укучыларга алдан хәбәр ителәчәк.

Хезмәт кешесе образын чагылдырган хикәяләр конкурсына килгән кульязмалар шулай ук шактый күп.

Журнал сәхифәләрендә бик күп шагыйрьләр мәйдан тотачак. **Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Зәки Нури, Гамил Афзал, Шәүкәт Галиев, Илдар Юзеев, Роберт Әхмәтҗанов, Фәнис Яруллин, Саҗидә Сөләйманова** һәм башкаларның яңа шигъри ачышлары белән укучыларны беренче чиратта таныштыру күздә тотыла. Шигырьләр күп тә, күп төрле дә, яхшы да булачак.

Каләм осталарының өлкәннәренә алмашка килүче яшь авторларга журналда һәр вакыт урын киң. Шулардан быелга **Тәүфикъ Әйди** «Бożра», **Марсель Галиев** «Ул чакта» дигән повестьларын тәкъдим иттеләр инде.

**«Елмаеп та, көлеп тә»** бүлеге укучыны кыска күләмле шаян хикәяләр, парчалар, чәнечкеле шигырьләр белән сан саен елмайтыр. Инде күпләргә таныш «Мәсәлчеләр мәҗлесе» дә үзенең сатирик программа буенча җитди эшен дәвам иттерәчәк.

**«Нәниләр дөньясы»** бүлегендә мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен кыска хикәя, әкият һәм шигырьләр күбрәк күренер.

**Публицистик мәкалә һәм очеркларда** советча яшәеш үрнәкләре, революция һәм сугыш ветераннары, илебезнең төрле почмакларында эшләп дан казанган якташларыбыз һәм республикабыздагы хезмәт батырларының образлары сурәтләнәчәк.

**Татар әдәбияты һәм сәнгате тарихына** караган кызыклы материаллар, бүгенге әдәби хәрәкәт проблемалары һәм үзенчәлекләре турында мәкаләләр әзерләнә. Шундый ук язмалар **«Халык юкаты», «Төрлесеннән», «Алар бездә булганнар», «Китап күзәтү»** исемле бүлекләрдә һәм яңалыклар хроникасында бирелә.

Үзешчән сәнгать коллективларына ярдәмгә кимендә ике яңа пьеса һәм нотасы белән берничә яңа җыр бастыру күздә тотыла.

**«Укучы сүзе»** бүлегендә урнаштыру өчен редакция укучыларыбыздан әдәбиятка, аерым әсәрләргә карата фикерләр, әдипләргә адресланган теләк һәм тәкъдим язмаларын көтә.

## ЖУРНАЛГА НИЧЕК ЯЗЫЛЫРГА!

Ул Бөтенсоюз каталогына кертелгән. Аның индексы — 73210. Урыннардагы «Союзпечать» агентлыкларында һәм элемтә бүлекләрендә шушы номерны әйтеп,

**ЖУРНАЛГА**

**СОВЕТЛАР СОЮЗЫНЫҢ ТЕЛӘСӘ КАЙСЫ ТӨБӘГЕНДӘ, ТЕЛӘСӘ КАЙЧАН ЯЗЫЛЫРГА МӨМКИН.**

Язылу һәркайда беренче сентябрьдән башлана.
Вакытында язылырга онытмагыз!

**Язылу бәясе 1 елга — 6 сум.**

1978 елда «Татарстан яшьләре» газетасы нинди булыр? Язылачак һәм газета битләрендә урын алачак очерклар һәм репортажларның геройлары кемнәр булыр? Бу сорауларга алдан ук тәгәл генә җавап бирел булмый, әлбәттә. Әмма шунысы хак: республика һәм ил күләмендәге кызыклы, мавыктыргыч вакыйгалар «Татарстан яшьләре» газетасында чагылыш тапмый калмаячак. Яшьләр газетасы — яшьләр тормышының көзгесе ул. Замандашыбызның күркәм эшләре, аның нинди уйлар, хыяллар һәм омтылышлар белән яшәвен һәр вакыт тоеп торасыгыз килсә, «Татарстан яшьләре» газетасына язылырга онытмагыз. Моның өчен бик соңга калмыйча теләсә кайсы почта бүлегенең ишегеннән шакырга һәм 3 сум 12 тиенеңне генә түләргә кирәк, аннары газета ел буе өеңә килеп торачак.

«Сердәш»,

«Классташ»,

«Интеграл»,

«Әдәбият-сәнгать»

һәм «Шимбә сәхифәсе» битләре дә һәркемнең күңеленә хуш килер дип уйлыйбыз. Газета редакциясе өлкән әдипләр һәм яшь язучылар, шагыйрьләр белән дә тыгыз элемтәдә яши. Сез ел дәвамында яңа шигырьләр, хикәяләр һәм повестьлардан өзекләр белән таныша алачаксыз. 1977 елда Бөек Октябрьның 60 еллыгы уңае белән өлкән әдипләрдән Гомәр Бәширов, Атилла Расих, Мостай Кәрим һәм республиканың М. Җәлил исемендәге комсомол премиясе лауреаты Равил Фәйзуллин белән әңгәмәләр урнаштырылды. Әдәбият һәм сәнгатьнең актуаль проблемаларына багышланган мондый әңгәмәләр киләчәктә дә дәвам иттереләчәк.

«Шимбә сәхифәсе» битләрендә сез кызыклы язмыш кешеләре, бүгенге көн геройлары белән танышачаксыз, яшьләр яратып өлгергән яңа җырлар да иң элек шушы сәхифәдә дөнья күрә.

«Татарстан яшьләре» газетасы редакциясе.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210